# КАЗАН УТЛАРЫ

*ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ*

*1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА*

## Бу санда

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Рәдиф ГАТАШ. Сиксән яшьтән соң: «Сөюнамә». *Газәлләр.* ........ 3

Флюра НИЗАМОВА. Илһамлану. *Повесть-сагыну.* ........ 10

Ризәлә ИСМӘГЫЙЛЕВА. Сабырлык дулкыны көйләнә... *Шигырьләр.* ........ 24

Зиннур ХӨСНИЯР. Әллүки. *Роман.* ........ 28

«Такташ FEST» бәйгесенә нәтиҗәләр: Булат ИБРАҺИМ, Зөһрә РАМАЗАНОВА, Гөлүсә БАТТАЛОВА, Гөлназ ӘХМӘДИЕВА, Илнар ФАТЫЙХОВ *шигырьләре.* ........ 89

Нәзифә КӘРИМОВА. Озын-озак язмышлар. *Повесть-истәлек.* ........ 94

КАРДӘШ ХАЛЫКЛАР ӘДӘБИЯТЫ

Тәнзилә ДӘҮЛӘТБИРДИНА. Эчәр сулар тагын тарта. *Шигырьләр.* ........ 141

ЯҢА ИСЕМНӘР

Рузалия ШАКИРОВА. Ап-ак көннәр белән яшим... *Шигырьләр.* ........ 144

«ОЯСЫНДА НИ КҮРСӘ...» ӘДӘБИ КОНКУРСЫ

Равилә ШӘЙДУЛЛИНА-МУРАТ. Чәчкә таҗларында күз яше. *Хикәя.* ........ 148

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Әлфәт ЗАКИРҖАНОВ. Инешләребез мул сулы булсын. ........ 155

Тәлгат ГАЛИУЛЛИН. Ике даһига – бер риваять. (*Дәрдемәнднең тууына – 165 ел)* ........ 164

КИТАП КҮЗӘТҮ

Фатиһ КУТЛУ. Ходай бирде! ........ 174

Мәһмәт АКИФ ӨЗТҮРК. Аяз Гыйләҗев һәм аның «Берәү» повесте хакында: «Кемгә кагылма, төзәлмәгән йөрәк ярасы». ........ 175

ӘБУГАЛИСИНА МӘГАРӘСЕ

Илдус ЗАҺИДУЛЛИН. Насыйри – рус-татар мәктәбе укытучысы. ........ 177

*Фотоархив:* Әдәби мизгелләр. ........ 185

ГАЗИЗ ТАВЫШЛАР

Гомере көрәшләрдә үткән. *(Шәрәф Мөдәрриснең тууына – 105 ел).* ........ 187

Ул язмышын театрга багышлады. *(Тимергали Зиннуровның тууына – 75 ел). Сәхифәне Нәсим АКМАЛ алып бара.* ........ 188

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ........ 190

КАЗАН УТЛАРЫ
*№ 11 (1225) 2024*

*БАШ МӨХӘРРИР –*
**Рөстәм Госман улы ГАЛИУЛЛИН**

*ИДАРӘ:*
**Ирада Әюпова**
**Рәдиф Гаташ**
**Искәндәр Гыйләҗев**
**Айрат Зарипов**
**Дания Заһидуллина**
**Ркаил Зәйдулла**
**Илгиз Зәйниев**
**Илфак Ибраһимов**
**Зиннур Мансуров**
**Ким Миңнуллин**
**Газинур Морат**
**Рүзәл Мөхәммәтшин**
**Айдар Сәлимгәрәев**
**Равил Фәйзуллин**
**Илсур Һадиуллин**
**Данис Шакиров**
**Ленар Шәех**

---

*Баш мөхәррир урынбасары:* **Вакыйф Нуриев.**
*Җаваплы сәркатип:* **Ландыш Әбүдәрова.**
*Бүлек мөхәррирләре:* **Фәнил Гыйләҗев, Рафис Корбан.**
*Мөхәррирләр:* **Элеонора Җамалиева, Гөлия Сәлахова.**
*Сайт мөхәррире:* **Ләйсән Зарипова.** *SMM-белгеч:* **Алинә Хәбибуллина.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Эльвира Камалова** (өлкән бухгалтер)**.**
*Машина йөртүче:* **Наил Кадыйров.**

---

✉✉: Редакция адресы: *420066, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Кабул итү бүлмәсе – 222-09-83 (өст.1618).*
*Баш мөхәррир урынбасары – 222-09-83 (өст.1612).*
*Җаваплы сәркатип – 222-05-50 (өст. 1617).*
*Шигърият, сәнгать һәм хатлар бүлеге – 222-09-83 (өст.1616).*
*Исәп-хисап бүлеге – 222-09-80 (өст.1267), касса – 222-09-84 (өст.1874).*
Сайт: kazanutlary.ru; электрон почта: kazanutlari@yandex.ru

---

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

---

Гамәлгә куючы – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Нәшер итүче – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Нәшер итүче адресы: 420097, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Академия урамы, 2.
Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды. Айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды 31.10.2024, график буенча 31.10.2024, басылып чыгу вакыты 08.11.2024
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108$^{1}/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ А-2525. Тираж 4520.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2020 елның 13 ноябрендә теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-79467.
Индекслар: ПО277 (Татарстаннан читтә яшәүче физик затлар өчен),
П2365 (Татарстанда яшәүче физик затлар өчен), П2368 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

---

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
420066, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2.
12+
© «Казан утлары», 2024 ел



Рәдиф
Гаташ

# СИКСӘН ЯШЬТӘН СОҢ: «СӨЮНАМӘ»

**(Яңа газәлләр диваныннан)**

*Гаилә елында*
*газиз татар кызларына –*
*илһамчыларыма*

## Укучыга бер сүз

Күр: «Сиксәннән соң – Сөюнамә» бу!
Гаҗәпләнәсеңме: «Нәрсә, нәмә бу?!

Мәхәббәтнамәләр булды шигырьдә,
Шуңа тәкълидме?» Юк, үзгә, яңа бу!

Борынгыдан мәгълүм газәл «шаһ»лары,
Гарәп, фарсы, төркидән – җиһанда бу.

Өйрәнеп бит шулардан – үрнәк алып,
Үзе дә мәйданга чыккан бәндә бу!

Гашыйклар яза газәл! Сиксәннән соң
Бер диванлык көч, дәрт каян миндә – бу?!

Милләт кызына, Гаташ, бурычлы син,
Дәлил моңа «Сөюнамә»ң. Менә бу!

***

И сазым! Өзелсә кылың, кем ялгар?
Күптән китте саз көйләр чын осталар!

Туфан, Хәким кебек остазлар юк шул,
Үзен шундый санаган бәгъзеләр бар!

Аһ, элекке шаулы шигъри табыннар!
Сез – үткәндә, җанда тик кайтавазлар.

---

Рәдиф ГАТАШ (1941) — *Татарстанның халык шагыйре; Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Биш томлык «Сайланма әсәрләр» һәм төрле телләрдә дөнья күргән күпсанлы китаплар авторы. Казанда яши.*

«Акмулла мәҗлесе кадере беленмәгән», –
Бу – «Асар»да Риза казый язганнар.

«Кани» – Кайда? – дип юксынганнар элек,
«Кани» бүген Илдар, Шәүкәт, Баяннар?

Рәшит, Робертлар, Зөлфәт, Әгъләм, Разил?!
Сездән калып, без соң кая барганнар?!

Гаташ, сазың ихлас бит? Әйтсен дөнья:
Сез – исән, җанын ачарга базганнар!

***

Илһам чакырам, алга ак кәгазь җәеп:
Каләмем намазга басса, ни гаеп?

«Лә илаһы иллаАлла…» шигырьдә бит
Күп гүзәлгә оедым, алиһә, дип.

Сиңа бәйле бүген Гаташ догасы,
Пакьләнгән рух көтә: вәхи килә, дип!

Тукай тапкан Коръәндә яры исемен,
Мин дә эзлим «Сүрәи Фәләнә…» дип!

Шактый тоттык, каләм, хистә ураза,
Яз! Булсын шигырьле табын. Бу – Гает!

***

Шагыйрьләр гыйшкына остаз – Әфләтун!
Калдырган тупас хисләргә нәфрәтен:

Сөюдә илаһилыкка чакырган! –
Җиң, дип, бәдәндә кан уйнау зәхмәтен.

Уйлыйк соң: рухи биеклек һәм пакьлек
Начармы? Онытсак тән шәһвәтен?

Ничә гасыр бәхәс! Әфләтун яклы
Күпме дәрвиш, суфи – «Хак дусты» ләкин.

Ул заманнар ерак. Бүген сәхнәдә
Иблис бугай остаз: күпләргә – хәким!
Кайда, ди, «Әфләтун гыйшкы!» Азгынлык
Туй итә: ачкан һәр җенес гаурәтен!

…Мин читтә бу тамашадан. Тик нигә
Арта әле, аңламыйм, мәхәббәтем?

Илаһидыр бу хис… Сиксәннән узгач,
Бәлки, башкасы кирәкми – ни әйтим?

***

Аңлыйсыңмы икән, Яр, әллә юкмы
Безгә чорның тубы төбәлгәнлекне?

Халыкларга, Яшәүгә ата бу туп,
Вата бүген Туган тел, Гүзәллекне.

Кемгә генә янамый аның уты? –

Үчле хәтта шигырь җанына тикле.

Тиз-тиз язам шуңа да газәлләрне,
Сизәм: нидер, вакытмы инде чикле.

Шик-шөбһәләр тулы хәтта Сөю дә,
Яр, беләсең юкса: Гаташың ипле!

…Хафизларга тиң булмаса бу диван,
Дөнья тоткан көчләр, тик Сез гаепле!

***

Миңа таныш күптәннән туган ягың!
Яшь шагыйрь чагым иде, гаярь чагым.

Үз итте сезнең авыллар безләрне –
Әдипләрне. Шушма, Каракүл тагын…

Алтмыш ел була тиздән, онытмыйлар
«Каз тавышлы» кунак егет авазын:

Яңа туган малайларга кушканнар,
Киткәч, исмем – «дан»ы яши «абзаң»ның!

Аннан соң да күп килдем сезгә. Әйтим
Хаҗи шагыйрь – дустым, яшьтәшем барын.

Ләкин ул да, фалчылар да! – әйтмәде
Гасыр ахырында Син – гүзәл зат туарын…

Бүген чал Гаташ дөньяга белдерә:
Бу  газәл, дип, саф сулышы шул ярның!

***

*Коллары шул без Тормышның, коллары, –*
*Җыр-шигырьдә генә патшалар бары.*
*Синең сүзләр.*

Таҗ-тәхетләрсез кем кала бу җирдә?
Патшалар бит! Шулай булган гомергә.

Ваз кичкәннәр, йә куылган тәхтеннән,
Бу язмышка кызыкмый бер шагыйрь дә.

Үзен мәңге биектә дип саный ул:
(«Бөкре» уен төзәтмәс бер кабер дә!)

Чыннан, зур бәхете – мәхәббәт тәхете,
Бу бәхеттән көчсез канун, җәбер дә.

Кол да, патша да сөюдә мин – Гаташ,
Буйсынам тик Хискә – ихлас әмергә!

***

*Синең шомлы төш турында газәл*

Укудамын, дип, төш күрәсең, имеш:
Яңа фәннәр… Тиргә төшкәнсең, имеш.

Әллә күкләр, әллә баш көч әмере:
Милли хистән азат икәнсең, имеш!

Каяндыр килгән «сөенечле» хәбәр:
«Кирәге юк тел өйрәнмәссең», имеш! –

Тизләтелгән Тел, Дин, Хәтерне җую, –
Татар исменнән син ваз кичкәнсең, имеш.

Кинәт төш бүленеп (азан тавышына!)
Елый-елый: «Тәүбә!» – дигәнсең, имеш.

Гаташ ник яза моны? Үзең: «Бу хәлне
Газәлгә керт!» – дип, үтенгәнсең, имеш!

***

*Уртак газәл*

«Илһамчыңа рәхмәт» – ди сердәш дустым,
Каләмеңә өргән утлы сулышын:

Яңа газәл – гөлләр чәчәк атарлар,
Бөреләре генә тизрәк тулышсын».

И шагыйрә! Ирешсен хакка доган:
Җырда «Әлфе ләйлә вә ләйлә» тусын.

Теләктәшләр, хәтта шигырьдәшләр сез,
Уртак иҗат дип раслыйм. Шулай булсын!

Гаташ канәгать. Укучы ни дияр…
Соңгы сүзме? Яр, синнән көтәм бусын!

***

Дөрес синең сүзләр: «Үлем элмәсен
Яшәү йорты ишегенең киләсен…»

Тукай үлгәч чыккан бәеттә дә бит:
«Килә белми нигә, Әҗәл, киләсең?»

Кайчан сузылыр безләргә аның кулы,
Белә күкләр… Минем килми беләсем.

Сине күргәч, яшәрдем. Яшәр идем
Әле озак, язып – «Сөю сүрәсе»н.

Килми: «Кердем бер ишегеңнән, Дөнья,
Икенчесеннән чыгам. Хуш!» – диясем.

Нинди матур – фани булса да – дөнья,
Бакыйда күрешербезме әле – белмәссең.

Шагыйрә, Яр! Гаташтан ихлас теләк:
Яшәү йортыңны тик илһам биләсен!

***

Җамбул, йә Кудаш яшенә җитәрәк
Минем хәлләр булыр, димен түгәрәк.

Думбра, курай тавышлары уятыр, –
Моң елатыр… Барсы булыр мөбарәк:

Бакчаларда кошлар мәңгелек серен
Ачар, бәлки, миңа – торсам иртәрәк.

Кудашны белмим, ә Җамбул язган, имеш,
Яшь гүзәлләр торса, җанын иркәләп. –

Йөз яшьтә бу! Гаташ сизми картлыкны,
Илһам кошым, күрәм, оча тирәләп!

***

Син дә барган икәнсең, Яр, Болгарга! –
Тузан кунган хәтернеме юарга?

Изге җирләр! Кагылгандыр яшь җаның
Тарих учагыннан тере кузларга?

Милли Гамь утлары ялмап, төштеңме
Иделдәй тирән агымлы уйларга?

Кайткандыр күңелең әремле далада
Ил бишеген җил тирбәткән чорларга!

Нинди киңлекләр ачылган – күзләргә,
Ирекле җыр, хөр дастаннар туганда.

Шәһре Болгар, Алтын Урдам, Казаным –
Татарның тулы йорты! Исән, канда…–

Белә Гаташ: тезләнеп, кыйлдың дога
Тугры калдык дип мирас йолаларга.

Халык – ташкын, калыккан күк мең пулат,
Кайтты хәтер китмәс өчен Болгарга!

***

Зур чыгырга тотынган хәлеңдә син:
«Габдрахман сәхабә коесы» – бу рәсем.

Бура өстендә чиләк, изге су тулы!
Шул суда нинди сурәтләр күрәсең?

Йосыфнымы чыгарганнар коедан,
Нур аламсың пәйгамбәр йөзеннән син?

«Зәңгәр кое» һәм «Кыз җавабы» дип,
Искә алдыңмы Гаташны биредә син?

Хан кызларын терелткән шифалы су! –
Зәмзәмгә тиң Болгарым җирендә син.

Эч, шагыйрәм, ал гомерлек гамь, илһам
Һәм дәва бул милләткә үзең дә Син!

***

Манаралар – чал тарих сөңгеләре!
Халкымның мең еллык көрәш өннәре

Күккә ашкан шуннан – Хакка ирешкән,
Күрмәгән бу моңлы җирләр кемнәрне!

Изге туфрак! «Тузаның сөрмә иткән»
Чит илләрдә каңгырган галимнәрме?!

Ничә кабат Болгарны торгызырга
Омтылган халкымның гаярь ирләре.

Һәм шагыйрьләргә дә изге Мәккә бу,
Кайсына, кем, монда вәхи килмәде!

Яшькелт күзле Болгар кызы! – дип Гаташ
Теләр күрергә Син йөргән эзләрне!

***

Сәхабәләр күптән инде килмиләр,
Белмиләрдер безнең хәлне, белмиләр.

«Мең дә йөз елдан артык вакыт үткән,
Нинди үзгәрешләр монда!» – димиләр.

Гарасатлар харап иткән бакчада
Көлдән үсеп чыккан гөлләр! Күрмиләр…

Кирәмәтләрен – хан кызын сырхаудан
Терелткәннәрен онытмас күңелләр;

Пәйгамбәр сүзләре хәтердә яңарды,
Сәхабәләр яккан утлар сүнмиләр:

Кабат чыкты Болгарда дин кояшы!
«Туңып йөрдең, Гаташ, җылын, кил!» – диләр.

***

*Белеп буламыни Кеше җанын,*
*Сурәтенә бары күз атып?*
Синең шигырьдән

Күз атарга сурәтләр күп тарихта! –
Артта калган безнең кызу барышта.

Булган күпме рәссам, нәкъкашлар җирдә,
Бер Гаребтә генәме? Һәм Шәрыкта!

«Җанлы очрашу кирәк», ди Яр: «Җан булсын!» –
Сурәтләр дә җан сорар бакыйлыкта!

Тик, әүвәл күреп сурәтен, Иясен
Тапканнар бит җир читенә барып та!

Яр! Гаташ та сурәтеңә Җан эзләр:
«Теләк булса, юл һәр заман ачык ла».

Сурәт һәм Җан… Шушы юлда адашып,
Кайталмасам, Тәңрем, үзең ярлыка!

***

Күз карашымны тарткан сер ноктасы!
Хис корабыма соңгы яр булсаңчы?!

Гүя арып егылдым хозурыңа,
Газәл тулы төргәгем – укып бакчы!

«Кайда булмаган ул, ни кичермәгән,
Күпне күргән бу «сәяхәтче» башы.

Яңа «исемнәр бакчасы» язганмы?
Татлы да кебек җимеше һәм ачы:

Сөю агачы үстергән бу гашыйк! –
Кызуда безгә күләгә булсачы!

Ә йөрәгеңдә күп яра, мөгаен:
Соң түгелме, аңа булсам дәвачы?!»

...Ял итә Гаташның хыял корабы:
Диван тәмам!.. Синме яңа җыр башы?

Мәңгелеккәме фатиха карашың?
Яр булмасаң да Чалга, бул – догачы!

***

Нинди булыр, каләм, безнең киләчәк?
Нинди бәһа безләргә ул бирәчәк?

Сез, бүген шашып мин сөйгән газәлләр! –
Кайсыгыз исемем биектә күрәчәк?

Кайсыгыз ерак юллар үтеп, минем
Соңгы учак урынын эзләп киләчәк?

Ә бу диван илһамчысы? Бәлки, ул
Һәм кызлары, укып, яшьләр түгәчәк?!

Язачаклар минем хакта истәлек!
Илаһи «роман»ны да яшермәячәк.

(Хәтта гаилә башына: «Бу Гаташ
Изге иде... искә алыйк!» диячәк.)

Бу – хыялда. Моңа ерак. Бүген кем
Диваным котлап, гөл тотып киләчәк?!

***

*Диванга соңгы сүз*

Вакыт җитте, йә, саубуллашыйк, диван!
Биш ай түгел гүя – гомерем сыйган

Бер «җанъязма» булдың. Әллә җиңелме
Аерылышу беркөн – газиз «җаның»нан?

«Кынысын туздырса да, сау – кылыч»,
Дигән Байрон. Мин дә шул хәлдә сыман:

Бер җиңеллекме тоям, үткәч Сөю,
Ниндидер йөктәнме, йә, җан арынган?

Моңсулыкмы әллә – якын дустыңнан,
Ярыңнан – сөекләңнән! – аерылудан.

Гаташ! Боларны укып аңларлар;
Әле бар татарча хисне таныган...

Ә Киләчәк бер Ходайның иркендә:
Бул, диваным – Аңа чын ихлас догам!



Флюра Низамова

# ИЛҺАМЛАНУ

ПОВЕСТЬ-САГЫНУ

**Мин бер төш күрәм…**

Тагы шул төш керә... Инде ничә тапкырлар шулай. Аз дигәндә дә, алтыҗиде тапкыр гына кергәндер ул төш. Имеш, түр бүлмәдә комод өстендә әти яңарак кына алып кайткан телевизор тора. Ниндидер могҗиза булганмы, шул телевизор Казанны күрсәтә, ә анда Илһам Шакиров җырлый. Төштә мин аның килеш-килбәтен, чыраен бик үк анык итеп күзаллый алмыйм, шулай да беләм: ул бик чибәр, төз, озын буйлы егет булырга тиеш, чөнки шундый матур тавышлы кеше ямьсез була алмый!..

Әлбәттә, бу бары тик төш кенә. Бала чагымда, инде үсмерлеккә кереп, Илһам Шакиров исемле җырчының язмаларын радиодан ишетә башлагач күргән төш. Алга таба ул төрле вариантларда кабатлана, әмма асылы бер үк – түр бүлмәдәге телевизор һәм ул Казанны күрсәтә, имеш. Минем хыялның, шулай төштә генә булса да, чынга ашуы. Ә чынында исә безнең телевизор Казанны күрсәтми. Анда нибары ике генә канал бар, берсе – Бөтенсоюз телевидениесе, икенчесе – Уфа каналы. Шулай иде бугай. Хәзер инде онытылып бара – Уфаныкы дигәнем аерым бер канал булдымы икән, әллә шул Мәскәү каналы тапшырулары арасына кереп алгалый торганы гынамы? Мөһим дә түгел. Барыбер Мәскәүдән – рус җырчыларын, ә Уфадан күбрәк башкорт җырчыларын гына күрсәтәләр: Мәгафур Хисмәтуллин, Фәридә Кудашева, Илфак Смаков, Филүс Гәрәев, тагын әллә күпме җырчыны. Дөрес, аларның берничәсе татарча да җырлый, чөнки үзләре татарлар. Фәридә Кудашева, Илфак Смаков, Зәки Мәхмүтов, мәсәлән. Илһамны, Әлфияне нигә җырлатмыйлар икән соң? Аларның җырлавын без баштарак урамда, багана башындагы колхоз радиосыннан ишетә башладык. Күрше Иске Турай авылындагы җирле коммутатор иртән бер, көндез бер һәм, кичке концерт тапшырганда, тагын бер тапкыр радионы Казан дулкынына көйләп куя иде. Югыйсә Татарстан безгә терәлеп кенә тора инде, шул Турай авылы Ык елгасы буенда гына утыра, ә Ыкның аръягында – Баулы районы, Татарстан... Илһамлы Татарстан!

Флюра НИЗАМОВА (1953) – *шагыйрә, журналист. Дамир Сираҗиев исемендәге премия лауреаты. Башкортстанның Ярмәкәй районы Иске Шах авылында яши.*

Илһам исемле егетнең җырлавы тыңлаучыга, гомумән дә, бер яңа бүләк булгандыр. Чөнки мондый үзе көр, үзе бәрхеттәй йомшак, үзе чын татарча бормаларга бай тавышны кеше бер ишетүдән үк хәтеренә ала да аның тавышы сурәтен күңеленә чигеп тә куя! (Яңа бүләк дигәч, Илһам Шакировның туган авылының да Яңа Бүләк икәне искә төшеп куйды. Туры килү...) Ул елларда, без үскән заманда җырчылар хәзерге кебек күп түгел иде. Халык арасында матур тавышлы кешеләр ул вакытта да күп булгандыр булуын. Югыйсә соңрак шул ук халык җырчыларының балалары, оныклары үсеп җитеп, яңгырдан соң ишелеп чыккан гөмбәләр шикелле каян күпләп пәйда булырлар иде дә, татар эстрадасы йөзләгән җырчыга баеп китәр идеме икән?! Әлбәттә, бу очракта баю дигәнем – сыйфаттан бигрәк, санны күздә тотып әйтелгән сүз. Җырчылар күбен күп тә, яңа Илһамнар, яңа Әлфияләр күзгә-колакка чалынып бармый шул...

Минем яшьтәшләр, авыл кызлары-егетләре – теге гасырның алтмышынчы еллар азагы, җитмешенче еллар башы үсмерләре – радиодан ишетеп, тизрәк ритмлы, җиңел-җилперәк җырларны отып алалар да, кичләрен су буенда учак ягып, берәрсе гармун тартып, шуларны җырлыйлар. Күбесе Илфак Смаков, Филүс Гәрәев җырлары – «Зимфирәкәй», «Раушаниям-бәгърем», «Гөлчирәкәй» кебек кызлар исемнәре белән аталган дәртле, тиз җырлар. Ә яшьләрнең кайберләре «Имәннәр шаулый»ны, «Әниемнең җылы кочагы»н, «Керфекләрең синең нигә кара»ны, «Ык буйлары»н да җырлыйлар. Аларны радиодан Илһам исемле яшь җырчы башкаруында еш кына ишетә идек. Билгеле, ул елларда яшәгән халкыбыз Илһамның тавышын ишетү белән, «Бу – минеке! Бу – безнеңчә!» дип, шул җырларны кадерләп күңел хәтеренә салып куйганнардыр. Бераз соңрак Илһам Шакиров башкарган «Өнсә», «Күн авылы көе», «Сарман», «Арча»җырлары халыкка үтеп керде. «Өнсә» белән «Күн» көйләре берсе-берсенә охшаш та кебек. Бәлки болар бер үк көйнең төрле вариантлары гынадыр да әле. Биектауның Өнсәсе белән Питрәчнең Күне бер-берсенә шактый якын утырсалар да, авыл көйләрендә беркадәр аерма булуы сәер түгел. Авыл көе димәктән, җыр поэзиясенә хас булган бер мода турында да әйтеп китик. Сугышка кадәр дә, соңрак та авыл, район, җирлек атамасы кушып җырланган искерәк көйләргә яңа сүзләр яздырту шаукымы булып алган. Мисалга, «Минзәлә», «Мөслим» көйләрен яңача сүзләргә җырлау. «Минзәлә» көенә яңа сүзләрне Әхмәт Ерикәй язган. Моны халык үзе эшләмәгән инде, билгеле. Күрәсең, өстән ниндидер бер күрсәтмә булгандыр. Иске җырларны сипләү дип әйтимме шунда. Сагышлы җырга яңача, советча оптимизм рухы өстәү, янәсе. Менә шундый ысул белән язылган «Гүзәлем» җырының көе – ул элегрәк Зифа Басыйрова җырлаган Мөслим көе. Илһам Шакиров «Гүзәлем»не радиога яздырткач, теге искесе төшеп калган. Илһамның аһәңе көчлерәк булып чыккандыр, күрәсең. Әле беркөн Әхмәт Ерикәй җыентыгын актарып утырганда, «Су буйлап» (икенче исеме – «Идел бит ул») җырына да Әхмәт абзый яңа сүзләр сипләгәнлеген күреп алдым. Ә менә Илһам Шакиров язмасында бу җыр иске сүзләре белән яңгырый. Аерылу, сагыш җыры булып. Совет сәнгате «диспетчерлары» һәр иске, моңлы-сагышлыны ялган оптимизм белән алыштырырга остарган булганнар, күрәсең. Ләкин җырчының сизгер күңеле бу очракта җырның «холкын» үзгәртергә каршы килгән.

Миңа җырчының «Туган як»ны җырлавы аеруча ошый иде. Ул елларда радио, телевидение аша концерт тапшырганда, дикторлар җырның авторларын да, башкаручысын да аермачык атап әйтәләр иде, шуңа күрәдер авторларының исем-фамилияләре яшьтән үк күңелгә сеңеп кала иде. «Туган як»ныкы да шулай – Мансур Мозаффаров көе, Мөнир Мазунов сүзләре. Нинди мәгърур көй, нинди камил сүзләр! Җырларга җиңел түгелдер бу җырны, чөнки ул агышы белән салмак, шул ук вакытта киң аһәңле, тирән гамьле җыр. Текстында һәр строфа, гадәттәгечә, дүрт юлдан түгел, ә алтышар юлдан тора. Барысы егерме дүрт юл. Бер караганда, истә калдырып бетерергә генә дә кыен шикелле. Ләкин Илһам дигән шәп җырчының тавышы колакта яңгырап торгангадыр инде, мин аны бик тиз отып алдым. Моны композитор һәм шагыйрь язганча тоемлап башкарыр өчен никадәр сулыш та, тавыш көче дә, уйчан акыл да, тирән моң да кирәк! Миндә ул чакта боларның дәһеле дә юк инде. Шулай да мин, тугызынчымы, унынчымы сыйныф укучысы, малайларчарак калын тавышым белән мәктәп залын яңгыратып җырлыйм:

Ә сине, ә сине, ә сине, туган як,
Бармы икән сагынмый торган чак?!

Әйтерсең лә туган яктан күптән чыгып киткәнмен. Югыйсә әнә ул Иске Шах, туган авылым, аның Биектавының сөзәк сызыгы күрше авыл мәктәбенең тәрәзәсеннән күренеп кенә тора. Үз тавышым башкаларга ничегрәк ишетеләдер, белмим, әмма колагымда, миңа көч биреп, Илһам исемле җырчының куе бәрхет тавышы яңгырый... Соңрак, күпкә соңрак, Уфада укуымны ташлап, Чаллыга килгәч тә, аннары шушы сихри тавыш чакыруына түзә алмыйча, Казанга килеп җиткәч һәм Илһам Шакировның репертуарын баштанаяк ятлап чыккач, Мансур Мозаффаров дигән композиторның җырчы тормышында, иҗатында никадәр зур урын тотканын белдем. Баксаң, Илһам абый бу композиторның җырларын каяндыр табып кына өйрәнмәгән, ә Мансур Мозаффаров үз җырларын яшь Илһамга шәхсән үзе өйрәткән, чөнки консерваториядә ул аның укытучысы, остазы да булган икән бит. Илһамга Мансур Мозаффаров дәресләр биргән һәм егетнең талантын иң беренчеләрдән булып бәяләп, яратып, һәр яңа язган көен аңа тыңлаткан, радиога яздырырга юл ачкан. Мозаффаровның «Хәерле иртә», «Башка берни дә кирәкми», «Кайда да йөрәктә», «Саумы, Кояш!» кебек җырларының симфоник оркестрга кушып җырлануы һәм радио фондында алтынга тиң мирас булып калуы да шушы иҗади бергәлекнең җимешедер. Кызганыч, бүгенге тыңлаучы бу җәүһәрләрнең күбесен ишетүдән мәхрүм. Көнозын сөйләп-җырлап торган хәзерге радиостанцияләр нишләптер шул гүзәл язмаларны халыкка җиткерүне кирәк санамый. Күрәмсең, сату-алуга корылган бүгенге вазгыятьтә мондый язмалар табыш китермидер инде. Гәрчә Илһамны тыңлап, аңардан җырларга да, репертуар сайларга да өйрәнеп үссәләр, яшь буын җырчылары һәрьяклап отарлар гына иде. Бу җәһәттән Филүс Каһировның, Ришат Төхфәтуллинның, Зәлидәнең, Айдар Рәкыйповның, Раяз Фасыйховның, тагын берничә егет-кызның җырлавында һәм репертуар сайлавында Илһам абый тәэсире тоемлана кебек. Беркөн, интернетта казынып утырганда, Лилия Шакирова дигән кызның җырлавына тап булдым. Әлегә эстрадабызда андый исем ишетелми бугай. Өйдә генә,

баянга кушылып, «Сарман вальсы»н җырлады кыз. Шундый көчле дә, киң сулышлы да, моңлы да тавышы! Тукай сүзләре белән әйтсәк, чын безнеңчә милли көй булып ишетелде миңа аның җырлавы. Җыры да Илһамнан. Өстәвенә, фамилиясе дә Шакирова бит әле. Бирсен Ходай дип кенә куйдым.

Кайсыбер яшьләрнең элеккерәк җырларны сайлап башкаруы сөендерә. Гади генә итеп әйткәндә, чын татарча җырлар эзләүгә кайтып кала ул. Татар көенең дә, татар шигыренең дә үзебезгә генә хас милли йөзе бар бит. Ул йөз, ул сурәтне эзләү – күз иләге аша кеше кешене ялгышмыйча танып алган кебек, татарның көен дә кабатланмас чырайлы итеп тануга тиң. Йөзләгән яшь җырчы арасында, бик сирәк кенә булса да, шушы хасиятне тоеп алганнары да очраштыра. Димәк, алар чын-чынлап бөек җырчыбызның җырларын тыңлап, аның җырлау рәвешен, җыр аркылы безгә җиткерергә теләгән гамьнәрен, моңын кирәк булганга гына түгел, ә үз күңелләре кушканга күрә яратып, шуны иҗатларында яңарталар. Татар халкының яңа шытым бирә алырдай иҗади туфрагы елдан-ел ярлылана баруга да карамастан, табигать әле, сирәгрәк булса да, без зарыгып көткән чын талантларны биргәли. Үрнәк өченме, гыйбрәт өченме...

## Һәркемнең үз Илһамы

Кемне ничектер, мине бала чагымнан ук Илһам Шакиров җитәкләп йөртте. Әллә күңелем артык нечкә, әллә музыканы тоемлавым шактый көчле, шушы тавыш гел үзенә ияртте дә алып китте. Ә тавыш бит үзе аерым гына яшәми (дөрес, радиогамы, башкасынамы яздыртылса, язмада аерым да яши). Шулай да, тавышның бит аның иясе бар. Шул тавыш иясен һәрдаим күрәсе килү, аның нindирәк кеше икәнен аңлыйсы килү, аның тирәлегенә омтылу – бу бер дә бетмәс нинди мавыгу, нинди сәер омтылыш икән?! Нормаль халәтме бу? Әллә берәр төрле тайпылышмы? Хәзер, инде олыгаеп барганда, үз тормышыма бәя бирергә тырышып уйланам да шундыйрак фикергә киләм: әлбәттә, бу хис энергиясенең ташып чыгу күренеше. Бу очракта тавышка ияргү, шул тавышны туктаусыз тансыклауның тавыш иясенә табынуга әверелүе. Уфада нефть институтында укыганда, тулай торактагы бүлмәмдә, караватым каршындагы диварда Илһам Шакировның ул вакытта мин белгән бердәнбер төсле фотосы эленеп тора иде. Ул – «Азат хатын» (хәзерге «Сөембикә») журналыннан кисеп алынган фотосурәт. Иртән йокыдан тору белән күзем иң элек шул сурәткә төшә. Бу фотодагы кешенең исем-фамилиясен, кем икәнен бүлмәдәш рус кызлары да белә иде инде...

Тора-бара, инде Илһам абый да ничектер мине танып, үз итеп, дус итеп йөри башлагач, ул берсүзсез табыну дигән нәрсә үзгәрде үзгәрүен. Ул гап-гади аңлауга һәм хөрмәт итүгә әйләнде. Үз халәтемне шәрехләргә тырышып, заманында шундыйрак бер шигырь дә язган идем әле, аны «Табыну» дип атаган идем:

Мин генәме табынучы
Тик берәүгә дөньяда?
Минем кебек иләсләнеп
Янучылар күп алар.

Тик минем табыну – үзгә,
Тик минем денем башка,
Сәҗдә кылмыйм, мәҗүсиләр
Табынгандай Кояшка.

Табынам үзем тапканның
Иң асыл җәүһәренә,
Баш идертә алган көчнең
Рухыма тәңгәленә!

Синең дә бит кояшкача
Алып менгән җырларың –
Күңелемнең үзем ачкан
Бер бөеклеге бары!

Горурлан: табынам сиңа,
Илһам бирүче Аллам!
Тик онытма: Аллаларны
Мин үзем сайлап алам...

Аңлашылса кирәк: бу шигырьдә мин гүя үз-үзем белән бәхәсләшәм, шул ук вакытта Илһам белән дә. Янәсе, мин аңа сукырларча табынмыйм, ә аның җырларын, илаһи тавышын кабул итә алган үз күңелемнең зурлыгын да расламакчы булам. Ә бит, чыннан да, зур талантны кабул итәрдәй, аның бөеклеген аңлардай кешеләр булмаса, ул талант иясе беркемгә дә кирәкмәс иде. Сөекле Тукаебызның «Кем белер кадереңне, җаным, дәртле күңел булмаса?!» дигәне сыманрак инде. Бусы бер. Икенче яктан карасак, халык дигән көзгедә Илһамның сурәте дә төрледән-төрле бит. Һәркемнең үз Илһамы, ягъни мәсәлән. Берәүләргә аның гади генә көйләре дә җитеп ашкан, әйтик, шул ук «Имәннәр шаулый», «Идел буе каеннары», «Гөлмәрьям», «Татар кызы», «Күзкәйләрең синең нигә кара» кебек сөйкемле, әмма шулай да беркатлырак җырлары. Ә кемгәдер аның «Карьят батыр»ы, Дәрдемәнд сүзләренә җырланган «Кораб»ы, Тукайның сагыш-зар тулы «Әллүки»е, «Зиләйлүг»е, «Тәфтиләү»ләре, Илһам үзе иҗат иткән «Син сазыңны уйнадың»ы (Нәкый Исәнбәт сүзләре), озын, гамьле «Җаныем-җанашым»ы, «Эскадрон»ы, «Һай, әле бик еракта идек без»е, «Кара урман»ы, «Әдрән диңгез» кадерлерәк. Әле тагын татарның зурлыгын, дәүләтләр тоткан көчле, ныклы милләт икәнен раслый торган җырларын алыйк. Александр Ключарёв белән Гөлшат Зәйнашеваның «Туган җирем – Татарстан» җыры үзе генә дә ни тора! Янә Сәйдәшнең, Рөстәм Яхинның, Сара Садыйкованың, Ренат Еникеевның, Әгъзам Фәттахның, тагын берничә композиторның югары пафослы, гамьле көйләре – «Татарстан – минем республикам», «Китмә, сандугач», «Үрләреңне менгәч», «Өченче көн тоташ кар ява», «Дөнья матур, дөнья киң», «И мөкатдәс илем», «Җырланмаган әле безнең җыр» кебекләре... Болары инде җыр сәнгатенең генә түгел, ә татар гавамының үзенең дә сыйфатына кагыла торган шәйләр. Сыйфат дигәнебез гавамда тормышны һәртөрле катлаулылыгында кабул иткән, яшәешнең кануннарын тоеп, фәлсәфи дәрәҗәдә аңлаучылар катламы булуга бәйледер. Зыялылар катламы, ягъни мәсәлән. Андыйларның күңел иләге бик вак или, ул иләк күзгә бәрелеп торган эрерәк чүпләрне – сәнгатьтәге зәвыксыз, арзан продуктны шундук тотып ала, күңеле түренә үткәрми. Ә чын талант иясләрен исә зыялылар бер күрүдән-ишетүдән таный һәм үз итә. Инде килеп, талант иясе үзе дә халыктагы төрле сыйфатларны үз шәхесенә сыйдыра ала бит. Ул авыл көтүчесе, игенчесе, терлекчесе шикелле гап-гади дә булырга мөмкин, икенче караганда – дөньяның зур фикер ияләренә генә хас философ та. Илһам абыйда шушындый гадилек тә, табигый аң-зиһен дә, тормышны нечкә тоемлау да, тирән акыл да – барысы бергә тупланган иде. Күрәсең, табигать үзе алдан ук белеп, туачак бер баласының орлыгына шундый сыйфатларны аерып, сайлап-иләп салгандыр инде. Шуңа туры китереп, ата-анасы ул балага нинди мәгънәле исем дә кушканнар бит әле – Илһам!

Без «бөек» сүзен еш кулланабыз. Бу сүзне кайсыбер вакытта чамасыз, урынсыз да китереп кыстырабыз. Теге яки бу шәхеснең бөеклеген нинди аршын белән үлчәргә соң? Халыкка күрсәткән хезмәтенең саны беләнме, шул санга сыйфатны да өстәпме? Әле ул сыйфат дигәнен ничек итеп билгеләргә-үлчәргә тагын? Моны, билгеләсә, әлеге дә баягы зыялылар катламы гына билгели аладыр инде. Зыялылар дигәч тә, алар барысы да югары белемгә ия, мактаулы исемнәр алган кешеләр генә дигән сүз түгел, әлбәттә. Халыкның үзендә дә җитәрлек алар – тумыштан зыялы, зирәк, сизгер күңелле кешеләр. Андыйлар авылда, җирдә яшәүчеләр дә була ала, завод эшчесе дә, нефтьче дә, табиб та... Төрле кешенең күңеле дә төрлечә бит, берәүләрнеке бик сай гына, икенче берләренеке – диңгезләргә тиң. Менә шундый табигый зирәклеккә, сизгерлеккә ия булганнар гына сайлап ала да үлчи инде кемнең кем икәнен. Ә Илһамны башка күп матур тавышлы да, киң сулышлы да, әмма кайсыдыр ягы белән барыбер кайтышрак бүтән җырчылар арасыннан инде күптән аерып алганбыз да бөек дип тамгалаганбыз икән, моның белән бәхәсләшеп булмый инде. Бу – аксиома. Яшьрәк чагында Илһамның сәләтен үз элгәрләре белән чагыштырган булсалар, бүген инде Илһам Шакиров – үзеннән соң килгән җырчыларга иҗат үрнәге, татар җырын башкару эталоны. Бервакыт залдан сәхнәдәге Илһамны тыңлап утырганда, башыма шундый бер нәни генә шигырь килде:

Кайсы – җырның суррогаты,
Кайсы – җырның иң чыны:
Куй да үлчә, әйтер аны
Илһам Шакир аршыны...

## Илһам арбасына утырып карасаң...

Илһам абыйны якыннанрак белгән кешеләрнең аның шәхесенә бәясе төрлечә. Кайберәүләр аны бик йомшак күңелле, сизгер, ярдәмчел дип бәяләсә, кайберәүләре шактый кырыс, кызу, хәтта урыны белән усал да иде дип әйтә. Бу ике төрле бәяләмәнең һәркайсында да хаклык бар, минемчә. Баштарак, җырчыны читтән генә күреп йөргәндә, аның хакында берәр кыек сүз ишетсәм, шундук ул сүз иясенең тетмәсен тетеп ташлый торган булсам, соңрак, Илһам абый белән якыннан аралаша башлагач һәм аның холкындагы төрле чалымнарны күзәтә-күзәтә, мин аның кырыслыгын да, йомшаклыгын да, гаделлеген дә, ә кайчагында кирәгеннән артык кызулыгын, каударлыгын да үземчә аңлап, аны ничек бар, шул килеш кабул иттем. Әлбәттә, минем аны тегеләй яки болай кабул итү-итмәвемнең Илһам Шакиров иҗатына да, язмышына да һичбернинди тәэсире юк. Мин кем дә, ул кем! Ләкин әлеге мизгелдә бөек җырчыбыз турында истәлекне, фикерләрне мин язып утырам бит әле. Күп тапкырлар өендә булып, бергә ашап-эчеп, хәтта концертларга да бергәләп чыгып йөргән кешемен, ни дисәң дә. Илһам Шакиров белән гастрольләрдә дөньяны аркылыга-буйга гизгән артистлар да җитәрлек. Алар да язсыннар иде үз истәлекләрен. Әлегә бик азы гына яза һәм сөйли. Бәлки аларга журналистлар барып җитә алмыйдыр? Чыннан да, тормышта нинди рәк кеше иде ул Илһам Шакиров? Җырдан башка, аны тагы ниләр кызыксындыра иде? Ниләр борчый иде? Күпләр белергә телидер моны.

Әлбәттә, Илһам абый гаделлек таләп итеп, кемнәргәдер каршы күсәк күтәреп, ызгышып-даулашып йөргән кеше түгел. Шулай ук мәйданнарга чыгып, байрак болгаганы да күренмәде шикелле. Ә күңеле белән дә, иҗаты белән дә ул һәрдаим үз милләте яклы булды, милләтенең хокуклары кысылуга бик сыкранды. Еш кына Тукай сүзләрен кабатлый иде, шул халыкныңмы хокукка хаккы юк дип (Тукайның «Олуг юбилей мөнәсәбәте илә халык өмитләре» шигыреннән). Йә булмаса «Милли моңнар»дан, үзе «Әллүки» дип җырлаган, әмма җырга керми калган юлларны әйтеп куя:

«Өзелеп-өзелеп кенә әйтеп бирә
Татар күңле ниләр сизгәнен,
Мескен булып торган өч йөз елда
Тәкъдир безне ничек изгәнен...»

Гомумән, Илһам абый киң карашлы шәхес иде. Гәрчә, төп һөнәреннән – җырчылыктан гайре, аңар башка өлкәләрдә системалы белем алырга туры килмәгән булса да. Әгәр дә җырчы булып китмәгән булса (моны күз алдына да китерүе кыен, билгеле!), ул йә язучы, йә шагыйрь, йә тарихчы, йә ким дигәндә журналист булыр иде. Элегрәк, энеләре, ике апасының уллары бер-бер артлы университетның татар филологиясе бүлегендә укып йөргәндә булса кирәк, аларга иярептер инде, үзлегеннән гарәп язуын үзләштергән. Берничә тапкыр университетка, үзе кирәк дип санаган укытучыларның лекцияләренә дә баргалаган хәтта. Менә кызык кына бер очрак: бервакыт, эштән кайтышлый, сөйләшенгән сәгатькә аның фатирына килсәм, ишеккә икегә бөкләнгән язу кыстырылган. Миңадыр инде бу дип алып ачсам, Илһам абый гарәп хәрефләре белән язып калдырган. Бүтәннәр укый алмасын өчен шулай яза иде ул кайчагында. Хәзер төгәл текстын хәтерләмим, мәгънәсе – Флүрә, җаным, минем фәлән-фәлән эшем килеп чыкты, фәлән вакытта кайтам дигән кебегрәк. Ахырда зур итеп, кирилл хәрефләре белән Ишак дип язып куйган. Аның шаян имзасы шундый иде. Мин ахмакның ул записканы сакларга акылым җитмәгән инде. Югыйсә бер кадерле ядкарь булыр иде. Гомумән, истәлеккә дип бергәләп фотога төшәргә дә башым җитмәгән. Кемнәрдер бөек җырчы белән бергә кадрга махсус керергә дә тырыша бит әле. Төркем-төркем кешеләр арасында гына Илһам абый белән бергә төшкән берничә фотодан башкасы юк...

Ул, кычкырынып-шаулап йөрмәсә дә, татарның хокукын-хакын иҗаты белән, җыры белән даулады. Һәртөрле ыгы-зыгыдан, тавышлы җыелышлардан, төрле фиркаләрдән, төркемнәрдән читтә торды. Шул ук вакытта илдә, республикада, үзе эшләгән Тукай филармониясендә барган эшләрдән, вакыйгалардан һәрвакытта да хәбәрдар булып яшәде. Үзара сөйләшеп утырганда, аш-чәй табыны янында сүз чыкканда, һәрнәрсәгә үз мөнәсәбәтен белдертеп куя торган иде. Гадәттә, ул мөнәсәбәт әче сарказмга йә булмаса йомшак юморга төрелгән була. Күп сөйләми, әмма вазгыятькә карата берәр төрле халык мәкален, әйтемен китереп куя. Йә булмаса Тукай шигыреннән берәр юлны алып «ябыштыра». Ә Тукайны ул яхшы белә. Берничә шигырен яттан да сөйли. Урынына күрә, аның шигырьләреннән берничә юлны китереп куя. Әйтик, «Шүрәле»дәге күп юллар теләсә нинди ситуациягә дә бик туры килеп тора бит. Теге яки бу гамәлгә карап, Илһам абый: «Сезде эшне Шүрәле дә...» – дип куярга мөмкин. Йә булмаса,

тәмәкеңне куй инде, аша дисәң, ул үзен җәлләткәндәй итеп: «...без ник болай соң? Без дә хакның бәндәсе», – дигән була да, бу мизгелдә бик мәгънәле сүз тапканына сөенеп, рәхәтләнеп көлә. Тәмәке дигәннән. Илһам абыйны тәмәке тарткан кеше иде дип тә, шул ук вакытта бөтенләй тартмады дип тә булмый. Күзәткәнемчә, ул эшендә дә, юлда йөргәндә дә үзе белән тәмәке йөртми, кешедән сорап та тартмый иде. Ә үз өендә, синең ашарга пешергәнеңне күзәтеп, кухнядагы бәләкәй өстәле янында бик кәефле генә сөйләнеп утырганда – сер түгел инде, алдында азрак мәе дә торса – гадәттә, ниндидер җиңел генә сигарет тарта иде. Бу урында төпченүчән укучы, билгеле инде, бармагын селкеп, ә-ә, менә-менә, ә эчү мәсьәләсендә ничегрәк иде соң дип сораячак. Әгәр дә мин, Илһам абый белән егерме еллап яхшы ук тыгыз аралашкан кеше буларак, юк, ул эчми иде, бу – дошман сүзе генә дисәм, моңа беркем дә ышанмаячак. Чөнки без Бауман урамында култыклашып йөргәндә, абыебызның шактый гына кәефле икәнен күргән кешеләр дә бардыр. Әле бер концертында Салаватның да, Илһам абыйны сәхнәгә чакырып чыгарып, шаярткан булып, мин синең артыңнан шешә җыеп йөрергә дә риза дигән сүзләрен дә ишеттек. Әмма шуны әйтә алам: беркайчан да Илһам абыйның егылып ятып эчкәнен күргәнем булмады. Әнә шул үз кухнясында, тел ачкычы өчен генә дигәндәй, аз-маз уртлап утыруыннан башкасын. Әле анда да ул сүз мантыйгыннан тайпылмый, төрле кызык хәлләрне искә төшереп, көлеп кенә сөйләшеп утыра. Кәефе күтәрелә, кыскасы. Ә кызык дигәннән, тормыштагы, сәхнә артындагы төрле мәзәк хәлләре аның бер капчык була торган иде. Берничәсе исемдә калган. Берсе күптәнге, сакаллы мәзәк. Мәзәк тә түгел инде, элегрәк үз авылларында (бугай) булган бер хәл.

Бер бабай, озак авырып, урын өстендә үлә алмыйча ята икән. Инде яшәп туйган. Тизрәк әҗәл килгәнен көтә. Үзенә гомер теләсәләр, ачуы килә, ди. Шуңа күрә, хәл белергә кергән күрше-күләне бабайга терелү түгел, ә әҗәл телиләр икән. Берсе керә дә: «Бабай, бүген төшемдә сезнең ындырыгызны кап-кара итеп сөргәннәрен күрдем», – ди. Кара җир – әҗәл җитүгә фал, янәсе. Бабайга бу ошап җитми, бик үк көчле юрау түгел дип саный. Икенче берсе керә дә: «Бабай, бүген төшемдә сезнең өйнең морҗасыннан ялкыны белән бергә төтен чыкканын күрдем», – ди. Бабай моңа да риза түгел: «Юк-юк-юк, бура бурауга җитми инде барыбер!» – дип кырт кисә. Илһам абый моны, теге бабай роленә кереп, бик холыксыз, тискәре кеше тавышы белән әйтә, юк-юк-юк дими, ә тупасрак итеп: «Җук-җук-җук», – ди.

Икенче мәзәге дә шундыйрак, үлем-китемгә бәйле. Хәзергечә әйтсәк, кара юмор инде. Шулай ук авылда, элекке бик фәкыйрь заманда, бер бабай үлеп китә. Җеназага килгән мәет юучы әбидән кәфенлек сорый. Ә әби аңа марля чүпрәк китереп тоттыра. Бигрәк сыек бит бу, юньлерәге юкмыни, дигәч, әби бик җитди генә әйтеп куя: «Ярап торыр покага!» Менә шундый мәзәкләр сөйләп, эчне катыра иде абыебыз. Хәмдүнә әйтмешли, абыкам. Сүз уңаеннан, кайчак безнең утырышуларга Хәмдүнә дә килеп эләгә торган иде. Мин – пешекче, ашатучы, табак-савыт юучы, кеше сыйларга яратам. Ә болар икесе авызларын-авызга куеп сөйләшәләр, бер бригадада эшләп йөргән чакларын искә алалар. Хәмдүнә, үзенең бер вакыты җиткәч, әбизәтелне елый башлый. «И абыкам, бәхеткәем булмады бит!» – дип,

«абыкасын» кочаклап, үксеп елый. Тегесе аны юатмый да, көлә генә... Менә шундый кызык та, кызганыч та минутлар булгалады. Кем уйлаган, Хәмдүнә дә арабыздан шулай иртә китеп барыр дип...

Илһам абыйны шаян кеше иде диләр. Әйе, бу шулай. Ләкин шаянлыгы белән бергә, күңеле сөймәгән кешеләргә яки күренешләргә карата ул аяусыз сатирик та иде. Берәр әче җөмлә әйтеп куя да шуның белән бетте! Бөтен усаллыгы шунда гына иде бугай аның.

Илһам Шакиров тирәсенә омтылучылар, хәтта ыргылучылар дип әйтик, бик күп иде. Мин аның белән үзе олыгаю чорына кергәндәрәк кенә ныклап аралаша башладым. Ә аның җырчы буларак искитмәле тансык чагын, үтә дә популяр чакларын күз алдына китерсәк! Кемнәр генә сырышмагандыр аның тирәсенә. Озын буйлы, төз гәүдәле һәм һушыңны алырлык сихри тавышка ия егетне концерттан соң, бер кочак чәчкә тотып, арткы ишектән чыкканын сагалап торучылар дисеңме, филармония адресына атна саен хат язып салучылармы, хәтта конверт эченә коймак тыгып җибәрүчеләре дә булган. Сыйлыйлар, янәсе. Алары инде җырчыга гыйшык тотып, көнетөне аның утында янучылар. Хәер, кайчандыр үзем дә шундый мәҗнүнәләр исемлегендә идем бит әле.

1974 елның феврале. Уфадагы укуымны ташлап килеп, Чаллыда төзелештә эшләп йөргән бер мәлем. ГЭСтагы «Энергетик» мәдәният сараена концерт куярга Илһам Шакиров килде. Мин әле ул вакытта Казанга ук барып җитмәгән, шунда бару юлында, кем әйтмешли, транзит белән, бер елымны Чаллыда эшләп йөрим. Ә бу юлның теге башында, билгеле инде, мине Илһам Шакиров көтеп тора. Гүя мине чакыра, тизрәк Казанга килеп җит тә минем казанымда кайный башла, ди.

«Энергетик»та мин үзем дә җырлап йөрим, атнага дүрт тапкыр – ике көн татар хорында, ике көн – рус ансамблендә. Яңа Шәһәрдән ГЭСка ара шактый ерак булса да, эшемдә штукатурлап-сылап-буяп, шактый гына арып кайтсам да, кичкә таба шунда – күрше бистәгә җырларга чыгып чабам. Кыскасы, мине бәхет басты: үзем җырлап йөргән Сарайда ике көн рәттән, көненә икешәр концерт куячак Илһам Шакиров! Миңа хәтта билет сатып аласы да юк, бушка керәм. Беренче көннең беренче концертына ук алданрак килеп утырдым. Кайда диген әле – залда түгел, сәхнә кулисасы янындарак урындык әзерләп куйдым да шунда – артистларның кереп-чыгып йөргән юлы өстендә үк утырам. Чөнки миңа Илһамны якыннан күрү кирәк, залда утырып тыңлап кына күңел булырлык түгел. Шунысы да кызык: миңа нигә әле монда утырасың дип сүз әйтүче юк. Күрәсең, мәдәният сараеның берәр хезмәткәре дип уйлаганнардыр инде.

Илһам абый сап-сары кримплен костюмнан. Төз гәүдәле, буе-сыны бик килешле. Бу костюмын мин аның былтыр, ул Уфада концерт куйганда ук күргән идем инде. Бер шигырь язып, аны чәчкә гөлләмәсенә кыстырып, сәхнәгә дә менеп төшкән идем хәтта. Ә бу юлы инде ул янымнан узганда җиле дә тиеп китә... Икенче концертны да шулай карадым. Икенче көнне дә рәттән ике концерт. Мин тагын шул ук урындыгымда утырам. Музыкантлардан берсе, баянчы Ирек Галимов шаяртып әйтеп тә куйды: «Сеңлем, туймадыңмы әле концерт карап?!» – ди. Ул арада Илһам абый да, аңа кушылып, «Карасын, җыр яраткан кеше әйбәт кеше була ул», – дип,

мине үсендереп үтеп китте. Түбәм күккә тиде инде! Шул кичне, концерт озаграк баргангадыр инде, Яңа Шәһәргә төнлә кайтып җитә алмадым, чөнки автобуслар, трамвайлар инде йөрүдән туктаган иде. Төнне урамда уздырдым. (Ул вакытларда такси дигәне дә юк иде шикелле.) Җепшек карлы февраль төнендә игълан тумбаларыннан Илһам Шакировның афишаларын кубарып җыеп йөргәнем хәтердә...

Илһам тирәсенә, аның даирәсенә якынаерга теләгәннәр күп иде дидем инде. Барысы да аңа тартыла, аның белән дуслашырга омтыла. Ә һәрдаим игътибар үзәгендә булуның бит аның шундый ягы да бар – дан иясенең үзен талкый ул, арыта. Аннары кеше шикелле иркенләп урамда да йөреп булмый, барысы да сине таный, туктата, сөйләшергә азаплана. Дөрес, яшьли үк халык яратуына күнеккән кеше буларак, Илһам абый үз шәхесенә карата булган зур игътибарга күпмедер дәрәҗәдә мохтаҗ да булгандыр бәлки. Шулай да, еш кына ул үзенә сырышкан кемсәләрнең беришеннән арынырга да тырыша, ләкин барыбер арынып бетә алмый иде. Үзенә чын иптәш, сердәш булырдай кешене эзли, һәм кайчагында ялгыша да. Казан уртасындагы иске фатирына, Николаев урамындагысына кемнәр генә кереп чыкмый иде аның. Үзе якын күргән сәхнәдәшләре дә, юньләп таныш булмаган үткенчеләр дә. Шулай кеше диңгезе уртасында яшәсә дә, минем фикеремчә, Илһам абый тома ялгыз иде. Аның бит әле тагын шул ягы да бар: балачагы, үсмер еллары ишле гаиләдә үткән. Туган-тумачасы, күрше-күләне, яшьтәшләре белән әвәрә килеп үскән егетне Казанга килү белән зур шәһәр йоткан да таш фатирга бикләп куйган. Урманлы, кырлы табигатьтә хөрлеккә өйрәнгән авыл баласының бер фаҗигасе инде ул таш каладагы тормыш. Барлык уңайлыклары булган хәлдә дә. Зур-зур залларда авыл турында, урман, елга, таулар иркенлеге турында җырлап йөргән кеше үзе, асылда, шул хозурлыктан күптән инде мәхрүм! Кара урманнар, үзе чапкан печәннәр, саф сулы чишмәләр аның күңелендә сагыну-сагыш булып кына яши. Ә бәдәни тормышы бөтенләй бүтәнчә. Тукайча әйтсәк, шушы «Аһ, бу нинди аерылу!..» дигән ачы чынбарлык нечкә күңелле кешене тоташ хәсрәтле, моңлы итәдер. Өстәвенә, төрле сәбәпләр аркасында вакытында гаиләсен кора алмый калган кешегә бу өсте-өстенә ялгызлык сынавын сала инде. Моны авылдан килеп, гомерен калада уздырган кеше аңлыйдыр. Үзем дә шундый хәлдә идем, яшьлегем таш калада узды. Инде олыгаеп барганда, туган авылыма кайтып яши башлагач та, бу сагынуның һаман да беткәне юк әле. Иртән уяныр-уянмас, тукта, мин кайда ятам әле дисәм, исемә төшә дә, Аллага шөкер, үз авылымда бит әле дип сөенеп куям...

Ниһаять, филармония дә – газиз Тукаебыз исемен йөртсә дә, ул барыбер артисттан акча эшләтеп, аның көчен, талантын сыгучы оешма гына. Ул – дәүләт абзый оешмасы, ә артистлар – дәүләткә акча эшләүчеләр. Мин моны хурлап та әйтмим, бу – факт, шул гына. Ә совет чорындагы концерт оешмалары алар инде, гомумән дә, кырыс эксплуататорлар иде. Хәлең, кәефең бармы синең, җырлыйсың киләме, юкмы, инде афишалар эленгән – бармый хәлең юк. Авылгамы, Уралгамы, Мәскәүгәме, Урта Азиягәме, елның кайсы фасылы – буранлы суык кышмы, язгы-көзге пычракмы – барыбер. Берсендә каядыр, белмим, кайсы тарафкадыр гастрольгә чыгарга тиешләр икән. Инде самолётка билетлар алынган, бригада юлга чыгарга әзер, ә Илһам кирелегенә каткан – бармыйм, бетте-китте. Бу киреләнү җырчының

ниндидер бер протесты булгандыр, мөгаен. Сәбәпсез генә түгелдер. Һәм андый очрак бүтән кабатланмаган диләр. Килешүләр, контрактлар төзеп эшли торган еллар түгел бит ул чорда. Синең хокукларың юк дәрәҗәсендә. Син җырла да җырла гына! Дәүләт оешмасына эшкә кергәнсең икән, русча әйтмешли, будь добр, пионер кебек һәрвакыт әзер булырга тиешсең. Әле түләү дигәне дә ташка үлчим генә. Хәзер әйтәләр дә ул, Илһамның концерт ставкасы, бүтән җырчыларныкы белән чагыштырганда, иң зурысы иде дип. Ул иң зур дигәне дә барыбер бүгенге «йолдыз»ларныкы янында чүп кенә булган, билгеле. Бүген танылган җырчылар үзләре оештырган концертлардан кергән акчаның иң зур өлешен үзләренә алалар. Шуңа да аларның күбесе яшьләй үк зур йортлар да сала, яхшы машиналар да ала, теләсә кая барып ял да итә ала. Дөрес, Илһам Шакировка да, Әлфия Афзаловага да хөкүмәт үз вакытында мактаулы исемнәрен дә, фатирларын да биргән бирүен. Ләкин ни генә дисәң дә, бу – алар лаек булганның иң кечкенә генә өлеше.

Илһам абыйның үзәктәге иске фатиры «сталинский» дип атала торган йортта иде. Биек түшәмле, стеналары калын, әмма канализация торбалары күптән искереп беткән. Балконы тузанлы якка, урамга – Тукай һәйкәленең аркасына таба чыга. Фатирда бер артык әйбер дә юк. Җиһазлары гади генә. Алтмыш биш яше тулгандамы икән, хөкүмәт ярдәме белән аның фатирына ремонт ясадылар. Бай кешеләрме, әллә хөкүмәтме – яңа җиһазлар да бүләк иттеләр. Туган көне белән котлап, машиналар да бирделәр. Бу бүләкләрнең иң кәттәсе – җиңел автомобиль иде. Аны Сарман районындагы якташы, эшмәкәр Сәлимхан акчасына алганнар. Ә Сәлимханның үзен машина ачкычы тапшырырга сәхнәгә дә чыгармадылар, ачкычны Сарман районының шул вакыттагы башлыгы тапшырды. Үпкәләгәндер инде... Иске ипподром биләмәсендәге ресторанда узган банкет та Сәлимхан исәбеннән иде дип беләм. Ул үзенең бөек якташын кадерләр өчен акча кызганмады. Инде үзе дә исән түгел, рухы шат булсын. Шуннан, янә бүләкләр дигәннән, машиналарны (алар икәү иде, әле тагы йөк машинасы да) Илһам абый туганнарына бирде шикелле. Бирдеме, үзара алыш-биреш ясадылармы, анысын белмим. Шуны гына әйтә алам: Илһам абый барыбер ул машинада йөри алмаган булыр иде, чөнки йөртә белми. Правасы булдымы икән әле, гомумән. Ул бөтенләй дә тормышка җайлашмаган кеше иде. Мал-мөлкәткә исе китмәде. Киресенчә, артык мал, әйберләр үз тормышында кирәкмәс мәшәкать тудыра торган нәрсә дип саный иде бугай. Җырчыны нигәдер кош белән чагыштырасым килеп китте. Кошлар да бит бала чыгарыр өчен генә оя корып алалар да калган гомерләрен очышта уздыралар. Суыклар башланыр алдыннан күбесе башка тарафка очып китә. Илһам абый да кош хөкемендәрәк яшәде, миңа калса. Бүген Ходай ни биргән, шуңа риза була белде. Артыгына үрелмәде.

Соңрак, кайбер яшьрәк җырчылар сигезәр, унар бүлмәле фатирларда, кайберләре үзләре төзеп кергән яхшы йортларда яши башлаган чорда, Президентыбыз Минтимер Шәймиев игътибары белән дип беләм, җырчыга Щапов урамыннан, чынлап та, заманча шартлары булган бик иркен фатир бирделәр. Бу Илһам абыйга җитмеш яшь тулганда булды, ялгышмасам. Лифтсыз, аз катлы йорт булганга күрә, өченче каттан җәяү менеп-төшеп йөрергә авыр дип, Илһам абый, үзенең ярдәмчесе (мин аны җырчының

адъютанты дип атап йөртә идем, шаяртып) икенче Илһам белән бергәләшеп, ул фатирны Мәрҗани мәчете янындарак, Каюм Насыйри урамындагы фатирга алыштырдылар. Бусы инде беренче катта. Чыгып-кереп йөрергә бик уңайлы диделәр. Миңа анысында булырга туры килмәде, чөнки, энем авырып китү сәбәпле, мин инде туган ягым Башкортстанга кайтып киткән идем. Истәлеккә, шул елларда минем фатирны котлап, Илһам абый алып килгән бик матур юрганы кайтты авылга.

## Нәрсә соң ул моң?

Берничә интервьюсында Илһам Шакиров үзеннән моң ни ул дип сорагач, моң-зарлы булу, сагышлы булу ул дигән иде. Илһам Шакировның балалыгы, яшьлеге туры килгән елларны алсак, сугышка хәтле, сугыш чорында һәм аннан соңрак яшәгән халыкның гамьнәре, уйлары, шатлыклары һәм хәсрәтләре асылда бер үк төрле, охшаш булган, бәхәссез. Илһамның үзе өчен болар – башта Сталин репрессияләре аркасында әтисез калу, ятимлек, аннан соң – сугыш, ачлык, фәкыйрьлек, инде сугыштан соңгы елларда да очны-очка ялгап кына көн күрү. Балигъ булганчы шулай. Казанга килеп, җырлап танылa башлагач кына, ул бер бүлмәле фатирга тиенгән. Үз замандашларының – авылдашларының, туганнарының барлык аһ-зарын үзенә җыйган ул, үз йөрәгенә төйнәгән. Кулыннан килгәнчә, барлык туганнарына да ярдәм иткәнен дә беләм. Аның җырларындагы моң-сагышны нәкъ шул заман кешеләре аеруча яхшы тойгандыр. «Гомерем булып, таш басмаса, ташламам, җанкисәгем» дип тә, «Герман җире яшел үлән, әллә саргаеп үләм» дип тә җырлады бит ул, «Бардым күлгә, салдым кармак, безгә балык эләкми, бетсен патша, янсын тәхет, безгә сугыш кирәкми» дип тә, «Сөялгәнсең чатта баганага, яфрак төсле сары йөзләрең» дип тә, «Сызыла иркен, тын һавада анда ил-зар моңнары» дип тә... Димәк, моң – ул тормыштагы һәр нәрсәне күңел аша үткәреп, йөрәккә якын кабул итүдән туган бер тойгы буладыр. Ә бүгенге тук заманда яшәүче яңа буын кешесенең, күп очракта, йөрәген май баскан. Михнәт күрмәгән рәхәт күрмәс дигән гыйбарә бар бит әле. Кыенлык күрмәгән кеше рәхәт тормышның кадерен белмәс дигән сүз инде ул. Бәлки бүгенге яшьләрнең тирәннән алып уйлана белмәве, якты сагыш, сагыну, моңлану дигән шәйләрне күңеленә якын алмавы заманадан да киләдер? Бәлки бүгенге яшьләргә дә нәкъ менә Илһамнар, Әлфияләр кебек үк, газиз әтиләрне, әниләрне югалту ачысын, ятимлек хәсрәтен, ачлык михнәтен, Сталинның чулак кулының вәхшилеген тәмләп карарга кирәктер? Хәер, эшләр шуңа таба бара да бугай инде... Бүгенгесеннән исән чыга алсак, алга таба музыка, җыр тарихында тагын бер моң чылбыры барлыкка килүе бар. Бер яхшының бер яманы дигәннең тискәре ягын әйләндерсәк, бер яманның бер яхшысы диясе генә кала.

## Башы булса, койрыгы да була

Илһам дигән җырчының иҗатына мөкиббән китеп, аны яратуым минем үземнең язмышыма да нык йогынты ясады дисәм, бер дә арттыру булмас. Студент чагымда мине ошатып, Илһам абыйның бер энесе, апасының улы игътибар билгеләре күрсәтә башлады, һәм без дуслашып киттек. Дуслык

яратуга әйләнде. Әмма төрле сәбәпләр аркасында бу яратышуның ахыры бигүк матур булып бетмәде. Очраклы мөнәсәбәт нәтиҗәсендә (соңрак үзе шулай дип аңлатты) егетем тиз генә бер Казан кызына өйләнеп куйды. Минем алдагы берничә ел гомерем күз яшенә манчылды. Рәнҗеш, газаплану, күңел ярасына... Ә соңрак, шактый еллар үткәч, егетемне үз хатыны ук кадап үтерде...

Инде килеп, язмыш юлларының тагын бер кисешүе. Бер килсә килә бит ул: туксан сигезенче елда эти гүр иясе булган иде, тагын ике елдан әни аягын сындырды. 75нче яше белән барган кешегә бу бик авыр сынау иде. Гәүдәнең ботка тоташкан сөяге сынган. Ә андый сөяк ялганмый, димәк, операция ясатырга кирәк. Әни энекәш белән авылда, Башкортстанда яшәп ята. Уфада медицинаның торышы ул вакытта кайтышрак, ә менә Казанда мондый операцияләрне яңача ысулда ясыйлар икән, Германиядән кайтартып, махсус материалдан ясалган «сөяк»не сынганы урынына утыртып ялгыйлар. Ә бит башта клиник хастаханә җитәкчелеге белән сөйләшергә кирәк, күрше республика кешесен алырмы икән алар? Рәхмәтләр яусын, Илһам абый булышты, кирәкле кешеләр белән сөйләште. Өстәвенә, ул вакыттагы баш табиб үзе дә Сарман кешесе, Илһам абыйның якташы булып чыкты. (Инде исән түгел, сүзебез рухына догалар булсын.) Дөрес, әнине РКБга болай да салган булырлар иде бәлки. Түләүле операция бит. Әмма чират дигән нәрсә дә бар бит әле. Илһам абыйның абруе эшне тизләтте. Шулай итеп, әнине авылдан алып килеп, операциягә салдык. Әнинең фамилиясе дә Шакирова, ул укытучы булып эшләгәнгә күрәме, фамилиясен үзгәртмәгән, эти фамилиясенә күчмәгән. Ул яткан палатадагы хатыннар моны үзләренчә легендага әверелдергәннәр. Янәсе, минем әни – Илһам Шакировның туганы икән, аңа монда операция ясатырга да Илһам абый булышкан! Туганы ук булмаса да, булышуы хак бит инде. Бу фаразга әни каршы килмәгән, шул версияне тартып-сузып раслаган. Бу операциядән соң әни әле тагын сигез ел яшәде, шуның алты елын үз аягында йөрде. Дөресрәге, үз аягындагы ясалма сөяк белән... 2001 елның февралендә, әле әни Казанда вакытта, филармония залында Илһам абыйга алтмыш алты яшь тулуга багышланган концертта мин аңа сәхнәдә, аяк вакыйгасы символы итеп, әни бәйләп биргән оекбашлар бүләк иттем... Бу вакыйгалар – минем язмышның Илһам абыйга бәйле «койрыклары»...

## Илһам җиләне

Моны мин бер язган идем инде: ул чагында «Шәһри Казан» газетасының баш мөхәррире Гөлнара Сабирова сораганга яздым. Илһам Шакировның мәңгелеккә күчкән көне иде бу. Күз яшьләремне тыя алмыйча, елый-елый утырдым компьютер каршында. Ул вакытта «Илһам чапаны» дип яздым шикелле. Аннары уйлап йөрдем дә, тукта, мин бигүк дөрес язмаганмын икән: чапан бит җылырак өс киеме була, ә сүз плащ турында бара иде, димәк, җилән дип язасы булган дидем. Ә сүз менә ни хакында.

Берсендә Илһам абый эшемә шалтыратты да кайтышлый миңа кер әле диде. Аңа сугылдым. Җәй ахыры булдымы икән, көз башымы, төгәл генә хәтерләмим, һаваның тотрыксызрак көннәре иде. Илһам абый миннән

нидер пешерттерде. Пылаумы икән, әллә балык кыздырдыкмы... (Сүз уңаеннан, ул балык ярата иде.) Озак кына сөйләшеп, ашап-эчеп утырдык та, мин кайтырга җыендым. Фатирым җәһәннәм тишегендә. Казанның иң читендә – Азинода. Тышта коеп яңгыр яварга тотынды. Илһам абый, әллә каласыңмы, миндә генә кун дип кыстаса да, миңа кайтырга кирәк иде. Ул шифоньерыннан искерәк бер плащын алып бирде. (Җиләнен диик инде, үзебезчә булсын.) Шул җиләнне ябынып, тукталышта автобус көтеп тордым әле... Соңрак бу җиләнне кире илтергә ничектер кул җитмәдеме, әллә Илһам абый кирәкми дидеме шунда, ул җилән миндә калды. Бервакыт тәрәзәгә күзем төшсә, ишегалдында, каршыдагы ун катлы йорт каршында балалар мәйданчыгы тимеренә бәйләнгән җигүле ат тора. Икенче карыйм – ат һаман тора. Күрәмсең, якын-тирәдәге берәр авылдан килгән кеше кемгәдер кереп киткән дә чыкмый да чыкмый, кунак булып утырадыр инде. Ә тышта яңгыр ява. Мескен ат күшегеп басып тора инде, нишләсен. Мин Илһам абыйның теге җиләнен алып чыктым да атның өстенә ябып куйдым. Икенче кат караганда, ат инде юк иде...

Шул ат шикелле гасыр җил-яңгырларында күшеккән, империянең кысрыклавына да карамастан телен, моңын сакларга дип җан тартышкан халкыбызга Илһам абыйның бай иҗаты, берсеннән-берсе моңлырак җырлары шул ышык биргән җилән сыманрак булды бит инде – башыма шундыйрак чагыштыру килде.

Мин әле дә сәер төшләр күргәлим. Күптән дә түгел болай дип күрәм. Имеш, Илһам абый безнең авылга кайткан да, иске өебездә, түр бүлмәдә сөйләшеп утырабыз икән. Теге үсмер чакта төшемдә күргән телевизорлы бүлмәдә. Уянып киттем дә аңышып бетмичәрәк уйлыйм: туктале, Илһам абыйның безнең авылга кайтканы булдымы соң әле?! Юк, булмады андый хәл. Башкортстанны аркылыга-буйга гизеп чыкса да, безнең авылга юлы төшмәде. Нишләп инде шундый зур җырчы бер бәләкәй генә авылга килсен, ди... Димәк, бусы да минем хыялымда гына калган...

Хәзер инде телевизорга да кытлык юк, теләсә кайсы каналны да карап була. Безнең күрше-тирә районнарның халкы тоташ татарлар, барысы да Казан телевидениесен карый. Илһам абыйның җырларын да күпме кирәк, шуның хәтле тыңларга мөмкин – интернетка керсәң, тезелеп киткән. Илһам абый үзе генә юк. Ә миңа ул әле дә исәндер кебек тоела. Казанга бара калсам, телефоныма шалтыратыр да:

– Флүрә, җаным, үтешли миңа сугылып чык әле, сөйләшәсе сүзләр җыелды, – дияр сыман...



Ризәлә
Исмәгыйлева

# САБЫРЛЫК ДУЛКЫНЫ КӨЙЛӘНӘ...

## Сер вә кер

Әүвәлгеләр серен суга салган,
Агымсуда керен чайкаган.
Сер сакланган, кер агарган, ләкин
Су төбендә юшкын-ком калган.

Әүвәлгеләр серен суга салган.
Су җил түгел, илгә сипмәгән.
Кеше күзләреннән тирәнгәрәк
Сабыр сандыгына бикләгән.

Әүвәлгеләр серен суга салган.
Иман торган сабыр сагында.
Капка эчләрендә сыгылса да,
Балкып чыккан урам ягына!

Әүвәлгеләр серен суга салган.
Су үз хәлен үзе белгәндер.
Бәлки, кайчагында үзенең дә
Ташып түгеләсе килгәндер.

Әүвәлгеләр серен суга салган.
Ә ул – салмак кына юлын алган
(Сандыкларның санын санамый).
Хәзергеләр суга карамый
Димәс идем...
Бүген башка заман!
Тик һаман да
Ышанам мин суның көченә!
Серләр генә суга сыймас кебек...
Керләр генә кайнатырлык сыман
Заман машинасы эчендә.

Ризәлә ИСМӘГЫЙЛЕВА (1974) – *шагыйрә, журналист, «Тәртип радиосы»ның җитәкчесе. Шигырьләре узган ел Татарстан китап нәшриятының «Яңа гасыр авазы» исемле күмәк альманахында дөнья күрде. Казанда яши.*

## И Казаным!

И Казаным! Кичер, кайбер көнне
Синең матурлыгың күрми калам.
Йөгерә-атлый гомерем үтә торган,
Кайнатыплар үстерүче калам!...

И Казаным! Саклый күр син берүк
Авыл бүләк иткән балаларың!
Беркатлылык саркыса да җаннан,
Сине яклар көче бар аларның!

И Казаным! Авылымны сагынып
Булгалыйдыр үпкәләткән чагым.
Нигеземә кайтып хәл җыям да
Сиңа килеп алга атлыйм тагын.

И Казаным! Аңлыйм, гомеремнең
Күп өлеше синдә узганын да.
Тик нишлисең, балачагым калган
Авыл урамының тузанында.

И Казаным! Уңышларың күреп,
Горурланам синең белән дә мин!
Туган җирем – яшел бишек булса,
Синдә – милли, затлы биләүдәмен!

И Казаным! Зирәк аксакалым!
Чал тарихлы, нурлы, моңлы калам!
Берни эшли алмыйм, күңелем белән
Мәңге авылныкы булып калам.

## Әни теләкләре

«Ни хәл, әни!» – диеп шалтыратсаң,
Син әйткәнне ишетми дә сыман.
Изге теләкләрен тезеп китә,
Җитәкләгән чактагыдай кулдан.

Кайчагында әйтәм дигән сүзем
Әйтелмичә эленепләр кала.
Сизгер ана һаман теләк тели:
«Раббым үзе ярдәм итсен, бала!»

Кайбер чакны үпкәлисе килә,
Тыңламый да бугай диеп мине.
Бер теләге – дөнья бәһаседер!
«Амин!» – диеп кенә тыңла, тиле!

Адым саен теләк тели әни!
Кабул була бара әйткән бере!
Әни сүзе бала өчен – калкан,
Әйтеп аңлатмаслык тормыш сере!

Бертуктаусыз теләк тели әни.
Һәр теләге – ачылачак бөре!
Гөлгә төрик дисәк киләчәкне, –
Хәер-фатихасын алып калыйк!
Үткәннәргә кайтып булмас кире...

## Каты итеп баса алмыйм җиргә

Каты итеп баса алмыйм җиргә.
Баса алмыйм үкчә киеп тә.
Тамырының көчен тоймаганда
Менә алмый кеше биеккә.

Каты итеп баса алмыйм җиргә.
Изелер күк газиз күзәнәк.
Шәһәр халкы бик аңламас мине,
Авыл балалары үзгәрәк.

Каты итеп баса алмыйм җиргә.
Ышанычлы юкса адымнар.
Юкка түгел бу сакчыллык, димәк,
Язылмаган мөһим канун бар!

...Таш калада горур атлаганда
Әллә ниләр килә уема.
Каты итеп баса алмыйм җиргә.
Гомер үтеп, матур картаясы,
Керәсе бар бер көн куенына!..

## Әти

*Алтын куллы булгансың син, әти!*
*Эш курыккан кулың кагылганда.*

Алтын куллы булгансың син, әти!
Күз алдымда бәйләм-бәйләм суган...
Бакча башындагы гади тал да
Синең кулдан кәрҗин булып туган.

Алтын куллы булгансың син, әти!
Бар да искә төшә сагынганда...
Капкадагы гөлең, тәрәз өлгең
Төсең булып тора авылга да.

Алтын куллы булгансың син, әти,
Искә алган саен хәйран калам...
Алтыннан ук булмаса да куллар,
Шөкер, әти, без дә синең дәвам...

## Әни

Син гаиләдә көтеп алган бала,
Хәсрәт кичкән әниеңә өмет!
Күздән саклап кына үстергәннәр
Төрле төсле күлмәкләрен тегеп...

Синең иркә чагың тиз югалган,
Сугыш чоры нужасына кереп...
Иксез-чиксез урман эчләреннән
Казаннарга кадәр җәяү йөреп.

Сиңа Раббым корыч холык биргән,
Чыныктырган, ятимлеген биреп.
Шуңа дадыр иң яраткан җирең
Басу-кырлар, урман һәм дә... ирек!

Син – Раббымның яраткан бер колы.
Үзең шуны беләсең дә кебек.
Тик нигәдер күңел сандыгыңа
Яшисең син йөз кат бикләр элеп.

«Бала – Алла түгел, табынма!» – дип,
Әйтүләрең хактыр, бик тә белеп.
Син дөньяда иң шәп әнидер ул!
Аңлап кына бетермибез кебек...

## Син ир бала

*Улым Инсафка*

Син – ир бала!
Шуңа сиңа вакытында акыл,
Вакытында камчы килешә!
Син – ир бала!
Шуңа синдәй зирәк фикерлеләр
Морадына һәрчак ирешә!

Син – ир бала!
Шуңа сиңа – атланырлык атың,
Учак саклар хатын тиешле!
Син – ир бала!
Шуңа синең барыр юлың иркен,
Кыяфәтең горур, килешле!

Син – ир бала!
Шуңа күрә егетләрчә итеп
Язылалар бүген юлларым.
Син – ир бала!
Ир балалы миллионлаган ана –
Сиздермәскә тырышадыр гына –
Сагыналар алар улларын...

***

Ай гына, ел гына, юл гына
Аера алмыйдыр кешене.
Сагыну Раббымнан бүләктер,
Көчлерәк итәргә көчлене!

Ай гына, ел гына, юл гына
Аера алмыйдыр баладан.
Сабырлык дулкыны көйләнә
Күрешү көтүгә яңадан.

Ай гына, ел гына, юл гына...

## Күзләр эзлим

Күзгә карап сөйләшүләр бетте –
Күрсәтерлек көзге югала.
Күңелдәгене чагылдырыр күзләр
Көзге түгел хәзер... пыяла.

Күзгә карап сөйләшүләр бетте.
Бетмәсә дә, бара югалып.
Елмаюлар сәер, чырайларга
Тегеп куйган кебек бер калып.

Күзгә карап сөйләшүләр бетте.
Яшерерлек гамәл күплектән.
Юкса, алдыбызда Алла колы,
Ул да табылмаган чүплектән!

Күзгә карап сөйләшүләр бетте.
Хөсет турый кара эчләрне.
Әле, шөкер, бизмән Раббымныкы!
Тигезләүче ул бар көчләрне.

Күзгә карап сөйләшүләр бетте.
Юкса, өлеш күптән бүленгән.
Күзгә карап сөйләр күзләр эзлим
(Ботак тишегеннән түгел!)
Багарлыгын күңел түреннән!

## Тауның матурлыгын күрим дисәң...

Тау башында басып торган чакта,
Күрмисең ул тауның матурлыгын!
Ә син
Итәгенә төш тә үзәннән бак!
Җитсә әгәр моңа батырлыгың!

Чып-чын сурәт бары шунда гына
Пумалаңнан күчәр кәгазеңә.
Күзләреңә ышан, алданганчы,
Колак салып вак таш «вәгазенә».

Тау гел текә – табигате шундый.
Биек менгән саен җиле салкын.
Ташка әверелми саклау кирәк
Үзәк җылытырлык үзән хакын!

Таудан төшү – ул тәгәрәү түгел,
Зирәкләрчә тамыр барлау гына!
Һәр киртләвен уч төбенә куеп,
Нәтиҗәләр ясап карау гына.

Сабыр гына, акыл белән күзләп,
Капшап чыга алсаң һәр сырын,
Синең тавың табигый, чын булыр –
Таш баскычка аяк басарың!

Ташлар эреп, тау ишелми. Аңла!
Бераз чүгә… Горурлыгы кала.
Ә син...
Тауның матурлыгын күрим дисәң,
Үзәнеңә төш тә өскә кара!

## Күпердә

Күпер уртасында басып тору –
Бәхет микән? Әллә сынаумы?
Соң арада акыл кешелеккә
Бик еш бирә шушы сорауны.

«Сынау!» диеп, фани сыкранганда,
«Бәхет!» диеп, бакый елмая!
Язмышына шундый бәхет язгач,
Китә алмый бәндә беркая!

Сүтә-сүтә чорлар йомгагын,
Бәйли бара нечкә кылларын.
Өзелмәсен өчен кыллары
Ямау итеп сала моңнарын!

Хәзинәгә тиңли үткәнен,
Өмет белән сыйлый көткәнен!
Сынатмаса, аңламый да кала
Морадына барып җиткәнен!

Халкын ихлас яратучы гына
Җавап таба алыр сораугa.
Күпер уртасында басып тору –
Бәхет тә ул, дуслар, сынау да!

## Пышылдап та гайбәт сөйли күрмә!

Җырдагыча... Җилгә сөялдем дә
Карап торам гади баланга.
Раббым, Аллам! Хәсрәтләрсез гомер
Бирсәң иде һәрбер баланга!

Ә баланым тәсбих тарткан сыман
Үзалдына гына нидер сөйли.
«Көзләр килми калмый бирәүгә дә,
Җил көчәйгән саен яфрак кими...»

Шәрәләнә барган саен салкын,
Җылытмакчы булып, җимеш яна…
Әй җимешем… Син янганнан гына
Җилләр тынып, җир җылынса кана…

Җил-җилбәзәк! Аның зәһәреннән
Яфрак ярар… Өзелмәсен өмет!
Һәр хәбәрен чынга ала күрмә,
Колагыңа ысылдаса килеп!

Һәр колакта яфрак булган кебек,
Һәр яфракның бардыр колагы!
«Пышылдап та гайбәт сөйли күрмә!» –
Дип пышылдый балан куагы.

Язның җиргә килми калганы юк.
Яфрак урынына яфрак үсәр!
Кар астында калганнары гына
Үзәкләрне өзеп искә төшәр.

Җырдагыча... Җилгә сөялдем дә
Карап тордым гади баланга.
Өмет өзәр хәсрәт бирмә, Раббым,
Җир йөзендә һичбер баланга!

Зиннур
Хөснияр

# ӘЛЛҮКИ*

РОМАН

**Ясминә.**

Тукаш Путанай ягында этләр улаган тавышка уянып китте. Ләкин төн уртасында күзләре шар булып ачылуга бер дә аптырамады, чөнки кичтән үк Каләм очына фикер кунган иде. Башы саф, чүмечтән генә салкын су чөмереп, язарга утырды. Иң әүвәл «Ясминә – бәхетсез хатын» дигән исем язып куйды...

Бу – Тукаш Каләменең беренче язмасы булды. Аның нигәдер Ясминәне Солтанның сөяркәсе итәсе килә иде. Мәкаләдә болай эшләп булмый, анда төгәл кешеләр хакында, булган хәлләр турында языла. Алайса, әдәби әсәр булырга тиеш!.. Әлегә жанрын төгәл билгеләмәскә булды, чөнки «бәян» дисәң, язарга ниятләгән хәл-вакыйгалар әлеге чиктән бүселеп чыгар кебек, «роман» дип куйса, алай артык зурга кизәнү шүрләтә, башкарып чыгасына шикләнә; җитмәсә, әлегә чынлап торып исеме дә юк язылачак әсәрнең... Шулай да, фантазиясен эшкә җигеп, ниятенә керешергә булды. Аңа кадәр ишегалдына чыгып керде, төнге күккә карады, анда йолдызлардан башка берни күрмәде. Кичтән капка төбеннән каз каурые да эзләп караган иде. Күршеләре кытай казлары асрый, шулар су буеннан кайтып кына кергәннәр иде әле. Ләкин каурый-мазар тапмады, кытай казлары каурыйларын коймый, ахрысы. Шуннан соң бу эшенә кул селтәде, ансыз да яза ала бит.

Ясминәдән бигрәк, шул рәвешле гел беренче булырга яраткан мактанчык Солтаннан «үч» аласы килде бугай... Әллә кайчан авылдан чыгып киткән сыйныфташы белән кайчан, кайда күрешкән Ясминә – шайтан белә! Әдәби әсәр өчен ул кадәрлесе әһәмиятле түгел. Димәк, күрешкәннәр. Бәлки, Хәлүш печәнлегендә кавышканнардыр? Ул төш тикмәгә кермәгәндер бит инде? Бәлки, вәхи-хәбәр төштә килә торгандыр хәзер?..

«...Туксабага иң беренче булып Солтан кайтып төште, – дип башлады ул. Шуннан соң дәвам итте: – Солтан кайтканчы моңарчы үзен бәхетсез хатын дип йөргән Ясминә яктырып китте. Кайдан килеп керде соң әле бу Солтан турындагы уй?! Җитмәсә, хәзинә турындагы хәбәрне дә беренче булып җибәрүче ул булды...»

* Журнал варианты

*Дәвамы. Башы узган санда.*

Тукаш каләмен тагын читкә куйды. Белә бит ул: мәктәптә укыганда ук Гафият гашыйк иде Ясминәгә. Теге чакта Гафият аннан Ясминәгә багышлап шигырь дә яздырды. «Борынгы чүлмәк таптык. Шул ваза кебек матур борынгы чүлмәккә уям мин аларны», – диде. Ләкин Ясминә, Гафияткә чыкса да, Солтанны һаман онытa алмый, имеш. «Мәхәббәт һәм хыянәт»нең күз алдындагы мисалы бит инде бу!» дип уйлап куйды Тукаш. Никтер күңелсез булып китте, нигәдер шул вакыт ул Мәликәсен уйлап куйды.

Сыйныфташы Ясминә хакында бар дөресен белмәсә дә, кыек атып, туры тидерә язган иде Тукаш.

Чын дөресе болай булды.

Соңгы араларда Солтан исеме кылчык кебек килә дә кадала Ясминәнең уйларына... Яше кырыкка җиткәндә, эшнең шырыкка таба китүе урынына сөю-сәгадәт турында уйлана башлады түгелме әле үзен бәхетсез итеп хис итә башлаган хатын?! Димәк, моңа кадәр яшәлгән гомер «шырык» булган, хәзер менә кинәт кенә яшь кызлардай мәхәббәт уты капты итәгенә!.. Сөю – сәгадәт ул, бәхет ул... Аның бик тә, бик тә үсмер чакта йөрәгендә ут кабызып калдырган Солтанны күрәсе килә башлады.

Әллә берәр сәбәп табып чакыртыргамы? Китеп олакканнан соң, туган ягыңа бер кайтып күренмә инде син?!

Хәер, хурлыгыннан качкандыр инде ул моннан! Сүз чыкты бит теге чакта, Миргали абыйсының Кала ягындагы сөйгән кызы Сәрвәр артыннан чаба икән дип сөйләштеләр. Шул хурлыкка түзә алмагандыр инде, ата мәче! Беркөн Ясминәне озат, икенче көнне үк Кала ягына чап! Кыз хурлыгыннан үкси-үкси елаган иде шул вакытта. Юкка түккән булган энҗедәй күз яшьләрен азгын сыйныфташы аркасында. Ичмаса, Гафиятне дә үпкәләткән иде. Үпкәләткән дип... Анысы да үзе гаепле, марҗага күзе кызды бит...

Авылда ул чакта да таң белән хуҗалык сөтен җыялар иде. Әнисе Нурфия үзе таңнан торып эшкә китә, иртәнге савымны кызына тапшырырга кушып калдыра. Бер көнне шулай Ясминә, чиләкләрен күтәреп, капка төбенә чыкса, сөт машинасы янында әйбәт киемнәрдән Солтан басып тора. Сөт машинасына утырып, Язлыдан Ханкалага йөрүче автобуска барышы икән. Машина янында күрше хатыннары кайнашканлыктан, бер авыз сүз дә алыша алмадылар. Киресенчә, Солтан кыздан карашын яшерергә тырышты. Бер атналап элек аның Ханкаладан килгән туристларны Ислемай тавына алып барганын һәм араларында бик чибәр кыз да булганлыгын ишеткән иде Ясминә. «Әллә?!» – дип уйлады ул. Югыйсә алар Ханкалага киләсе атна башында икесе бергә барырга тиешләр иде. Солтан авыл хуҗалыгы, Ясминә медицина институтына документлар тапшырабыз дип сүз куештылар. Әнә Солтан аңа да әйтмичә юлга җыенган. Ясминә үпкәләде сыйныфташына, кая баруы турында сорашмады да.

Кыз сөтен тапшырды да, буш чиләкләрен күтәреп, ишегалдына узды. Җаны тузгыган иде. Чиләкләрне чайкап куясы, иртәнге көтүне куасы бар әле, шуңа күрә өйгә кереп тә тормады; тиле кебек арлы-бирле ишегалды буенча йөренде. Сөт машинасының кузгалып киткәне капканың бу ягына ишетелә иде.

Шулчак көтмәгәндә урамда шау-шу купты, ике хатын дөнья беткәндәй әче тавыш белән кычкыра башлады. Берәр җиргә ут капкандыр дигән

шомлы уй белән кыз капкага атылды, чыкса, ни күрсен: Дәүбаш Дәриясе белән Тәбә Тәслимәсе бер-берсе белән ызгыша икән. Ясминә аларны сөт тапшырганда күргән иде, икесенең дә йөзләре бурлаттай кызарган, әмма кеше янында бер-берсенә ябышырга кыймадылар, ахрысы. Хәзер менә үз капкалары төбенә кайтып җиткәннәр дә, биш-алты өй аша торып, телне куырырлык тәмсез сүзләр әйтешәләр. Тәслимә аягындагы галошларын тегеңә таба очрытып җибәреп, яланаяк килеш басып тора; бу – аның өчен гадәти нәрсә, Дәүбашлар хатыны күптән Иванов алымы белән шөгыльләнә, кар өстендә ялантәпи йөри, салкын су белән коена. Анысы китмән тоткан. Тәслимәнең кулында тырма, ул әледән-әле шуның белән айканып куя. Элеккеге кодагыйлар болар. Тәслимәнең малае Хисам белән Дәрия кызы Хания әле күптән түгел генә аерылышып йөрделәр. Яңа гына балалары туган иде. Бер яше тулды дигәндә, нәни кыз авырып китә, гел салкын тиеп җәфалана. Тәслимә аны, беркемгә дә әйтмичә, ягылмаган мунчада сыныккан су белән коендыра, шулай итсә, имеш, баланың авырулары юкка чыгачак икән! Кызчык шуннан соң озак тормады, үпкәсе кабарып, хастаханә юлында күзләрен йомды.

Тәслимә, кызымны да үтерә, ахыры, бу тинтәк дип, аны җитәкләп кайтты. Кода-кодагыйлар эт белән мәче кебек яши башлады. Әле аңа кадәр дә – дөрес булса, аларны өч буын туганнар дип сөйлиләр – араларында тавыш чыккалап ала торган була. Имеш, Тәслимә туганының тормышыннан бик көнләшә икән, үзенең ире үпкә чире белән егылгач, җаен туры китереп, Дәриянең Мотыйгына күз салган икән, юк кына сәбәп табып, капка яныннан узып барган ирне ишегалдына чакырып ала; анда алар нишли торгандыр, анысын бер Ходай белә. Тәслимә малае Хисам аңа карап тормады шул, клубтан кайтканын сагалап торып, Ханияне урлады. Иртән Дәрия кызы артыннан йөгереп килеп җитсә дә, соң иде, чүпрә җибәрелеп өлгергән иде инде.

...Яз көне өй юганда, хатын түшәмнең ул төшен әллә нинди кыйммәтле порошоклар белән ышкый-ышкый юа, суына белизна кебек сыекчалар да кушып карый, сурәт түшәм ярыгына гына качып торган кебек, «мәхәббәт бишеге» тирбәлә башлауга, пылт итә дә янә калкып чыга, пылт итә дә тагы күренә. Караватның урынын да күчереп карады. Файдасыз – «теге» алардан калмый. Моңа бик борчыла ул, үзен бик нык битәрли, иң кыены: инде менә ничәмә ничә еллар буе үзен ире алдында уйнашчы хатын кебек тоеп яши. Әнә хәзер Солтанның сурәте генә түгел, үзе дә күпме гомердән соң авылда пәйда булган. Китмәскә кайткан дип сөйли авыл... Бәлки, теге сурәте үз өенә олагыр... Аннан соң ул да бик бәхетле итеп хис итә башлар үзен...

Һәркемнең җанында иң якын дустына да сөйләргә ярамаган яшерен бер сер була... Аны читләргә дә сөйләргә ярамый, җилгә сибәчәкләрен көт тә тор аннан соң...

Тукаш белән Ябалак урманына барабыз дигәч кенә, Ясминәнең күңеленә тынычлык иңгәндәй булды: бер атна элек анда нарат диләнкесе карап кайтканнар иде. Яңа өй җиткерергә йөриләр бит. Үзе дә иреннән калышмады, каенатасы сугыштан әләктереп кайткан немец трофей бинокльне табып алып, печәнлеккә алып менеп куйды. Болай булгач, кирәге чыгуы бар җете күзле нәмәрсәкәйнең... Солтан үзгәрде микән,

картайгандыр, тагын да ябыккандыр, танымаслык булгандыр? Әй болай... ире янәшәсендә яткан чакта күңел күзе белән күрә торган түшәмдәге йөзсурәте гел яшь чактагы шикелле...

«Яшең җитсә кырыкка, эшең китәр шырыкка» дигән әйтем аңа һич тә туры килми! Хатынның эшләре, киресенчә, шырыкка түгел, «мырыкка», тагы да төгәлрәк әйткәндә, сөю-сәгадәт газапларына таба бара түгелме соң?! Җитмәсә, кибеттән кайтканда, каршысына Зөлфәкар очрап, соңгы вакытларда алсулык иңгән йөзенә бер генә күз ташлады һәм әйтеп салды: «Ана мәченеке кебек яна күзләрең, Ясминә матур! Бүген бик бәхетле что ли син?!» – дигән була.

«Бу тилемсә нәрсә дә сизгәч инде?!» дигән шомлы уйга калды хатын. Җанына оялый башлаган шайтани хисләрдән болай да курка иде инде ул. Күптән онытылган, күз уңыннан гына түгел, күңел өметеннән дә югалып торган теге чактагы яшьлек тилерүләре кабат эчен айкарга кереште... Алла язмаганны, татар хатыны була торып?! Чын-чынлап пошаманга калды әле тупырдап торган, йөз-күзеннән наз бөркелеп торган коңгырт күзле, матур калын иренле, озын алтын толымлы уенчак хатын. Көзгегә бакса, сискәнеп китә, хәтта уң як битендәге канәфер төсендәге матур миңе дә чак кына зурайган кебек! Аның үз гомерендә иренә хыянәт иткәне булмады... Ә эчтән генә сөю хыянәткә, азгынлыкка керәме икән соң ул дип баш вата башлады. Серләрен ачып салырлык ахирәте юк, кемгә сөйләсәң дә, урамга сибәрләр шикелле. Ятларга сөйләмә серләреңне, читләргә ачма күңелеңне... Бигрәк тә заманасы шундый хәзер; ул янәшә күршеләрне дә биек коймалар эченә ябып куйды, кәҗә чикләвеге кадәрле генә шатлыгың булып, шуның белән уртаклашсаң да, үз алдыңда куанган кебек кыланырлар да, шул нәни генә бәхетеңнән дә көнләшеп, сиңа яманлык теләрләр кебек; кайгыңны әйтсәң, тыштан көенгән булып, эчтән сөенер якыннарың...

Күңелдән генә чит ир-атны сөю хыянәт саналамы икән соң ул, Ходаем?! Чит тә түгел бит әле ул, Солтан үзе ләбаса! Туксабаның Мирсәет ага малае, башлангычтан бер сыйныфта бергә укыган Солтан!

...Солтан Башкаладан кайтып төште. Үз нигезен теге чакта ук туганына тапшырып киткән иде, шуның күршесеннән иске генә буш йорт сатып алды. Сәрдәр Сарматта яшәп ята. Анысының, үзеннән өлкән булса да, гомер иткән хатыны бар дип сөйлиләр. Онытмаган тагы үзе Солтан, Ясминәгә бүләккә Ырымбур шәле алып кайткан. Шул затлы бүләкне күрсәтеп, Ясминәне аяктан екмакчы иде, әмма тегесенең әллә ни исе китмәгән булды. Баксаң, нәкъ шундый ук бүләкне Солтан сыйныфташы Мәликәгә дә биргән... Аңламассың бу ир-атны...

Бу егетләр элек бергә тәгәрәп үскән Туксаба авылы малайлары иде. Аларны Туксабаның «Әлли» дип аталган урам берләштерде; барысы да бик мут: җиденчедә укыганда ук, ярыша-ярыша, Ханкаладан кунакка кайткан кызларның «мамыкларын» койдылар, бар чибәр аларныкы иде. Хәер, Зөлфәкар тугызынчы сыйныфка кадәр генә алар белән өстерәлеп барды да, мәктәпне капылт кына русча укытуга күчергәч: «Урыс мәктәбендә ыштан туздырып йөргәнче, өйләнәм мин лутчи!» – дип, укуын дәвам итмәде. Тумыштан сәеррәк иде малай. Кечкенә чакта әлеге сәерлек күзгә бик

бәрелеп тормаса да, үсә төшкәч, малайның чүмәләсе кыйшаеп ук китте, һәрчак бик дөрес сүзләр сөйләп йөрсә дә, Зөлфәкарнең башы чуалган диделәр. Шуңа күрә аны үзе теләгәндә генә ияртteләр. Солтан белән күрше иде алар, Зөлфәкар әбисе белән генә тора, Ханкаладагы әнисе Хәрисә боларга кунакка гына кайтып йөри.

Кайчакта Ясминә җанындагы чуар хәлләрне Мәликә белән уртаклашмавына үкенеп тә куя. Бәлки, ахирәте берәр киңәш биргән булыр иде. Ул укый торган берәр мәхәббәт китапларында җавап табып булыр, бәлки? Әле соң түгел бит дип куйды ул үз-үзенә һәм Мәликәнең почта алып килгән чагын туры китерергә булды. Матрас астыннан теге китапны да тартып алды. Моңарчы игътибар ителмәгән булган икән, эт теле чаклы юка гына китап «Татар юрап китерер» дип атала икән...

Мәликә күренми дә күренми. Аптырагач, Ясминә капка төбенә чыгып басты. Үткән-сүткән аның белән бик җылы исәнләшеп китә. Ни дисәң дә, Ясминә – авылның шәфкать туташы. Теше сызласа да, аңа килә халык. Ул, алгарак чыгып, капка-коймага күз ташлады: буялган һәм бик матур иде аларның йорт-җире. Урамда иң матурыдыр әле. Аннан соң хатын янә бер кат үзенең киемен күздән кичерде. Кигәне дә бик килешле. Гел кеше янында син, энәдән-җептән киен ди бит Гафияте. Шуларны янә бер кат искә төшергәчме, әллә Ходайдан вакыты җиткән идеме, шулчак, капка төбендә басып торганда, тиктомалдан, көтмәгәндә, Ясминәнең иләс-миләс күңеле кинәт үз урынына утырмасынмы!

Нәрсә кирәк аңа тагын?! Тормышы бар яктан җитеш, ире әйбәт, гаиләсе тигез. Тагын нәрсә кирәк хатын-кызга?! Акча дип тә аптырамый, чөнки ире әйбәт эшли, баласы алма кебек, Аллага шөкер, сау-сәламәт! Тагын ни җитмәгән?! Күңеле тузгыймы? Юк, хәзер анысы да тынычланды. Хатын шулчакта Солтанны түгел, нәкъ менә үзенең «Газыен» – Гафиятен өзелеп яратуын аңлады. И Ходай хикмәтләре: нишләп газапладың хатынны, күптән мондый хисне салган булсаңчы җанына! Хуш, соң булса да, уң булсын, ди. Бәлки, башта ук шулай булгандыр ул? Ясминә бары аларны, чуалчык хисләрен, сүтә генә алмагандыр?..

Ясминә Мәликәне дә көтеп тормады, өенә керде һәм ире кайтышка ашарга пешерә башлады.

## Мәликә

Ә Мәликә бу вакытта китап җыю белән мәшгуль иде. Ямаш-Тукашы чынлап торып китап кадәр китап яза башлагач, моңарчы үзе укып чыккан мәхәббәт китапларын җыйды да китапханәгә илтеп бирергә ниятләде. Ире язачак китапны укыйсы килә иде хатынның. Болары башны бутап ятмасын дигәндер инде.

Балачактан китап укырга ярата иде кыз. Ханкалада яшәгән туганыннан калды бу гадәте. Ул кунакка кайтканда, күчтәнәчләр белән бергә сумкасына берәр кызыклы китап та салып кайта. Кайткан шәпкә, болында чәчәкләр җыя. Рәхәтләнеп су коена, көтү кайтканда, бик кызыксынып, урамны күзәтә, Мәликәдән урамда тәрәзә аша күзенә чалынган күрше-күлән егетләре турында сораштыра, һәркайсы турында бик җентекләп кызыксына, әнисе

мич ашы пешергәндә, аның янында кайнаша, бик озаклап мунча керә дә аннан соң, кайда икәнлеген дә онытып, алып кайткан шул китабына каплана иде. Ул юкта Мәликә дә алып карый китапны, укый, һәм китап кызны үз эченә алып кереп китә. Киткәндә, кунак әлеге мәхәббәт китабын авылда калдыра. Әле тагын ошбу китапның авторын белә икән, бер очрашуда аннан автограф алганлыгы турында да тәмләп сөйли, авыл кызын кызыктыра иде. Мәликә кызыклы китапка гына түгел, аның язучысына да гашыйк була һәм хисләр белән исереп йөри. Китап укылып беткәч, күңел башкасын тели. Кыз клубтагы китапханәгә бара, тышы күңеленә ошаган берничәсен алып та кайта. Зөләйха апасыннан авторы хакында кызыксына. Китап ошаса, шул хисләр белән атналар буе исереп йөри торган иде. Китап укырга яратуы шуннан калган.

Китапларда аларда башка тормыш, авыл кызының гади һәм гадәти хәятенә охшамаган ят, кызыклы тормыш. Китап геройлары язмышы белән яшәп алуның ләззәте озакка сузыла. Кояш тагын да югарырак, Ислемай тавы тагын да биегрәк, Күлтәк күле тагын да тирәнрәк булып тоела. Китапның кызга тәэсире гаҗәп көчле иде. Әсәрләндерә, мәхәббәт хәлләре бер елата, бер юата, бөтереп, үз эченә алып кереп китә. Шундагы тормышка башың белән кереп чумасың, аннан чыгасың, аерыласың килми. Кунак апасы, шулай бер кайтканында, язучының култамгасы булганын алып кайтты. Язучыны яхшы белүе, аның үзенә матур комплимент әйтүе турында тәмләп сөйләде. Апасыннан көнләшеп үлә язган иде шулчакта Мәликә! Менә нинди сөенеч! Менә нинди бәхет! Ул китапны кыз кат-кат укыды. Тышлыгы мунчалага әйләнгәнче, кулыннан төшермәде.

Тукашның каләм алуына иң сөенгән кеше Мәликә булды...

Ишек төбендә алар Путанайдан Абрар дигән кеше белән очраштылар. Тегесе, Мәликәнең бер олау китап-кәгазьләрен күреп, бик кызыксынды. Һәрберсен кулына алып карап, тикшереп чыкты. Үзенә кирәклесен таба алмагач, күңелсезләнеп кул селтәде.

...Шушы урында Каләм язмага нокта куеп торды.

Йөрәк «хәлләре» турында да язасы бар бит әле. Мирсәет белән Сәрбиназ мәхәббәте турында...

## Сәрбиназ

### Өченче хикәят

Сәрбиназ язмышы Туксаба авылының тагын бер сере иде.

Мирсәет агайның шулай дип әйтүе дә аңлашыла, чөнки ул Котбыйлар нәселенә төшкән каргыш кебек имеш-мимешләргә ышанмаучы бердәнбер кеше бугай Туксабада. Хатыны Мәдинә әйткәнчә, ягъни монысы Мирсәетнең «ата коммунист» булуыннан килми.

Хәтта Тукаш та Мирсәет абыйсыннан ул тарихны сөйләтә алмады. «Үзем дә очын-очка җыя алмыйм әле», – диде тегесе, көрсенеп. Үзе исә, ничә еллар буе аңына сеңгән гадәте буенча, яшь чакларның үкенечле хатирәләрен хәтер киштәсенә ипләп тезә дә, соңгы хатирәне урнаштырам дигәндә генә, барысы капылт ишелә, чуала һәм ул бу гамәленә тагын кул селти; ул хакта уйлый алмый, хәтта исенә төшерәсе килми.

Нәрсәсен сөйләсен? Ни дип сөйләсен?! Үкенәм дисенме? Юк, бүгенге тормышы, Мәдинәсе белән тормыш-хәяте тамчы да үкенерлек түгел. Ә Сәрбиназ?! Сәрбиназ ул – йөрәктәге мәңгелек җәрәхәт... Һәр яңа таныш хатын-кыздан, һәр буй җиткән кыз-кыркыннан Сәрбиназ сурәтен эзләп яши Мирсәет. Бу гамәле зина кылуга яки хыянәткә керми. Сәрбиназ хыялда, ул якты образ сыйфатында. Тормышта шулай да булуы мөмкин ләбаса. Яшь чакта берәр кызга күзең төшә дә, аның белән аралашып китә алмыйсың, ләкин ул барыбер күңелеңдә кала, матур хатирә булып яши башлый. Бу җанның хикмәтләрен аңлап бетерерлекмени?..

Ул Сәрвәрне күрүгә: «Булачак килен кемгәдер охшаган! Тик кемгә?» – дип әйтеп куйгач, бу сүзләрен ишеткән хатыны Мәдинә төрттереп:

– Кемгә булсын, шул Сәрбиназыңадыр инде! – дигән иде, үпкәләп.

Әйтте бит ул аның үзенә дә, күзләренә туры карап әйтте танышканнан соң: «Син минем беренче мәхәббәткә охшагансың!» – диде. Мәдинәнең бик ачуы килгән иде бу сүзләргә. Дөресрәге, көнләште бугай...

Әйе шул, Мәдинәне Сәрбиназдан соң очратты Мирсәет. Ул чакта, Сарытауда партия югары мәктәбен тәмамлап кайтып, Ханкала шәһәрендә партиянең Төбәкара Комитетында эшли иде. Буфетта үзенә таныш кебек тоелган кызны күргәч, әүвәл имәнеп китте егет һәм: «Сәрбиназ!» – дип кычкыра язды. Телен тешләде, монда, обойларына кадәр дәһшәт сеңгән партия комитеты бинасында, хисләнергә ярамый, бу андый урын түгел. Тик ул барыбер урыныннан кубарылып китә алмады, буфетчы кызга карап торуын дәвам итте. Менә тегесе борылды, хәзер Мирсәет кызның йөзен дә күрә! «Сәрбиназ бит!» дигән уй тагын телгәләп узды баш миен! Махсус урнашканмы кыз Төбәкара Комитет буфетына?! Белә бит Мирсәетнең бу бинада эшләгәнен. Әлеге уйлары бераз аңына китерде егетне. Ул туп-туры «Сәрбиназ»га таба атлап китте. Кыз егетнең үзенә текәлеп карап торуын күргәч, уңайсызланып, карашын читкә борды. Шунда гына аңлады Мирсәет: бу Сәрбиназ түгел, әмма аңа ике тамчы су кебек охшаган икенче бер кыз затыннан иде. Исеме дә Мәдинә иде бу кызның...

Шулай да алай ансат кына булмагандыр инде. Хәтерли бит, Сәрбиназ гүзәлнең якты сурәте һаман тынгылык бирми аңа. Хәтта килене Сәрвәр карашында да тоя ул аны. Миргалие шул кызга өйләнәм дигәч, беренче булып ул куанды. Мәхәббәт – дөньядагы иң бөек сер! Менә ничекләр итеп яшәтә бит ул адәм баласын – төс-кыяфәте Сәрбиназны хәтерләткән килен бирә!..

Сәрвәр Сәрбиназның яшь чагы иде. Коеп куйган диярсең. Мәдинәсе исә аны үзенә охшаган ди, Миргалие кыз әнисенә охшаганга гашыйк булгандыр. Ир-ат үз мәхәббәтен әнисе яки апалары сурәте буенча эзли диләр...

Теге чакта Сәрбиназны әтисе Хәйдәр ага Хәлүш урманына илтеп яшергәч, икенче көнне үк Мирсәет кыз катына барырга тиеш иде. Милиционер Салихҗанның булачак киленен эзләвен дә ишетте. Әмма егетне ул гына тыеп торырлык түгел иде. Тик таң белән аны Ханкалага чакыртып алдылар, Мирсәет шуннан кайткач барырга уйлады Сәрбиназы янына. Партия мәктәбенә җибәреләчәк рәсми кәгазьләргә кул куясы бар икән, шул уңайдан бер инструктор белән күрешәсе дә була. Анысы тагын чираттагы сынау – әңгәмә үткәрәчәк, ди. Егетне тагын бер кат иләктән

үткәрүләре иде бу. Инструктор Абтюков дигән кеше Хәйдәровның килүен көтеп торган икән, ишекне ачуга, каршысына йөгереп диярлек килде. Йомшак тавыш белән медер-медер сөйләшә тагын үзе, егетне каршысына утыртты. Партия җитәкчеләре, гадәттә, корыч тавышлы була торган иде. Күрәсең, монысы – йомшак җәеп, катыга утырта торганнардан. Кыскасы, Абтюков фамилияле инструктор Мирсәеткә бик ягымлы булып тоелды.

Абтюков әүвәл гаилә хәлләре, киләчәккә планнары хакында сораштырды һәм әйтеп куйды:

– Синең алда, Хәйдәров, зур перспективалар ачылачак. Киләчәктә син министр була алырлык кеше! Тик барысы да үзеңнән тора! – диде ул һәм өстәл өстеннән бер кәгазь алып, аңа сузды. – Бүген үк Сарытауга чыгып китәсең. Анда иртәгә собеседование башлана. Барырга теләүчеләр күп. Мин сине сайлап алдым. Бабаң Хәйдәров Хәлим заманында колхоз рәисе булган, аннан партком секретаре! Синең кандидатура туры килә.

Мирсәет бу тәкъдимнән имәнеп китте: ничек бүген үк?! Ә Сәрбиназ?! Сәрбиназны яшерәсе, сөйгән кызын урнаштырасы бар бит әле аның!.. Башкала астындагы Казыйм ягында әтисенең дуслары бар. Ул анда ел саен авылдашларын – балта осталарын эшкә оештырып җибәрә, түрәләргә икешәр катлы йортлар салалар. Мирсәет Сәрбиназны шунда урнаштырырга тиеш иде. Аннан күз күрер, Башкаладгы «ВПШ»га да кучерәбез дигәннәр иде. Якын булалар бит кыз белән. Өйләнешерләр, Алла боерса!..

Әллә Алла боерып җиткермәгән, әллә язмыш катырак булып чыкты (Мирсәет моны бүгенге көнгә чаклы язмышына сылтап килә, әйтерсең аның үзенең тамчы да гаебе юк!): бүген үк юлга чыгып китәргә куша Абтюков...

Нишләргә?!

Министр буласы кеше син, Хәйдәров!

Бармый чара юк дигән карарга килде Мирсәет, бик озак уйлагач. Йөрәгенә шулчак ут капты, дөресрәге, теге чакта кабынган уты дөрләргә кереште. Ул әле дә сүнми... Ул яндыра, көйдерә. Тик аны түгел, партия комитетында эшләп, каешланган партия солдатын да түгел! Партия идеаллары белән үзеңнең өч тиенлек шәхси тормышыңны бутарга ярамый, партиягә синдәй егетләр кирәк!

Саубуллашканда Абтюков:

– То ли стать мне президентом США,
То ли взять, да и окончить ВПШа!..

– дип, ул чакта мәгълүм бер җырның сүзләрен көйләп күрсәтте. Монысы үзара гына. Абтюков аны якын итә. Шуңа күрә дә ихлас киңәшләрен бирә торгандыр инструктор...

Министр булырга кызыкмый ул. Әмма партия таләбенә дә каршы килә алмый. Җанында бит аның партия идеаллары. Чын коммунист ул. Партия кушса, хәтта җаныңны да корбан итәрсең, иптәш Хәйдәров. Аларны шулай дип тәрбияләделәр.

Нишләргә?!!

Һәй, Абтюковның чын ниятләрен белгән булса шул чакта! Хәер, каян белсен, Абтюков фамилияле бу инструкторның төп чыгышы аларның Туксаба ягы белән бәйле икәнлеген дә күпләр белми. Чынлыкта, Абтюков

Әптүк атлы мулланың оныгы булып, дин юлыннан кереп китәсе кеше иде. Дин кысылгач, син барыбер күз өстендәге каш кебек кеше булырга тиеш дигән ният белән партия баскычлары буенча үрмәли башлады...

«Нишләргә?!.» – диде Мирсәет үзалдына, әлеге хәленә борчылып.

Нәкъ шундый сорау ул чакта Сәрбиназ атлы гүзәлне дә борчый иде. Борчый гына түгел, утларга сала, суларда агызырга җыена!..

Ә ул гүзәл кыз түземле иде, ул үз-үзенә тагын бер кат: «Сабыр бул!» – диде. Менә Мирсәете килеп җитәр дә, алар гомергә бергә булырлар! Шул рәвешле авыл «Шурулла»сыннан качып киткән кыз урман «шүрәлеләре» янында, Мирсәетне көтә-көтә, тагын берничә көн яшәргә мәҗбүр булды.

Ләкин Хәлүш тә, Абрар да ашыктыра, аны эзләп табулары бар иде. Абрар, Башкалага нарат бүрәнәләре илтергә тиешле зур машиналарның берсенә утырып, Сәрбиназ белән шул якларга китәргә тиеш. Егет кызны озата бара.

– Мин моннан, бу урманнан беркая да китмәс идем, – диде кыз, яшьле күзләрен бу юлы егеткә төбәп. Әйтерсең шулчак аның ихлас күз карашы Абрарның йөрәгенә үтеп керде дә үзенчә аңа ялвара иде. «Сакла, якла, кыерсыттырма!» Ләкин Абрар җавап итеп кызга бер сүз әйтә алмый. Ул аптырап калган. Әллә аның йөрәк турысын әлеге ихлас караш чеметтереп үк алдымы? Йөрәге тасырдый башлады. Кызгандымы ул аны бу мизгелдә? Яклыйсы, саклыйсы килү теләге уяндымы? Бәлки, бу гади инстинкт кынадыр?.. Ир җенесеннән булган затның Илаһының көчсез затын үз канаты астына алырга әзер булган бер гади теләк кенәдер?.. Ни булса да, Абрар шул мизгелдә үзен бик көчле итеп тойды. Ул аюга каршы тора ала, ул бүреләр өереннән дә курыкмый!..

Сәрбиназ капылт исенә килде һәм, оялып, карашын яшерде. Аннан соң җәһәт кенә торды да Җиңгәй аш-су белән кайнашкан бүлмәгә чыгып китте.

Бу вакытта Хәйдәр абзый атның дилбегәсен кулына алган һәм ул Хәлүшкә соңгы гозерен әйтеп маташа иде.

– Хәлүш, бүген кичен малай монда килеп, Сәрбиназны алып китәр. Зинһар, аңа кадәр кеше күзенә-мазар чалынмасын инде.

Тегесе:

– Абрарны сакка куям. Аның монда икәнен бер җан иясе дә белмәс! – дип, белешен юата. Тагын өстәп әйтә, дөресрәге, сорап калырга ашыга бугай: – Башкала ягына кузгалганчы кая качырмакчы була соң аны Мирсәетең?

Хәйдәр абзый, белмим әле дигәндәй, иңбашын сикертеп ала.

– Мин хәзер өйгә кайтмыйм әле. Хуҗалар авылына сугылам. Анда чыбык очы туганнар бар безнең. Тиз генә никах укытып алабыз да...

Күренеп тора, ул әле катгый карарга килмәгән. Ничек никах укытсын инде ул коммунист малаена? Аннан соң Мирсәеткә башлы-күзле булырга да иртә, кеше буласы бар. Менә тиздән аны – Путанайдан Гаврилов дигән егет белән икесен – Партия мәктәбенә укырга җибәрергә тиешләр. Юлламасы әзер ди инде. Димәк, әлегә өйләнә алмый Мирсәет. Хәлүшнең кайда да үз кешеләре бар, чөнки йөзьяшәр наратлар аның урманында гына, дөнья читләреннән киләләр аның катына коттеджлар салучы байбәтчәләр. Күбесе Башкаладан ук. Яңа байлар катлы-катлы йорт-сарайлар салу өчен такта кебек төзелеш материалларын гына түгел, кадакны да читтән вагонлап китертә; әмма мондагы шикелле наратлар чит илдәге буржуйларның

төшләренә дә керми. Сәрбиназ атлы мескинә кызны Касыймдагы Френк атлы немец белеше, үземә сыендырам дип телефоннан вәгъдә бирде.

Җигүле ат чаптырып китеп бара. Байтак вакыт арба тәгәрмәчләре астында коры ботакларның шартлап сынган тавышлары гына ишетелеп тора. Урманчының ихатасында Хәлүш карт, Җиңгәй, асрамага алган улы Абрар һәм Сәрбиназ атлы кыз гына калалар.

Кичен килергә тиешле Мирсәет ул көнне түгел, иртәгесен дә күренми. Аның каравы милиция Салихҗан бу тирәдән табыш эзләгән козгын кебек ике мәртәбә әйләнә. Сәрбиназны Абрар Тәбәнәк тау урманындагы җәйге ызбага алып китә. Алар шунда качып яталар. Икенче килүендә урманда кунып кала участок милиционеры. Салихҗан эчүгә бик хирыс кеше, мари ягына килгәч, көмешкәгә чума торган гадәте була. Бу юлы да Хәлүш аны «төнлә туган» белән сыйлый. Таң белән, атасын эзләп, ат өстендә Хәмит килеп җитә. Салихҗан дөм исерек, өйдә Хәлүш үзе, хатыны. Ә Абрарлары кайда соң? Ник күренми Хәлүшнең асрамага алган малае? Хәмит Абрарны таптыра. Аны ауга китте диләр. Ләкин киткән кеше бер кайта бит ул. Алайса, кайтканын көтәм ди Хәмит. Үзсүзле Шуруллага сиздермичә генә Абрарга хәбәр җибәрәләр: «Кайт тизрәк!» Абрар Сәрбиназ янында дусты Макайны калдырырга була. Балачактан бергә уйнап үсәләр, ышанычлы кеше Макай.

Макай аңарчы да болар янына килеп киткән була. Туксаба кибетеннән ашарларына алып кайта. Абрарның тәкъдименә куанып риза була, чөнки Сәрбиназ атлы бу кыз аларның урманында иң озын нарат башына кунган якты йолдыз кебек. Туксабага барган чакта кызны күргәне була аның. Кыз да аны белә. Тик нигә бар йолдызлар да Абрарга гына булырга тиеш ди, әле?! Сәрбиназ аның, Макайның, йолдызы булырга тиеш. Туксаба малайлары Шурулла белән Мирсәет шундый йолдызны кулларыннан ычкындырганнар икән, димәк, ул аларга насыйп булмаган. Абрар да кызны калдырып китә. Макай гына кала аның янында. Димәк, Сәрбиназ – Макай йолдызы! Мирсәет белән Шурулла – кирәмәтләр!

Күптән түгел атасы Кугуй янына Кызыл-кала рухание Макарий килеп китте. Поп чиркәү салырга ниятләп йөри. Буй җиткергән Макайны күргәч: «Өйләндерергә вакыт икән оланны! – дигән. – Күз уңында тоткан бер кыз бар!» – дигән. Тәре таккан кызың үзеңә булсын дип уйлады Макай, поп киткәч. Ләкин үзе дә Макарий аскан тәрене салып ташламады, бу сиңа матур кыз теләп торачак диде бит. Аны күлмәк өстенә чыгарды. Ә тәненә тиеп торган, поши мөгезеннән ясалган Шочы Ава бөтиен үбеп куйды. Тудыручы Ана билгесе ул. Нәкъ Сәрбиназ кебек. Монысы – бабасы бүләге. Әлеге бөтине үзе ясаган. «Сиңа матур кыз теләячәк ул, салма бу амулетны, улым», – дия торган иде Бәлүк баба. Кара урманда матур кыз һәрчак кирәк. Җылытып тору өчен кирәк.

Макай матур кызларны ярата. Сәрбиназ – матур кыз. Рәхмәт сиңа, Шочы Ава!

«Салам лийже, Макай!» (Сәлам, Макай!) Яңадан тууың белән!

«Сәрбиназ – мотор удыр!» (Сәрбиназ – матур кыз!)

Бар матур да Абрарга булмасын әле. Килмешәк Абрарга...

Макай Сәрбиназны үз урман хуҗалыклары «Кужла»га алып китү өчен сәбәп эзли, һәм ул табыла да: «Шурулла килергә мөмкин икән монда! Тиз

генә качарга, арырак китәргә кирәк!» Алар урман арасыннан kача-поса атасы Кугуй урманына таба кузгалалар. Юлда яңгырга эләгәләр. Макай кызны үз йортларыннан ары урнашкан умарта бакчасына алып китә. Умарта өендә бу вакытта эт тә юк. Хәер, сакчы эт бар. Алабай токымлы бозау кадәрле эт ят кызга өрә башлый. Тавышы тавыш кына булса, ярар икән алабайның, бар урманны яңгырата. Макай кызны умарта читендә урнашкан мунчага яшерә. Монда иркен. Агач үзләрендә булгач, Туксаба осталары мунчаны ындыр табагы чаклы итеп ясаганнар. Кызыл-кала түрәләре монда куна-төнә ята. Яшь бичәләр белән киләләр дә... Әтисе кушуы буенча Макай аларга һәйбәтләп мунча яга торган иде. Мунчага терәп үк салынган ял итү бүлмәсе дә бар. Анда караватлар, өстәл, бильярд тора. Кечкенә генә бассейны да бар. Берзаман шулай җитәкчеләр белән ияреп килгән яшь кыз, үзен монда нигә алып килгәннәрен тәмам аңышып җиткәч, ягылган мунчадан шәп-шәрә килеш качмакчы була. Оят җирләре әрекмән яфрагы белән генә капланган кызны күргәч, Макай әүвәл өнсез кала. Бу вакытта ул «тылсым җирләре»нең кая һәм ничек булганын белә иде инде. Кыз, аны күрүгә, әүвәл кычкырып җибәрә. Аннан соң аңына килә, бу яшүсмер – аның бердәнбер коткаручысы! Бу – зур корсаклы түрә түгел!.. Җитмәсә, егетнең муенына да нәкъ аныкы кебек бөти асылган, ул – Шочы Ава тамгасы.

Макай кызга күлмәген салып бирә дә аны Абрар белән икесе ясаган яшерен шалашка алып китә. Аларны моннан эт таба алачак түгел. Дөрестән дә, түрә агайларның ярдәмче бурзайлары кызны эзли чыга, әмма таба алмыйлар.

Алар таңга кадәр Ольга атлы бу кыз белән шул яшерен шалашта качып яталар. Макай аңа Җиңгәйнең киемнәрен алып килеп бирә. Ольга, аерылышканда, рәхмәт йөзеннән Макайга «мәхәббәт» бүләк итә...

Ләкин Ольга нигәдер нарат очында йолдыз булып кабына алмады. Югыйсә, Ольга аңа гашыйк ук булган иде. Нәфис бармаклары белән Макайның маңгай өстендәге бөдрәләрен сыйпап: «Макай, син шундый әйбәт егет!» – дип, кайнар сулышы белән колак яфракларын яндырды, кочагына сеңеп иркәләде. Урта буйлы, коңгырт чәчле, коңгырт күзле урман егете бик ошаган иде кызга. Иреннәренең кайнарлыгы шактый озак сакланса да, беркавымнан онытты аны яшүсмер.

Урмандагы иң биек нарат башындагы йолдызны Сәрбиназ кабызды!..

Әлеге йолдыз, үз чиратында, моңарчы бер-берсеннән башка тора алмаган ике ятим яшүсмер, ике дус арасында гомерлек дошманлык дөрләтте...

### Бүре малае...

Бәхетле чучканың борын очында гел ризык булыр, ди. Абрар үзен бәхетле «чучкага» саный. Мал бәхет китерер дигәне дә бар әле. Ул мал таба белә торган ир-ат иде. Бердән, кулы һөнәр белсә, икенчедән, каны гади кан гына түгелдер? Татармы ул, урыс-улакмы, әллә җәбрәй кавеменнәнме? Фамилиясе мариныкы диләр. Бәлки, ул шуларның барысының да кушылма-катнашмасыдыр!

Кара урман уртасында урманчы Хәлүш гаиләсендә үсте ул. Хәлүшнең ихатасы – урман эченнән ага торган Илләт суы буенда. Товар поезды машинисты Хәлүш арттагы вагоннан табып алган. Бик кычкырып елаган

ул. Аны машинист ишетеп алган. Күрше вагонда дуңгызлар төялгән булган, әүвәл чучка баласы тавышы дип уйлаган машинист. Бик ачыкса, дуңгыз балалары да кеше тавышлары чыгарып елый-кычкыра икән. Бәхеткә, бик кызыксынучан кеше булган инде машинист агай, иренмәгән, башта чучкалар төялгән вагонны ачып караган, анда ул-бу ишетелмәгәч, икенче вагонга киткән. Өстәвенә ул чакта яшь балаларны чит илгә сату буенча кәсеп чәчәк аткан була. Урман уртасындагы хатын-кызлар өтерманендәге хатыннарның балаларын тартып алып, чит илгә «уллыкка» бирәләр, кайберләрен әгъза-органнары өчен саталар!.. Милиция бу җинаятьнең эзенә төшкәч тә, керемле кәсеп тукталмый, товар поездлары өтермән яныннан узганда – ул станция янында ук була – балаларны, чүпрәк-чапракка, иске шәлләргә төреп, вагоннарга ташлыйлар, икенче тукталышта махсус кешеләр күтәреп тора һәм шулар «тауар»ны алдан килешенгән төбәкләргә озаталар. Шул рәвешле бу кабахәтләр зур акчалар эшли!.. Хәлүш тә шакмаклы калын шәлгә төрелгән яшь баланы вагоннан табып алган. Бишмәте кесәсеннән бер кәгазь кисәге генә килеп чыккан. Ул кәгазьдә бер такмак та булган әле: «Татар әйтә «бисмилла» ди, Урысныкы – «памилуй». Ошбу такмакка әллә ни игътибар да итмәделәр, баласын ташларга җөрьәт иткән мәлгунь хатын, күрәсең, гөнаһын ярлыкасын өчен шул рәвешле Ходайдан ярдәм сорагандыр?

Бар кеше дә алай дип уйламады, әлбәттә. Арада, ни өчен язганнар бу сәер такмакны диючеләр дә булды. Андыйлар сирәк иде, чөнки кәгазьне кулга алучылар арасында татарча белгән бөтенләй юк та иде. Әүвәл нинди телдә язылган икән бу дип әйләндерә-әйләндерә карадылар. Ят тел бит инде. Күптән дөньялыктан югалган сәер тел. Мондый телдә хәзер үзен хөрмәт иткән кеше сөйләшми дә. Халкы динозаврлар кебек күптән юкка чыккандыр. Бәлки, бу кәгазьне музейга куярга кирәктер диючеләр дә булды.

Ләкин кара урманда әлеге тел бер кешедә сакланып калган иде. Хәлүш атлы кеше иде ул. Исеме дә төркичә, «Хәйрулла» тамырыннан килеп чыккан булырга тиеш.

Борынгы бабасыннан бирле шулай килә: алар нәселендә татар телен яхшы беләләр. Буыннан-буынга күчкән әлеге тел. Кара урман уртасында патша хәзрәтләре төрмәсе, аннан соң йөзләрчә солдатларны ачтан үтергән хәрби уен лагере, шуның артыннан ук коммунистларның ГУЛАГы оешкач, ачтан интеккән халык күршедәге Туксаба дигән татар авылында үзенә икмәк таба алган – исән калганнар. Шул хөрмәткә алар бу телне дә гаилә истәлеге итеп хөрмәт йөзеннән буыннан-буынга саклыйлар икән.

Күп тел белү зур бәхет дигән уйда торган Хәлүш баланы ятимнәр йортына илтеп тапшырган чакта әлеге язуны күрсәтмәде. Малайга «Абрар» кушыгыз дигән гозерен әйтте дә кәгазьне үзендә яшереп калдырды...

Бик күп гомерләр узгач кына, әлеге саргаеп беткән кәгазь Чуракан атлы кешегә – Мордовиянең Сары Кояш төбәге татары кулына килеп эләкте. Монысы үзенә бер тарих иде.

Студент кына иде әле Чуракан ул чакта. Ханкаладагы пединститутка Мордовиядән юллама белән килде. Укыган чакта ук Туксаба кызы Зөләйха белән танышты. Кыз тарих-филология факультетында укый иде. Берчакны шулай Яңа ел алдыннан буран бик котырды, юллар өзелде,

Чуракан каникулга туган ягына кайта алмый калды. Зөләйха тулай торакта ялгызы торып калган танышын үзләренә чакырды. Авылында сүз әйтүче булмаячак, Зөләйханың тәртипле кыз икәнлеге билгеле, ә сабакташны кунак итүгә әнисе каршы килмәячәк; уйласын шунда күршеләр, Зөләйха егетен ияртеп кайткан дип гайбәт сатсыннар. Менә нәкъ шул чакта Чуракан өчен дөньяның асты-өскә килгән кебек булды! Кызның туган авылында да аның ерак Мордовиясе ягындагы диалектта сөйләшәләр иде! Ханкала шәһәре артындагы Туксаба кайда да, аның туган шәһәрчеге Сары Кояш кайда! Аралары гына да мең чакрым бит! Сарматы тагын... Анда да, шуннан әллә ни ерак булмаган Касыймда да берүк диалекттагы татарлар булып чыкты! Туксабаныкыларны «татар» дип атыйлар, аның туган ягындагы төрки-татар «мишәрләр» булып тамгаланган!..

Ай-һай, Үзәк сәясәте төрки-татар-кыпчак-мишәрнең (бер үк халык ләбаса!) тарихын мәче үз тизәген яшергән кебек бик тирәнгә күмгән икән! Туксабага кайткач, үз якларындагы сөйләшне, аерым сүзләрнең берүк әйтелешен ишеткәч, башта ул үзеннән көлә торганнардыр дип уйлады. Имеш, алдан ук белеп алганнар да шул рәвешле үчеклиләр! Бер күрше хатыны Зөләйха үзе белән таныштыргач, әнә, арттан нәрсә дип кала:

– Кийәү буласыңгарга джегерме дә тулмаган икән әле. (Булачак кияүгә йегерме дә тулмаган икән әле.)

Кыскасы, нәкъ алар ягындагы сөйләш инде! «Җ»ләштерү: җегетләр – егетләр, җуалар – юалар; арткы рәт сузыгы урынына алгы рәт сузыгы килү: әчлек – ачлык, вахыт – вакыт; н-ң тәңгәллеге: куя иден – куя идең, ин – иң; т-ш тәңгәллеге: тушындый – шушындый, тушылай – шушылай; ике сузык арасындагы «ң» авазы янына «г» өстәлү: күңгелле – күңелле, анга – аңа. Сүз азагындагы «н» авазы кире ассимиляциягә дучар була: җыйыллар – җыеннар, килгәлләр – килгәннәр кебек бик күп мисалларны күрде егет. Пысак, өспысмак, җылан, җерәк, җаратам шикелле сүзләр дә – бу якларның үзенчәлекле сөйләше.

Шуннан бирле аңа кадәр химия фәнен генә үз иткән Чуракан Зөләйхага тагын да якынлашты, шуннан бирле тарих һәм тел белән дә кызыксына башлады.

Бер-берсенә болай тиз ияләшеп киткәч, тора-бара арада мәхәббәт уты да кабыныр дип ялгышты бугай Чуракан. Үзара хөрмәтләре бик зур иде, читләр аларны бер-берсен үлеп яраткан бәхетле пар дип уйлый торгандыр. Ләкин, нихәл итәсең, йөрәк утлары бергә кушыла алмагач, һәркайсы үз «бәхете» белән яшәде. Икесе дә, бәби тугач, дөньялар үзгәрер, сабый йөрәкләрне дә үз урынына утыртыр дип эчтән генә хыялландылар...

...Табылдык Абрар ай үсәсен көн үсте. Ятимнәр йортында булса да, әллә ни кимсенү сизмәде малай. Җитмәсә, биш яше тулганнан соң аның «туганы» да табылды: Хәлүш атлы мари урманчысы килеп йөри башлады малай янына. Хәлүш, машинист һөнәрен ташлап, урманчы булып урнашкан, әлегә үз йорт-җире юк.

Абрарга ун яшь туласы җәйдә (Хәлүш агасы туган көненә кадәр бүләк булып чыкты!) ул малайны ятимнәр йортыннан үзенә кире алды. Калын урман уртасында үз йорты белән яши башлаган иде Хәлүш; өстәвенә гомер

буе рельслар өстендә буйдак килеш каңгырып йөргән агай Абрарны уллыкка алыр алдыннан «Кужла» урман хуҗалыгы директоры Кугуйның сеңлесе Улинәгә өйләнеп тә куйган икән. Татарлар аңа «Җиңгәй» дип якын иткәнгә әйтәләр иде. Яңа урманчыга бик ярдәм итте Кугуй. Шул рәвешле Абрар куян, төлке, тиеннәр арасында – кара урман уртасында яши башлады.

Беркавым үсә төшкәч, Хәлүш малайны үзе белән ияртте; урман хуҗалыгы урнашкан бистәгә барсалар да, Илләт елгасына балыкка төшсәләр дә, бигрәк тә ауга чыккан чакларында алар гел бергә булды. Табылдык малайның тормышы түгәрәк иде, кагу-сугуны, кимсетелүне белмәде ул. Урман хуҗалыгы бистәсенә мәктәпкә йөртте аны агасы.

Урман шавы малайның күңел көе белән бергә кушылды; иң якын дуслары тиен малайлары, төлке балалары булды. Берзаман ул алар «телендә» сөйләшергә дә өйрәнеп җитте. Зиһенле иде малай, башы йомры иде аның. Ул моны чагыштырып карап та белә.

Илләт урманчысы Кугуйның да Абрар яшендәге Макай атлы малае бар.

Аңа кадәр Абрар тормышындагы зур вакыйга табылдык бүре баласы белән дуслашу булды. Бүрене бүреккә салсаң да, урманга карар диләр. Бу хактыр. Әмма урман уртасында яшәгәнлектән, аның дус бүресе кай тарафка караса да, шунда урман иде. Ул яшь дустын ташлап китмәде.

Эш болай булды. Көннәрдән бер көнне Хәлүш баздагы кәстрүлдә сакланган тозлы итнең бик тиз кимүенә игътибар итте. Хатыны да моңа аптырый булып чыкты, бары иренә әйтмәгән генә икән. Абрарга ул чакта ун яшь тулып киткән инде. Укудан кайтуга, урманга чыгып китә, ерак бармый, берәр маҗарага тарып, үзе кайтып керә, аннан соң күргәннәрен бик тәмләп сөйли. Өйдән ерак китмәсен белгәнгә, Хәлүш башта борчылмады, өстәвенә малай урманда ерткыч җәнлекләр булуы хакында кисәтелгән, җитмәсә, ауга барган чакларда урман тормышын үзе дә күрә иде. Күп вакыт Макайны да үзе белән ияртә, бергә булгач, күңеле тыныч Хәлүшнең.

Кәстрүлдәге ит кими дә кими генә бит. Хәлүш малайдан шикләнә башлады. Бер көнне аның артыннан күзәтергә уйлады. Абрар, мәктәптән кайтып, киемнәрен алыштыра, ашый-эчә дә, базга төшеп, берәр кисәк ит эләктерә һәм урманга кереп югала икән! Хәлүш артыннан барды. Баксаң, ул бер куелыкта бүре өненә юлыккан! Оя янына килә дә теге ит кисәген кар өстенә куеп, үзе читтән күзәтеп тора. Берзаман оядан бүре баласы чыга һәм, мырлый-мырлый, бик тәмләп әлеге калҗаны өзгәләргә керешә. Малай шул рәвешле көн дә бүре баласын сыйлый!

Хәлүшнең коты алынды, чөнки ана бүренең кайтып керүе бар бит! Баласы янында кеше күрсә, шунда ук өзгәләп атачак лабаса!

Абрарга бик ныклап аңлаттылар, куркыныч икәнлеген төшендерделәр. Ялгызы урманга чыгуны тыйдылар.

Бер көнне Абрар тагын югалды. Гадәттә, Хәлүш кыш көне янәшәдәге Илләт елгасында берничә бәке ясый да ике малай шунда балык тота иде. Әүвәл балыктадыр дип уйлады. Кабаланып, Кугуйларга чапты. Тик Макай өендә иде.

Ул бәкегә китте. Тегесе анда да юк иде. Янәшәдәге бар сукмакларны йөреп чыкты, малай табылмады. Ул көнне аңа урман хуҗалыгы директорының урынбасары, Туксаба кешесе, урманчы Якуб килгән иде. Аның белән бергә

эзләделәр. Аеруча Якуб тырышты. Аның беренче хатыннан туган кызы Ханкала якларына китеп югалган иде...

Абрарны эңгер-меңгер эленгәндә генә табып алдылар. Адашкан булган. Кар ерып йөреп-йөреп тә өйгә юлны таба алмаган. Алҗыган, кар өстенә ятып йоклаган.

Хәлүш белән Якуб урман аланында карда күренгән зур карамчыкка тап булдылар. Алар якынлашыр алдыннан, әлеге карамчык ике булды да, берсе урманга кереп югалды, икенчесе шунда ятып калды. Якынрак килсәләр, шаклар катты икесе дә: Абрар йоклап ята. Янында бүре эзләре! Баксаң, кар өстендә йоклап яткан малайны ана бүре кочагына алып җылыткан булып чыкты! Соңыннан малай монысын үзе сөйләде. Кар өстендә салкыннан куырылган малайга үзе ашаткан бүре баласының анасы тап булган! Абрар үзе генә булса, бу хәлгә беркем дә ышанырлык түгел иде! Якуб та күрде, ышанмый хәлең юк. Хәтта ул чакта әлеге хәлне зур вакыйга итеп газеталар да язды. Телевидение килеп сораштырды, аптыратып бетерделәр.

Хәлүш малай табылуга бик сөенде, күңеле йомшарып, табылдык малайның үзләре генә белгән серен дә чишкән иде Якубка. Теге чакта, вагоннан малайны табып алганда, кәгазь кисәкләре берничә иде. Берсендә шигъри такмак язылган. Күпме генә тырышса да, Хәлүш үзе генә бу табышмак серенә төшенә алмады. Барысын да күрсәтмәде, ике юлын гына Якубка да укытты. Әмма әлеге серле такмакның җавабын икәүләшеп тә аңламадылар. Якуб та, аптырап, иңбашларын гына сикертте. Шулай да ул кәгазьдәге язуларны блокнотына күчереп алды. Авылдашы Мирсәетнең Ханкалада иске язуларны таный торган гыйлемле танышы бар. Аңа күрсәтеп карарга булды.

Абрарга «Бүре малае» дигән кушамат ябышып калды...

Якубның үз исәбе дә бар иде. Әгәр ул малай табылса, ике дә уйламыйча ул аны үзенә уллыкка алмакчы булды. Үзенекеләр, Ямаштан башкалары, җитлекми тудылар...

Әлбәттә, Хәлүшнең кулдашына әйтеп бетермәгән сере дә бар иде. Малайның бишмәт кесәсеннән килеп чыккан кәгазьдәге хәбәргә караганда, тиздән бик зур хәзинәгә тап булырга тиеш ул. Тик хәбәрнең очын-очка гына ялгап бетерәсе бар. Бервакыт шулай белеш мари Абрарга сөяк саплы чыбыркы бүләк итте. Аның сабына да шулай дип язылган иде: «Татар әйтә «бисмилла», ди, урыснықы – «памилуй»... Ике генә юллы такмакның исеме дә бар: «Алтын ачкыч» дип атала ул. Нигә мондый исем кушканнар? Нинди ачкыч икән ул, өстәвенә алтын да әле үзе?!

Бәлки, алтын – хәзинә ачкычыдыр ошбу юлларда?

Фани дөнья тозлы су кебек, ди, яшәгән саен яшисе, белгән саен тагын да күбрәк беләсе килә.

Бу вакытта чуалган җепнең очы Туксабада табылачагы хакында белми иде әле ул. Теге чакта серне Якубка чишеп, әллә дөрес эшләде, әллә ялгышты, тәгаен билгеле түгел, чөнки аны Якуб, чынлап та, авылдашы Мирсәеткә укыткан һәм тегесе, үз чиратында, бик озак еллардан соң булса да, Башкала архивларыннан эзләп карарга дип, улы Солтанга җибәргән иде.

Ул такмак такмак кына булмады! Зөлфәкар Тәкә елгасыннан тапкан чүлмәк шешәдән килеп чыккан язу да нәкъ шуңа охшаш ләбаса! Мирсәетнең башы чуалды, аннан да бигрәк, бу хакта укытучы Чураканга әйткәч, анысы

бик аптырады. Аптырау, белергә теләү, үз чиратында, кызыксынуга китерә, химикның тәмам тынычлыгын югалтты әлеге язу-такмаклар.

Сәрбиназ аркасында Хәлүшнең асрамага алган малае кыйналды. Макайның бер күзе агып чыкты. Кулы сынды, кабыргалары имгәнде. Шул килеш урман уртасында ташлап калдырды да үзе Сәрбиназ белән Башкалага агач илтүче озын әрҗәле машинага утырып качып китте. Башка әйләнеп кайтмады ул Хәлүш йортына. Хәлүш тә, үги анасы Улинә түти дә мәңге гафу итмәячәкләр иде аны. Хәлүшнең дуслары гына түгел, Мирсәет тә эзләп карады аларны. Кугуй ялчылары да эзләмәде түгел. Ләкин малайның эзе суынган иде...

Хастахәнәдән чыккач, Макай урман буйлап бик озак Абрарны эзләп йөрде. Тик тегесе суга төшкән кебек юкка чыкты диделәр. Әллүки чишмәсе янында зур таш ята. Макай белән Абрар шул ташка икесенең дә исемнәрен уйганнар иде. Макай, бик тырышып, таштагы «Абрар» исемен бетерде, хәзер ташта «Макай» гына чекерәеп тора.

Әлеге биниһая зур ташны алар Абрар белән кузгалтып та кармакчылар иде, чөнки аның астында нindидер серле нәрсә булырга тиеш кебек. Кузгалту түгел, кымшата да алмадылар. Хастаханәдә ятканда Макайның башына бер фикер килгән иде, ул хәзер шуны тормышка ашырырга уйлады. Әтисенең умарта бакчасы коймасы янында бик озын трос ята. Урман ташучы зур машиналардан калган булса кирәк. Малай шуны таш янына сөйрәп алып килде. Иплэп кенә ташка бәйләде. Тросның икенче очы янәшәдәге юлга кадәр җитә. Менә шуны урман ташучы берәр зур машинаның әрҗәсе астындагы ыргакка эләктерергә мөмкин ләбаса! Таш үзеннән-үзе «йөреп» китәчәк! Моның өчен машинаның ул төштә аз гына булса да туктап торуы кирәк. Моның да җаен тапты Макай: юлга чокыр казыды һәм анда чишмәдән су агызды.

Көн буе каравыллап ята торгач, узып баручы куәтле бер машинага эләктерә алды ул аны. Тик таш кузгалырга да уйламады, әйтерсең аның имәннеке кебек тамыры бар һәм ул бик тирәнгә киткән иде.

Малай бу ниятеннән кире кайтты. Беркавым уйланып йөри торгач, Абрар исемен «сөрткән» урынга: «Макай Непомнящий балалары» дип язып куйды. Кайчан да булса, Макайның балалары булыр һәм ул аларның исемнәрен әлеге «тирән тамырлы» ташка өстәп язачак!

Бу Макайның үз-үзенә бер шөгыль табуы кебегрәк булды...

## «Любовь в жизни есть всегда, взаимной нету не фига»

Солтанның исәбе туп-туры Башкала уку йортларының берсенә барып керү иде. Бер караганда, бу авыл малае өчен буй җитмәслек хыял булса, икенчедән, унынчыны тәмамлаганда, аның Башкаладагы бер хакимнең бердәнбер матур кызы белән танышлыгын белгән Ясминә тамчы да шикләнмәде. Керәчәк ул Башкаладагы уку йортына, аннан соң исенә дә алмаячак Ясминәне... Һәм аннан соң, кыз уенча, гомер буе Ясминә дип өзгәләнеп, үкенеп яшәячәк!.. Гафияте дә Марижан дип бик шашып йөрсен әле менә...

Алар иртән, чык кипкәнче үк, Ислемай тау итәгеннән башланып киткән

Биектау ерганагында балтырган, какы җыярга барырга тиешләр иде. Шул көнне таң белән Чыбык күпер буена нәни автобус килеп туктады. Ислемай тавына килүче туристлар икәнлеген әллә каян белде аларның Солтан һәм, Ясминәне дә көтеп тормастан, юл күрсәтергә шул автобуска утырып китте. Ислемай тавына килгән туристларга (болары студент геологлар һәм филологлар булып чыкты) юл күрсәтү – малайларның уч төбенә бераз акча кертә торган табышлы шөгыль, хәзергечә әйтсәк, бер бизнес иде... Көне буе ул турист-сәяхәтчеләрне таулардагы үзең генә белгән сукмаклардан алып йөрисең, алар белән бергә ял итәсең, бергәләшеп төсле ташлар җыясың. Бүген андый уе юк иде Солтанның. Ләкин автобустан иң соңгы булып төшкән кыска чәчле зур күзле кызның: «Юл күрсәтә алмассыңмы? – диюе, әле шуңа өстәп: – Алайса, адашып үләбез бит без монда синнән башка!» – дип, иркә тавыш белән ялваруы Солтанны сихерләде дә куйды. «Әллә моның тылсымы Ясминәнекенә караганда да көчлерәк микән?» – дип уйлый-уйлый, ул үзе дә сизмәстән автобуска кереп утырды.

Солтан студентларны туп-туры Ислемай тавына алып китте. Боларны ташлар һәм тауның төрле катламнары кызыксындыра торгандыр дип уйлады ул. Ләкин гел Бану янында бөтерелгән кызыл сакаллы студент-филолог, ахрысы, ул гел атамалар турында сөйли. Һәм бу якларны каян белә ул?! Беренче мәртәбә аяк басуы бит? Хәер, тора-бара аңлашылды: китаптан гына укыган икән, хәзер менә үз күзләре белән күрергә килгән. Зур күзле кыз шулай диде. «Геолог булсам да, мин дә кызыксынам алар белән», – ди. Хәер, Солтанга барыбер иде, чөнки ун сыйныф белеме аңа тирәнтен уйларга мөмкинлек бирми. Әмма егетнең болардан бер өстенлеге бар, ул атамаларны яттан белә. Менә һәр кыяның исем-атамасын, үзе белгәнчә, аңлатып-сөйләп бара. Ләкин авыл исеменең дә кайдан килеп чыкканын чамаламаган малайлар шуннан ары уза алмыйлар. Хәтта укытучы Миутын да белми авыл исеменең килеп чыгышын, тауларның нилектән «Ислемай» дип аталуын да әйтә алганы юк. Күлтәк күле нигә «Күлтәк»? Ирдеш нишләп ни «Иртыш» түгел, ни «Идел» атамасына ятышып бетми?.. Шулай да Туксаба малайларының мондый экскурсияләрдә «гид» булып йөрүе беренче мәртәбә генә түгел, азу тешен ярган егетләр. Гадәттә, тауның исеме ошый иде сәяхәтчеләргә. Сораштырып теңкәгә тиеп бетәләр. Туристларның күңелен күрергә, әлбәттә, моңарчы ишеткәннәре җитә. Кирәк булса, үзеңнән дә өстәп куясың. Нәрсәсенә аптырыйсың инде аның: Ислемай тавының итәгендәге чоңгыллардан элек керосин җыйганнар, шуннан ары сабын кебек күбекләнеп торган сулы чокыр булган. Ул ислемай хәзер тау ярыгына кереп качкан, атамасы гына калган. Аның итәгендә бүгенге көндә сазлык. Белгән кеше генә аерым сукмаклар аша тауга менә ала. Ислемай тау атамасы үзе үк сөйли инде тау башында нindидер хикмәтләр барлыгы турында.

Егетләрнең икесе сакалсыз, берсе, йөзен сакал басканы, ягъни филологы, аспирант булып чыкты. Атамалар белән шунысы кызыксына инде. Чалбарлы ике кызның зур күзлесе, Бану атлысы, кыр кәҗәсе кебек: килеп җитүгә, әле бер кыяга менә, әле икенче таучык башыннан: «Монда килегез!» – дип аваз сала. Ләкин һәркайсы бик белдекле рәвештә үз эше белән мәшгуль булганлыктан, аның янына барырга атлыгып торучылар күренми; аптырагач, Солтан китә. Малай башта ук игътибар итте, сакаллы аспирант

әүвәл гел Бану тирәсендә кайнашты. Тик кыз күбрәк кыр кәҗәсе кебек ташлар өстендә. Аңа табыш-эзләнүдән бигрәк тау башында хозурланып йөрү күбрәк ошый төсле. Җиңел генә менгән таш өстеннән кыз балага кире төшү кыенрак, ләкин сакаллы аспирант, аңа ярдәм итәргә һәрвакыт әзер торса да, кул бирми, күтәреп алырга да җыенмый, бары тыныч кына таш кырыенда кызны көтеп тора. Шулчакта Солтан пәйда була һәм кызга төшәргә булыша, кулын суза яки күтәреп үк төшерә. Сизә Солтан: Бануга бу ошый, ул тагын ташлар өстенә үрмәли, күңеле булгач, төшәргә ярдәм сорап, Солтанның килгәнен көтә.

Берсендә шулай Солтан килеп җитә алмады, кыз кәҗә кебек үзе сикереп төште, җиңел иде ул, кемнәндер ярдәм көтеп кылана гына бугай. Барыбер күп очракта егеттән ярдәм көтүе аны сөендерә иде. Аспирант Бану Солтанга «тагылгач», үпкәләде, якын килмәскә тырышты. Солтан шунысына игътибар итте: аспирантка нигәдер барысы да «Паша» дип дәшәләр, югыйсә килгән шәпкә, Бану «Пауль» дип таныштырган иде. Солтанга үзенең кыяфәте белән дә бик ошап бетмәде аспирант, йөзе Буратинонықы кебек агачтан юнып ясалгандай, борыны да шакмаклы, кыяфәте дә дүрт почмаклы. Сугыш киноларында күргән немецны хәтерләтә иде ул.

Солтанның бар игътибары кызда. Менә озын буйлы (Солтан аны эченнән генә озын торыклы дип атады), коңгырт күзле бу чибәр кыз кыя башына менеп баскан да әйләнә-тирә дөньяга хозурланып карап тора. Башка иптәшләре кулларындагы ниндидер җайланмалар һәм кечкенә кәйләләр белән әле нидер тикшергән, үлчәгән булалар, әле, берәр таш табып, чүкечләре белән тукран кебек шунда чүкенәләр. Кыяфәтләре бик җитди, күрәсең, тизрәк берәр ачыш ясап, иптәшләрен шаккатырмакчылар. Бануның кулында чүкече дә, шакмаклы тартмасы да юк. Кулында бер бәйләм күк төсендәге ала миләүшәләр. Бу якта әлеге чәчәкне русча исеме белән «лаванда» дип атыйлар.

Кыз тау битендәге кыя сыман урынның иң биек җиренә менеп баскан да хәзер тагын төшәргә куркып тора. Солтан аптырады, куркырлык урын да түгел бит инде, Ясминә белән дә килгәннәре бар аларның монда. Ясминә бередә тау кәҗәсе кебек йөри. Солтан, Бануга кулын сузып, төшәргә булышты. Шулчак үсмерне ток суккандай булды, аларның авыл читендәге трансформаторныкы кебек иде әлеге ток; шулай да кызга бу рәвешле ярдәм кулы сузу аңа рәхәтлек бирә. Күп очракта, ярдәм итәргә теләп, Ясминәгә дә кулын суза ул, ләкин тегесе, үзем дип, һәрчак ярдәмен кире кага торган иде. Ә менә студент кызга Солтанның булышуы кирәк!.. Шул кыланышы әсәрләндерде дә инде аны, рәхәт булып китте, ул үзен «әллә кем» итеп хис итә башлады. Әйтерсең, әгәр Солтан булмаса, бу чырылдык кыз тау башында бәлагә дучар булыр төсле. Бары Солтан аркасында гына ул тау өстендә шулай җиңел йөри ала...

Ислемай тауларыннан ары урыннарны да яхшы белә иде ул, алар хакындагы риваятьләр, халык телендә йөргән төрле фаразлар да яхшы таныш аңа; шуларның барысын-барысын да сөйлисе килеп китте. Бабасы гел әйтә иде бит: аның атасы, имеш, сөйли торган булган – Булат атлы аталы сәүдәгәр – (Солтанның ерак бабасы була бит инде; ул, чынлап та, Ефәк юлы буйлап Кырымнан алып Кытайга чаклы йөргән!) Ислемай

тауларының түбәсенә менеп бассам, Кара диңгез шавын ишеткән кебек булам дип. Ислемай тауларына барып җиткәнче, Ирдеш күпере аша узарга кирәк. «Ирдеш» сүзен ишеткәч, Паша, үзе дә сизмәстән, аны төзәткәндәй булып: «Иртеш» – дип куйган иде. Тик елганың исеме Иртеш түгел, ә нәкъ менә «Ирдеш» икәнлеген кабатлап әйткәч, уйга калды. Елгалар исеме Иделдән Ирдешкә, аннан Иртешкә үзгәрә-үзгәрә, ерак Себергә чаклы китеп барганмы соң? Әллә шул яктан Идел буйларына кайтканмы? Солтан, белдеклеләнеп, шул фикерне дә өстәп куймакчы иде, тик тыйлыгып калды; бәлки, ялгышадыр; студентлар, мөгаен, аннан да күбрәк белә торгандыр дигән уй комачаулык итте чәчрәп чыгарга. Тик ялгышкан икән, башкалар казынуларын белсәләр, Паша Солтаннан халык телендә бу яклар хакында йөргән риваятьләрне сөйләвен үтенде. Аспирантның йөзе үк яктырып китте, әнә ул игътибар белән тыңларга әзер. Бану дә кәйләсен таш өстенә куйды, һәм аның да тыңларга исәбе.

Әүвәл Солтан икеләнде, бу ялкау кызның кулына кәйлә тотып, тукран кебек тукылдыйсы килмиме, әллә инде Солтанның үзенә күзе төшүен сизенәме? Ие, шуннан ни ди? Кирәгең бар иде синең сала башың кәттә шәһәр кызына! Хыялланган бул тагы!..

Әлеге уй-хыяллары бик тиз арада «тар куышка» кереп сеңде һәм шулчак «Ислемай» тавының атамасы турында Банудан үзе моңарчы белмәгән яңалык ишетте: мондагы суда «бензол» дигән хуш исле химик элемент бар икән! Ул бик белгән кыяфәттә, бензол булгач, нефть ятмалары да табылачак дигән фикер әйтә. Нефтьтән ислемай эшлиләр. Бензол үзе дә хушбуй кебек исле икән җитмәсә! Менә кайдан килеп чыккан тауның атамасы!

Гадәттә, чибәр кызлар акылга бик үткен булмый дип уйлый иде Туксаба малайлары. Ясминә бик чибәр, Мәликә дә матур кыз, әмма ул да үзе укыган китаплардагы гыйшык-мыйшык белән саташып йөргән геройлардан уздыра алмый. Әнә, кара!.. Марижан нинди гүзәл! Андый матур беркайда юк! Ләкин ул ике ел рәттән бер сыйныфта утырып кала. Гомумән, Марижан укуны, китапны кызлар эше түгел дип исәпли. Сөю-сәгадәт китаплары да күп хатын-кыз өчен...

«Бану башка...» – дип уфтанып уйлады Солтан. Әллә күңеленә үк кереп утырды инде... Бабасы: «Бер күктә ике ай, бер җанда ике мәхәббәт булмый», – ди торган иде. Шулаен шулай да...Тик, тегермән ике таштан, мәхәббәт ике баштан тора дигәне дә бар бит әле әйтемнең. Бану аның хакында ни уйлый икән? Хәер, авыл гыйбады диптер инде... Әлеге уе егетне капылт сискәндереп җибәрде, ул йодрыгын төйнәп, тешен кысты һәм, күкрәгенә тирән итеп тау һавасын алды; димәк, моннан соң аның тормышында зур үзгәреш булачак! Үзгәрешнең сәбәпчесе – Бану атлы Ханкала кызы!..

Тагын бабасының шаян такмагы исенә төште:

Любовь в жизни есть всегда
Взаимной нету не фига.
Бер күрүдә ошаса да,
Җавап бирми ул нигә?!

Солтан белән беренче очрашкан вакытта Бану Ханкалада әнисе белән генә яшәгән икән, өченче курска җиткәч, аның Башкалада әтисе барлыгы билгеле булган, ул, зур түрә кеше, «табылдык кызын» үзе янына чакырса

да, тегесе укуын Ханкалада тәмамларга карар иткән, әнисен ташлап китәсе килмәгән, күрәсең.

Солтанга Башкаладагы югары уку йортына керергә Бануның әтисе ярдәм итте. Шакир Рәимов дигән нефть компаниясе җитәкчесе аны Губкин исемендәге нефть институтына кыстап караса да, малай кыенсынып кына Авыл хуҗалыгы академиясе каршындагы югары уку йортына керергә теләвен әйтте. Карарының ныклыгы сизелеп тора, чөнки алдан ук әтисе белән дә киңәште. Мирсәет ага исә улының бу ниятенә каршы килмәде, киресенчә, аның җиргә якын булырга теләвен хуплады гына. Нинди генә алтын басмалы баскычлар буйлап күкнең түбәсенә чаклы ук менсәң дә, барыбер кайчан да булса җиргә кире төшәсе була.

## Су буенда бер бака, бер бата да бер калка

Әлбәттә, теге чакта аны бөтенләй үк бетереп атмаслар, юкка чыгармаслар да иде. Ләкин Мирсәет кәҗәләнде: Ханкалагыз үзегезгә булсын дигәндәй, туган ягына кайтып китте. Тик анда озак юанырга ирек бирмәделәр, Төбәк Комитеты Хәйдәровны райкомга икенче секретарь итеп билгеләде. Авыл хуҗалыгы өчен җаваплы иде ул. Туксабада торып эшләде, районга барып-кайтып йөрде.

Мирсәет ага, кармак алып, Күлтәк күленә китте. Күл тынычландыра, балыгы эләкмәсә дә, ара-тирә чиртеп куюлары җанны көйли торган иде. Монда үз уйларың. Әнә алар күл дулкыннары өстендә тирбәләләр: кирәклесен генә үз яныңа «чакырып аласың» да хатирәләргә биреләсең.

Адәм гомере искән җил кебек, ни арада шатлык яшьләрен сөртеп ала, ни ара чыланган керфекләрне киптерә, аннан соң кинәт кенә юкка чыга кебек. Хәер, «кебек» кенә шул. Кешенеке башкача, хатирәләр калкавыч сыман бер бата да бер калка.

Ханкалада эшләгән чагында аңа Беренче өчен милли темага доклад әзерләргә куштылар. Татар телен, рус теле кебек үк, көндәлек тормышта куллану темасына иде ул. Мирсәет ВПШда бергә укыган дустына шалтыратты, Камил Вәзиев атлы бик башлы егет Казанда эшли иде. Ул да өлкә комитетында шактый дәрәҗәле урында утыра. Казанда милли мәсьәлә темасы тагын да кискенрәк вакытлар бит. Татар дөньясының башкаласы булуга кармастан, мәктәпләрдә туган тел укыту беткән диярлек. Урамда татарча сөйләшсәң, сиңа хәтта күрше татарың да сәерсенеп карарга мөмкин!.. Кыскасы, туган телнең хәлләре шул дәрәҗәгә китереп җиткерелде бездә дип сөйли торган иде Камил. ВПШда Зарецкий фамилияле профессор бар иде. Җаен туры китереп, ул акыллыбаш курсантларга шактый кызыклы нәрсәләр сөйләде. Мәсәлән: «Әгәр сезне милләтче дип гаепләргә уйласалар, моннан котылуның бик әйбәт җае бар. Инглиз галиме, дөньяга атаклы социолог Робертсның: «Тәрбия – милли компонентлы булганда гына тәрбия ул. Туган телдә балага сеңгән тәрбия – иң нәтиҗәле тәрбия. Әгәр бала чит телдә генә тәрбия ала икән, аңа гүзәл энҗеләрнең кырык проценты гына барып җиткән дигән сүз. Димәк, индивидум нәкъ алтмыш процентка буш була». Бу цитатаны КПСС Үзәк Комитеты секретаре Фәләнов иптәшнең бер докладына да кертердем мин. Укыды теге бик тәмләп, авызларын

чапылдата-чапылдата, нәрсә сөйләгәнен үзе дә чамаламады, бахыр...» – дип, ачы итеп көлә белә иде куркусыз яһүд.

Зарецкийның әлеге лекциясеннән соң курсантлар арасында туган теленә йөз чөергән кайбер «иптәшләргә» мыскыллап: «Алтылы» дигән кушамат тагылды. Бу «туксан тугызлы», ягъни моның бер шөребе җитешми дигәнгә караганда да мыскыллырак иде. Русчасының тәэсире тагын да көчлерәк: рус сүзе «шесть» саны тамыр ителеп, «шестерка, шестирить» дигән мәгънәгә кадәр барып җитә иде.

Сабакташы үзләрендәге хәлләр мисалында әйбәт кенә киңәшләр бирде Мирсәеткә. «Бездә монда, рус милләтеннән булган Инатов фамилияле Беренче өстеннән татар кавемле Ибәт Мулатов белән Галим Бәтиевләр Башкалага әләк язып тора. Аны «татар милләтчелегендә» – Татарстанда татар телен тормышка кайтарырга тырышуында гаепли кулдашлары... Сак булыгыз», – дип кисәтте.

Язды докладны. Аннан соң дистәләгән кеше җентекләп тикшереп чыкты әле. Чыгыш алдыннан, Беренче аны чакырып, кәгазьләрне үзенә сузды да: «Синнән соң күпләр кул тыккан моңа. Беренче экземплярын, үзең эшләгәнне, бир әле», – диде. Һәм ул, ахыр чиктә, чыгышын шул нөсхә ярдәмендә әзерләгән булып чыкты! Көндәлек тормышның һәр тармагында татар теле гамәлдә булырга тиеш! Эшләр татарча да алып барылырга тиеш!

Беренчегә атака башланды. «Үзе рус булуга карамастан, фәлән-фәсмәтән!» дип, Башкалага әләкләр яуган. Мирсәетне, пропаганда бүлегенә чакырып, мунча керттеләр. Мөдир Романовның әйткән сүзләре әле дә бәгырен тырнап тора, югыйсә теге үзе дә татар бит, үз милләттәше.

– Алланың кашка тәкәсе булдыңмы, милли мәсьәләләр өчен җаваплы инструктор дигәч тә?!

– Мин бары егерме беренче елгы Декретны гына искә төшердем. Мин чыгарган декрет түгел ләса, хөкүмәт карары! – дип карышты Мирсәет.

– Әйтәм бит, Алланың кашка тәкәсе! Елгагыз да шундый исемдә, хәер, үзегез соң, сез үзегез дә... сарык бит сез! Оныттыңмы әллә үзеңнең сарык көтүеннән икәнлегеңне! – диде мөдир ачу белән.

Мирсәет куырылып килде. Ул җитәкче каршында, кирәк булса, ялагайлана ала – партия шулай өйрәтте, татарлык, мескенлек шулай итә – әмма горурлыгына кагылуны җене сөйми иде. Эчтән кабынды Мирсәет, шартларлык булып кабарды, әмма тагын дәшми калды һәм дөрес эшләде: сабырлык аның төп шигаре иде.

Тик эченнән барыбер: «Нигә алай дисең соң әле син? Үзең дә татар кавеменнән бит ләбаса син?!» – дип уйлап куйды. Гөнаһ шомлыгына каршы, уйлары телендә үк әйләнгән икән, ул моны пышылдап әйткән.

Теге урыннан ук сикереп торды һәм төкерекләрен чәчә-чәчә:

– Партия таләп итсә, мин татар гына түгел, рус кына түгел, марсиан да булам, беләсең килсә! – диде.

Мирсәет дәшмичә аңа карап торуында булды. Үзе белән ризалашты, үзе белән килешә дип уйлады бугай теге Мирсәетне һәм тагын да канатланып китте:

– Җәбрәй булам мин, мәгәр кирәксә! Мәгәр партия таләп итсә!.. – диде.

Мирсәетнең күзләре шар кебек зурайды, алар аның маңгаена ук менеп утырдылар бугай. Теге, моны сизеп, каушады, яһүд исемен телгә алып,

ялгыш сүз әйткәнлеген үзе дә аңлады һәм үзара туган киеренкелекне йомшартыр өчен:

– Слушай, Хәйдаров, әйдә, синең дә фамилияңне үзгәртик. Партия баскычлары буйлап күтәреләсең килсә дим инде, – дип, ялагайлана ук башлады. Чөнки Мирсәет аның «яһүд булам» дигән сүзләрен кирәкле урынга җиткерсә, эшләре мөшкел булачак иде. – Менә безнең фамилия Хәбибрахманов булган. Әүвәл башын «кисеп» атып «Рахманов» булып йөргән идем, аннары «Романов»ка ук үзгәрттем. Давай, син «Хайдеров» бул, ә? Ә, юк, давай, «Гайдаров» дип, урысныкын ал! Рус язучысы Аркадий Гайдарны беләсең бит инде? Атаклы фамилия!

Аның бу сүзләреннән Мирсәетнең чынлап торып күңеле булды, ирексездән елмайды ул һәм пышылдап диярлек:

– «Гайдар»да татарча була бит инде, иптәш Романов, – дип куйды. Тегесе беркавым уйланып торды торды да:

– Чёрт с тобой, миңа димәгәе, нигә хоть «Суворов» дип үзгәртмисең шунда! – диде.

Мирсәет шулчак тагын да батыраеп китте, инде ул елмаеп кына калмыйча, көлә, тантана итә иде. Фамилиясен генә түгел, исемен дә, кемнәргәдер ярыйм дип, «Миңсадыйктан» бары «Садек»ка, атасы исемен «Мирхәбибулла»дан «Мир»гә калдырган Садек Мирович Романов бик кызганыч булып тоелды аңа.

– «Суворов» фамилиясе дә татарча була, татардан чыккан фамилия ул, иптәш Романов! – диде. Әле тагын өстәп: – Миңсадыйк Мирхәбибуллович, – дип куйды.

Бу юлы сүзләрен кычкырып ук әйтте. Тегесенең маңгае тирләп чыкты, ыкы-мыкы килде дә:

– Молчать! – дип, бала-чаганыкы кебек нәни йодрыгы белән өстәлгә сукты.

Телен тыйган булса шунда Мирсәет: үзәктән килгән комиссия Романов тәкъдиме белән чыгышка милләтчелек исе килә дигән ярлык чәпәде. Гаепле итеп аны калдырсалар да, Инатовны да алып аттылар. Урынына өстеннән әләк язган татарны куйдылар. Аның ишләре, татар телен укытуга ата-аналар каршы дигән уйдырма сылтау белән Декретны өстәл тартмасына яшереп куйды. Менә шул иде бар булган тарих. Югыйсә әллә ни нәрсәсе дә юк, бары Себердә табылган археологик материалларга сылтама ясап, татар тарихының бик борынгы икәнлеге әйтелә дә, асаба халыкның туган теле көндәлек тормышның һәр тармагында кулланылырга тиеш диелә иде.

Романов белән булган бәхәс гомер буена исендә калды: ул аның җанында нәни генә булса да, горулык хисе кабызып өлгергән иде...

...Калкавыч кинәт су астына төшеп китте. Зур балык, ахрысы: кармак таягының очын бөгеп китерде. Мирсәет ага җайлап кына аны тартып алды. Озынлыгы уч төбеннән терсәккә чаклы булган корбан балыгы эләккән! Күлтәкнең бу урынында кәрәкәдән башка балык юк иде кебек, каян килгән мондый корбан дип, ул балыкны чирәм өстенә сузып салды. Аннан соң ипләп кенә авызын кармактан ычкындырды. «Рәхмәт төшкере, балык, син абзыеңның кәефен күтәреп җибәрдең бит әле! Каян килеп чыктың монда безнең суга? Корбан буласың килдеме, корбан балыгы?!» – дип сөйләнә-сөйләнә, өскә күтәрде.

Тирә-юньдә кеше-кара да күренми, ичмаса. Балык тоту дәрте кергән кеше мактанмыйча түзә алмый, шаккатырасы иде берәр малай-шалайны. Тик шулчак балык талпынып алды да, кулыннан шуып чыкты һәм яр кырыена сикерде, беркавымнан ул суда иде инде. Мирсәет аның койрыгын гына күреп калды. Ул тыела алмыйча көләргә кереште. Рәхәтләнеп, кычкырып көлде, ичмаса! Күңеле бушап калды. Кендек турысына килеп бөялгән таш эреп юкка чыкты.

Мирсәетнең әтисе Хәйдәр абый колхозда вак-төяк эшләрдә йөрде. Кулыннан бар нәрсә дә килә иде, шуңа күрә эшсез тормады. Шуның белән көндәлек тормыш өчен акча да эшли иде. Күрше агайларның һәммәсе дә диярлек ат җигә. Малайлары гел ат өстендә. Мирсәет шуларга кызыгып үсте. Хәйдәр ага моны сизә, сирәк кенә булса да, печәнгә яки урманга утынга барам дигән сылтау белән берәр күршесенең атын сорап тора һәм дилбегәне Мирсәеткә тоттыра иде. Хәйдәр ага беркөнне малаеның эчке халәтен күптән сизгән ата буларак әйтеп куйды:

– Зур түрә булып, машиналарда җилдерерсең әле, улым! Ат заманы узып бара, – диде ул. Мирсәет шулчакта әтисе белән аяк терәп бәхәсләшкәнен хәтерли. Ничек итеп ат бетсен, ди, ничекләр итеп атның кирәге калмасын, ди?! Әкият сөйли әтисе: ат авыл кешесе өчен гомергә кирәк булачак! Ат чабышларыннан башка Сабантуйлар ничек узсын, ди?!

Хәер, нәкъ шул вакытта Хәйдәр абзыйга, авылда башка кеше булмаганлыктан, бригадир вазифасын йөкләгәннәр иде...

Аннан соң күп вакыт үтте. Сабантуйлар да ел саен уза тора, анда атлар да чабыша, ләкин колхоз беткәндә атларны да үзе белән алды. Әтисе мең тапкыр хаклы булган. Югыйсә дүрт сыйныф белемле карт иде. Мирсәет шул хакта уйлый да көрсенеп куя: ул хәзер әтисенең шул чактагы яшендә. Ат кына түгел, килмәскә һәм бетмәскә дип килгән Партия хөкүмәте дә юкка чыкты. Зирәк булган икән әтисе. Ул да менә, алтмыштан узгач, еллар белән үзенең зирәклеге артуын да сизеп тора. Атлар алып та дөрес эшләде. Райкомда эшләгәндә, үзалдына уйлап куйган чакларын хәтерли әле: хуҗалыгында ат тоту иде теләге. Атлар асрап, тыныч кына көн күрү иде. Чөнки алтмыштан соң аңа яшәү башлана гына сыман тоела. Югыйсә пенсия яше – ул «мич башы» дигән сүз бит инде. Ләкин тормыш башка яклары белән ачылып китте: Мирсәет ага бик тәмләп кенә оныклар ыгы-зыгысы белән яшәргә хыяллана башлады. Бу нияте бик тәмле, бик кадерле, әйтерсең ул гомер буе шул бәхетенә таба барган һәм бары шул хакта гына хыялланган. Бәхетне аны дөньядагы бар нәрсә белән дә чагыштырып аңлатып була. Әнә, баядан бирле су буенда яткан бака белән дә. Әле суга чума ул, әле яңадан калка да яр буена сикереп чыга.

Бу минутларда Мирсәет күптән хыялланган бәхетенең, үз бәхетенең өскә калкып чыгуын көтә кебек иде. Моның уллары Миргали һәм Солтан белән бәйләнгәнен белеп көтә картлач.

Үлән кыштырдаган тавышка артына борылып караса, кармак таяклары тотып, аңа таба ике малай килә. Кала ягы малайлары, балык тотарга исәплиләр. Килеп җитешкә берсе:

– Мирсәет абый, монда эләкми бит! Әнә тегендә, таллык кырыенда каба! – ди. Мирсәет шулчак малайларга бая тоткан берәк буе чаклы корбан

балыгы хакында сөйләмәкче иде, тик барыбер ышанмаячак инде бит болар дип, ачылган авызы шул килеш калды. Ул кармакларын җыйды да малайлар күрсәткән урынга таба атлады. Шулчак малайларның икенчесе:

– Ә мин монда менә моның шае корбан тоттым! – дип мактана. Иптәше аңа ышанмый, шыттырма, ди. Малай Мирсәеткә таба борылып: – Мирсәет абый, билләһи газыйм менә! – ди. Мирсәетнең бу сүзләрдән күңеле була һәм ул бу юлы:

– Ә мин ышанам! – ди. «Миңа да эләкте бая!» дип өстәмәкче була, ләкин тагын тыелып кала. Ул ышана, ә менә аңа ышанмаячак авылдаш малайлар!..

Килер беркөн, бу малайлар, Алла боерса, елганың «тәкә» сүзеннән килеп чыкмаганлыгын, Күлтәк күленең башка исемдә булганын белерләр дә, ниһаять, ышана башларлар. Әлбәттә, беренче чиратта, үз-үзләренә...

Шуның белән бергә икенче бер хәерсез һәм шомлы хис-тойгы да талкый башлаган иде аны: медаль ике яклы була, бу гамәлләре икенче яктан китереп сукмасмы?! Солтаныйның алга таба да яшисе бар, карьера баскычы буенча менәм дигәндә генә, нәкъ аның язмышына охшашлы хәлләр аякларына богау салмасмы малайның?!

Мирсәетнең җанын чынлап курку алды. Улын да милләтчелектә гаепләсәләр, «террорчы» дигән тамга таксалар?! «Хәер, – дип куйды ул үзалдына. – Моны рус эшләмәс. Моны татарга каршы татар үзе эшләргә мөмкин... Нигәме?..»

Мондый уйлар икенчеләрен кузгатып җибәрә һәм шулчак партия мәктәбе профессоры Зарецкийның бер гыйбрәтле мисалы исенә төшеп, бар уй-фикер дөньясын актарып ташлый. Лекциядән соң тәмәке тартып торганда, Зарецкий Гаврилов белән Мирсәеткә бер булган хәлне сөйләгән иде. Изахетдинов фамилияле бер чечен дусты булган профессорның. Шуның белән төрле темага ачылып сөйләшеп була иде, ди. «Мин шулай Изахетдиновтан: «Әйт әле, Рәшит, менә сез Чечен-Ингуш республикасы дип аталып йөртеләсез. Ике халык та бер тамырдан. Нишләп чеченнар актив та, елгыр да, ә ингушларның тавышлары бик чыкмый?» – дип сорадым. Бер җөмлә белән генә җавап бирде ул минем бу сорауга: «Чеченнар үзләренең ундүрт буын шәҗәрәсен яхшы белә, ә ингушлар тугызны гына!» – ди. – Эшнең «тугызда», «ундүрт»тә түгел, саннарда түгел икәнлеге яхшы аңлашыла торгандыр. Гомумән, эш монда үз тарихыңа, үткәнеңә мөнәсәбәттә. Халыкның мөнәсәбәтендә. Тарихын яхшы белгән милләт, аның шәхесләре куәтле була! Рухи энергиясе көчле була! Монысы бернинди тышкы кануннарга да буйсынмаган хакыйкать! Ходай хикмәтеме ул яки хәзер без аңлаткан эволюция законнары буенча барамы? Ничек кенә булса да, шулар бозылган очракта «каннар дулый» башлый, чөнки геннар мутациягә дучар була. Монысы исә аерым фәнни тема. Рәшит миңа әнә шул хакта әйтергә теләде. Гаврилов, менә син рус милләтеннән, Хәйдәров – татар. Үзегезнең рухи энергиягезне, ата-бабалардан килгән энергиягезне ни дәрәҗәдә көчле дип уйлыйсыз?» – дип сорап куймасынмы. Егетләр аптырап калды. Профессор үзе соравына үзе үк җавап бирде: «Бик зәгыйфь ул, чөнки икегез дә чын тарихыгызны, милли һәм нәсел шәҗәрәгезне юньләп белмисез!» Гаврилов аңа каршы чәчрәп чыкты: «Профессор! Рус тарихы яхшы өйрәнелгән бит!» – диде. Профессор көлде генә: «Ялган

тарих. Риваятьләр, әкиятләрдән торган тарих халыкны беркайчан да бөек ясамый. Киресенчә, рух энергиясен генә җимерә. Геннар арасында мутация барлыкка китерә!..» Дошман сүзе сөйли бит бу Зарецкий! Мирсәет тә дустын яклап чыкмакчы булды, әмма үзләренең «Тәкә» елгасының исеме, серле авыл исеме, күл атамалары исенә төште дә телен тешләде. Хәзер менә әлеге сөйләшүнең бары асыл мәгънәсе хәтерендә аеруча җете чагыла: «Без ундүрт буын шәҗәрәне, алар тугызны гына белә!..»

Мирсәет җиңел сулап куйды. Рәхәт булып китте. Күрәсең, чын хакыйкатьне белү һәрвакыт шулай рәхәт була торгандыр инде ул...

## Рәимовлар

Теге чакта студент-филологлар белән геологларның уртак экспедициясен иганәче сыйфатында Бануның әтисе, «Кара алтын» нефть корпорациясенең башлыгы Рәимов оештырган булган. Филологлары бу яклардагы фольклорны өйрәнә, тегеләре исә нефть эзләргә тиеш икән. Дөрестән дә, аспирант бераздан, алардан аерылып, авылга китте һәм күбрәк әби-чәбиләр, бабайлар тирәсендә кайнашты. Хәзер уйлый Солтан: фольклор ул нәкъ җиде кат җир астындагы хәзинә кебек, әгәр аның төбенә төшсәң, күп серләр ачылырга мөмкин!

Бану инде геологлар төркеме белән генә Ислемайга тагын ике мәртәбә килгән, тик анысында Солтан Башкалада керү имтиханнары биреп йөри иде, күрешергә насыйп булмагандыр. Беренчесендә аларга Денис гид булган, икенче килүендә Тукаш туры килгән. Кыз икесен дә бик хисләндергән. Әмма алар якыннан танышып китә алмаганнар.

Тукашның Мәликәсе бар. Ялгышмаган ул. Паша белән Бану шуннан соң ике тапкыр Путанайга кайталар әле.

Паша-Пауль исемле аспирантның фамилиясе Вольфганг, Алманиядән килгән студент. Чыннан да, геолог түгел икән Пауль-Паша, төркиләр, аларның сөн бабалары хакында диссертация яза, ди. Фәнни җитәкчесе көнчыгышны өйрәнүче атаклы галим Данил Френк үзе бик үтенгәч, Рәимов аны махсус геологлар экспедициясенә керткән. Рәсәй төркиләренә Орхон-Енисей язмаларын укып биргән данияле галиме Томсен, аларны дөньяга чыгарган немец галиме Радлов, аңа кадәр Ибн Фадлан сәяхәте язмаларын шаулаткан бабасы уңышлары канатландыргандыр инде Френкны! Белгән зирәк немец галиме: Ханкала тирәсендә һун-сөннәрнең эзләрен «табарга» Башкала рөхсәт бирмәячәк! Андый мөмкинлек булдырмаячак Башкала. Сөннәр кайда да, мондагы татарлар кайда, имеш! Икесе ике төрле халык! Татарның тарихы һич кенә дә Кытай чигендәге сөннәргә кадәр барып җитә алмый! Идел Болгары калдыкларыннан формалашкан болгарлар гына бит алар! Монгол калдыклары!.. Менә шуннан соң Френк белән Рәимов яшерен экспедиция оештыралар. Рәимов берьюлы ике куянның койрыгын тота: нефть эзләү дәвам итә һәм тарихи хәзинәләрне дә өйрәнергә җай чыга!

Бану Денис белән тәмам якынлаша. Баш-аягы белән гашыйк була Паратов малае кызга!.. Тик шуннан соң аларның эзе суынган, чөнки Абрар агай чүлмәкле хәзинә эчендә табылган кәгазьләрне күрсәтмәгән. Денис бик ялынып сораса да, риза булмаган өлкән Паратов. Имеш, шуннан соң Бану бик нык үпкәләгән һәм башка аяк басмаган, ди.

Солтан Бану белән якыннан аралашып китә алмады. Беренчедән, шундый зур кешенең кызы янына барырга курка иде егет, икенчедән, Бану аңа, юк-бар йомыш табып, моңарчы үзе шалтыратып торган булса да, тора-бара әлеге элемтә дә өзелде. Солтан моңа үзен гаепле дип саный. Чөнки Бану аны Ислемайга чакырган иде. Нәкъ шул көнне Шакир Рәимов Солтанны, үзе белән ияртеп, командировкага алып китте. Туган якларына кайта алмауның сәбәбен Бануга әйтергә базмады егет. Ул чакта Ислемай тавына геологлар төркеме барган, ләкин Солтаннан башка гына... Менә шунда якынайган булган инде алар Паратов малае Денис белән!..

Ләкин Солтанга озак саргаерга туры килмәде, авылда калган Ясминәдән кинәт хат килеп төште, анда бары бер генә җөмлә сырланган иде: «Солтан, сине көтимме, әллә кияүгә чыгыйммы?! Монда мине сорарга килергә тиешләр... Синең Ясминәң» диелгән иде анда. Ул көнне Солтан Рәимов белән Рязань якларында йөри иде. Рәимов кызы белән аралары суынып бара; Солтан үзе шундый карар кылды, чөнки Бану, Паратов акчасына зур экспедиция оештырып, Себер якларына китеп барган иде. Денис Паратов – хәзер зур байбәтчә. Замана акчалы кулында. Рязаньдагы җирләрне сатып алуы гына җитмәгән, Денис Бануны дә кулга төшерде.

Чукын шунда, кызый!..

Солтан бар даланы яңгыратып: «Көт, Ясминә! Мин сине яратам!» – дип кычкырды. Бану да «ишетсен» дип кычкырды ул! Тик тавышы, кайтаваз булып, кире үзенә кайтты, Бануга чаклы барып «ирешмәде». Ясминәгә дә «ишетелмәде».

Ыгы-зыгы белән икенче, өченче көнне дә шалтыратырга җай чыкмады. Ә өч көн узуга, Ясминәбез, ике дә уйлап тормыйча, Гафиятне Марижаннан суытып, кияүгә чыгып куйды. Соңгы өметләр дә өзелде.

Солтаннар төркеме ил күләмендә хәлиткеч зур эшкә кереште.

Хәер, өметсез шайтан гына була, ди. Шул чакта егетнең йөрәгендә давыл купты. Давыл тузаны арасында ике шәүлә күренә: берсе Бану, икенчесе Ясминә атлы кызлар.

Ясминә сурәте балачак хатирәсе белән бәйле. Ул күңелнең кай түрендәдер урнашып, әлегә сүрелеп кенә торадыр кебек. Яшүсмер чагында тауда күмәкләшеп ат чанасында шуганда кабынган гыйшык-мыйшык хиссияте бит иде ләбаса. Айлы кичләрдә алар малай-кыз чакта тауда шудылар. Ләкин малайлар бераз гәүдәгә тартылып, тавышлары кытай казыныкына охшый башлагач, кызларның күкрәкләре калкып кабарган бер чорда зур ат чанасына ничек кирәк шулай сузылып ятмыйлар иде инде. Ясминә гел Солтан белән бергә туры килергә тырыша, Солтанның да ният шундый. Ясминә янына Гафият тә тартыла. Әле күп очракта арага Мәликә дә килеп кысыла, ул да күбрәк Солтан янына елыша. Араларына Мәликә килеп керсә, Солтан сайланып тормый, ике кызны да тигез күргәндәй, үзенең бишмәтенә чытырдап ябышкан кулларны сыпырып төшерми, киресенчә, әле берсенә, әле икенчесенә елыша. Мәликә булган җирдә һәрвакыт Ямаш та калмас. Менә шул рәвешле алар тау башыннан аска таба кузгалып китәләр. Тауның яртысына җиткәндә, Солтан белән Ясминә икесе бер булып бетә яза, һәммәсе шатлыктан чырылдап кычкыра. Әлеге тавышлар чананың тизлеген генә арттыра кебек. Тау итәгенә җиткәч тә, кыз-малайлар

белән әрдәнәләп иелгән авыр чана туктарга уйламый, инешкә таба оча. Бу вакытта Солтан колак төбендә Мәликәнең кайнар сулышын тоя. Кай арада сылангандыр аның янына. Менә Ясминәнең тавышы капылт туктый. Хәзер инде Солтанның уң колагын кызның кайнар сулышы пешерә. Гафият белән Ямаш, аларның өсләренә аркылы сузылып ятканнар да чанага көч биргәндәй шаулашалар, кычкыралар.

Җиденче сыйныфтан соң Солтан клубтан Ясминәне озата кайтты. Аның мизгелләре хәтердә калмаган инде, бары гел Ясминә янында бөтерелгән Гафиятнең ул кичне клубта юк икәнлеген генә белде. Юк-бар сөйләшә-сөйләшә, Ясминәләрнең капка төбенә кайтып җиткәннәрен сизми дә калдылар. Капкага якынлашуга, караңгылык эченнән каршыларында бер «карачкы» пәйда булды. Гафият кызны эскәмидә көтеп утырган икән. Солтан белән Гафият каушап калсалар да, Ясминә коткарды: ул кесәсеннән (Күрәсең, алдан әзерләп куйган! Кызларның бар нәрсәне алдан уйлап йөрүенә шаклар катарсың, билләһи!) ике шырпы алды да, берсен яртылаш сындырып, егетләргә карады. Тирә-юнь капка янындагы багана башыннан саркылган сары ут көлтәсендә коена иде, шуңа күрә җете күзле яшьләр барысын да ачык күрә.

– Кемгә шырпының озыны чыга, бүген йолдызларны шуның белән саныйбыз! – диде кыз, җитди итеп.

– Шобагамы? – дигән булды Гафият, бу эшкә риза булганлыгын белдереп.

Солтан дәшмәде, Ясминәнең кулларына үрелде, шырпының бөтене аңа эләкте, димәк, айлы кич аныкы бүген. Икенче көнне дә, өченче көнне дә шул рәвешле шобага тоттырды аларга кыз, тик, ни гаҗәп, һаман Солтан өстен чыга, Гафияткә ялгыш кына булса да, Ясминә белән бергә капка янындагы эскәмиягә утырып, йолдыз санарга туры килмәде! Моның сере, әлбәттә, кызның үзе генә белгән хәйләсендә иде, ул үзе шулай оештырды.

«Шобага» хакында беркавымнан Мәликәгә дә ишетелгән, күрәсең, беркөнне клубта уен тәмам булыр алдыннан ул Солтанны почмакка кысты да:

– Шобага-фәлән салып тормыйм, әйдә, мин сине бүген үзем озатам, – диде. Солтан, аптырап, кызның мәхәббәт тулы йөзенә бакты. – Җә, син мине озатасың! – ди өстәде кыз.

Ясминә белән Мәликә дип янучы бер Солтан гына түгел бит әле, Ямаш та, Гафият тә, әлбәттә, бу хәлгә риза түгелләр. Гаделсез иде Ясминәнең шобагалары. Ялгыша, саташа иде Ясминә! Солтанның җырлавына гашыйк булган ул. Мәликә дә шул халәттә тилереп йөри. Ямаш – гармунда, Гафият гитарада уйнарга өйрәнделәр. Күрәсең, егетләрнең бу гамәлләре тормышларындагы беренче дөрес карарлары булгандыр; алар бүгенге көнгә кадәр күгәрченнәр кебек парлашып яшиләр бит әле! Ясминәнең көндәлек тапшырылган сөтне терки торган амбар кенәгәсе кырыенда бер такмак бар:

Хатын-кыз бәхте ни була? –
Баганадай ир була...
Татар хатыны бәхте ни була? –
Орчык кадәрле бәби була.
Шул газизе туган телендә
«Әнием» дип әйтү була.
Хатын-кыз бәхте ни була? –
Аның бәхете өй була.

## Мәхәббәт өтермәндә дә мәхәббәт ул...

Абрар Паратов бу юлы малае Денисның кайтканын аеруча түземсезләнеп көтте. Шәҗәрә серен чишәргә, теге чактагы хәлләрне Дениска сөйләргә вакыт җиткән иде. Дөнья болганырга тора. Коммунистларны хакимияттән бәреп төшерделәр. Рәсәйдә яңа инкыйлаб җилләре исә башлады. Аның уенча, бу бер дә җүнлегә түгел, беркайчан да, бернинди революция-инкыйлабның да яхшыга илткәне юк, бигрәк тә аның гади халыкка бәхет алып килгәне булмаган.

Мантыйгы дөрес, борыны сизгер, пеләш башы әле дә саф иде Абрарның. Тик менә, чыннан да, яһүдме икән ул, калын урманда үскән мари нәселеннәнме, әллә тамыры Туксаба авылы тарихына тоташкан татар микән? (Теге чакта үзен тотып яруларына үч итеп, Денисы татар-туксабаларны «чүчмәк» дип тә атый.)

Бер Алла белә...

Абрар Паратов белми... Алайса, зирәклеге дә шуның чаклы гынадыр инде...

Әлбәттә, үзен асрамага алган атасы Хәлүш сөйләве буенча бераз чамалый, актан караны аера...

Хәлүш теге чакта Якубка биргән язулар арасында килеп чыккан кәгазьдә язылганча, малайның кыскача биографиясе мәгълүм иде. Абрар үсә төшкәч, Хәлүш аны үзенә дә сөйләде. Аңа атасы фамилиясен йөртергә ярамый икән, чөнки ул нәсел бик бай булган, аларның байлыгына сәвит хөкүмәте конфискация ясаган. Алар «чит элементлар» икән, ди. «Паратов» фамилиясе белән тынычрак яшәрсең диде. Шуңа күрә Абрар чын шәҗәрәсен белә алмады. Соңыннан әнисе ягыннан булган нәсел агачын табып, үзен шунда «кушып» куйды. Бу хакта малаена да әйтмәде, киресенчә, малайга «Денис» кушты, аны үз нәселеннән ераклаштырырга теләде. Әлбәттә, мулла язган метрикәдә ул «Динислам» дип теркәләгән иде. Әмма киләчәктә кирәк булыр дип, төп нәсел шәҗәрәсенә катнашы бар икәнлеген дә раслатачак, моны дәлилләгән документларны эзләтәчәк. Рәсәйдә бүген болай, иртәгә тегеләй: уңган кешеләрне, байларны йә типкәлиләр, йә алар ил белән идарә итә...

Мари урманнары уртасында хатын-кызлар өтермәне бар. Әнисе аны шунда утырган чагында тапкан. Әтисен дә утыртырга теләгән булганнар аның, әмма ул качып өлгергән. Сәбәбе дә билгеле: атасы революциягә чаклы бабалары хуҗа булган алтын базларын кире кайтарырга йөргән. Хәтта хөкүмәтне Халыкара судка да биргән. Шуның өчен эзәрлекләгәннәр аларны. Корсагы борынына җиткән хатынын тотып утыртканнар. Игезәк сыңары да булган. Анысы үлгәндер, чөнки әнисенә төрмәдәге бер йомшак күңелле өтермән назире ярдәм иткән, балаларны үзенә алып кайтып яшергән. Сизеп алгач, игезәкләрне товар поездына салып җибәргән. Өтермәндә бала тапкан хатыннарның күбесе шулай итә икән, нарасыйларын коткару өчен төрле юллар белән шуннан узган товар поездларына салып җибәргәннәр. Икенче станциядә сабыйларны махсус кешеләр көтеп торган. Алары исә ул сабыйларны балалары булмаган гаиләләргә, күп очракта чит илләргә сату эшен җайга салганнар. Кугуй урманчы бәхетенә туры килгән малай да «шакмаклы шәл» эченнән пәйда булган.

Абрар икеләнә, игезәк сыңары үзен төргән иске шәл эчендә тончыгып үлгәндер дип уйлый. Шуннан башкасы аңа караңгы иде... Канәфер төсендәге шакмак шәлгә уралган малайның (Абрар үзе!) бишмәт кесәсеннән килеп чыккан язу ошбу караңгылык пәрдәсен күтәрергә ярдәм итмәсме?.. Бер кырыен ачса гына да җитә. Таяк сыман нәрсә табып алган иде бит инде ул. Көтүче чыбыркысының сабы булгандыр дип уйлады, шуннан чыбыркы ясады. Көтү көтәргә алынган малае Дениска да шул чыбыркыны тоттырды.

Язуда такмакка охшаган юллар иде: «Татар әйтә бисмилла урысныкы памилуй хочешь стать богатой найди клад золотой». Ноктасы да, өтере дә юк...

Денисны үзе «көтүче» итте ул. Һәм көтүне чиркәү янында көтәргә кушты. Тукмак борыны гына түгел, күңеле дә сизгер иде Абрарның... Юкка гына «бисмилла белән помилуй» димәгәннәрдер дип уйлады.

Денис чиркәүдән тапкан алтыннар ярап куйды: шуннан килгән процентлар акчасына Абрар «НОКТА» дигән уртак совет-инглиз кооперативы ачып җибәрде. Ханкалада җимерек иске бер пассаж бинасы сатып алды. Пыяладан гына торган тарихи сәүдә рәтләре иде ул. Төзекләндереп сафка бастырсаң, шәһәрнең йөзек кашы булырлык сәүдә галереясы буласын алдан чамалады. Ишекләре күрше урамнарга да чыга. Бутиклар өчен менә дигән урын инде.

Дөрес чамалаган булган Абрар, «НОКТА» аркасында Денисы Ханкала байбәтчәләре рәтенә күтәрелде. Эшләре бик хутлы бара. Башкала архивларыннан нәсел шәҗәрәсен дә эзләтте. Тапканын таптылар, тапмаганы урынына кәсепче тарихчылар үзләреннән өстәделәр һәм Паратовлар нәселенең ерак очын раввин Исраэль кавеменә үк китереп куштылар.

Шәҗәрәне Денис агач рәвешендә ясатты. Алтын кысага алынган, пыяла астында тора, диварга элү өчен җайланмасы да бар. Әүвәл, нәсел агачын күреп, Абрар бик әсәрләнгән иде, күзләренә яшь тулды, елыйсы килде, ләкин яшьләре шулчаклы гына булган икән, алар мизгел эчендә кибеп юкка да чыктылар. Ошамады аңа шәҗәрә! Җанына ятарлык түгел иде ул. Бу вакытта әнисенең өтермәндә утыруы да, шунда игезәк малайлар табуы да, ул малайларны нindидер түрәләрнең үзенә алырга теләве дә, соң чиктә балаларны яшереп товар вагоннарында ул яклардан еракка озатулары да мәгълүм иде. Баксаң, затлы нәселдән булган алар. Бабалары заманында алтын приискаларына хуҗа булып торган. Бу хәл исә аларның яһүд нәселеннән булуына шик уята. Чөнки ул вакытта яһүдләрне бик кысалар, мөгаен, хөкүмәт аларга алтын приискасына хуҗа булырлык ирек бирмәгәндер. Ул үзе мари гаиләсендә тәрбияләнсә дә, кавемгә катнашы юклыгы да мәгълүм. Татар да түгелдер, чөнки патша Россиясе татарга да андый ирек бирде микән?! Советлар бирдеме соң? Юк, бирмәде. Элек данлы, шанлы булган Ханкала биләмәләрен бүлгәләп бетергәннәр, инкыйлаб елларында Мирсәет Солтангалиевләргә татар халкы азат, ирекле кавем булыр дип вәгъдә итсәләр дә, Ленин дилбегәне каты тарткан, Сталин исә, үз чиратында, бу халыкка шактый кабахәтлек кылган. Димәк, татар да түгелдер?!!

Игезәк сыңары кайда? Исән микән ул? Әллә шул товар вагонында җан тәслим кылганмы ул сабый?! Рәхмәт төшере, аны яхшы кешеләр үзләренә

сыендырды, какмый-сукмый тәрбияләп үстерделәр. Ит яхшылык, көт яманлык дигәндәй, ул әлеге яхшы кешеләргә яхшылык белән җавап кайтара алмады...

Икенче яктан, чыбыркы сабындагы язуының сере ачылырга тора. Ләкин аны туксабалар да сизенә шикелле. Абрар моны белеште һәм авып китә язды: Денисның яшьтәшләре әлеге язу ачкычын кулга төшерү юлында. Бары бер адым гына калган!.. Чит кеше табарга тиеш түгел чын шәҗәрәне! Түгел! Югыйсә Паратовның бар ниятләре юкка чыгачак!..

Әлеге туксабаларның исемлеге төзелде: Солтан, Сәрдәр, Гафият, Тукаш, Зөлфәкар атлы яшьтәшләре икән Денисның! Миутын кушаматлы химия укытучысы да бар әле!..

Абрар шуларны уйлады да көлеп җибәрде. «Эрләмәгән-сукмаган, җиңгәй, сиңа күлмәклек!» дигән кебегрәк килеп чыга инде – нәкъ туксабалар телендәге әйтем кебек. Шуны исенә төшереп көлде Абрар.

Байлык белән генә әллә ни кылып була торган ил түгел бу. Банклар янса, кесәңдә шымытыр да калмаска мөмкин. Акцияләр дә бик ышанычсыз кәгазьләр. Тагынмы? Тагын шул: Денис та байлык белән әллә ни кыра алмый, югарыда көтү көтеп йөргән элеккеге хәерчене бик санга алучы юк. Шәҗәрәне ачыкларга кирәк. Әгәр нәсел тарихының чынын таба алсалар, берьюлы ике куян тоталар дигән сүз: исем-дәрәҗә дә үсә, бабаларының алтын базларын да кире кайтара ала Абрар Паратов. Хәлүшкә әйткәннәр бит теге чакта, бу малай гади бала түгел, революциягә кадәр ата-бабалары алтын базлары тоткан дигәннәр!.. Имеш, әтисе белән әнисен советлар шуның өчен өтермәнгә япканнар, тавышлары чыкмасын, янәсе. Ул алтын базларын кире кайтарырга йөрмәсеннәр, янәсе.

И, сөйлиләр инде...

Теге чакта да, Денис чиркәүдән алтын чүлмәк казып алганда, андый сүзләргә әллә ни исе китмәде аның, байлык үзендә дә бар, Паратовка шәҗәрәне раслаган мөһерле кәгазьләр кирәк; шуңа күрә мәчет-чиркәү нигезләреннән, Башкала архивларыннан документлар эзләде Паратовлар.

Беркөнне Абрар яшьтәше, урманчы Кугуй малае Макайны очратты. Балачак дуслары һәм күптәнге ике дошман соңгы елларда аралашырга мәҗбүр. Беренче булып Макай үзе килде Абрар янына. Йөрәк сере аркасында...

Макай:

– Туксабалар – Чуракан белән Зөлфәкар атлы ике тилемсә – чүлмәк эченнән тапкан язулар мөһерләнгән, – диде.

Күренеп тора: әйтеп бетерми Макай, тагын нидер яшерә. Яшерерлеге дә бар, чөнки теге чактагы үч кайның торгандыр бу кешенең җанында. Сәрбиназ өчен тотып кыйнады бит ул аны. Алай гынамы, агач ботагы ялгыш тиеп тишсә дә, күзен югалтуны бары Абрардан гына күрә торгандыр. Алар теге чакта аңлашканнар иде шикелле. Күптән түгел тагын сөйләштеләр бу хакта. Макай, Башкала табиблары янына барып, «ясалма күз» куйдырырга хыяллана. Бик тели ул моны. Нигә матур буласы килгәнен әйтми. Әйтмәсә дә белә: Макай һаман Сәрбиназны кире кайтару турында уйлый. Имеш, Сәрбиназның Касыймда бала тапканын ишеткән һәм аны үзенеке дип уйлый иде. Хыяллана инде. Хыялдан адәми затны кем тыеп тора ала. Алмый... Бу заманда хыял ул – гади кешенең бердәнбер иреге, бәйсезлеге. Абрар

Макайга күзен дәваларга зур акчалар вәгъдә итте. Кирәксә, чит илгә дә җибәрәм диде. Ул чакта Германиядә катлаулы операцияләр ясыйлар дигән сүзләр дә чыккан иде. Матур буласы килә бит аның. Шуңа өметләнә Макай. Өмет дигәннәренә хәтта партия дә чик куя алмады.

Абрар әүвәл түземлеген җыеп көтте; һаман ачылмый яшьлек дусты. Сизде каһәрең, үзе җиткергән хәбәрдән соң Абрарның күзләре яна башлаганын сизде, тел төбен яшерә. Абрар аңа тагын акчалар да вәгъдә итте, зур сумма да әйтеп карады. Әмма Макай: «Ул акчалар гына җитми миңа!» – диде. Алтын чүлмәкләрне тапкан очракта, Макай белән бүлешергә вәгъдә бирсә, серне чишәргә дә мөмкин икән. Абрар вәгъдәсен бирде. Шуннан соң гына Макай кызыл балчыктан катырылган мөһер чыгарып күрсәтте. Аждаһа сурәте ясалган мөһер. Бу Абрар өчен әле бернәрсә дә аңлатмый. Ул тагын Макайга төбәлде. Макай: «Монда «Печать царства Ханкалы» дип язылган булган», – дигәч кенә, авызы ерылды. Рәсәй патшасының мөһере була бит инде бу! Элек бар Рәсәй «Казан патшалыгы» дип аталган. Чит илләр, бигрәк тә Аурупа рус кенәзлекләрен санга да сукмаган, алар өчен бары Казан ханлыгы-патшалыгы гына дәрәҗә саналган!

Йә, хуш... Шуннан ни? Иң кирәкле серне Макай соңрак чиште: мөһер кырыена аның кайдан табылуы хакында язылган булган. Бик вак хәрефләр белән сырланса да, танып була: «Касыйм» диелгән.

Димәк, Касыйм!

Денисны шул хәбәрне җиткерү өчен дә көтә иде өлкән Паратов. Аннан соң өйләнү яше җиткән улына кыз да карап куйган иде. Боларны телефоннан да әйтеп булмый, хат аша да җиткерергә ярамый!.. Хәзинәне Касыймнан эзләргә кирәклегенә ишарә иде ул... Моны Хәтмулла шәкерт һәм аның командасы тагын да яхшырак белә, ди, Макай. Денис тиз арада шәкертне эзләп табарга тиеш иде. Югыйсә аларның нәсел сере дөньяга чәчелергә мөмкин бит! Бу Паратов өчен бик куркыныч, бар хыялы чәлпәрәмә киләчәк иде. Тик моны шәкерт үзе белергә тиеш түгел!..

Ләкин Денис Паратов тиз генә, бик ашыгыч рәвештә диярлек, Касыйм тирәсендәге җирләрне арендага алып өлгергән иде инде. Әтисенең серен белмичә эшләде ул моны. Башкала түрәләренә зур акчалар түләнде, кыскасы, кемнәрдер майланды, кемнәрдер җайланды. Аеруча бер төбәкнең иң зур түрәсе ярдәм итте, чөнки зур агрофирма белән хөкүмәттән бихисап кредитлар алып була һәм аларны кире кайтару да бигүк мәҗбүри түгел. Ә акчалары Башкала түрәләренең «җонлы кулларына» озатылачак, димәк, агрофирманың эшләре дә гөрләп барачак дигән сүз иде бу...

Денис әлеге ниятен әтисенә дә чишмәде, үзе генә белгән яшерен сер иде бу... Әтисенең дә малаена да чишми торган сере бар. Йөрәк сере ул. Шуңа күрә чишелеп китми картлачы. Ләкин Денис чамалый: Туксабаның Сәрбиназ атлы бер гүзәле белән бәйле ул. Әтисенең яшьтәше Макай да бар анда. Туксабадан элеккеге түрә Хәйдәров Мирсәет дигән кешенең дә катнашы бар.

Денис әлегә әтисенең үзенә кыз карап куйганын да белми. Белсә дә, исе китмәс иде, чөнки ул Бануга гашыйк. Паратов үзен Рәимовларга лаеклы кияү дип исәпли. Байлар белән байлар туганлаша торган замана лабаса...

Әлбәттә, Денисның йөрәк түрендә икенче сурәт тә яши. Анысы ерактарак булса да, кайнаррак кебек. Кайсын ярата ул: Банунымы, Туксаба кызы Мәликәнеме?

## Гаврилов

Чыннан да, бәхет дигән нәрсә Күлтәктәге калкавыч кебек: бер караганда, дәү балык аны төпкә алып төшеп китә, икенчесендә тагын дулкыннар өстендә калка. Аның «калкуы» Мулланурга дә уңай булырга охшап тора бит әле. Тик уллыкка Гафиятне алу дөресрәк булыр, ди, хатыны.

Төньяк бистәнең шулай ук төньягында гектарлы мәйданда урнашкан «Апрель» яшелчә хуҗалыгы бу тирәдә атаклы, андагы яшелчәләр ярты Ханкаланы туендырып тора. Директор Гаврилов белән моңарчы килешеп эшләделәр. Альберт Иванович төпле җитәкче булса, Мулланур – ушлы агроном. Тик туксанынчы еллар башында Альберт Ивановичка да нидер булды, ул эшкә кулын селтәп, көннәр буе Ирдеш елгасы буенда балык тотып утыра башлады. Әүвәл хуҗаның мондый сәерлеген Мулланур да аңламыйча гаҗиз булган иде, тик «сер» үзеннән-үзе ачылды. Рэкетирлар Гавриловны почмакка кысканнар икән, үзләренең «ярдәмнәрен» тәкъдим итеп, шактый табышны сул якка каерганнар.

Беркөнне Альберт Иванович Мулланурны да үзе белән балыкка алып китте. Элек документлар салып йөргән күн сумкасы кабымлыкка дигән яшелчә, көмешкә шешәләре белән бүлтәйгән. Гавриловның аңарчы да берәр атна «фестивальдә» йөри торган гадәте бар иде, бу юлы да директоры беркавымнан тагын җиң сызганып эшкә керешер дип юатты Мулланур үзен. Альберт Иванович Мулланурны үз итә, атасы Путанай кешесе Газинур абзый белән электән дус булганнар. Теге чакта – илдә үзгәртеп кору дигән афәт башланмаган иде әле – Мулланурны да эшкә ул үзе чакырды. Яшелчә үстерү серләренә дә өйрәтте. Хәтерли Мулланур, малай чакта әтисенә ияреп Путанайдагы белешләре «Ибан» абыйларга баргалый иде ул, шулчакта кыяр ашаганы, кып-кызыл помидорлардан авыз иткәне гомергә хәтерендә калган. Алар авылында суган белән бәрәңгедән башка нәрсә үстермиләр, кыярны да Путанай ягыннан күреп берничә кеше генә утырта, алары да әллә ни уңыш бирми; шуңа күрә татар мондый шөгыльне бигүк өнәмәде. Ә менә Путанай руслары гомер буе яшелчә үстерде, кәбестәләре хәтта колхоз басуында да күп була торган иде. Җәен-кышын балык тотты путанайлар, йорт саен күпләп чучка асрыйлар иде, игенчелекне бик өнәп бетермиләр, Путанай басуына җир әрәм булмасын дип, Туксаба чәчә иде арыш белән бодайны.

Альберт Иванович үзе белән берничә кармак чыбыгы алган. Икесен үзе салды, берсен Мулланурга бирде. Шәп урын сайлаган директор Ирдеш буенда, уңда – елгага кереп баскан таллыклар, сул якта – гәрәбәдәй сары комлы яр.

Альберт Иванович чишенеп атты. Аның камыт аякларына күз төшергәч, Мулланур елмаеп куйды. Альберт Иванович – озын чандыр гәүдәле, зур бөкре борынлы, зур зәңгәр күзле, озын чәчле бер кеше. Исенә төште Мулланурның: аның әтисе Ибан дәдәй дә озын чәч йөртте; шулчактан ук

калган бер фикер кыйпылчыгы да истә, бар рус кешесе дә озын чәчле була, юк ла, киресенчә, мәгәр кешенең чәче озын булса, ул рус милләтеннән, ди, имеш... Совхозда руслар күп эшли, әмма араларында камыт аяклы Альберт Иванович үзе генә. Татарныкы кебек камыт аяклы. Шуны уйлап көлемсерәде Мулланур. Җитмәсә, директор машинасы була торып, атка атланып йөри. Сугымлыкка да ат ала иде. Хәер, атлар комбинатныкы булып исәпләнә, берничәсен Альберт Иванович төньяк бистәсендәге йортында тота, махсус ат караучысы да бар. Чабышкы атлар иде алар, Туксаба Сабан туенда һәр елны беренче килә. Бәлки, атка атланып йөрүдән аяклары татарныкына охшый башлагандыр дип шаяртырга уйлаган иде, моның артык икәнен аңлап дәшмәде; Альберт Ивановичның холкы катлы-катлы, аңа нәрсә ошаганын кайчак чамалап бетерү дә кыен. Таләпчән һәм кырыс булса да, Гаврилов – кече күңелле, кешеләргә әйбәт директор. Кем әйтмешли, ул бу ягы белән түрәгә охшамаган да: һәрчак ярдәмгә килер, вакыты кемнедер кайгыртып узар. Комбинаттагы бар кешенең ничек эшләгәнен генә түгел, өендәге хәлләрен дә белеп тора һәм, кирәге чыкса, ярдәм итәргә дә әзер. Кайберәүләр аны шушы сыйфаты өчен Альберт Иванович дип түгел, «Айболит Иванович» дип атыйлар. «Айболит»ның аяклары, чынлап та, җайдакныкы кебек кәкре. Сынаулы карашны Альберт Иванович та сизде һәм чалбарын кире киде, бер дә үзе турында сөйләшүне яратмый инде ул, әйтерсең аның өчен дөньяда яшелчәләрнең һәм эшчеләренең мәшәкатьләре генә бар. Ул шуның белән генә яши.

Кармакларны салып, җайлап комга утырдылар. Бераз арырак, чирәм өстенә, Альберт Иванович ашъяулык белән ашау нигъмәтләре җәйгән иде. Дөресрәге, Мулланур монда машинасы белән килеп туктаганда, директорның шофёры Гриша кайнаша иде, «өстәл»не шул корган, хәзер ул читтә, таллыклар артындагы күләгәдә шашлык кыздырырга учак ягып маташа. Бу Альберт Ивановичның үз урыны иде, бистәдә балыкчылар күп булса да, монда берәү дә килеп кармак салмый, беләләр, чирәм өстендәге алачык та, су кырыеннан чыгып торган уклау кебек кармак таягы куя торган җайланмалар да директорныкы. Халык түрәдән куркудан түгел, директорны хөрмәт иткәннән комачаулап йөрми бу тирәдә. Мулланур белгән тагын бер сер бар: Альберт Иванович шулай ялгыз башы балык тотып утыра-утыра да, туйдыра башласа, чишенеп атып, Ирдешкә чума һәм колачлап аргы якка йөзә. Анда бистәгә сыенып ук утырган, ләкин ике араны Ирдеш кенә бүлгән бер авыл бар. Андагы халык таш күпердән совхозга эшкә йөри. Ә Альберт Иванович шул авылда яшәп яткан бер яшь кыз янына йөзә. Мәрьям атлы ул кыз. Татар кызы. Туып үскән Путанаенда Мәрьямгә караганда мең өлеш чибәрләр бар! Тик аның җаны Мәрьям дип сулкылдый.

Кичкә таба була бу, гадәттә. Кояш инде акрын гына Туксаба ягына таба китеп маташа. «Апрель»дәге эшчеләр смена тәмамлап, өйләренә кайтып киткән чак. Шофёр Гриша вахта автобусына утырып маташкан кызның колагына пышылдый: «Шеф бүген балык тота». Тегесенә үзенчә хәбәр бу: әзерләнеп, көтеп тор, янәсе. Тегесе, кеше күрүдән дә тайчынмыйча, Гришаны этеп үк җибәрә һәм:

– Әйт хуҗаңа, йөрмәсен! – ди.

– Мариша, син нәрсә инде?! – ди Гриша, хуҗасы кебек үҗәтләнеп.

Шул арада башкалар да колакларын шомарта, директорның серләрен белү дөньядагы иң тәмле «помидор»дан да тәмлерәк «Апрель» эшчеләре өчен. Кайберәүләр эчтән генә Маришаны тиргиләр, җүләр кыз, үзенә Гаврилов кебек кеше күз салган, ә ул карышып маташа!.. Гриша сөйләшүне бүтәннәр ишетүен теләми, ашыкма дигәндәй, автобус шофёрына баш кага да кызны читкәрәк тарта:

– Әгәр теге чактагы шикелле кертмәсә, урлап китәм, ди, ул сине! Белдеңме?!

– Ха, исем китте! Кем курыккан аннан! Аек килеш килгәне дә юк бит аның!

– Аек барырга курка ул синең янга!

– Курыкса, йөрмәсен җанымны талап! Эчмичә килсен башта. Күз күрер...

Кызның соңгы сүзләре кырыс һәм катгый, шул ук вакытта алар өметле дә: димәк, аек килеш барырга кирәк!.. Тик бу хакта Альберт Ивановичка ничек әйтсен Гриша? Мизгел эчендә Гришаның башына акыллы фикер кибәге очып куна: Мулланур аша җиткерергә! Альберт Иванович байтактан ялгыз башы яши, яман шештән вафат булган хатыныннан соң өйләнергә ашыкмады. Бер дә бер көнне аның янына үзеннән шактый яшь татар кызын җитәкләп килделәр, булачак хатынын алып килгәннәр икән ул чакта директор янына! Эшкә урнаштыруын үтенделәр. Тәкъдир эшеме бу? Гриша Мулланурга кызның сүзләрен төкми-чәчми җиткерде. Калганы агроном эше иде.

Әле кичкә кадәр ерак. Альберт Иванович бүген нигәдер иртәләде. Иртәнге летучканы да аннан-моннан гына уздырды. Югыйсә Гаврилов үтә дә җитди һәм таләпчән җитәкче иде, һәр нәрсәне үзе тикшерә, берәр саргайган кыяр үсентесе өчен дә пыр туздырырга мөмкин иде. «Апрель» җирләре тимерчыбык белән әйләндереп алынган. Мулланур килгәнче үк шулай булган. Моннан берничә ел элек директор каяндыр юан тимерчыбыклы яңа коймалар кайтартты. Аларны өч-биш ел саен буяп тормасаң, каралып, ямьсезләнәләр. Мулланур үз белдеге белән буяулар сөйләште, үрнәк өчен бер савытны үзе белән дә алды. Летучка башланганчы ук шуны директорга күрсәткән иде, тегесе юка иреннәрен кысып елмайды да:

– Татар, ахры, син, – дип шаяртты. Мулланурга аңлашылмаслык киная түгел иде бу, аларның Путанаенда бер генә йортның да буяу әсәре күргәне юк. Урман кырыенда ук булганлыктан йортлар шыгырдап торган бүрәнәләрдән салынса да, капка-койма булмый гадәттә, койма урынына читән генә һәм тәрәзә йөзлекләре дә беркайчан буялмый, шул рәвешле алар кышкы салкыннан һәм җәйге кояштан каралып бетәләр, әмма берәү дә аларны буярга ашыкмый. Моны бер кеше дә гаепләми дә, Путанай йортлары шундый була, алар моңарчы да шундый кыяфәттә булган һәм моннан соң да шул кара сурәттә булырга тиешләр дигән фикер буяу тидерергә ирек бирми йөзлекләргә.

Альберт Ивановичның уе балык тоту түгел икәнлеген Мулланур килүгә сизеп алган иде. Әнә ул Гриша ягына карап ымлады, тегесе җәһәт кенә ашъяулык янына атылды һәм аннан кабымлык белән чирек шешәгә салган көмешкә алып килде. Гриша көмешкәне ике алтын путалы нәни чәркәләргә сала башлады, ләкин Альберт Иванович янә аны ымлап кына туктатты,

Гриша эшне аңлап, кырлы стаканнар алып килде, көмешкәне шуларга агызды. Мулланур төшкә кадәр хәмер эчәргә өйрәнмәгән, гомумән, татар акылы төштән соң дигәндәй, организмы андый нәрсәне кич кенә кабул итә иде. Тик Альберт Ивановичка каршы килеп булмый, ул тустаганны кулына алды, директор икенчесенә пыяла банкадан кыяр алып тоттырды. Гриша тәлинкәгә икенче банкадан гөмбәләр салды, помидор турады, ипи куйды. Директор Мулланурга таба шулай ук баш кагып кына алды да көмешкәсен бер сулышта эчеп бетерде, Мулланур йөзен чытарга да яхшысынмыйча, тустаганын авызына китерде. Аның беркайчанда директор белән чәкештергәне юк иде, бу олпат һәм дәһшәтле кеше белән кара-каршы эчеп утыруны хәтта күз алдына да китерә алмады, шуңа күрә батыраеп китте һәм тамчысына кадәр эчеп куймыйча булдыра алмады; тиз генә кыярга үрелде, аның артыннан икмәк алды, гөмбә капты. Ләкин директор тәгамгә кагылмады да, Гриша аның өчен термоска салкын чишмә суы әзерләп куйган, әмма ул да хуҗасының гадәтләрен (Альберт Ивановичның беркайчан да кеше янында яки читләр белән эчкәне булмады, аның «фестивальләре» мәрхүмә хатыны Марфа Семёновнага гына мәгълүм иде) белеп бетерми булса кирәк, суны зур корсаклы фужерга агызды да кулында тотып тора башлады. Альберт Иванович фужерны алып, суны эчте, кире Гришага бирде, әмма шуннан соң да кабымлыкка орынмады, аның бар кабымлыгы чишмә суы иде, күрәсең. Кендек турысы кыза башлагач, Мулланур кыюланып китте, ул тиз генә машинасы янына барды да аннан кибеттән алганда аяк киеме салына торган тартма күтәреп килде, аны ачып, чүпрәккә төрелгән пистолет чыгарды.

– Альберт Иванович, менә Сезгә нәрсә таптым әле мин, – диде. Үзе ни әйтер икән дип, курку һәм көтү катыш күзләре белән директорга төбәлде. Альберт Иванович пистолетны кулына алды, тикшереп карады һәм Гришага сузды:

– Рәхмәт, Мулланур, – диде ул һәм тагын Гришага ымлады. Тегесе, пистолетны кире тартмага салып, машинага куйды да аннан ялтырап торган винтовка алып килде. Альберт Иванович винтовканы кулына тотмады да. Винтовка затлы иде, автомат рәвешендә, бинокле дә бар. Аннары ул барыбер винтовканы үзенә алды, күрәсең, ул корылган иде, беркавым күккә күтәреп, каядыр төзәгәндәй дә булды. Аннан соң инде җылынырга өлгергән тавышы белән:

– Курыкмыйм бит мин алардан, – дип куйды. – Ә моны, шәп нәрсә, кәнишне, Кирилл, әтинең энесенең малае, Сарматтан алып кайтып бирде, трактор заводында шундый нәрсәләр дә эшләп яталар икән качып кына, – диде.

Мулланур дәшмичә директорга тик аптырап карап утыра иде. «Курыкмыйм мин алардан!» диюен аңлады аңлавын. Паратовлар яшелчә комбинатын үзләренеке итмәкче булып йөриләр. Гаврилов белән Паратов арасында тартыш бара.

Көмешкә дә сүз кушарлык кыюлык бирә алмады әлегә.

– Үзем өчен яшисем килә. Туйдым, – дип куйды ул. – Син буяу алып кайткач, тагы да көчәйде бу теләгем. Үзеңнең менталитеттан узып, барыбер әллә кем була алмаячаксың, Альберт Иванович, дим үзалдыма. Ниемә кирәк

миңа байлык?! Беләсең, әти тирә-юньдә атаклы умартачы иде, аңа кадәр лесхоз директоры. Хәтта кирпечтән йорт та җиткерә алмады, ихатаны койма белән әйләндермәде. Үз җаена яшәде, үз җаена акрын гына китеп тә барды. Байлык артыннан кумады. Мин дә әти яшенә җитеп киләм бугай. Хәтта нәкъ аныкы кебек илледән соң сул колак та шаулый башлады. Ул Паратовларны юк итә алам мин, әлбәттә. Кишка тонка у них! Көтүчедән олигархка әйләнеп кенә бар дөньяны үзеңнеке итеп булмый әле ул.

Аның бу сүзләреннән соң Мулланур сискәнеп китте. Сизде моны Гаврилов һәм:

– Беләм. Көтүче түгел алар. Затлы нәселдән булырга тиеш өлкән Паратов. Кулында ут уйната. «Рождённые ползать летать не умеют» дигәннең киресе. Башлы кеше, оча торган кеше, – дип куйды. Аннан соң сүзен дәвам итеп: – Мирсәетнең Ханкалада связьлары калгандыр әле. Хәйдәровне әйтәм, Паратовларны шуңа куштым мин. Урыннарына утыртсыннар! – диде.

Мулланур аның сүзләренә каршы:

– Абтюков булса гына инде таянычы, – дип куйды.

– Абтюков?! И в воде не тонет, и в огне не горит ул кеше. Тәки исән-сау калды бит. Ә Мирсәетне чөйделәр! Ул Комитетта икейөзле булсаң гына эләгеп торып була шул.

Мулланур Абтюковны бик өнәп бетерми иде, шуңа күрә Гавриловтан аны мактатасы килмәде:

– Энесе Салихҗанның тормышын бозды, ләгънәт! – дип куйды. Альберт Иванович бу кадәресен белми иде, шуңа күрә сораулы карашын Мулланурга төбәде. – Участковый Салихҗан энесе бит аның. Бертуган абыйсының малае. Шуның хатыны белән типтерде дә, Салихҗан, аптырагач, аерып җибәрергә мәҗбүр булды. Малае да асылынып үлде, – дип куйды.

– Район больницасында эшләгән майлы күзле медсестра шул хатынмы инде? – дип сорады. Күрәсең, аз-маз ул да хәбәрдар иде.

– Шул, – диде Мулланур. – Абтюк урнаштыргандыр.

Мулланур аның баягы «туйдым» дигән сүзләрен исенә төшерде һәм әлеге сүзләренә каршы килергә җөрьәт итеп: «Ә балалар?» димәкче иде, Альберт Иванович аның ни әйтәсен сизгәндәй:

– Кара әнә минем абыйны, Назар Ивановичны әйтәм. Өч баласын аякка бастырды да, тегеләре кайда хәзер? Берсе Дубайда, икенчесе Англиядә, төпчеге Германиядә, кайтып күренгәннәре дә юк. Абый алар дип күпме урлады, төрмәгә эләгә язды. Оныклары белән русча сөйләшә алмый абый. Чөнки тегеләрнең туган телләре инглизнеке. Кайтты бер Мюнхендагысы, Сергей исемле иде, хәзер Сержга әйләнгән. Безнең Газинур Гафиятуллин урамына геройның портретын эшләтеп куйган идем бит әле, беләсеңме, нәрсә диде миңа Сергей-Серж?! Ишетсәң, артыңа утырырсың: «Нигә бу идолны куйдың монда?!» – ди. Бу малайлар ирекле илдә яшәсен, кеше булсын өчен немец дзотына капланган герой «идол» булган аңа! Шулай дигән идем, авызны шалт томалады: «Немец җиңгән булса, хәзер бавария пивосы эчкән булыр идең», – ди. Күзен дә йоммый, бәдбәхет! Шуннан, беләсеңме, нишләдем? Минем әти – моның бабасы сугышта аягын өздереп кайткан бит әле – шулчаклы ачу килде, шартлый яздым. Муеныннан гына тотып, бакчага сөйрәп чыктым башта, аннары ыштанын салдырып, койма

буендагы кычыткан белән пешердем тегенең арт ягын! Арттан кәнтәе йөгереп чыккан. «Найн, найн!» – ди! «Гитлер капут!» – дидем дә немкасын ялангач килеш кычыткан өстенә төртеп утырттым. «Найн! Найн!» – дип кычкырып калды арттан. Кич белән абый килеп җиткән, и, тузына, күрсәң! Мин сине болай итәм дә тегеләй итәм, имеш! «Абый, – дидем, – мин үкенәм. Ул малаеңны теге чакта ук кычыткан белән пешерәсе калган икән», – дим. Теге чактагыны яхшы белә абый. Шулай дигәч, шым булды.

Ул бәдбәхет малай мәктәптә укыганда, гаражына алдап алып кереп, Галимә түтиләргә кайткан кунак кызын көчләгән иде. Беләсең бит инде Галимә түтине? Теге, элек безнең кантурда уборщица булып эшләгән? Апасы Степан дигән нефтьчегә кияүгә дә чыккан иде әле? Аннан соң Ханкалага китеп бардылар. Мужым тумасы бит ул, безнең күрше авылдан. Менә шуның бердәнбер кызы чибәр Мариҗанны. Малайны төрмәгә япмасыннар дип, акчалар түләп, йомып калдым. Степаны командировкада иде, шуңа күрә Ханкалага барып, әнисе Гасимә белән лично үзем сөйләштем. Абыйны мәңге тыңламаячак иде, директор кеше үзе ялынгач, тавыш чыгармады тагы. Ничек түзгәндер инде мескен. Җәй көне кайтып торырсыз дип, сезнең Туксабадан йорт сатып алып бирдем. Бу турыда милиция түгел, хәтта күршеләре дә белми калды.

Альберт Иванович сүзен әйтеп бетермәде, кырын яткан җиреннән кузгалды да, винтовканы алып, күл өстендә йөзгән болытларга төзәде. Шуның артыннан ук аткан тавыш ишетелде. Директор бер карганы бәреп төшергән иде.

– Малай чакта әнинең түтәлендәге кыяр орлыкларын чүпләп үзәгенә үтәләр иде, – дип куйды ул һәм бу юлы тустаганнарга көмешкәне үзе агызды. Кулына кашык алып, банкадан гөмбә сөзде, алдына аркылыга туралган кыяр куйды, икмәккә үрелде.

Алар шул рәвешле бик озак сөйләшеп утырдылар. Бу директорның беренче мәртәбә ачылуы иде. Бер караганда, сәер дә, баш-аягы белән хуҗалык эшләренә чумган, башка вакытта хәтта һава хәлен дә иркенләп сөйләшеп булмый торган, бик коры холыклы Гаврилов йомшарып алды һәм әлеге сөйләшү Мулланурның күңелендә мәңгелек эз калдырды. Альберт Ивановичны бөтенләй икенче яктан ачты ул көнне Мулланур. Менә сиңа мә, директор, кырыс холкылы гап-гади түрә дип йөр син аны! Җанында утлар кайный! Бик белдекле, гаҗәеп кеше Гаврилов... Альберт Иванович моңарчы ачыктан-ачык сиздермәсә дә, Мулланур турында да бар нәрсәне белеп тора икән. Аларның уллыкка малай алырга теләүләре хакында да ишеткән. Ул, башын кыегайтып, Мулланурга туры итеп карады да:

– Зөмәрәнең кызы синеке дип сөйлиләр? – дип сорап куйды. Әллә көмешкәдән бераз мәлҗерәде инде Альберт Иванович. Чөнки аның беркайчан да гайбәт сөйләгәне генә түгел, гайбәтчене тыңларга вакыты да юк иде. Мулланурның шулай ук башына киткән иде, ул бу турыда ишеткәч, әүвәл озак итеп көлде, аннары кинәт җитдиләнеп:

– Альберт Иванович! Дорогой Альберт Иванович! Матур гайбәт бу, кәнишне. Миңа бик ошый. Ну, кызганыч. Минеке түгел Зөмәрә! Ышансыңмы, юкмы, теге чакта да мин ул Зөмәрәнең кулын да тотмадым хәтта. Дөресрәге, җай чыкмады. Шакир Рәимов өлгеррәк булып чыкты, – дип куйды.

– Рәимов как собака на сене, үзенә дә юк, кешегә дә юк. Шундый хатынны ташлап кит әле! Әниләре Хәлимә түти минем әни белән дуслар иде. Зөмәрәне кечкенә чагыннан беләм. Во дигән инде ул! Настоящий татар хатыны! Ул Рәимовның артын тискигә кыстырырга кирәк! Койрыгын сыртына салып, Башкала якларына чыгып сызды.

– Аны бит Кирмәнбашның якыны диләр! – диде Мулланур.

– Органнарда бугай иде элек.

– Ай-һай, Альберт Иванович, алай микән, зур эшләр майтарып йөри ди ул!

– Нефтьчеләргә авыл хуҗалыгын торгызу йөкләнде бит. Рәимов Касыйм ягында нефть акчасына зур агрохолдинг оештырган. Беткән авылларны торгызмакчы янәсе.

– Зур эшләр майтаралар алар. Русин дигән бик зур авылны аякка бастырган.

– Майтаралар пычагым, илне капиталистларга сатып җибәрергә әзерләнәләр. Аларның Тамгалы сарыгын Англия күптән патрахасы белән сатып алды инде. Кара син ул Тэтчерның сөйләшү манерын! Күзләренә чыккан Рәсәйне күрә алмавы. Үзе юха елан кебек боргалана! Англия гомер буе Россияне яратмады!

«Ялкау-хөрәсәнне кем яратсын, ди... Кем яратсын, ди, гел сугыш чыгару хакында уйлап йөргәнне. Талап, үтереп баерга теләгәнне?!» – Тэтчерга Рәсәй хакында сорау биргәч, шулай дип җавап биргән, имеш...

– ...?!

– Нигә аптырадың әле, Альберт Иванович! Син әйткән хатынның сүзләрен генә китердем мин. Әнә нинди яла яга ул.

– Алай дисәң генә...

Елга буенда аулакта бу рәвешле сөйләшергә ярый иде. Бигрәк тә салган баштан. Андый чакта адәми зат эчендәгесен бушата.

Аерылышканда Гриша Мулланур абыйсына:

– Мин әйткәнне әйтмәдең. Тагын кертми инде аны Мариша, – дип көрсенеп куйды.

Алар икенче мәртәбә Путанайда күрешеп, ачылып сөйләшеп утырдылар. Альберт Иванович инде өйләнгән, яшь хатыны – элек «Апрель»дә эшләгән Мәрьям атлы бик чибәр ханым. «Мариша» шул кыз була икән инде. Ирдеш аша шул кыз янына йөзгән булган ул. Мәрьям-Мариша Альберт Ивановичка малай алып кайтып бирде. Хәзер ул да буйга җитеп, Ханкалада институт тәмамлаган, күптән түгел өйләнгән дә икән.

Эштән киткәч, Гавриловның җәйләрне авылда уздырганын белә иде Мулланур, шуңа күрә махсус барды, үзе белән затлы хәмер дә кыстырды. Альберт Ивановичның күзләрендә теге чактагы гаярь ут сүрелә башласа да, сүзләре төпле, фикере кискен тоелды. Акыл белән талантны эчеп бетереп булмый шул дип уйлап куйды ул. Шунысы гаҗәп: маңгаен җыерчыклар басса да, Гавриловның чәчләренә һаман кырау төшмәгән, җирән чәчләре һаман да үз төсендә, әмма алар инде кыска итеп алынган иде. Альберт Иванович Мулланурның ни хакында уйлагынын сизеп булса кирәк:

– Мариша яратмый озын чәчне. Рус кебек йөрмә ди! Соң, мин бит инде чын русның үзе булам дим тегеңә! Шуннан көлә башлый! – дип әйтеп

куйды. Аннары сүзне икенчегә күчереп: – Саттылар илне с патрахами, – диде. – Шул дәрәҗәгә барып җиттеләр ки, хәзер бар нәрсә белән янкилар идарә итә, хәтта министр урынбасарларын да алар белән килештермичә куеп булмый икән!

Мулланур аның бу сүзләренә ышанасы килмәгәндәй карап тора иде. Тик әлеге уеннан черки кебек килеп кунган башка фикер бүлде: Гаврилов татарча сөйләшә, ә ул үзе русчага күчте түгелме соң?! «Татар!» – диде үз-үзеннән көлеп Мулланур һәм Гавриловны тыңларга әзерләнде. Гаврилов элеккеге гадәтенчә иреннәрен кысып куйды һәм:

– Рюриковичлардан соң теге чакта башланган смута килер кебек. Шунысы куркыта. Менә син әйт әле, смута башланса мәгәр, мине коткарырга алынырсыңмы, Миша? – диде ул кинәт. Мулланур баядан бирле Гавриловның җыерылган чыраена карап тора иде, Альберт Иванович кичтән «балыкны күбрәк тоткан», ахры, дип уйлады ул. Мулланур ул шулай диюгә, машинасыннан теге затлы хәмерне алып килде, тел очына килгән сүзен әйләндереп: «Мин коткарырга һәрвакыт әзер, Альберт Иванович, менә бит!» – димәкче иде, тик дәшмәде, Гаврилов аның өчен һаман да дәһшәтле бер шәхес бит әле. Күләгәсе дә куркыта элеккеге директорның. Хәер, акыллы кешегә шулай бераз куркып та, шикләнеп тә карый торган гадәт бар инде ул адәми затта.

Мулланур, Гавриловның сүзләрен һаман санга сукмыйча, бер сүз дә дәшмичә үзалдына уйланып торуында булды. Сәясәттән ерак иде ул. Тик тормыш белән сәясәт турыдан-туры идарә итә башлагач, аннан качып котыла да алмыйсың, монысы хак. Шуңа күрә Гавриловны игътибар белән тыңлады.

– Ул чакта Россияне татарлар саклап калган. Теле киселгән, дене кысылган халык тагы Россия өчен күтәрелеп чыгармы икән? Безгә үзебезнең татарлардан түгел, һаман да кордон артындагы кавемнән шикләнергә кирәк. – Беркавым сүзсез торгач, Гаврилов дәвам итте: – Карап торам да, син бит, Миша, мине коткарырга килгәнсең икән... – дип, ул аның кулындагы шешәне алды да кунагын бакчага әйдәде, хатыны тиз генә такта өстәлгә кабымлык әзерләде.

Гаврилов әүвәл үз тустаганына хәмер тутырып салды да, аның ягына борылып та карамыйча, бер сулышта эчеп бетерде һәм бермәлдән елмаеп куйды, бу юлы теле йомшарган иде:

– Менә бит, Мулланур (бу юлы нигәдер чын исеме белән дәште), коткарырга килгәнсең мине кичәге хәлләрдән соң! – дип шаяртырга ук көч тапты. – Замминистрлар турында... – дип, бая өзелгән сүзне дәвам итмәкче булды, ахры, аннан соң кулын селтәде һәм бары: – Рәимов сөйләде боларны, ул, үзәгендә кайнагач, белә торгандыр инде, – дип куйды.

Күренеп тора, Гавриловның сөйләшәсе, күңелендәгесен кемгәдер бушатасы килә иде. Күрәсең, пенсиядәге кешенең байтактан андый әңгәмәдәше булмаган. Кулын селтәп, башка сәясәт хакында сөйләшмик дисә дә, сәясәт ишегалдыңдагы бакчаңа кадәр килеп кергәч, күрәсең, аннан җиңел генә арынып булмый торгандыр. «Если проявить терпение, то можно увидеть, как враги сами себя уничтожат», – диде ул, үзалдына мыгырдап. Аннан соң янә ачылып китте:

– Хәтерлисеңме, бистәдәге мәктәптә син татар классы ачыйк дигәч, мин карарбыз дип кенә кул селтәдем дә, шуның белән шул булды, вак мәшәкатьләр белән онытылды. Син дә кабат искә төшермәдең.

– Хәзер дәүләт үзе татар гимназияләре ача бит. Әйтергә дә куркам, күз тимәсен.

– Әйтмә син, Миша, алайса, чынлап та, күз тияргә мөмкин. Бу илдә бер нәрсә дә даими түгел!.. Бер акыллы баш әйткән, «мәгәр сабыр итсәң, дошман үз-үзен юкка чыгара башлаячак!» дидем бит әле. Дөрес әйтелгән. Бик хак сүзләр. Моңарчы без – татарның милли хисен тыйган өлкән туган – хәзер үз-үзебезне бетереп ятабыз. Кайда русның культурасы, сәнгате?! Ач телевизорны, бар нәрсә читтән кергән хлам йә аның копиясе! Тел пычранды, әдәбият вакланды, арзанлы детектив басып алды. Без нәкъ татарлар кебек, кавемне юкка чыгару белән маташабыз; без ялкаулыктан үз-үзебезне юкка чыгара барабыз, татарлар үзара хөсетлектән! Теге чакта Мирсәетне ничек тәгәрәттеләр! Шул туган тел аркасында бит инде. Имеш, татар теленең киләчәге юк аның! Комитет секретарена каршы барган!

– Аның өчен генә дә түгелдер инде. Шовинистлар Куликов кырындагы бәйрәмне илнең бәйрәм көне итик дигәч, бер төркем татар галимнәре Башкалага хат язган булганнар. Утызлап кеше кул куйган. Барысы исемле кешеләр. Беләсеңме кем оештырган моны? Шул Хәйдәров оештырган булган!

– И шуннан Башкала Инатовның, Беренченең, башына суга, тегесе монықына! Шулаймы?

– Барыбер түземле, сабыр халык татар.

– Берәү шулай ук әйткән, татарның бәхете гомерлек көрәштә аның дигән.

– Безнеке дә шулай... Безнең халыкныкы диюем. Мин элек уйлый идем, рус холкы белән байлык артыннан куа торган кавем түгел дип, һәрбер урында сөйләп йөри торган идем...

Ишектә хатынның башы күренде:

– Альберт Иванович, бер минутка мөмкинме? – дип, ул ирен өйгә чакырып алды.

Мулланур Мәрьямне күреп кенә белә иде. Туксабаның Әлли ягы Вәис абыйларның туганы, хәтта туганнан туганы да бугай әле. Вәиснең малае Сәрдәр артыннан Сарматка ияреп киткән иде, аннан кире кайтты. Абыйсы Газинурның сөйләгәне истә калган: Альберт Иванович яшь чакта баш-аягы белән Мәрьямнең туганнан туган апасы Әнисәгә гашыйк булган. Ул чакта әле Мәрьям бакча баласы гына. Әнисәнең атасы, ул кавем белән канны бозасы юк дип, араларын суыткан, ди, имеш. Ул чакта Гаврилов Ханкалада зур түрә булып эшли, авылга да еш кайта. Урман арасыннан әүвәл таш юл түшәттерде, тора-бара Путанайга чаклы асфальт салдыручы да шул – анысы «Апрель»гә директор булып килгәч. Сиксәннең башында ук Ислемай тавы итәгендәге Крачин сазлыгыннан авыл читендәге чучка фермасына таба үзәнлектә май таплары йөзгән инеш хасил булган; дуңгызлар кырыла башлагач, Гаврилов аның юлын да читкә бора – казыта, актарта; халык сөйләве буенча, канауны бөтенләй башка якка борып, крачинлы инешне тирән чокырга ага торган итеп көйлиләр. Тузгаклы туксанынчы еллар башлангач, Путанай ягындагы урманны кычкыртып таларга керештеләр,

урман аланнары тәртипсез ташланган ботак-сатак белән тулды. Үзенең элемтәләрен файдаланып, моңа да чик куйдырды Гаврилов; киселгән һәр агач саны кадәр яшь үсенте утырту гадәткә керде. Халык телендә Гаврилов хакында әйбәтен сөйләү дә, гайбәт чәйнәү дә дәрәҗә санала һәм ул гадәткә кергән иде.

Ире Әнисәне, дәһшәтле Гавриловтан куркып-көнләшеп, Себер якларына ук алып китә. Гаврилов барыбер алар белән аралашуын туктатмый, чөнки бер туганнары ул эшләгән министрлыкта хезмәт куя, гел аралашып яшиләр; әле мәктәп баласы гына булган Мәрьямне дә егет шул чакта күреп ала.

Альберт Иванович янә «салулый» башлады, эчемлек пары баш миенә тарала башлаган иде, ахрысы, ни әйткәнен онытып, сүзне бөтенләй икенче якка борды:

– Син, Мулланур, ачулансаң ачулан. Мин акцияләрне абыйның малаена бирдем. Хәзер чит илдән торып идарә итәләр бит Рәсәй белән, – диде. – Бәлки, шулай дөресрәктер... Менә мин дә ике кулны күтәрдем бит. Куак артына качтым. Юк, әнә теге койма буендагы кычытканнарны күрәсеңме, шулар артына качтым. Теге чакта абый малаеның артын пешекләгән кычытканнар артына, – дип көлемсерәде. – Ә сиңа рәхмәт, Мулланур. Бу әйберең минем баштагы смутаны ачып җибәрде бит әле, – дип, көлеп саубуллашты. Хәер, аерылышыр алдыннан Мулланурның исендә калган тагын бер сүзе булды элеккеге директорның. Мулланурның җиңеннән тотып, лапас ягына әйдәде дә: – Күрәсеңме бу буяуларны, кичә Гришадан китерттем. Хатын әйтә, раз җәй авылда яшибез дисең икән, наличникларны буят, ди. Үзем буярга алындым. Гришаны кайтарып җибәрдем, үземнең буйыйсы килеп китте әле дидем.

Мулланур абзарда, хуҗасын сизеп, ат кешнәгән тавышка елмаеп куйды. «Альберт Ивановичның җанында ялкын бар әле, шөкер!» дип уйлады ул.

**Икенче кисәк**

## Сөннәтле поп

Тәгәрмәчләре белән күккә караган машина астында ыңгырашып яткан Сәрдәр капылт аңына килгәндәй булды. Бу вакытта аны бәрдергән зур джип кире әйләнеп килгән һәм шофёры аның үлгәнме, юкмы икәнлеген тикшерә иде бугай. Аңында булса да, Сәрдәр үлгән кыяфәттә ята иде. Шофёр кесә телефонын алып:

– Денис Абрарович, всё! Капут этот Сардар! – дип хәбәр салды да китеп барды. Сәрдәр аның: «Что я могу сделать?» дигәнен дә, «Что, что?!! Ничего уже!» кебек җавабын да ишетмәде.

Сәрдәр бу вакытта үлмәгән иде әле. Шул мизгел эчендә күз алдында улы Гайнанның йөзе пәйда булды. Ул тагын ыңгырашты һәм үзалдына: «Кайларда йөрисең икән син, бала?!», – диде. Шуннан соң тагын аңын югалтты.

Ә баласы Гайнан – җиткән егет – бу вакытта бик еракта иде.

Үлем көтеп яткан Сәрдәргә иң якыны Макай булды. Ул Сәрдәрне машина эченнән өстерәп чыгарды да чалкан сузып салды. Йөрәген тыңлап карады, леперди иде. Макай беркавым уйланып торды да яралыны күтәреп торгызды, аягына бастырмакчы булды. Ләкин тегесе капчык кебек ишелә

дә төшә, ишелә дә төшә. Макай мәет хәлендәге Сәрдәрне аркасына салды һәм якындагы урман ешлыгына кереп югалды. Макай куәтле иде, Макай көчле иде. Урман буенча байтак бардылар. Тәбәнәк тау дип аталган җирдә «Әллүки чишмәсе» дип аталган салкын сулы чишмә бар. Макай Сәрдәрне чишмә буена сузып салды, эшләпәсенә су алды һәм аны йөзенә бөркеде. Яралы аңына килмәде, бары су тигән иреннәрен генә кыймылдатып куйды. Якында гына юкәлек булырга тиеш иде. Макай итек кунычындагы кечкенә балтасын кулына тотты да юкә таякларына дип китте. Аның нәни балтасы һәрчак үзе белән йөри. Балта Макайның коралы да иде. Ул аны бик оста ата белә. Яшь чакта Абрар белән көннәр буе балта атып уйныйлар иде. Уенның файдасы булды, балта хәзер Макай кулында көчле корал. Ул аны качып барган куянга тондырса, тегесе сөрлегеп китә, бүрегә атса, ерткычның маңгае ярыла, хәтта зур гәүдәле аю да, маңгаена балта эләккәндә, ыңгырашып куя, бермәлгә сизгерлеген югалта, шул арада Макай аюның йөрәк турысына сөяк саплы пычагын батырып өлгерә. Бу балтасы белән чабып барган пошиның мөгез очын да кыеп төшергәне бар. Бүген балта юкә агачларыннан җайланма әзерләү өчен кирәк иде. Юкә кабыгы белән ныгытып бәйләгәч, ярыйсы гына күтәрмә килеп чыкты. Аны күтәреп йөрергә дә кирәк түгел, бер башы җирдән өстерәлсә дә ярый. Яралы егылып төшмәсен өчен шул ук юкә кабыгы белән нык итеп бәйләп тә куйды.

Әллүки – бу якларда каты тавыш белән челтерәп агучы бердәнбер чишмә. Челтерәве урман шавына кушылгач кына юашланып кала ул, бишек көе кебек кенә ишетелә башлый. Әмма шунысы кызык: урман чишмә тавышы белән шаулый башлый. Аның янында теге алагаем зур таш та ята. Әллә урман эчендә булганга, әллә, чынлап та, агымы кызу, ошбу тавыш әллә нинди көйләр булып ишетелә. Бәлки, зур таш астында мәгарә авызы бардыр, тавышлар шуннан чыга торгандыр? Макай аны теге чакта машина белән дә урыныннан кузгалта алмаган иде.

Сәрдәр чишмә тавышына уянып китте. Колак төбендә барабан каксаң да, күзен ачарлык хәлдә түгел иде ул. Чишмә тавышы уятты. Күрәсең, аны Сәрдәр җаны белән тоя-ишетә иде. Ошбу чишмә турында кызыклы риваять бар. Имеш, борын-борын заманда Шүрәле авылдагы бер кызга гашыйк була. Кыз да битараф түгел икән, ди. Боларның араларында мәхәббәт уты кабына. Күп тә үтми, бу хәлне кызның агасы сизеп ала. Иптәшләре белән җиләккә дип киткән сеңлесе һәрвакыт тулы чиләк белән кайта, калганнарның чиләк төпләре дә яшьнәми икән, ди. Әле алай гынамы соң, җиләкләре бик эре була, үзләре кып-кызыллар, ди. Күңеленә шик кергән агасы бер дә бер көнне җиләккә җыенучы кызларның артларыннан үзе дә иярә. Сеңлесе, урманга җитүгә, иптәшләреннән аерыла да ялгыз башы калын урман эченә кереп югала. Агасы да бара инде моның артыннан. Менә бер аланга килеп җитәләр. Караса, алан уртасында Шүрәле басып тора икән, ди! Юкә кабыгыннан үрелгән кәрҗине җиләк белән тулы, ди! Менә алар күрешәләр, Шүрәле кәрҗиндәге җиләкне кызныкына бушата. Өйгә кайткач, агасы бу хакта атасына сөйли. Тегесе исә бик курка, кешегә әйтсәң дә, ышанырлык хәл түгел бит инде. Әмма озак яшерә дә алмыйлар, кызның буенда бар икәнлеге сизелә башлый. Шуннан соң тиз генә тотып, аны авылның бер аңгырарак егетенә кияүгә бирәләр. Егет тә бик бәхетле инде, чөнки аңа авылның чибәр кызы эләгә бит.

Инде килен булган кыз бер төнне сәер төш күреп уяна. Имеш, туачак баласының маңгай турысында нәни генә мөгезе бар икән! Болай булгач, баласы Шүрәледән булып чыга бит инде! Хур булырмын дип куркып, икенче төнне ул тиз генә урманга качып китә. Алар Шүрәле белән гаилә корып яши башлыйлар. Шүрәле бәбигә юкә кабыгыннан бишек ясый, яшь әни баласын чишмә янында җырлый-җырлый тирбәтә икән, ди. Җыры да мәгълүм:

Мәхәббәттән балам булды,
Әллә хурлык, әллә шатлык?
Хурлыгы ни – белмимен,
Шатлыгы ни, сизмимен.
Йокла, балам, элли-бәү,
Матур көйләр көйлимен,
Безнең мәхәббәт хәлләрен
Бу чишмәгә сөйлимен.
Чишмә аны салыр көйгә,
Һәм, ияртеп искән җилгә
Дөньяларга таратыр,
Әлли-бәлли, бәллүки,
Бу баланы атасы да,
Бу баланы анасы да
Күз карасы күк яратыр...
Әлли-бәлли, бәллүки...

Үзенең хәле турында уйлыйсы урынга, Сәрдәр, аңына килүгә, шул риваятьне исенә төшерде. Үлем якасыннан алган мизгелләрдә нигә бишек җыры ишетелә соң әле?!! «Адәми зат бишек җыруы белән дөньяга килә һәм шул көй аны мәңгелек йокыга озата!» – ди торган иде бабасы... Тикмәгә генә түгелдер, үлем түшәгендә ятканда киленнән – Сәрдәрнең әнисеннән – бишек җыры көйләвен сораган ул... Әнисе: «Бабаңның баш очында әтиең дога укып торды, мин бишек җыры җырладым. Бик сөенде инде, күз карашы белән рәхмәт әйтте. Елмаеп үлде каенатам. Урыны җәннәттә булсын», – дип искә ала иде.

Шулчак Сәрдәрне ток суккандай булды: «Бишек җыры белән дөньяга килә, үлгәндә дә шул бишек җыруын тыңлаган кебек кенә, йокыга киткәндәй генә китеп бара. Бишек җыры көенә, «Әллүки» көенә мәңгелек йокыга китеп бара адәми зат! Йа Хода, хикмәтле серең бик гади икән ләбаса... Мин бит шул көйне үзгәртергә теләп, бөтен гомеремне әрәм иткәнмен түгелме соң? Һәр милләт баласының үз «Әллүки»е була. Канында ул аның, әлеге көй аның кан тамырларында туганда ук ага... Шуны тот та үзгәрт, имеш...» – дип уйлады ул. Сораулар моның белән генә бетмәгән иде: әллә кайчангы бабасы нигә исенә төшә әле?! Аның беркайчан да, хәтта төшенә дә кергәне юк иде бит! Үз гомерендә икенче мәртәбә күрә ул аны. Беренче тапкыры өйләнгәч тә булды. Хатыны Любаның апасы Лена, бала табуга, ире, малай минеке түгел дип, ташлап китте дә беркавым аларда торып алган иде. Күп тә яшәмәде, тик ул көннәрнең һәркайсы ел булып тоелган иде шулчакта. Лenaның бишектәге баласы бик елак. Берничек тә тынычландыра алмадылар аны. Бишектә (Моңарчы сабый агач бала караватында ятты, Сәрдәр күршеләрнең чормасыннан бишек табып алды) тирбәтү дә ярдәм

итмәде. Бөтен өйне аякка бастырды малай. Шуннан соң Сәрдәр, башына ниндидер фикер килеп, бишек янына үзе килде. Нәкъ әнисе кебек исендә калган такмакларны көйләргә кереште. Ул такмак әле дә булса тел очында:

Әлли-бәлли итәр бу,
Мәдрәсәгә китәр бу...

Шуннан соң бала тынычланмасынмы!.. Бөтен өй шаккатты моңа!.. Үзенең дә корсагы борынына җитә язган хатыны Люба исе китеп, сокланып читтән карап торган иде тиздән яшь эти булачак иренең бу кыланышына. Әмма бала беркавымнан янә еларга кереште. Бу юлы тагын да катырак елый бугай... Сәрдәр, кулын селтәп, чыгып китте. Аны ул мизгелләрдә үзенең тиздән туасы баласы күбрәк борчыды бугай. Ул да шундый елак булса?!

Беравыктан ул ачык тәрәзә аша янә бишек җыруы ишетте. Лена иде монысы:

Спи, моя радость, усни...

Шуннан соң малай янә тынычланды һәм елавыннан да туктады!.. Бик сирәк ишетте аның елаган тавышын Сәрдәр. Хәер, алар үз йортларына кайтып киттеләр. Сәрдәр ул кадәрлесе белән башка кызыксынмады. Шулай да менә ул хатирәләр капылт яңарды бит әле!.. Һәркемгә үзенеке кирәк шул! Гайнанга бишек җыруын еш кына үзе дә көйләде. Тегесе шундук тынычлана торган иде.

Шулчакта үз гомерендә икенче мәртәбә бабасын төштә күрде ул.

Сәрдәр күп итеп үпкәсенә һава алды да беркавым тынып торды. Һәм аңын югалтты, күкрәгендәге соңгы йотым сулышы, нәни кошка әверелеп, аны ташлап очып китте. Нәкъ шагыйрь язганча: очып китте шулчак дөнья читлегеннән тарсынып күңеле кошы. Үлем алдыннан башына килгән баягы уй-фикерләрне ул беркемгә дә сөйли алмас инде. Малае Гайнанга да сөйли алмас...

Адәми затны җан яралганда да, гомере өзелгәндә дә, шул берүк җыр каршы ала, озата бара икән: ул – бишек җыры!.. Беренче һәм соңгы мәртәбә туган телендә яңгыраган әллүкие... Үзенең газиз татарыныкы!..

Хушын җуяр алдыннан Сәрдәрнең колагына бишек җыры белән бергә әле тагын поезд тәгәрмәчләренең келтерәгән тавышлары да ишетелгән кебек булды... Имеш, ул поездга утырып өлгергән икән, улы Гайнан утыра алмаган, поезд артыннан чаба. Тиздән менә-менә куып җитәр кебек...

Имеш, Сәрдәр утырган поезд җир асты юлыннан бара икән. Мәңгелек юлы икән бу. Алда бернинди яктылык та юк...

* * *

...Товар поездында дала буйлап тәүлектән артык барганнан соң, сирәк кенә булса да, авыллар шәйләнә башлады. Гайнан берәр авыл тирәсендә сикереп төшеп калырга ниятләде. Өс-башы чыланган, өстәвенә үтереп ашыйсы килә. Алда авылга охшаган корылмалар күренә, елгасы, аннан читтәрәк чиркәве дә бар кебек. Чиркәүләр икәү икән. Берсе авыл читендә үк. Мөгаен, бик зур авылдыр. Поезд да тизлеген акрынайта төшкән иде, егет, уңайлырак урын сайлап, юл читенә сикерде. Шактый каты төште бугай, байтак вакыт урыныннан тора алмыйча ятты. Күз алларындагы караңгылык пәрдәсе ачылгач, кыймылдап карады, уң аягы тездән авырта,

басып булыр кебек. Ул, кулларына таянып, дүртаякланды, аннан соң сак кына күтәрелде дә, берәр таяк-мазар булмасмы дигәндәй, елга буендагы куе таллыкка таба титаклады. Су буенда ботак-чатаклы кәкре таяк табып алды һәм, аксый-аксый, яр буйлап авылга таба китте.

Беркавым баргач, күзенә ком өстендә карамчык күренде. Якыная барган саен, әлеге карамчык кеше гәүдәсе сурәте кебек шәйләнде, кемдер гәрәбәдәй сары комлыкта кызынып ята иде. Тик моның киемнәре бар түгелме соң, шунда гына төбе белән комлыкка кадалган кармак чыбыгы, яр кырыенда целлофан пакет, иске чиләк ауный. Балыкчы шул рәвешле ял итәме, яки чирткәнне көтеп, йоклап киткән идеме? Чиләк янәшәсендәге тастымал чаклы газет өстендә киселгән икмәк, берничә кыяр таралып ята. Моны күргәч, Гайнан, эчен тотып бөгелде һәм, титаклый-титаклый, шул урынга килде, хәтта хуҗа ягына борылып карап, аңа сүз кушарга да чамасы юк иде, комсызланып, икмәккә ташланды һәм, авызына ризык кергәч кенә, комлыкта таралып яткан чандыр гәүдәле ир-атка күз ташлады. Тегесе йоклый иде булса кирәк, кармагына балык эләккән, калкавыч су өстендә бөтерелә. Гайнан якынрак килде, иелеп, йөзенә карады, чынлап та, гырылдап йоклап ята балыкчы. Гайнан газета өстеннән тагын бер сынык белән бу юлы кыяр да эләктерде һәм, тыгыла-тыгыла, чәйнәргә кереште. Беркавымнан тамагы туйды кебек. Балыкчы һаман уянмый. Гайнан кармак таягын кулына алды һәм калкавычны тартып чыгарды. Кармакка шактый симез шыртлака эләккән иде. Гайнан аны чиләккә салырга уйлап, тагын балыкчы янына килде, чиләктәге су түгелеп бетмәгән, хәтта берничә балык та сикергәли. Ул шунда гына комнан башы чыгып торган аракы шешәсен күрде һәм аны тартып чыгарды. Яртылаш эчелгән шешә кәгазь бөке белән томаланган иде. Аңлашылды, балыкчы исерек, гырылдавы да шуңа охшаган.

Тамагы туйгач, ул үзенең киемнәре юеш икәнлегенә игътибар итте, су өстеннән искән салкынча җил калтырата башлады. Ул кәгазь бөкене тартып алды да авызыннан гына аракы чөмереп куйды. Гәүдәсенә шундук җылы керә башлады. Тик эчеп бетермәде, шешәсен комлыкка кире батырып, хуҗаның уянганын көтәргә уйлады һәм, кыяр чәйни-чәйни, читкәрәк китеп, кояшта кызган комлыкка утырды, дымлы костюмын салып, янәшәсенә җәйде. Тик, шешәне урынына куйганда, пыяланың чык итеп нәрсәгәдер бәрелгәне ишетелде. Гайнан, шешәне күтәреп, чокырга кулын тыкты, чынлап та, шешә тимергә бәрелгән икән. Гайнан аны казып чыгарды. Үзе кечкенә генә булса да, шактый авыр тимер кисәге иде ул. Шакмаклы тимер. Бакырга охшаган. Тышына кызыл балчык каткан. Гайнан тырнак очы белән балчыкны кыра башлады, бакыр кисәге булып чыкты, ахры, шуңа күрә сары төстәдер, шул сәбәпле авырдыр дип уйлады ул. Әмма нигәдер тамгаланган, «999,9» дигән саны аермачык күренә. Гайнан аны учында сикертеп алды да кырыйга ташлады.

Хәзер инде йокы баса башлады. Таралып китәргә язмаган икән, Гайнан авыл ягыннан үзләренә таба җил-җил атлап килүче матур сынлы хатын-кызны күреп, куркуыннан җәһәт торып басты, газета өстеннән тагын бер ипи телеме алып, чалбар кесәсенә яшерде, комдагы аракыны тагын да тирәнгәрәк батырды, хәзер аның башы гына күренер-күренмәс булып тора. Ул костюмын эләктерде дә, чатанлап, таллыкларга таба китте. Эчкә үк

кереп, шуннан яшеренеп күзәтергә уйлады. Хатын, кара халатлы бик чибәр нәрсә, килеп җитүгә, йоклап яткан ир-атка таба иелде, аның ләх исерек икәнлеген болай да белә иде, ахрысы, сулыш алуын күргәч, тынычланды һәм әүвәл сак кына:

– Паша! Салкын тия бит монда сиңа! Йә җен алыштырып китә! Су буенда йоклап ятсаң! Әйдә, өйгә! – дип эндәште. Тегесе селкенергә дә уйламады, хатынның ачуы килә башлады. – Ты, академик чёртов! А ну-ка, вставай! Алкаш хренов! – дип тарткалый ук башлады. – Мин аны китапханәдә көтеп утырам. Ә ул! Мин генә тузан суларга тиешме әллә ул китаплар арасында!

Тегесе селкенмәде дә. Хатын, аны уяту уеннан кире кайтып булса кирәк, су буена килде, халат итәген ботларына чаклы күтәреп, эчкәрәк керде, шул килеш беркавым кояшка йөзен куеп торды. Тик озак юанмады, ярга чыкты да ир-атка тагын бер мәртәбә дәшеп карады һәм, кулын селтәп, читкәрәк китеп басып, халатын салды, аны Пашаның баш астына кыстырды һәм шуннан соң су керергә ниятләде бугай. Тик ул кинәт артына борылып карады, ком өстендә яткан баягы бакыр кисәгенә күзе төште. Хатын аны тиз генә кулына алды, әйләндереп карады да ачулы итеп Паша ягына карап алды. Менә аның янына килде һәм: «Ты, академик, сволочь!» – дип, аңа аягы белән төртеп алды. Аннан соң бакыр кирпечне ком өстендә өелеп торган киемнәре астына яшерде. Тиз генә як-ягына каранып алды.

Менә ул, кеше-кара юклыктан файдаланып, күлмәген салды, анадан тума шәрә килеш суга керде һәм колач салып йөзәргә кереште. Гайнан суламыйча да утыра иде. Гади кара халат кигән хатын-кыз шундый матур сынлы булыр дип кем уйлар, ди! Ялангач сылу аңа гүзәл Су анасы кебек күренде. Ул, батыраеп, качкан урыныннан чыкты һәм, аксак икәнлеген дә онытып, җәһәт кенә баягы урынга килде, шешәне тартып алды да янә таллыклар арасына качты. Шушы мәлдә нигәдер үзенә гайрәт, кыюлык өстисе килеп китте бугай, әүвәл, бөкене теше белән генә йолкып атты да калган аракыны чөмерде. Чынлап та, гайрәт керде, шуның белән бергә башына әллә хатын янына суга чумаргамы дигән уй да килде. Бу гамәленнән аны нидер тыеп калды, өстәвенә «Су анасы» да – Су анасының кызыдыр әле – ярга чыгып килә иде. Сөртенергә сөлгесе булмаганлыктан, хатын кояш нурларында беркавым анадан тума килеш басып торды.

Гайнанның отыры кытыгы килә башлады. Үзе дә сизмәстән, качкан урыныннан калкып та куйды. Мондый матурлыкны яшь егетнең киноларда гына күргәне бар, әмма ул кино гына лабаса! Ә монда шәрә матурлык каршысында ук! Йөрәге дөп-дөп тибәргә кереште. Аны иң гаҗәпләндергәне тагын шул: кара халат эченә кыз-хатын шундый матурлыкны ничекләр итеп яшерә алган? Әле генә исерек ирен уятып азапланучы бер гади хатын иде ләбаса бу фәрештә!

«Фәрештә» озак юанмады, әллә ят күз карашын тойды инде, ялт-йолт як-ягына каранды һәм башта күлмәген киде, аннары ирнең баш астыннан халатын тартып алды. Бу юлы исерек ирне көйләп тормаска булды, чиләктәге балыкларны комга сипте дә, елгадан су алып чыгып, Паша дигәннең башына койды. Хәсрәт балыкчы мыгырдана-мыгырдана уянды, комга тезләнде, әүвәл карашы белән нидер эзләгән кебек булды, аннары хатынга күтәрелеп карады да:

– Сарби, я акулу поймал! – дип куйды. Дүрт аякланган килеш куллары белән ком өстен капшарга кереште, күрәсең, теге шешәне эзләве иде. Сарби аны күтәреп торгызды һәм, култык астына кыстырып, авылга таба алып китте. Кармак та, газета да, аның өстендәге сыңар кыяр белән икмәк валчыклары да, балыксыз чиләк тә шул килеш утырып калдылар. Яр буенда, нишләргә белмичә аптырап, Гайнан белән бергә комда әвәләнгән шыртлака, чабак балыклары гына сикерешеп калды...

Пашаның монда тиз генә әйләнеп килмәячәге көн кебек ачык; Гайнан, инде бу юлы шикләнмичә яшеренгән урыныннан чыкты да, берни булмагандай, балык тотарга кереште. Үзе һаман нишләргә, кая барып сыенырга дип баш ватты. Шактый гына балык та эләкте тагын үзенә. Аларны пакетка салды да, калган аракыны чалбар кесәсенә тыгып, авылга таба атлады. Тик авылга килеп җитмәде, байтактан тәбәнәк тау башындагы чиркәүне күзәтә иде ул. Чиркәүләр икәү булып, берсе авыл читендә кебек күргән иде. Анысы шактый җимерек хәлдә, өстәвенә, анысы аларның Сарматындагы чиркәүләргә бик охшамаган да. Гайнан соңыннан гына аның лютеран чиркәве икәнлеген белде. Әби патша заманында монда яшәгән немецлар салган булган, ди.

Сәгатьләр буе карап утырса да, чиркәүгә керүче-чыгучы да, ул тирәдә кайнашкан кеше заты да күренмәде. Авылга кереп, бер белмәгән кешенең капкасын шакыганчы, әүвәл йокы туйдыруың, өс-башны рәткә китерүең яхшырак булыр дип уйлады. Аның хәлендә мондый кыяфәттә кеше-кара күзенә чалыну шүрләтә дә. Шикләнеп тикшерә башласалар, участковыйга әйтсәләр?.. Кемлеген ачыклау өчен Сарматка хәбәр китә калса – бетте, милициядәге мәгълүмат бандитларга көнендә үк ирешәчәк!..

Чиркәү эченә аяк басуга, каршыда, түрдә үк, хәтта Христос сурәтеннән дә өстәрәк Сармат чиркәвендә күргән икенче сурәт тора. Ул аны элеккеге танышыдай яктырып каршы алды, өстәвенә тәрәзәдән дә нәкъ шунда нурлар сирпелә, ул махсус шулай итеп куелган, яктылык туп-туры аның өстенә төшә. Гайнан якынрак килеп карагач күрде: әлеге яктылык тәрәзәдән түгел, янәшәдәге, хәтта бераз өстәрәк эленгән алтын кысалы сурәттән икән. Анда – Мәрьям ананың якты чагылышы. Кинәт егетнең башы әйләнеп киткән кебек булды, Мәрьям ананы бая су буенда күргән хатынга охшатты ул. Әллә, киресенчә, ул матур хатын Мәрьям анага охшаган инде? Су буенда очраткан хатын Сарматта калган сөйгән кызы Фатыйманың әнисе Фәгыйләне дә хәтерләтә кебек.

Ул чакта Фатыйма белән очрашуны тыйдылар Гайнанга. Әнисенең рус милләтеннән икәнен ишеткән атасы: «Йөрмә, читләр белән канны бозасы юк әле», – дигән. Гаиләдә ата сүзе төп сүз иде. Фатыйма селкенә дә алмады, алар аерылыштылар. Бу хәлгә Гайнанның күңеле бик рәнҗеде. Ул Фатыймага әйтеп тә, аңлатып та карады: «Минем әти Сарматтагы болгар милли оешмасы җитәкчесе бит, кан бер безнең, – диде. – Теләсәң, муллалыкка укыйм», – дип ялынды. Тик Фатыйма: «Әти сезнең өйдән иман качкан дип әйтә», – дигән сылтау белән һаман каршы торды. Соңрак егет: «Мин – атеист! Ике динне дә өнәмим!» – диде. Фатыйма аның ягына борылып та кармады. Шул көннән Гайнан сөйгәне белән арасын өзгән ике динне дә күралмас булды! Ләкин болар эзсез узмады, күкрәк турысында,

эчтә үк, авырту тойды. Йөрәктә түгел иде ул, нәкъ менә «күкрәк авызы» дигән төштә. Рәхмәт төшкере, тора-бара авырту бетте, Гайнан аның хакында бөтенләй онытты...

Бу чиркәүдә бер кич кенә булса да кунып чыгарга мөмкин иде. Ташландыкка охшамаган, артык бай җиһазлы булмаса да, эче җыештырылган, хәтта шәмдәлләрдә яңа шәмнәр дә күренә.

Гайнан урамга чыкты, кеше-кара юклыгын тагын бер кат тикшерү иде исәбе. Күрәсең, монда кеше сирәк килә, авылы да ташландыкка охшаган. Тик йортлары яңа әле. Димәк, күптән түгел монда тормыш гөрләгән.

Кинәт читтә, авыл кырыенда ук тавыш ишетелде. Гайнан, кешегә күренмәс өчен, бур кебек иелеп диярлек, шул якка атлады, тик ерак китмәде, бер калкулык артында тукталып калды. Сазлык кебек җирдән берсе авыл читендәге фермага таба көтү куалаганга охшаган. Үзе дә, маллары да моннан күренми, тавышы гына ишетелә, ферма түбәсендәге Ак калай аермачык булып ялтырап тора. Аны күргәч, Гайнанның эченә корт керде: ферма заманча итеп салынган озын, зур бина иде. Күрәсең, монда халык читтән килеп йөреп эшли торгандыр, чөнки шул көтүчедән, баягы балыкчы һәм аның хатыныннан башка кеше-кара күзгә чалынмый.

Менә эңгер-меңгер төшә башлады. Чиркәүгә кире кайтканда гына күрде ул: караңгылык пәрдәсе тирә-юньне чорнап алгач, ферма янындагы бер йортта ут кабынды. Мөгаен, каравылчы-мазардыр дип уйлады егет. Ләкин монда кемнеңдер килеп чыгуы бар, милициягә әләгәсе килми иде аның, шуңа күрә чиркәүгә ышыкланып, шул тирәдә йөрде. Күз тәмам бәйләнгәч, чак кына чиркәү янында казылган чокырга мәтәлми калды. Нигәдер нәкъ шул тирәне казыганнар, балчыгы яңага охшаган. Бәлки чиркәүгә кышка җылылык кертергә исәплиләрдер дип уйлады Гайнан. Бу вакытта кеше-кара йөрергә тиеш түгел инде, егет эчкә узды һәм фуфайкасын астына җәйде дә идәнгә чүмәште. Ару-алҗуы тәмам җиткән, нинди кыяфәттә булса да, таңга кадәр йоклаячак инде ул хәзер.

Егет таң атар алдыннан тыштагы тавышка сискәнеп уянып китте. Нәрсәдер тышкы якта, нигез буенда ук, кыштыр-кыштыр килә, чак-чок бәрелгән тавышлар да ишетелә. Гайнан тын да алмыйча байтак тыңлап ятты. Монда керә күрмәсеннәр дип курка иде ул. Хәзер генә аңлады, тыштагы кеше арбага ташмы, кирпечме төйи иде, шакылдаган тавышлар шуңа охшаган. Кемдер чиркәүне нигезеннән сүтә башлаган, ахры, дип уйлады ул һәм беркавымнан, курка-курка гына, ишектән башын чыгарды. Тик бу вакытта кемдер дигәне кул арбасын этеп китәргә кузгалган, Гайнан аның аркасын гына күреп калды. Урамга чыкты, чокыр янына килде. Чокыр тулы кызыл кирпеч, балчык астыннан зур мәрмәргә охшаган таш кырые да күренеп тора. Димәк, авылда кеше бар, чиркәүнең кирпечен өенә ташый торгандыр. Үзен куркыткан тавышның сәбәбен аңлагач, ул янә эчкә керде, баягы урынына сузылып ятты. Күзеннән йокы качкан иде инде. Ни гаҗәп, күңелендә куркуның әсәре дә калмаган, киресенчә, тынычланып калгандай. Ул кабат торды, шәмдәлдәге шәмнәргә ут элеп чыкты. Чиркәү эче яктырып китте. Хәзер аңа каршыдагы изге Мәрьям ана сурәте аермачык күренә. Ул төбәп, аңа карап тора шикелле. Сурәт кайчандыр әнисе өй почмагына куйган сурәткә охшаган. Шуның өчен әтисе белән күпме талаштылар. Ахыр

чиктә барыбер әнисе җиңде. Сурәт белән малайны алам да ташлап китәм дип куркытты бугай әтисен.

Менә изге Мәрьям ана аңа күз кыскандай булды, килдеңме ди кебек иде ул. Гайнанны әнисе, әтисе күрмәгәндә, чукынырга өйрәткән иде. Ул көнне бик яхшы хәтерли ул, чөнки кичен аны әтисе үзе белән кичке намазга мәчеткә алып китте. Мәчет эченә керергә курыкканы да хәтерендә, чукынганын белеп, Алла бабай аны яшене белән сугып үтерер кебек. Тик кермичә дә булмый. Догаларның кайсын укырга кирәк икән, Алла бабайгамы, Иисускамы? Гайнан куркуыннан икесен дә укырга булды.

«Боже, очисти мя, грешнаго, и помилуй мя».

Аннан соң мәчет каршында кинәт туктап калган әтисенә күтәрелеп карады. Ул малаена ишетерлек итеп шулай ук дога укый, ләкин аның догасы Алла бабайга иде. Малай әтисе артыннан кабатлады:

– «Әллааһүммәфтәх лии әбүәәбә рахмәтик» (Аллаһым! Миңа рәхмәт ишекләреңне ач!)

Әтисе шуның артыннан ук мәчеттән чыкканда укыла торган доганы да ятлатты. Күрәсең, гел әнисе янында кайнашкан улына шикләнеп карый иде Сәрдәр абый.

– «Әллааһүммә инниии әс-әлүкә мин фәдълик» (Аллаһым! Синең фазлыңнан сорыйм), – диде ул, малайның башына дәү кулын куеп.

Мәчеткә керделәр. Аяк киемнәрен салып, эчкә уздылар. Әтисе янәшәсенә малай да намазлыкка басты. Мәчет эче тып-тын. Ниндидер илаһи, рәхәтлек бирә торган тынлык иде ул. Тик бераздан арттан кыштырдаган тавышлар ишетелә башлады. Алла бабай аның Иисуска укыган догасын ишеткән дә, хәзер аның иманын укытырга Гайнан иң курыккан явыз җанварын – тычканны җибәргән. Тычкан башта аның колагын тешләп өзәчәк, аннары бөтен тәнен кимерергә керешәчәк!..

Куркуы шулкадәр көчле иде ки, тагын бер кыштырдау ишетелүгә, малай, аңын җуя язып, намазлык өстенә сыгылып төште...

Гайнан дивар кырыендагы өемгә сөртенә язды. Бая су буенда күргән бакыр «кирпечләре» рәт-рәт төзелеп куелган. Берсен алып, күзенә якын китерде, боларга да шундый ук «999,9» тамгасы сугылган. Күрәсең, шәһәрчектә бакыр коя торган завод бардыр дип уйлады ул һәм «кирпечне» урынына ташлады.

Беркавымнан шәм яндырып, аны Николай Чудотворец сурәте алдына куйды. Бу дошманнарыңның гаепләрен гафу кылып, аларга саулык теләгәндә шулай эшләнә иде. Сарматта калган бандитлар исәнлегенә куйды ул аны. Бәлки, шуның белән тегеләрнең күңелләре йомшарып, аңа булган ачуларын онытырлар. Аның да, дошманнарның да гөнаһларын юкка чыгарыр Гайсә пәйгамбәр хикмәте...

Кинәт яман шыгырдап, ишек ачылып китте һәм анда хатын-кыз башы пәйда булды. Гайнан шундук таныды аны, бу кичә елга буенда ул читтән сокланып күзәткән матур хатын иде. Ул Гайнанны күрүгә:

– Господи! Отец Григорий?! Это Вы, наверное?! Когда Вы приехали? Мы Вас ждали дома, – дип, аңа таба якынлашты.

Гайнан, каушавыннан бер шәм алып, хатынга сузды. Моның белән вакытны үз файдасына отуы иде аның. Шул арада баш мие отыры котырып

эшләргә кирәкшеп: димәк, аны ниндидер Григорий атакай дип кабул итәләр?.. Монда яңа поп киләсе булгандыр, аны йөзгә белми бу хатын...

– Тәки туя белмәде инде бу Ермолай бандитлары! – дип куйды хатын. Гайнан аптырап, аңа карады. Хатын сүзенә ачыклык кертте: – Бар монда башкисәрләр. Ермолай дигән бандит шайкасы. Тизәккә җыелган кебек бер секретный завод тирәсендә кайнашалар. Алтын кою заводы инде ул. Секрет дигәч тә, бар кеше белә. Башкаладан килеп ачтылар.

Гайнанның бернинди завод-мазарда гаме юк иде, ул мизгел эчендә Григорий атакайга әйләнде дә куйды. Юлда угрылар талады дип аңлаткач, чынлап та, ышанырлык, «атакай» рәвешен туры китереп, чиркәү гореф-гадәтләрен үтәде. Хатын Сарби Даниловна атлы икән, алар Пал Палыч (Пауль Вольфганг) белән монда Алманиядән практика узарга килгән тюрколог-аспирантлар. Кулдашы белән бер түбә астындагы йортта аерым бүлмәләрдә яшиләр. Остазлары Данил Френкның бар Россия буенча җыйган архивын тәртипкә китерәләр икән. Остаз дигәне Сарбиның әтисе икән. Гайнан әлегә бары шуларны белде.

Сарби Даниловна аны өенә чәйгә чакырды һәм сүз уңаеннан поп яшәргә тиешле фатирның күптән әзер икәнлеген дә әйтеп алды. Урамга чыктылар. Сарби, теге чокырны күреп, авыр сулады һәм Гайнан-Григорий аңламаса да, аңа да ишетерлек итеп:

– Ну, Тукаш! Тик тора белми. Тәки үз дигәнен эшләр, ахры, бу үҗәт Гоголь-Моголь! – дип куйды.

«Паратов белән Рәимов чиркәүгә күптән поп эзлиләр иде инде. Менә мин табып бирәм попны аңа. Солтан «үз побын» китермәкче була. Паратов үз ягына каера. Берсенеке дә булмаячак поп монда. Сарби побы утырачак чиркәүдә!» – дип, үзалдына сөенеп тә уйланды хатын.

Гайнан берни сораштырмады, үз җае белән хатынның барын да сөйләячәге болай да күренеп тора. Дөресен генә әйткәндә, аның үз уй-борчулары көчлерәк. Григорий түгеллеге барыбер ачылачак бит инде, кайчан булса да фаш ителәчәк, адәм хурына калачак; татар башы белән атакай роленә керергә маташа… Соңрак бу гамәле зур фаҗига китереп чыгармасмы, бәлагә тармасмы ул?! Берсеннән котылдым бугай дигәндә генә, икенче бoҗрага тыкмасмы муенын?! Муены берәү генә бит... Әлеге шик-шөбһәне икенче уйлары йомшарта: хатын бик чибәр, аның янында Гайнанга ничектер аңлатып булмаслык рәхәт, тыныч, җылы иде. Фатыйма белән икәү генә калгандагы халәтне кичерә түгелме соң ул?.. Эреп ага яза бит инде. Эчендә – ут, җанын җылы йон йомгакка төреп куйган кебек.

«Аллага тапшырдык! – дип уйлады ул үзалдына, хатын артыннан авылга таба атлый-атлый. – Господи, помилуй... Спаси, Господи!.. Или бәндәңнең гөнаһлы гамәлләреннән үзең спасайся! Аллаһы әкбәр! Амин!»

Шул рәвешле Гайнан «Григорий атакай» булып китте...

...Григорий атакайның исә поп булу хакында төшенә дә кереп караганы булмады моңарчы. Язмыш үзе поп ясады аннан.

Сарматтагы илгә атаклы машина-трактор заводы тирәсенә, майлы калҗа эләктерергә исәпләп, бар илдән козгыннар җыелды. Козгыннарның оясы шактый еракта, читтә икәнлеген берәү дә белми иде.

Гайнан кебек буй үстергән Сармат малайлары тормышыннан да читтә калмады завод тормышы. Әзер машиналарны сату өчен йөзләгән дилер-фирмалар хасил булды, аларның башында чын башкисәрләр иде. Үзара талаш, үтереш башланды. Ат аунаган җирдә төк булса да кала дигәндәй, мәктәпнең соңгы сыйныфында укучы яшүсмерләр, тегеләр әвәрә килгән арада запчастьларны булса да эләктереп калырга тырышалар һәм җәһәт кенә яшереп тә куялар иде. Ә запчасть сорап, заводның үзенә турыдан-туры килүчеләр бихисап. Тик бар кешегә дә максатына ирешү тәтеми. Өч малай, өч сыйныфташ Гайнан, Роберт һәм Илья, аннан-моннан урлап «җыештырган» детальләрне менә шуларга сату эшен көйләп җибәрделәр. Үзләрен яшь бизнесмен-эшмәкәрләр итеп хис итте алар. Сармат елгасыннан ерак түгел бер чокыр-ерганак буенда ташландык чиркәү бар иде. Аның тимер ишеген каерып ачтылар да шуны склад иттеләр.

Гайнанны атасы өч ел элек, Сармат уртасындагы гимназиядән алып, елганың аргы ягындагы рус мәктәбенә күчергән иде. Анда хатынының туганнары яши, торуы да шуларда, Сәрдәр акча белән ярдәм итеп тора. Хатыны Люба вафат булгач, ике балага күз-колак булу атаның үзенә генә кыен булса да, балачактан терекөмеш кушаматы алган тиктормас малай ялгыш юлдан китәр дип шикләнсә, күңелендә генә йөрткән башка хыялы да бар иде. Заманалар капылт үзгәреп китте, шуңа күрә татар-болгар телең белән генә әллә кая ерак китә алмыйсың, ана канын сеңдерергә кирәк дип фикер йөртте ул. Аннан соң ата телен такы-токы белгән малайны читкә җибәрү кулайрак булачак. Моның белән ул ике куянның койрыгын тота: «Рус» малайны күздән яшерә, яшь хатыны колак итен ашаудан туктый... Ә малай өчен шатланырга гына кирәк. Әтисе аның киләчәге хакында уйлап, шулай эшли ләбаса! Яшьләргә тиздән зур юллар ачылырга тора!.. Сәрдәрнең яшь хатыны малайның болай «урнашуына» аеруча сөенде.

Бандитларның фирмаларыннан «запас частьләр», бик кирәкле детальләр акрын гына малайлар ягына шуа торды. Тегеләр, урлауда бер-берсен гаепләп, атна саен атыш оештырып тора. Мәгәр чын «күселәрне» белеп алсалар, малайларның эшләре хөрти булачак иде. Шуңа күрә сатуны итәк астыннан гына эшләделәр. Өчесе дә шәһәр читендәге өч төрле машина югычка урнашты, чөнки Сарматка читтән килүчеләр, гадәттә, шушы юлдан узалар, һәркайсының шәһәргә чиста машина белән керәселәре килү дә табигый хәл. Монда исә яшерен сату шактый хутлы барды.

Мәктәп тәмамлаганда, егетләр өчесе дә шактый гына мая туплап өлгереп, киләчәк турында уйларга вакыт иде. Гайнанның балачактан бөреләнгән хыялы – артист булу. Укыган чакта да мәктәп театрында баш рольләрдә катнашты, тавышы әйбәт, көе, моңы да бар иде егетнең. Ләкин шул вакытта кемдер «артистлар хәерче бит алар!» дигән шом салды. Татар артистлары – хәерче. Мәсәлән, Мәскәүнең шоу-бизнесында миллионнар әйләнә диләр. Ул рус артисты булып китәчәк. Хәер, фамилияне калдырсаң да була икән, чөнки әйбәт яңгырый: Григорий Лаисов! Сары газета журналистларының башлары катсын әле кайсы милләттән икән бу бөек артист дип уйлап!.. Әтисе теләге буенча, әле яңа алган паспортын үзгәртеп, милләтен «болгар» дип яздырдылар.

Ләкин бу уйлар әлеге хыялда гына калды. «Бизнес»лары яхшы бара, аннан баш тарту ахмаклык булыр иде. Тик хәзер товарлар күбәеп киткәч,

аларны сакларга кирәк була башлады. Акчалары булса да, алар каравылчы тота алмыйлар; шуңа күрә «склад-чиркәү»не чираттан сакларга килештеләр. Беренче төнне бик шәп уздырган иде Гайнан, агач сәкегә сузылып ятты да таңга кадәр йоклады, хәтта иптәшләре килгәндә дә уянмаган иде әле. Ләкин каравылчы болай булырга тиеш түгел, аңа шелтә эләкте. Ә икенче көнне Роберт йокыны ача торган ниндидер үлән табып килде. Шуны тәмәке урынына тартсаң, чыннан да, күзләр шакмак була, нинди йокы килү, киресенчә, уйныйсы, биисе, сикерәсе, дөнья матур, дөнья киң дип кычкырып җырлыйсы килә башлый. Малайлар каравыл алдыннан шул тәмәкене суырырга гадәтләнделәр. Болай тыныч, склад яхшы саклана иде.

Икенче каравыл чиратында Гайнан чиркәүнең эчен яхшылап карарга булды. Бәлки берәр яшерен бүлмәсе бардыр? Бәлки әле кирпеч ватыклары арасыннан берәр алтын тәре-мазар килеп чыкмасмы? Әтисе сөйли торган иде бит, яшь чакта элеккеге алпавыт утарының һәр аршынын көрәкләр белән казып чыкканнар; янәсе алпавытның яшерелгән хәзинәсен эзлиләр! Бәлки, андый бәхет малаена язгандыр?!

Гайнан йокысын ачар өчен теге тәмәкене тирән итеп суырды да, баш әйләнүе бераз басылып, күзләре шар булып ачылгач, кулына фонарь алып, чиркәүнең моңарчы алар аягы басмаган почмакларын актарырга китте. Юравы юш килде, кирпеч-пыяла ватыкларын ерып, шактый ара узгач, арткы якта ул бер кечкенә ишеккә юлыкты. Ишек гайре кечкенә һәм бик тәбәнәк иде, моннан, мөгаен, лилипутлар гына кереп-чыгып йөргәндер. Шунысы гаҗәп: ишек аркылы тимер белән бикләнгән, йозак та кибетнеке түгел, кулдан ясалган зур борынгы йозакка охшаган. Андый йозакны күргәне бар иде Гайнанның: әтисе аны авылдан алып килгән, ул еш кына безнең бабай кулак булган, амбарлары тулы ашлык, тарантаслары, кара айгырлары булган дип сөйли һәм дәлилгә ат башы чаклы шул амбар йозагын күрсәтә иде. Бу йозак озак ачылмаганга охшаган, чөнки тишегенә күгәрек укмашып каткан.

Гайнан арматура кисәге белән йозакка сукты. Бер сукты шулай, ике сукты һәм кинәт артына егылып китә язды: колагына чиркәү чаңы ишетелә башлады. Әлеге тавыш малайны башта куркытса да, тора-бара ул аңа кыюлык кына өстәде, кызыксынуын көчәйтте. Ишек артында зур гына бүлмә бар. Бүлмәнең урта диварында тузанга капланган рәсем-портрет та тора кебек. Малай җиң очы белән рәсемнең тузаннарын сөртте һәм авызын ачып аптырап калды: рәсем-портрет дигәне борынгы икона булып чыкты. Түгәрәк өстәл әйләнәсендә өч фәрештә тезелешеп утырган. Шуларның уртадагысы кинәт малайга күз кысты. Бу инде чиркәү чаңы тавышы ишетелү генә түгел, монысы гайре табигый гамәл-күренеш иде: малайның тез буыннары калтырарга кереште, авызы чатнап кибеп, иреннәре иренгә ябышты, ни артка, ни алга кузгалып китә алмыйча тик басып тора. Менә уртадагысы аңа тагын күз кыса. Малайның бөтен эчен калтырау алды. Бу юлы ул шырылдап кычкырып җибәрде һәм ишектән ничек чыгып киткәнен үзе дә сизми калды. Шул кызулыктан өенә кадәр йөгергән, ишеген дә бикләргә оныткан иде хәсрәт каравылчы!

Кояш баюга, чиркәүнең ачык ишегеннән әүвәл сөт кәҗәләре кергән, аннан соң малкайларын эзләп, хуҗа хатын килеп җиткән; ул үзе генә чиркәү-складта машина резиналарын чәйнәргә керешкән кәҗәләрен

кубарып ала алмагач, малаен чакырткан. Тегесе исә андагы байлыкны күреп шаклар каткан. Чыбыксыз телефон аша әлеге хәбәр дилерларга да барып ирешкән һәм шундук Гайнаннарны эзәрлекләү башланды. Роберт белән Илья нишләгәндер, Гайнан, өйдәгеләргә ашык-пошык нидер әйтте дә, паспортын эләктереп, тимер юлга чапты. Вокзалда күренеп йөрергә ярамый иде. Тимер юлда егетебез узып баручы товар поездына эләкте дә тизрәк моннан кыяклау ягын карады. Дөрес итте, соңыннан хәбәр килде: Ильяны тотып алып, чиркәү диварына терәп атканнар, Роберт каядыр качкан, кыскасы, Гайнан котылып өлгерде һәм аны озын поезд Аксу елгасы буенда утырган гүзәл табигатьле Касыйм шәһәре якларына таба алып китте.

...Сарби Даниловна Гайнан-Григорий атакайны күршедәге буш йортка урнаштырды. Көне буе алар өч чуваш хатыны ярдәме белән чиркәүдәге чүп-чарны чыгардылар. Атакай иконаларны рәткә китерде, тузаннарын сөртте, купканын яхшылап кадаклады, кыек торганын турайтты. Чуваш хатыннарының берсе «Изге Троица» белән кызыксынса да, ул аңа соңыннан, соңыннан дия-дия, игътибарын читкә юнәлтә алды, чөнки үзе дә аның хакында юньләп белеп бетерми иде.

Теге бакыр коелма кирпечләрен Сарби күз ачып йомган арада агач тартмага тутырды да каядыр күздән югалтты.

Үзенә аталган өйдә ялгызы гына калгач, җиңел сулап куйды Гайнаннан «Григорий атакай»га әйләнгән егет. Төнлә аңа нигәдер инде күптән исенә дә алмаган Муся, Мариҗан түтиләр, аның Лукерья атлы гүзәл кызы керде. Лукерья Гайнаннан шактый өлкән, шулай да яшүсмерне тәки гашыйк итә язган иде.

Төн уртасында ул сискәнеп уянып китте дә кайда икәнлеген һәм нигә төшенә нәкъ менә Лукерья кергәнен байтак аңышмыйча ятты. Ул әтисе белән әле үсмер чакта Ханкала ягына – Туксабага кунакка кайткач Лукерья аңа уч төбенә сыярлык кына «Святая Троица»ны бүләк итмәкче иде, тик, Муся түтәй күреп, аны егетнең кулыннан тартып алды. Ә төштә алар Лукерья белән икесе генә чиркәүгә керделәр. Шәмнәр кабызып куйдылар да, Лукерья аны нигәдер тизрәк урамга чыгарга әйдәде. Ишек төбендә Муся түтәй пәйда булып, юлларына аркылы төште. Гайнан чыгып китмәкче булып, әле бер якка, әле икенче якка тартыла, Муся түтәй юлына аркылы баскан да, ни урамга чыгармый, ни кире эчкә кереп китәргә ирек бирми. Шуннан соң Лукерья аның кулыннан алды да үз артыннан урамга таба әйдәде, икесе булгач, Муся түтәй дә каршы килмәде. Урамга чыксалар, каршыларында каяндыр әтисе пәйда булды, күзгә-күз очрашсалар да, әтисе аны күрмәгәнгә салыша, нәрсәгәдер үпкәләгән. Аның артында ук әнисе дә басып тора икән. Анысы улына елмая, нидер әйтергә тели. Шулчак әтисе капылт кына ниндидер зур кошка әверелде дә Ханкала ягына таба очып китте. Чиркәү каршында алар өчесе генә басып калды. Бер-берсе белән сөйләшмичә шулай бик озак әтисе очкан тарафка карап тордылар. Лукерья Гайнанның кулын ычкындырды да аны читкә этәрде, үзе ак томан эченә кереп югалды. Шулчакта әнисе дә юкка чыкты. Теге гүзәл ханым Лукерья түгел икән, ул Сарби икән ләбаса!

Гайнан бик озак вакыт күргән төшеннән арына алмыйча ятты, йокысы

да ачылган, төш өнендә дә һаман дәвам итә. Җәйләрен әтисенең туган ягына кайткач, ул берәр атна әбиләрендә кунакта булып китә иде. Ул чакта Лукерья Путанай авылыннан туганнарына кунакка килә, әле дә хәтерли: йортлары Чыбык күпер дип аталган урында иде.

Ул килгән көнне Лукерья аның белән генә уйный, чөнки Никон капканы эчкә яктан бикләп куя иде. Кунаклар китүгә, Лукерья янә койма башына менеп утыра, дөресрәге, аларның ишегалдына коймага сөяп өелгән, өстенә шифер капланган утын әрдәнәсе бар иде. Шул шифер шарт-шарт килә башлауга, Гайнан ян бакчага чыга, «шиферлы тавыш» кыздан «мин монда» дигән хәбәр кебегрәк иде. Хәтерендә тагын шунысы калган: Лукерья һәрчак гаилә булып уйнарга ярата, ул хатын-кыз, имеш, уен вакытында Гайнан аның ире була инде. Комлыкта йортлар өяләр, Лукерья «ире» эштән кайтышка ашарга пешереп тора. Күрәсең, айлар буе командировкада йөргән әтисен сагына иде кыз, телендә дә гел: «Әти кайтса яки әти миңа тегене апкайта, әти миңа моны апкайтты» кебегрәк сүзләр иде. Соңгы кайтуында ул Лукерьяны танымады, кыз кинәт кенә буйга да тартылып киткән, юка күлмәге аша күкрәк турысында нәни туп та пәйда булган, чәчен элек үреп йөри иде, хәзер ул тузгыган. Комлыкка таба хәзер икесе дә борылып та карамадылар. Кичләрен капка төбендә утыралар, сөйләшәләр, хәзер ни турында сөйләшкәннәрен дә хәтерләми, әмма Лукерья белән бик кызык иде. Ул һәрвакыт нидер уйлап таба яки берәр кызык сөйләп көлдерә. Беркөнне Лукерья аны Путанайга барырга чакырды. Ияреп китте Гайнан, кыз нигә барасын әйтмәсә дә, барыбер кыланчыкланып: «Баргач, күрерсең менә!» – генә диде. Путанайга җиткәч, кыз туп-туры авыл кырыендагы чиркәүгә таба турылап китте. Чиркәүнең ишеге ачык, кеше-кара юк, ләкин берничә икона янында шәмнәр янып торганы күренә. Кыз, ике шәм алып, берсен Гайнанга бирде һәм ут алдыргач, шәмдәлгә куярга кушты да, Гайнанны ишек төбенә бастырып куеп, үзе каршыдагы Иисус сурәте янына басып, бик озак тын торды. Аннары алар кайтып киттеләр. Шул көнне кич утырганда, Лукерья аның битеннән үпте һәм: «Без хәзер ир белән хатын шикелле!» – дип, кайнар сулышы белән пышылдап, колагын пешерде. Гайнанның тәнен ут алды, кыюланып китеп, ул да кызга елышмакчы иде, шулчак капка шыгырдаган тавыш ишетелде, алар икесе дә сискәнеп киттеләр. Муся түтәй икән.

Лукерья белән менә тагын күрештеләр, тик бу юлысы төштә, анысы да Гайнан төшендә генә.

Лукерьяның төшкә керүе гаҗәп түгел, Сарби Даниловна кичә кайсы ягы беләндер балачак авылындагы шул кызны хәтерләтеп куйды. Төсе-кыяфәте беләнме, бәлки, тавышлары охшаган идеме икән?

Чиркәүнең төшенә керүе аңлашыла, кичә кичергәннәре кайный торгандыр баш чүмечендә. Тик нигә әтисе белән бергә йөри торган мәчетнең кергәне юк соң?! Чиркәү дә, чиркәү... Хәер, бу сорауга әтисе җиңел генә җавап биргән булыр иде. Улым, дияр иде ул, бүген сәясәт шундый, мәчеткә бигүк урын юк, дияр иде, мөгаен...

Төш тәэсире акрынлап эреп юкка чыкты, егет фани дөньяга кайтты. Монысы аны тагын да куркытты. Кем уйлаган, аны монда атакай итеп кабул иттеләр, хәзер ул чиркәүдә атакай, ягъни поп булып хезмәт итәргә тиеш. Догаларның күбесен яшьтән үк белә, әтисе өйдә юк чакта әнисе аларны бик еш колагына пышылдый иде. Яшьлекнең хәтере үткен, мөселман

догалары белән рәттән христиан догаларын да бик һәйбәт сеңдерә. Тик догалар белән генә берни кыра алмыйсың, монда барысын да шартына туры китерергә кирәк булачак.

Гайнанның исенә өстәл өстенә утырган компьютер төште, ул өстеннән юрганын алып ташлады да яланаяк салкын идәнгә басты, зиһене ачылып китте. Компьютер эшли, хәтта интернетка да кушылган иде. Ул, ашыга-ашыга, чиркәү хезмәте кушымтасын эзләп тапты, йотлыгып укырга кереште, һәрнәрсәне хәтеренә сеңдереп барды. Болай булгач ерып чыгарга тиеш. Тик чиркәүдә «поп» булып озак хезмәт итә алырмы, хәер, әлегә мая тупларга кирәк, акчасыз берни кылып булмый, аннан соң берәр җаен турып китереп качып китәргә, Башкала ягына сыпыртырга! Ошап китсә мәгәр, монда ук калыр. Сармат бандитлары да чиркәүгә килеп эзләп йөрмәсләр. Вакыт үзе күрсәтер аннан соң.

Таң атканда, Гайнан шундый иләс-миләс фикерләргә килеп өлгерде һәм бу аның күңеленә шактый тынычлык иңдерде. Юынып, аруланып алгач, атакай киемнәрен киеп, көзге алдында әйләнде, шартына туры китереп, махсус тавыш белән сөйләшеп карады, вәкарь белән генә атларга йөрәнде. Сакалы кыскарак кыскасын, үсәр әле, бер атна узмас, чын попка охшап калыр Гайнаның... Григорий атакайга әйләнер. Тормыш җайлана болай булгач. Җаны да әллә ни битәрләми, чөнки әнисе христиан бит, кан ана ягыннан да килә. Беркем дә, беркайчан да гаеп ташлый алмаячак аңа. Иманын саткан дия алмаслар. Ике диндә дә иман шул берүк инде ул. Иманың җаныңда булмаса, аны адәми затка дин генә кертә алмый. Бабалар каны буенча килгән денең булмаса әгәр?!

Ишек шакыдылар, Гайнан керүчене ишегалды тәрәзәсеннән күреп калган иде, күрше Сарби Даниловнага мондый киемнәрдән күренү әйбәт тә әле. Ул тиз генә караватын җыештырып куйды. Ишек биктә түгел иде, эчтән җавап булмагач, хатын үзеннән-үзе өй эченә шуып керде. Әлеге мөлаем хатын өй эченә үзе белән саф һава алып кергән кебек булды, сулыш алулары җиңеләйде, хатынның уңай аурасы аның кәефен күтәрде.

Хәл-әхвәл сорашкач, тегесе аны өенә чәйгә чакырды.

– Григорий атакай, Солтан кайта бүген, Хәйдәров, то есть монда, Русинга килә. Синең белән дә таныштырырмын. Бик сөенер чиркәүнең атакайлы булуына, – дип өстәде.

Солтан исемен ишетүгә, Гайнан дерт итеп куйды. Тик бик тиз тынычланды, дөньяда Солтан исемле кешеләр бер атасының сыйныфташы, авылдашы гына димәгән ләбаса дип юатты үзен. Тиз тынычланды, чөнки ул чакта һәр яңа туган көн үзе ярдәм итте Гайнанга. Аңа чын поп булып кыланырга да кирәк түгел икән, Сарби Даниловна лютеран динендә. Бу бистәнең икенче очында элек немецлар салып калдырган лютеран чиркәвен дә күрде бит. Ләкин ул ташландык чиркәүнең язмышы бөтенләй өметсез, ди. Православие рус чиркәве поплы булырга тора, ә пастырьны каян табасың? Әле өстәвенә сугыштан соң ул чиркәүне мондагы җирле халык немецларга үч итеп махсус җимергән.

Русин авылының инеш артындагы икенче ягына немецлар нигез салган. Әби патшаның мәгълүм манифестыннан соң 1766 елда монда күпләп немецлар килеп утыра. Лютеран динендәге халык үз чиркәвен (кирха)

булдыра. Саксония белән Пфальцадан була ул гаиләләр. Бу як халык телендә беренче старостаның исеме белән Шефер дип аталып йөртелә. Сугыштан соң җирле халыкка үзләренә дошман булган немец исемен «оныттырырга» тырышсалар да, әле дә шул исем белән йөртәләр. Әтисе галим Данил Френк юкка гына монда төпләнмәгән икән.

Сарби Даниловна кыскача гына әлеге тарихны сөйләп алды да:

– Минем өстәл әзер, атакай, – диде назлы тавыш белән. – Аннан соң мунча да кереп чыгарга мөмкин, ягылган, – дип өстәде.

Мунча бик кирәк иде Гайнанга, монысына ул шатланып риза булды. Әмма ялгышкан, беренче көнне үк шул мунча дигәннәре аны харап итеп ташлый язды, мунча аркасында Григорий атакаебыз чак кына бар дөньяга хур булмыйча калды...

Бу турыда Сарби, шактый гомер узгач, шаярып төрттерде Гайнанга. Ул, салкын су кертергә дип, мунча алачыгына узган. Гайнанның күз-башы сабынлы чакта, салкын суның кайда икәнлеген әйтергә, мунча ишеген ачып караган. Попның сөннәтле икәнлеген күргән хатын чак авып китмәгән шулчакта (Ялангач яшь егет күргәч, еллар белән инде куера башлаган каны кинәт кайный башлап, шулай булганмы, әллә аптырау-гаҗәпләнүме – анысын әйтми чая хатын); тиз генә чыгып сыпырткан мунча алачыгыннан...

### Хәләл чучка...

Башка берәү булса, шул сәгатьтә үк, ялган попны фаш итеп, кара тавыш чыгарыр иде. Сарби, иреннәрен тешләп, тын калды. Соң үзе дә шул кавемнән ләбаса ул, сөннәтлеләр кавеме (төрки-татар һәм немец яһүде) кызы! Атасы – немец яһүде. Әнисе, Ханкала артындагы бер татар авылындагы «мәхәббәт хәлләре» аркасында аннан җәяүләп качкан, исемен Сәрбиназдан Софига үзгәртеп, яңа паспорт ясатуга, немец галиме Данил Френк белән Алманиягә үк китеп барды. Хәзер вакытлыча Иранда яшиләр, чөнки Данил Френк – атаклы тюрколог, андагы китапханәдә эшли.

Сарбиның апасы чит гаиләдә, Ханкала артындагы бер авылда тәрбияләнгән, ди. Ханкалада яшәгән бертуган апасының үз баласы булмагач, үтенеп-ялварып сорап, нәни кызны үзенә алып киткән булган. Сәрбиназның Касыймдагы ташландык бер тулай торакта көнен төнгә ялгап яшәгән чагы була бу. Шуннан соң тегеләр Ханкаладан Туксаба дигән авылга күченеп китәләр, Сәрвәр атлы бала «үз кызлары» була.

Сарби Даниловнаның аны күргәне дә юк, чөнки бу хакта күптән түгел генә ишетте. Сарби үзе, Сарбина булып, Алманиядә дөньяга килгән. Андагы Көнчыгышны өйрәнү институтында тюркология буенча диссертация яклагач, әтисе кызны практика узарга Россиягә озатты. Монда ул Пауль Вольфганг белән танышты. Пауль үзе дә Алманиядә туган, шунда укыган. Ул да – тюркология буенча диссертация язучы яшь галим. Алманиянең монда «йокыдагы» шымчысы булып исәпләнгән. Россиядә фәнни эшчәнлеге буенча практика уздыру шарты белән аны Алман разведкасы үз кармагына эләктерә. Моның да үз сәбәбе бар: Паульнең әнисе ягыннан бабасы Альтенберг – Эренфридерсдорф руда таулары янындагы металлургия заводында металл коючы. «Академик» кушаматы

алган гади эшче Берман кургашын табуның яңа ысулларын уйлап чыгара. Оныгын да үз һөнәре серләренә өйрәтә. Паульгә зур өметләр баглыйлар. Тик тегесенең «гуманитар башы» барыбер бүтән юлдан китә. Икенче Бөтендөнья сугышында катнашып кайткан Рудольф бабасының кызыклы әкиятләре үзенә күбрәк тарта аны. Бабасы оныкларына васыятьнамә язып калдырган була. Алар гаиләсенә «Фон Рудольф васыятьнамәсе» дип телгә кергән язмалар белән династияне дәвам итүчеләр бала чактан танышып үсә. Фон Рудольф, чыгышы буенча дворян булса да, Бөтендөнья сугышында гади ефрейтор булып катнаша. Һәм гади «солдафон»ның васыятьнамә язып калдыруы гадәттән тыш хәл итеп кабул ителгәндер инде. Югыйсә гаиләдә ошбу васыятьнамәгә булган мөнәсәбәтне башкача аңлата алмый Пауль.

Немец разведкасына нәкъ менә шуның өчен дә кадерле була Пауль. Беренчедән, аны Россиядә тюркология өйрәнү дигән ширма астында яшерергә мөмкин, икенчедән, разведкага таралып барган рус иленең исәпсез-хисапсыз яки чутсыз алтыннары кирәк була! Пауль Вольфганг бу ягы белән дә аларның яшерен ниятенә туры килә. Күрәсең, «акыллы баш» немец рус аракысының атом бомбасына караганда да куәтлерәк корал икәнлеген искә алмаган... Чөнки Россия бишегендә тирбәлә торгач, бөтенләй «йоклап» китте Пауль Вольфганг. Мондагы руслардан эчәргә өйрәнде. Шул яман гадәте аркасында Алмания разведкасы үзенә кул селтәгәч, аны мондагы КГБ «күреп» алган. «Госфонд» алтын заводына беркеткәннәр. Таралып бара торган Коммунистлар партиясе җитәкчеләренең иң зурлары, ул алтынны яшерен генә үзләштерү максатыннан Пауль ярдәме белән күп хәзинәне үз кесәләренә шудырдылар. Алай гынамы, алтын аларга барып җиткәнче Касыймның үзендә үк талана башлый. Барлыгы ярты тоннага якын алтын юкка чыга!

Бу эш ничек эшләнә соң? Бер кичне Шакир Рәимов Сарби Даниловнага бу тарихның кайбер өлешен сөйләде. Калганын ул Пал Палычтан үзе дә белә иде.

Пауль әйтә: «Мин дөньяга атаклы тюрколог булырга тиеш идем. Френк миңа зур өметләр баглый иде, бу алтын минем башым җитте», – ди. Тагын нидер яшерә аннан Пауль. Монда алтын эзләргә дә, тюрколог буларак кына да килмәгән ул… Нәрсә яшерә, нинди сере бар егетнең? Пауль бик тә Сарбига якынаймакчы була, инде ничә мәртәбә мәхәббәт аңлатты. Ләкин кыз ашыкмый, әнисе әйтмешли, ашыккан ашка пешкән, ди, икән татар. Шулай да Паульның аңа булган хисләре серне ачарга ярдәм итәчәген белә иде ул. Үзе дә ашыкмаска булды.

Паульнең иң якын дуслары һәм аралашкан кешеләре татарлар арасыннан. Шакир Рәимов дигәне бертуганы кебек якын кешегә әйләнде. Элегрәк Рәимовның кызы Бану белән экспедицияләрдән кайтып кермәделәр. Рәимовы исә соңгы вакытларда гел Касыйм тирәсендә кайнаша. Монда Ханкала ягыннан башка кешеләр дә килеп тулды. Араларында шәкерт-мулла да, журналист-язучы да бар. Хәтмулла атлы бәрхет тавышлы шәкерт монда туп-туры Ираннан кайткан, ди.

Чыннан да, барысы да Сарби Даниловнаның күз алдында, Рәимовның Касыйм белән кызыксынуы бермә-бер арткан чак иде бу. Моның шактый

саллы сәбәбе дә бар. Үзе бер тарих иде ул сәбәп. Язмыш тарихы, аның нәсел тарихы. Шулар турында Шакир Закирович авызыннан ишетте Сарби Даниловна.

### Алтын

Солтан Хәйдәров Рәимовка Касыймда хәзинә барлыгы турында әйтте. Дөресрәге, булырга тиешлеге хакында. Шакир Закировичның хәзинә дигәнгә исе китмәде, чөнки белә, «Госфонд» алтыннарын ниндидер юллар белән елгыр караклар кесәләренә шудыралар, күпләр Касыйм тирәсендә катлы-катлы коттеджлар салып чыкты. Башкаладан заводка килеп күпме генә тикшерсәләр дә, каракларны фаш иткәннәре юк әлегә. Шул турыда әйтә дип уйлады ул аны. Ләкин Солтаннан ишеткән икенче хәбәр Рәимовны битараф калдыра алмады, чөнки ул туп-туры аның үзенә кагыла. Солтан аңа туган якларында ишеткән серле такмак турында сөйләде: «Татар әйтә бисмилла урысныкы памилуй хочешь стать богатой найди клад золотой». Имеш, халык аны хәзинәгә ачкыч дип уйлый икән.

Шакир тетрәнеп китте! Шундый ук юллар аның бишмәт кесәсеннән дә табылган бит! Шәлгә төрелгән баланы, аның үзен була инде, товар вагонынннан табып алып, балалар йортына озаткан булганнар. Әлеге такмак язылган кәгазьне яхшы хәтерли малай. Сүзләре гел исендә тора: «Татар әйтә бисмилла урысныкы помилуй хочешь стать богатой найди клад золотой». Монысында да бернинди өтер, нокта юк.

Рәимовның тетрәнеп китүе менә шул сәбәпле иде: бар хикмәт әлеге такмакларда, бер-берсенә охшаш ике такмакта... Такмаклар – игезәк. Аның кебек, алар кебек. Ул үзенең игезәк сыңары булганлыгын яхшы белә, ләкин таба гына алмый. Икесен дә товар поезды вагонынннан табып алганнар!.. Өтермәнгә утырткынчы ук әнисе йөкле булган һәм елгыр адәмнәр моны бик оста файдаланганнар, кыскасы, ул ятимнәрне чит илгә уллыкка сату эше оештырыла; төрки-татар кавеменнән булган малай-кызлар бик кыйммәт йөри икән!.. Ул сабыйлар алтын «тауар» була! Һәм аларны төрле юллар белән шунда ук Алманиягә озаталар, ди.  Соңгы вакытларда икенче төрле хәбәрләр дә чыкты: ул балаларны Алмания лабораторияләренә саталар да анда исә төрки-татар нарасыйлары белән төрле фәнни сынаулар үткәрәләр!.. Нидер эзли икән дөнья галимнәре...

Моны белүнең бердәнбер юлы Солтан Хәйдәровны туган якларына җибәрү иде. Әлеге ниятне күңелендә беркетеп куйса да, әле һаман вакыт таба алганы юк. Кызы Бану ул якларда – Ислемәй тауларында – берничә мәртәбә экспедициядә дә булып кайтты. Бануга ул хатыны аша (кызы белән элемтәсе булмаса да, аерылган хатыны Зөмәрә белән сирәк булса да аралашалар иде) йомышын да әйтте: ул якларның җирле фольклорын җыеп кайтырга кирәк диде. Юлыкмасмы янәсе теге такмакка?! Алар төркеменә студент тюрколог немецны да кушты.

Тагынмы? Тагын шул: Солтан сөйләве буенча Денис Паратовның да әлеге такмакка катнашы бар икән!

Паратов – бу җирләрнең яңа хуҗасы, зур агрофирма төзи. «Ерак бара алырсыңмы икән, энекәш? Агрофирмаңа эшче кулларны каян алмакчы буласың? Башкаладан бомжлар китертсәң генә инде!» – дип уйлый Рәимов.

Шунда шәп фикер килә: чиркәүне ремонтлап, чаң авазын ишеттерсәң, бәлки, халыкны тартып булыр?! Бу эшне оештыруны Солтанга кушты. Солтан күптән түгел үзләре бер дөнья булып яшәүче татар авылларына барып кайткан иде. Әлеге авыллардагы тормыш аны бик әсәрләндерде, канатланып кайтты ул һәм яңа фикер-«кишерләре» дә бар иде. Ул да беренче адымны диннән, бу очракта мәчеттән башларга кирәк дип уйлады. Тик үзенә шундук каршы да төште: эш урыны кирәк беренче нәүбәттә! Яшәү өчен йорт, клуб, шәп юл, башка төрле инфраструктуралар зарур. Ләкин Рәимов Русинда чиркәүне торгызу хакында әйткәч, каршы килмәде, бәлки, шулай дөресрәк булыр кебек иде. Ул чакта зур хыяллар белән тотынды алар бу эшкә һәм нәтиҗәләре дә күренә башлады. Баһадур дигәне тагын өч мәхәлләле зур авылга әйләнде, Русинда исә халык азрак иде, яртысына чувашларны кертеп утырткач, шактый бөтәеп китте. Чуваш – эшкә батыр халык, шундук иген игәргә керeште, күпләп мал асрый башлады.

Рәимов хәзер баш ватып утыра: ул вакытта эш майлаган кебек барды да, хәзер менә, ничә еллар узгач, Баһадурга килеп, террорчы эзләргә керештеләр. Матбугатта Баһадурдагы ниндидер секталар хакында сүз куерталар?!

Хәер, ул чакта да «майланып» җитмәгән булган, күрәсең. Баһадур, тагын берничә татар авылы, рус авылларыннан Русин тернәкләнде, аннан соң проектны яптылар бит. Яптылар дип, Башкала шәһәрендә баш калкыткан либераллар кулга алды Русинны. Хәер, күпме сулар аккан инде аннан соң...

...Күптән түгел ул еллардагы әлеге гамәлләр турында Солтан сүз кузгатты. Чит ил фирмалары нефть белән газны, башка табигый байлыкларны гына түгел, җирне дә үзләренә алып, илне ач калдыра язгач, Башкала сәясәтчеләре янә җир эшкәртүгә әйләнеп кайтырга уйлаган.

Чит ил агентлары монда гөмбә кебек үрчеде ул чакта.

Монысы аның үзенә дә сер түгел, нефть эзләүчеләр төркемендә немец белгече дә бар иде. Данил Френк атлы әлеге немец чын ниятен яшерми, аңа нефть кирәк түгел; бабасының бабасы Көнчыгышны өйрәнүче күренекле галим булган һәм менә аның эшен ул да дәвам итә. Нефтьче һөнәрен үзләштерсә дә, кан тарта, ди, ул: ата-баба мавыгуы мине дә үзенә ияртте, мин Россия мисалында Көнчыгышны өйрәнәм, бигрәк тә ислам белән бәйле халыклар кызыксындыра, ә андый милләт исә ул, беренче чиратта, татарлар, ди, торган иде.

Ярый, хуш, әлеге эштә башлап Солтан йөрергә тиеш иде. Россияне коткару өчен тагын татарлар кирәк безгә дип, бу юлы турыдан-туры әйтәләр. Федераль хөкүмәт әлеге проектка акча да бүлеп биргән. Россия һаман да икмәкне күпләп сатучы булып кала.

Рәимовның инде үз эшендә дә киңәшче генә булып калырга исәп тотып йөргән көннәре иде, еллар хисап төймәсен тарта, көч кими. Тик Солтан авылларны яңарту хакында килеп әйткәч, яшь чагына әйләнеп кайткандай булды картлач! Киңәш-табыш итәргә син кирәк диюе, бөтенләй канатландырып җибәрде. Тик Солтанның бер фикере белән килешмәде ул, имеш, татарны милләт итеп бары авыллар гына яшәткән. Борынгыдан шулай булган, янәмәсе... Соң... Ул Алтын Урда калаларын, аңа кадәр булган Болгар шәһәрләрен, Атилла вакытында ук Идел буенда калыккан Тәтеш шәһәрләрен кемнәр салган да, анда нинди халык яшәгән?! Әлбәттә, татарлар! Ул чактагы татарларны читтән килеп күргән сәяхәтчеләр,

елъязмачылар «болгар» исеме белән атасалар да, алар бер халык, бер үк кавем, ди, иде Френк. Аның бабаларының асылташ приискаларында хезмәт иткән кешеләр барысы да эшчеләр булган канә!..

Татарның бишеге авыл гына түгел, аның бишеге шәһәр дә ләбаса! Татар шәһәрләре... Рус шәһәрләре... Тагынмы? Хәзер бар шәһәрләр дә Ауропа калаларына әйләнеп бара кебек. Элмә такталар инглиз телендә, ашау-яшәү рәвеше йә янкиләрдән, йә инглиз-француз, немецтан... Русның үзенең ние калып бара соң? Бөек Пушкин теле яртылаш диярлек чит ил алынмалары белән чуарланып бетте... Берәр чит ил сүзен ялгыш басым белән әйтсәң, яисә интернет өлкәсенә килеп кергән берәр «әрсез» яңа терминны ишетми калган булсаң, синнән көлә башлыйлар. Артта калган бу диләр.

– Без Россияне коткарып калырга тиеш! – диде ул Солтанга.

– Атилла римлылар басып алуыннан коткарган кебекме?

– Алтын Урда Скандинавия баскынчыларыннан коткарган кебектер дә әле...

– Кузьма Минин кебек тә...

– Заһидовлар, Җәлилләр, Гафиятуллиннар, Матросовлар кебек тә...

– Аларга кадәрле үк әле... Солтангалиевләр, Хөсәен Ямаш, Шамил Усманов, Мулланур Вахитов кебек хисапсыз-сансыз каһарман татар егетләре! Алар булмаса, ай-һай, авыр булган булыр иде Ленин белән Сталинга Зур Тәхетне алу.

– Вахитов, Солтангалиевләрнең кадерен белмәгәннәр бит! Алай гына да түгел, аларны алдаганнар, идеалларына төкергәннәр соңыннан!

– Яһүдләрне дә шулай иткәннәр. Аңа карап, яһүд авызын салындырып үпкәләп утырмый. Барлык нефтьне үз кулларына алдылар. Әнә, күрәсеңме, Земин дигәне Ханкала тирәсендәге бар җирләрне үзенеке ясап бетергән. Киләчәктә шуларны сатып кына да капитал эшләячәк ул. Калҗа-калҗа байлык эләктерәләр. Моңа Ленинны гаепләмик. Ленин белән Сталинны идол итеп күтәргән яраннары күбрәк гаепле.

– Димәк, ышанырга дисең инде бу юлы?

– Күз алдына бит, Ханкалада ачылган татар гимназияләре, татар телендә нәшер ителә башлаган дистәләгән матбугат мисал, дәлил түгелмени, Солтан туган? Болай булгач, эшләр худка китәчәк.

– Татар белән советлар аның нефте өчен генә санлаштылар бугай.

– Советлар санлаштымы, санлашты, пычагым, автономия кысаларына кертеп, йозак белән бикләп куйдылар да. Ханкала кибетендәге сыер маена да Башкала рөхсәтеннән башка бәя куя алмыйлар иде. Ә хәзергеләр чын рухи ирек бирәчәк безнең халыкка. Мисаллары күз алдында дидем бит.

– Тора-бара, гайканы тыгызлый башламасармы кайнар татарофоб башлар?! Тагын алдамасłармы дим? Күпме телисез, шулкадәр суверенитет алыгыз дигән була да ул. Федерациядән чыгып китмәс өчен! Татарлар сан ягыннан икенче урында, федерациягә ул халык кермәсә, мало не покажется!

Ошбу сорауга Рәимов нигәдер җавап бирмәде шикелле.

Бу аларның – ике татарның – сүзсез генә, күңелдән генә аңлашуына охшашлырак бер әңгәмә шикеллерәк килеп чыкты.

Сүзне беренче булып тагын Солтан башлады:

– Бу җирләрне тергезеп, тәртип ясасак, халыкны эшле итсәк, ипиле

итсәк, киләчәктә монда үзебезнең балалар өчен бакчалар, мәктәпләр дә ачарбыз әле, Аллаһы боерса! Бу Касыйм җирләре элеккеге татар ханлыгы җирләре бит. Ләкин моның туфрагы агулы. Шушыннан торып, Ханкаланы басып алган Явыз Иван. Димәк, мондагы туфракны сафландырырга, аруландырырга кирәк нәҗестән. Агымсуга кадәр төрки-татар елгасы. Үзебезнең туган телдә укыта торган мәктәпләр ачыйк, татар телен кулланылышка кертик диюем.

– Ханкалада бар бит инде мәктәпләр! Димәк, ышанып була.

– Мин ихластан ышанам, Шакир Закирович! – диде Солтан малайлар сыман тыйнак кына.

– Тавышың бик сыек чыкты әле... Сталин булмас бар түрә дә... Ул башта вәгъдә иткән, аннары бар вәгъдәсен оныткан, алай гына түгел, киресен эшләгән.

– Ленин каршы булган бит?

– Пычагым да каршы булмаган, анысы да татарны көчәйтүдән курыккан. Гений диләр, шуны да аңламагач, нинди гений була торгандыр инде.


– Нәрсәне аңламагач?

– Россиянең тотнагы, асабасы – татар дөньясы, татар менталитеты. Россия элек тә, хәзер дә «татар» дигән мәгънәне аңлаткан. Чөнки рус халкы белән бергә алар беркайчан да үз илләрен дошманга бирмәгән! Шул уртак көч нык булганда, Рәсәй дә яшәячәк, чәчәк атачак. Бүгенге түрәләр моны яхшы аңлый. Ханкалада тагын яңа татар гимназияләре ачабыз дип вәгъдә итте миңа Кирмәнбаш. Башкалада да булачак, һәр халык үз телендә белем алырга хокуклы дип язылган бит Конституциядә!

...Алар Солтан белән Русинга китеп бардылар. Теге чакта Русинда шактый зур хуҗалык оештыра алган иде нефтьчеләр. Шуннан соң бер генә йорт та арттырып булмады. Хәзер Русинда йортлар ишлерәк, йөздән артык. Тик төп халыктан берән-сәрәне генә утырып калган, Касыйм шәһәре якын булгач, соңгы егерме ел эчендә халык шәһәргә кыяклап беткән. Ә Павел Павлович һаман монда, Павел Павлович һаман исән-сау! Ул инде күптән Пал Палычка әйләнгән.

*(Ахыры киләсе санда.)*

## «ТАКТАШ FEST» БӘЙГЕСЕНӘ НӘТИҖӘЛӘР



*Күптән түгел талантлы яшь каләм ияләрен барлау, берләштерү, иҗатларын активлаштыру максатыннан республикабызда өр-яңа шигырь бәйгесе үткәрелде. Һади Такташ иҗатына нисбәтле булган әлеге бәйгене Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе һәм «Новые Медиа» мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә иҗади проектларны тормышка ашыру буенча автоном коммерцияле булмаган оешмасы гамәлгә куйды. Әлеге бәйгедә Булат Ибраһим, Гөлүсә Батталова, Зөһрә Рамазанова, Гөлназ Әхмәдиева, Илнар Фатихов һәм Фәнис Зыялы актив катнашты. Бәйгедә катнашучыларның кайбер иҗат үрнәкләре белән сезне дә таныштырабыз.*

# Булат Ибраһим

## Үзгәрми бу заман!

*(Такташка)*

Үзгәрми бу заман,
Бохарага китеп кайтсаң да.
Тыныч түгел
Күңел дигәннәре,
Тыныч йокы теләп ятсаң да.

Җир уллары шул ук –
Һабиле дә, Кабиле дә туа.
Чана юлын кар томалый кышта,
Арба юлын җәйдә яңгыр юа.

Ташлап китә ирен хатыннары,
Хатыннарын – ире.
Һәр заманның каһәр суккыры бар,
Һәр заманның чире.

Гөлчәһрәләр, һаман Галя булып,
Ертык күлмәк кия – тамаша.
Юлбашчылар, кабинетка тулып,
Анкеталар тутырып алдаша.

Ай һаман да өйләналмый әле,
Бөтерелеп йөри йолдызлары.
Ә хыялда толымнарын сүткән,
Шаян күзле пәри кызлары!

Әллә нинди телләр өйрәнсәк тә,
Каз бәбкәсе телен белмибез.
Ачуланган саен ай башына
Шлем кидертергә телибез.

Юлдан-юлга, елдан-елга йөртә
Каләмнәрне акчасызлык чоры.
«Ай-ли, вай-ли» уйнап көйләтә шул,
Дары бетмәс,
тынмас «Мылтык җыры».

Европага китә микән казлар,
Тракторлар безгә кайтамы?
Син бу җиргә өр-яңадан тусаң,
Озак тотмаслар бунтарь баланы.

Җил һаман да төнлә йөргәннәрнең
Бүрекләрен урлап китә әле.
Үзгәрми бу заман, ак чәчәкләр ява,
Матур дөнья Сине көтә әле...

## Иртә йә соң барыбер китәсе

Бу тормышны тукта сөюеңнән,
Иртә йә соң аннан китәсе.
Һәм кем белгән салкын кыш аеның
Ни китерер әле иртәсе.
«Дөнья матур» диеп мин әйтмәдем,
Ә Такташка шулай тоелган.
Ап-ак карлар утлы күмер кебек
Бизәк ясап җанга уелган.
Һәм кайдадыр тәндә, бик тирәндә,
Без үзебез яшибез кебек.

Әнкәй (о)заткан кышкы карлы юлдан,
Без йөрибез бары җил кебек.
Әнкәй, әнкәй! Без кар кебек салкын,
Кимсетергә әзер киемсезне.
Мин үзем дә шундыйрак бер ятим,
Утка атыр идем үзебезне.
Утка атыр идем бу тормышны,
Тизрәк туса әгәр иртәсе.
Сөткә канны бутап язып куйдым:
«Иртә йә соң барыбер китәсе».

# Зөһрә Рамазанова

***

*Һәрбер совхоз,*
*Һәрбер гигант колхоз*
*Яшәү көче безгә бирәчәк!*
*Һ.Такташ*

Дигән идек. Уртак малны җыеп
Уртак көчләр белән төзелгән
Колхоз бетте. Юк, зарланмыйм!
Безгә диңгез чыпчык тезеннән.
Төзи-сүтә, вата һәм җимерә –
Шунсыз мөмкин түгел вазгыять!
Кичә шайтан суын иптәш иткән
Намаз укый. Йәгез, бер аять...
Мәчетләрне торгызды һәм сүттек,
Манарасын  кистек утынга.
Әле һаман шуның белән мәшгуль –
Урын җитми намаз укырга.
Күптән инде колхозларны
Дус-ишләргә бүлеп тараттык.
Базар икътисады дия-дия,
Башка төсле байрак кадаттык.
Ә хәл-әхвәл һаман шул тирәдер.
Һаман шул ук йөзле кешеләр.
Шөкер итеп яшәүчеләр шактый,
Сүз әйтмәүче, безнең ишеләр.

Колхоз бетте, тик маллары гына
Күчә китте зуррак кулларга.
Каберләрен әби-бабаларның
Белмәүчеләр калды дөньяда.
Колхоз бетте. Җирләр хәллерәктә,
Басу-кырлар, иген, икмәк тә.
Авыл кешесенең кадере бетте,
Шәһәрләштек инде кирәккә.
Авыл бетте. Юк, юк, авыллар бар!
Тик бетәргә ерак калмаган.
Авылында яшәп калучыны
Заман шаукымы да алмаган.
Бөтен өмет, бар ышаныч шунда –
Килер безгә матур киләчәк!
Колхозлары бетсә, авылы калсын
Бар дөньяга икмәк игәчәк.
Бетте колхоз! Яшәр көчне безгә
Колхоз бирмәгән лә ләбаса!
Ватып-җимермичә яши белми.
Халкы шундый. Холкы. Зараза!

***

*Синең тормыш авыр әкият булды...*
*Һ.Такташ*

Бу тормышлар һаман син язганча,
Адым саен очрый Мокамай.
Яктылыкны гына күреп яшәү
Җиңелләрдән түгел шул алай.

Балачакның яман гадәтләре
Үсмерчакка килә сагалап.
Ак хыяллар берчак юкка чыга,
Тормыш үзе – ярык тагарак.

Пафос заманасы хөкем сөрә,
Экран аша карау дөньяга.
Кешелекнең изге сыйфатлары
Сирәк җанда гына уяна.

Күзләр тона ялган чынбарлыктан,
Ясалмалык үтә чикләрне.
Ялтыравык тормыш кызыктырып
Харап итә һаман күпләрне.

Такташ абзый! Безнең хәлләр шулай.
Гасыр үткән – берни үзгәрми.
Каләм белән агартучы җанны
Сезләр ни дә монда, безләр ни?

Үкенечле юллар узганнарны
Нигә якын алам тагы да?
Язмышлары йөрәк әрнетүче
Мокамайлар бар шул янымда.

## Гөлүсә Батталова

### Идеаллар

*Җир безнеке булыр! Ачулансак,*
*Шлем киертербез айга да...*
*Һади Такташ*

Киереп ач, әйдә, тәрәзәне,
Күмәртәләп керсен яз җиле!
Ютәл, томау – пүчтәк! Кучәреннән
Дөнья бора бүген бер тиле!

Борау белән дивар каезлаган
Күршегә дә бераз эләгер.
Комачаулап йөрмәс моннан ары,
Йонга төргән, ахры, йөрәген!

Җир шарының бөек симфониясе
Туып ята безнең башларда!..
Ноталардан калган күпме ярык
Кирпеч дигән затлы ташларда!

Буш кесәне искә төшермәле –
Тормыш ваклыгыннан мең гарык!
Уй бәләкәй икән, буең – карыш,
Тагаракны боза бер ярык!

Бөек хыялларны биек күккә
Эләр өчен баскыч эзләсәң,
Корбаннарсыз булмый – жәл түгел лә,
Баштан шуып төшкән эшләпәм.

Киереп ач, әйдә, тәрәзәне –
Тал песие исен иснәрбез!
Тишек түшәм аша кояш күргән
Барып чыккан соңгы исәр без!

Һавадагы торна – торна гына...
Булгач булсын таулар бөркете!
Дөнья үзгәртәм дип җиң сызгандык –
Чыпчыкны да кулдан өркеттек...

Әйдә, ярар, ач карыннан гайре
Берни дә юк, бары хыяллар!..
Әле ярый ватык пыялалы
Тәрәзәдән дәшә идеаллар...

### Җүләрләр йорты

*Мин тиләләр сахрасында*
*Төндә ялгыз утырам...*
*Һади Такташ*

Тәрәзәнең тимер челтәрләре
Яктылыктан көн дә пароль сорый.
Акыл белән хисап өзгән гәүдә
Тар коридор аша кая сөйри?

Тыштан йозак элгән бүлмәләрдә
Чәчен йолка кемдер, ирек даулап...
«Эврика!» – дип, шәрран яра галим,
Гаскәрбашы кайткан җиңү яулап...

Монда бар да үзен даһи саный,
Монда фикер хакыйкатьтән өстен!
Тышкы дөнья тимер челтәр аша
Бигрәк төссез акыллылар өчен!

Ачкыч ярыгыннан теш ыржайта –
Каһкаһәләп әллә язмыш көлә?
Сары төскә манган шушы йорттан
Дөньясына сары йогып килә.

Пәрәвезле тәрәз ырмаулары
Җан газабын инде потлап йоткан...
Күктә очам дигән иләсләрне
Әллә кайчан кемдер төртеп еккан...

Балы кипкән, агу гына саркый
Касәләргә тулган кәрәзләрдән...
Сиңа охшаш берәү карый төсле
Тимер челтәр элгән тәрәзләрдән...

## Кызыл кан, ак кәфен

*Таң ата...*
*Гыйсъян явы әкрен генә*
*Канлы кырлардан басып җырлап килә;*
*Уртада «ул» – Октябрьнең билгесе,*
*Җил белән яу уртасында селкенә.*
*Һади Такташ*

Буталды... Һәммәсе буталды...
Кайда уң, кайда сул? Кыйбласы?
Ялгышмы, язмышмы – кем юрар
Җилләрнең җаннарны кыясын...

Кызылга, акларга бүленми
Саклыйсы иде лә Ватанны!
Иләктән иләнгән чагында
Кем таныр ананы-атаны?!

Кем хаклы, кем түгел – һай, авыр!
Буранда адашу бик җиңел!
Акылмы, йөрәкме – әйдаман,
Нигә соң давыллы бу күңел?

Исәпсез корбаннар. Мәгънәсе?
Бәясе дәверләр чатында?
Дошманнар батырга әйләнеп,
Күзгә-күз орышка чакыра.

Хәрабә өстендә хәрабә –
Һәр чорның насыйбы – патшасы.
Кызыл кан, ак кәфен – кем булып,
Мәңгегә Күкләргә ашасы?

Чор үтәр. Үзгәрер барысы...
Ил белән һаман да... чоңгылда.
Тик Берәү күзәтер дәүләтләр
Упкынга очканын соңында.

# Гөлназ Әхмәдиева

## Үткәнгә хат

Сәлам, Такташ! Киләчәкнең
Билгесез бер кешесе мин булам.
Хәзер инде җавап итеп сиңа,
Сәлам сүзе белән
Хат язарга теләп утырам.
Хатың
Үз кешесен озак эзләмәде,
Кулдан-кулга күчеп йөрмәде –
Интернет бар – шуңа
Конверт-фәлән кирәк күрмәде.

Беләм, бабай, бу хатымны
Син беркайчан укый алмассың.
Ләкин
Даның синең күмелмәде, халык таный
Үз чорының бунтарь баласын.
Җирдә ирек, яшьлек чәчәк аткан
Иң матур бер чорда яшибез.
Безгә кирәк түгел «Иптәш»ләр дә,
Иптәшлеккә мохтаҗ түгел без!

Безнең кырда аткан чәчәкләрнең
Бөреләре озак ачыла.
Бәлки орлыклары начар,
Бәлки...

Дөрес урын кирәк сайларга.
Сез теләгән тыныч көннәр чоры
Тоткарланды әле бик күпкә.
Сыйнфый көрәш алмашынды хәзер
«Махсус»лашкан хәрби көрәшкә.

Һәр чорның да чире булган сыман
Һәр заманның була чирлесе.
Яки үзе теләп авырганы,
Яки... берәр гади киресе.
Күп сыйфатлар хәзер үзгәрделәр,
Күпмеләре юкка чыктылар.
Үзе өчен яшәүчеләр артты...
Хәер, алар
Сезнең чоргы да бит җырчылар...

Әй син, Такташ! Күп нәрсәне әле
Сөйләр идем бәйнә-бәйнә.
Беләсеңме,
Вакыт хәзер бик кадерле.
Шуңа янә язармын хат.
Ул чагында ләкин башка булыр бары:
Мин дә, дөнья да
Кайсы якка үзгәрербез – белмим.
Үзгәртмәбез ләкин дөньяны.

***

Табаныңны Җомга саен
кытыкласа чирәм шавы,
үткән өчен җавап тотма –
һәр үткәннең үз чаршавы.

Һәр үткәннең киләчәге
башкаларга охшамаган.
Башы гына шигыремнең –
рифмалары таушалмаган.

Кауша, урам! Бит син генә
кануннардан курыкмыйсың.

Җиргә ят та күккә кара:
болытларда синең исем.

Үзәннәрдән тамчы көлә
ярып илһам кәсепчесен.
Шаулат димен диктофоның!
Тынсын бераз җил ачысы.

Яз тамчысы – гашыйклыгым
катыш нәфрәт сүрәләре.
Безгә тәнкыйть бирерсезме,
мәхәббәтнең түрәләре?

# Илнар Фатыйхов

***

*...Әллә кемнәр әрле-бирле йөренәләр;*
*Йөренәләр... Туктыйлар да илерәләр,*
*Шуннан: ап-ак кәфеннәргә төренәләр...*
*Һади Такташ*

Караңгыдан күпләр куркып кача.
Ай яктысын күпләр якын күрә.
Ә кайбере бара ахыргача,
Курыкмыйча атлап бара үлеменә.

Ә кайбере ай тотылган төндә
Күреп атлый сазлык баткагына.
Шундыйларны саклап сала сөрән
Карт ябалак, шәрә агач ботагыннан.

Мондый төндә ишетелә бары
Җил китергән ерак илләр шавы,
Гасырлардан килә тавыш ярып:
Сак белән Сок эзләшәләр тагын.

Урман сазлыгына берәү керә,
Карашында өметсезлек чаткылары.
Шомлы төнгә, ахры, инде күнгән,
Шомлы иртә куркытадыр бары.

Мәхшәр илен артта калдырганда
Сөенергә кирәк кебек, ләкин
Ике утның арасыннан сайлап
Алган Җирдә һәммәсе дә ятим.

Җил улавы катыш тавыш килә,
Үле урман уртасында – тавыш.
Ярдәм сорап кычкырамы икән?
Кай тарафка хәзер китеп барыш?

Урман уртасында берәү атлый.
Ай күптәннән сатлыкҗанга чыгып,
Эшләгәнен яхшы диеп яклый-яклый
Куак арасында сыдырылып

Посып ята. Төнге шомлы урман.
Берәү инде сазлык кочагында.
Калган тавышлардан өмет корган
Җаннар да бит эреп оча комга.

Афәт чолгап алган бу җирлектә
Кеше заты көн дә чума сазга.
Чиста җаннар сазда әсирлектә,
Чиста җанның бәясе дә арзан.

Нәзифә
Кәримова

# ОЗЫН-ОЗАК ЯЗМЫШЛАР

ПОВЕСТЬ-ИСТӘЛЕК

**Хатлар һаман килә...**

1990 ел 28, май. Әни хаты: «Кызым, хатың килгәч тә, хат яза алмый тордым. «Азат хатын» да «Май кырмыскасы» дигән хикәяңне укыдык. Бик күңелле чыккан».

Кызым Айгөлгә ай ярым вакыт 1971 елның июнь аенда язган хаты әнинең. «Кызым, бала ничек, үсәме? Башына кидертеп өйрәт. Кыз кешенең башы матур, түгәрәк булсын. Кидертмәсәң, озынча булып үсә ул бала башы. Салкын тидерә күрмәгез. Бәләкәй чакта салкын тигән бала чирләшкә була».

Әни! Безнең әни күп балалы гаиләдә алтынчы бала булып дөньяга килә. Әнидән соң әле тагы бер сеңлесе туа. Шул җиде баланы ятим калдырып, кырык яшендә әниләре вафат була. Әнинең хатларында аның бар туганнары да исән әле. Үги ана белән яшәгән әни 13 яшендә күтемкәсен асып, Берсут совхозына олы апасы янына китә. Кырык чакрым җирне җәяү үтеп, ул юллардагы җиде чакрымга сузылган калын урманнарны кичеп, барып җитә аның янына. Сугышка кадәр анда яши. Сугыш вакытында Алабугада механизаторлар курсын бетереп, сугыш беткәнче совхозда тракторда эшли. Безнең әни бары тик дүрт кенә класс укыган, анысы да латин хәрефләре вакытында. Ә инде хәзерге без яза торганга үзлегеннән өйрәнгән. Әнинең язуы үзенчәлекле иде. Кайбер хәрефләрне латин хәрефләре белән дә яза иде ул. Ләкин мин аның хатларын аңларга, танырга өйрәндем. Әнинең тәрбиясе дә бәлки шул хатлар аша килеп җиткәндер минем җаныма, күңелемә, акылыма. Чөнки әни янында булганда, иркәләү сүзләре ишетергә бик туры килмәде. Бездә алты бала, мин – олысы. Ярату бәләкәйләргә тия иде.

Шул ук елдан тагы бер хат: «Әле һаман уракны бетерә алмыйлар. Хәлим (бертуган энем) быел комбайнда. Яңгыр комачаулады. Быел бәрәңге дә бик начар булды. Бер дә юк. Тавык йомыркасы чаклы. Үсмәде, яфраклары корып бетте. Начар яңгыр яуды. Кислоталы диләр. Суганнарны да, бәрәңгене дә корытты. Орлыклык булса, ярый инде. Ашарга дигәне дә бик вак. Колхоз да икмәк бирми әле быел. Менә чикләвек булды быел урманда. Әйбәт кенә җыйдык. Алфира (кечкенә сеңлем – *Н.К.*) быел Казанга укырга керде.

*Дәвамы. Башы узган санда.*

Укытучы булачак. Ничек укыр инде. Тулай торак биргәннәр. Кызым, тамагың авырта икән, анысын Мәймүнә сөйләде. (Классташым, Садретдин абыйның врачлыкка укыган кызы ул Мәймүнә. Мәскәүдә миңа килеп киткән иде.) Тамак авыртканда, үги ана яфрагын кайнар суга манчып, авырткан җиреңә бәйләп куй. Файдасы тими калмас». Болар барысы да бер хатта. (Әнинең хатлары ничек язылган булса, шулай бирәм. Әни язмаларын төзәтмәдем.)

Алабугада укыганда, мин хатларны саклык белән генә ача идем. Ул хат эченә әни бер сум булса да акча тыга иде. Инде үзем эшли башлап, үзем ярдәм итә башлаган чакларымда да, әнинең хатларын саклык белән ача идем. Әйтерсең анда да акча салганнар! Мин дә аның үрнәгендә шаяртып булса да, хат эченә акча салуны үземә гадәт иттем. Шунысы кызык: барып җитә иде бит! Бер хатында әни: «Кызым, синең биш тәңкә тыккан хатың да килеп җитте. Мин аңар ураза фытрасы итеп дога кылдым. Ураза бәйрәмнәре вакытына туры килде. Ураза фытрасын үзем әнигә төшердем» дип язган (Әнинең үги әнисе – әби исән чак). Әни уразасын да, намазын да калдырмый иде.

Әни бер хатында болай дип яза: «Кызым, карточкалы икенче хатың да килде инде, җавап яза алмый тордым. Малайлар бик сөенде. Хәлим битенә куеп йөрде. Кызым, калганын кайткач сөйләшербез рәхәтләнеп. Өйдә бик рәхәт, гөлләр чәчәк атты. Хат яз. Көн дә көтәм». Җырсыз булмый инде. Әни җыр язган:

«Кәстрүлдә пешкән ашларыңны
Чоланнарга чыгып суытма.
Дөнья мәшәкатьләре күп диеп
Шәһәрдә, анаңны онытма».

Безнең әни укырга бик ярата иде. Алты балалы әнинең укырга вакыты каян табылгандыр, белмим. «Колхозчы тавышы» дигән район газетасын, балаларга «Яшь ленинчы» газетасын да яздыралар иде. Мин Алабугада мәдәни-агарту училищесының беренче курсында укыганда – 1962-63 уку еллары – әни хат эченә «Яшь ленинчы» газетасыннан кисеп алган фото һәм шигырьләр салып җибәргән. Ул хат хәзерге көндә миндәге хатлар арасында булмаса да, мин аның эчтәлеген бик яхшы хәтерлим: «Кызым, кара әле бу матур егеткә, ул шигырьләр дә яза икән. Армиядә чакта турниктан егылып төшкән дә имгәнеп калган», – дип, газетадан кисеп фотосын да, газетада басылган шигырьләрен дә җибәргән. Ул егетнең исеме Фәнис Яруллин иде. Мин әни җибәргән ул фото белән шигырьне кечкенә чемоданымның эченә ябыштырдым. Ул чемодан озак еллар минем белән булды. Шулай итеп, Фәнис Яруллин миңа бик якын, иҗатын бик яратам. «Яшь ленинчы» әнинең хатларында тагы берничә тапкыр телгә алына: «Кызым, «Яшь ленинчы» газетасында синең «Авылым җыры» дигән хикәяңне басканнар. Синең турыда Хәкимҗан Халиков дигән кеше бик матур сүзләр әйткән». 1986 елның июнь аенда язылган хатында әни болай дип яза: «Кызым, кичәге Сабан туенда, мәйданда Шаһинур Мостафин минем яныма килеп, синең «Җәнлекләр кайта» дигән китабыңны биреп китте. Көлешә-көлешә укыдык өйгә кайткач. Мин балаларга боларның барысы да дөрес язылган

дип әйттем. Әле шул Сабан туе уеннарында да катнаштым бит. Кашык белән йомыркалы йөгерештә икенче урында килдем!» дип язган әни.

Әнидән алган хатларны укыганда «Кызым, җибәргән посылкаңны алдык. Бер әйбере дә бозылмаган» дигән юллар булса, миңа бик рәхәт булып китә. Ул аңар озак-озак рәхмәтләр яза. Кайбер хатларын икешәр көн, туктый-туктый язганга алдагы хәбәрләр хат ахырына яңадан кабатлана. «Әле, кызым, бездә почта эшләми торды. Почта кызы Казанга киткән, ачкычын үзе белән алган. Килгән посылка да ята, ди, хатка конверт та алып булмады. Ә менә бүген дүрт хат, бер посылка килеп төште. Почта кыз кайткан» дип яза әни.

Әни хатлары турында язу болай авыр булыр дип уйламаган идем. Бигрәк тә миңа үпкәләгәнрәк юллар булса. Бер хатында болай дигән: «Син дә сирәк яза башладың. Сездән хат килмәгәч, бик читен. Көн дә көтәбез. Укыганда, ешрак килә иде хатларың. Хәзер инде үстең шул. Тик син миңа барыбер шул унбиш яшьлек бала бит. Үземнең картайганымны чутламыйм. Чәчем ап-ак хәзер. Һәрбер балам турында уйлаганга ул. Ярар, кызым, сау булыгыз, тигез, сау булып кына яшәгез.

Ишегалдым – түгәрәк күл,
Көн дә әйләнеп узам,
Сезнең яктан кошлар килсә,
Хат юкмы дип, кул сузам!»

Әнинең күпчелек хатлары менә шулай, үзе язган шигырьләр белән тәмамлана.

Илгиз белән өйләнешеп, ярты ел үткәннән соң, әни Мәскәүгә килде. Берүзе! Әти авырып торганга күрә туйга килә алмаганнар иде. Ул вакытта Мамадыштан да еракка китмәгән әни, тәвәккәлләп, Мәскәүгә килеп җитте. Бу 1971 елның феврале иде. Мин аңа Мәскәүне күрсәттем, Кызыл мәйданда да булдык. Чират аз иде, Мавзолейга да кердек. Бәлки анда керергә кирәк тә булмагандыр дип уйлыйм. «Кабергә төшеп менгәндәй булдым», – дигән иде әни.

Мәскәүдән кайткач язган хатында: «Мине поездга утырткач, үзегез ни хәлдә кайтып җиттегез өйгә? – дигән әни. – Аерылган минутлардан бирле күз алдымнан җибәрә алмыйм сезне. Аллаһы Тәгалә мәңге рәхәт, тигез тормыш бирсен. Бик әйбәт кунак иттегез, зу-ур рә-ә-әхмә-ә-әт! Кадерле киявебез һәм кызыбыз кулыгызны кысып, икегезне дә үбеп, әниегез, әтиегез, балалар. (Кич сәгать 8, 7 март, 1971 ел.)»

Әнинең соңгы хаты 2001 елда килгән. Шул елны аларга телефон керттеләр, әни белән бик еш телефоннан сөйләшә идек. Әнинең соңгы хаты – васыяте шул булгандыр: «Кызым, мәңге хәер-дога сиңа, рәхмәтем яусын! Аяк атлаган саен әни хәер-догасы бу диген. Мәңге рәхәт яшә. Кая барсаң да, эшең уң булсын, сүзең өстен булсын, адәм арасында йөзең якты булсын, үзеңне зурлап йөртсеннәр, йа Рабби Ходаем. Миннән теләк шул сиңа, кызым, балакаем, рәхәт яшә».

Әни авылда төпчек улы – энем Хәлим гаиләсе белән яшәде. Аларга өч бала үстереште. Киленебез Фирдәүсә безгә дә, әнигә дә ягымлы булды, һәрвакыт «әни, әни» дип торды. Безнең әни каенатам вафатыннан соң дүрт

ай узгач, 2006 елның гыйнварында бакыйлыкка күчте. Соңгы минутларына кадәр үз аңында иде. Белгән догаларымны укып, кулыннан тотып, янында утырдым. «Әни, доганы дөрес укыйммы»? – дип сорагач, әни: «Дөрес укыйсың, кызым, дөрес укыйсың...» – диде. Барыбыз да җыелышкан идек.

Әни озак авырып ятмады. Һәр өйдә була торган олы, матур сандык әнинеке дә бар иде. Сандыгын ачкач, барыбыз да гаҗәпләндек. Әни хәер-садакага бирәсе һәр әйберне төреп, һәрберсен пакетка салып, язып әзерләп куйган. Су китерүчеләргә, су биреп торучыларга, юындыручыларга, тастар башы тотучыларга, өй юучыларга һәм башкаларга. Сандыкның бер почмагында яулыкка төрелгән зур гына төенчектә беренче чыгарылышыннан башлап Ислам календаре, әнинең үз кулы белән догалар язылган дәфтәрләр. Әнинең вафаты вакытында көннәр бик салкын торды. 16 гыйнвар иде. Җил, 35 дәрәҗә салкынлык иде. Энем кабер казырга кеше килерме икән дип борчылды. «Безнең әни изге кеше ул, менә күрерсез әле, көнне җылытачак!» – дидем. Чынлап та, шулай булды. Җил тынды, дымык кына йомшак кар ява башлады, көнне җылытып җибәрде. «Кабер казырга күрше авыллардан ук көрәкләрен күтәреп, бик күп кеше килде», – диде энем. Җир каты булмаган, кабер эченнән җылы пар күтәрелеп торган.

Әти-әниемне, каенанай белән каенатаемны искә алмаган көнем юк. Алар минем догаларымның башында. Бу хатлары белән дә алар һәрвакыт минем янымда. Рухларыгыз шат булсын, кадерле кешеләрем.

## Әткәй көндәлекләре

Каенатай көндәлекләрен 1941 елның ноябрендә фронтта яза башлаган. Ул вакытта аңар 22 яшь кенә әле. Бу турыда: «Бик тырышып, язу дәфтәре тектем. Каты кәгазь белән җилемләп тышладым. Бүгеннән башлап, сирәкләп булса да, көндәлек язарга, башка килгән фикерләрне теркәп барырга уйлыйм...» дигән. Соңгы язмасы 2005 елның апрелендә теркәлгән. Аерым китап булып чыкмаса да, «Көндәлекләр» аның 10 томлык «Әсәрләр» җыентыгына 10 нчы том булып кергән. Биредә әткәйнең мин белгән, мин белмәгән, хәтта ишетмәгән вакыйгаларга бәясе, фикерләре, уйлары, кайгы-хәсрәтләре, моң-зарлары, үпкәләре, шатлык-куанычлары теркәлгән. Аның турында күбрәк мәгълүмат бирер өчен мин дә кайчагында көндәлек битләрен сак кына ачып, сезгә дә аның хисләрен җиткерермен дип уйлыйм...

## Әткәйдән диңгез сәләме

Әткәйнең миңа атап язган бер хатын китерәсем килә. Ул аны 1971 елның 22 сентябрендә Дубылтыдан, язучыларның иҗат йортыннан язган. Анда шаккатарлык бернинди хәбәр дә юк, иң мөһиме – хат башкаларыннан аермалы буларак, татарча язылган, шуңа күрә миңа аталган дидем. Әлбәттә, ул миңа гына түгел, безнең гаиләгә язылган. Хат ахырында «Нәзифә! Минем татарча язуым шәп килеп чыкмады бит әле» дигән. Хат болай башлана:

«Айгөл һәм башкалар! (Айгөл – кызыбыз. Аңа ул вакытта 4 ай.)

1940 елда мин Язучылар союзында консультант булып эшли идем. Шул чак Сәгыйть Агишның зур кызы (9-10 яшьләр тирәсе) әкият язып китергән.

Исеме «Аю һәм башка кошлар». Әле дә шуның шикелле килеп чыкты.

Бу хатны сезгә диңгез сәламнәре җибәрү һәм үземнең исәнлекне белдерер өчен генә язам.

Яшәп ятам шулай. Бу атнаны күп укыдым һәм ял иттем. Азлап эшкә тотынмакчымын. Көннәр бу арада ару гына әле.

Шалтыратканда, әнкәгезгә сәлам әйтегез. Ул уннары тирәсендә Москвага килсен, шулай сөйләшкән идек. Мин дә 10ысында кайтып җитәрмен. Әгәр минем каршылауны теләсә, 11ендә килсен. Ә бәлки аның алданрак киләсе килер. Үзе карасын инде.

Артык яңалыклар юк. Өчегезне дә әп итеп калам. Картатай».

Менә нинди кайгысыз, рәхәт көннәр булган. Без дә яңа гына тормыш башлаган. Әткәй белән әнкәй әле генә иллеләрен тутырган. Аларның да, күп михнәтләр кичкән булсалар да, рәхәт итеп яшәрлек күпме гомерләре бар! Ә инде алда нәрсәләр буласын әле без дә, алар да, беркем дә белми...

Әткәйнең 1971 елда безне Яңа ел белән котлап җибәргән открыткасы сакланган архивта. Ул открыткада өч песнәк рәсеме. Әткәй рус телендә язган:

«Эй люди! Смотрите на обратную сторону. Там три хвостливых, задиристых синицы. Они кого-то напоминают. Вот. Живите родные, милые, бесконечно дорогие синички, радуясь и радуя нас. Не унывайте. Предки тех синиц спалили море. Помните об этом всегда. Обнимаем. Папа, Мама, Альфия, Олег. 23.12.1971.»

## Көндәлектән

31.12.84. «Елның соңгы көне. Быел энемне югалттым. Кирәй Мәргәнсез, Габдулла Әхмәтшинсыз торып калдым. Күңел тынычлыгын күбрәк югалттым, аз эшләдем, аз яздым. Үземне юатырлык нәрсәләр дә күп. Рауза аяк өстендә, балаларыбыз исән-сау, олылары да, кечеләре дә безгә хөрмәт күрсәтә. Тимербулат унын тутырды. Тагы 8-9 ел яшәсәм, рухы ныгып, ихтыяры төпләнеп калганын күрер идем. Бәлки йогынтым да тияр иде. Шушы елда мин әдәби хезмәтем өчен югары бәһа алдым, тик аның шатлыгын гына тоя алмадым. Бу хәл энем белән дустымның җеназа көннәренә туры килде. «Ярлыкау»ны тәмамладым диярлек. РСФСР Югары Советына депутатлыкка күрсәтүләре турында хәбәр килде. Кыскасы, узган ел шома гына булмады».

1984 елда Мостай Кәрим хезмәтләре өчен Ленин премиясенә лаек булды. Шул ук елны «Халыклар дуслыгы» орденын алды.

## Рэкетирлар яный

90нчы еллар... Дәһшәтле еллар иде. Әткәйнең иң авыр кичергән, аның җанын талаган еллар иде ул. «Мостай агай, Мостай агай» дип, артыннан чыгып, күзенә караучылар соңрак аңа, янәсе, «турысын» әйтүдән, ачыктан-ачык нәфрәт белдерүдән тартынмадылар. Бер танылган журналист атналар дәвамында көн саен әткәйләрнең өй телефонына шалтыратып, дөньядагы барлык кабахәт сүзләрне әйтеп, ачуын чыгарган. Ләкин ул журналист белән әткәйнең очрашканы да булмаган. Мостай Кәримнең аңар бер генә начарлыгы да тимәгән. Тик ул үзе кебекләр белән теләктәшлектә булганын

менә шулай белдергән.

Ел буена хәтта рэкетирлар да аңар хатлар язып, акча таләп иткәннәр. «25 майда, – дип сөйләгән иде әткәй, – Мәскәү штампы сугылган хат килде, рэкетирлар җибәргән. 90 мең сум акча сорыйлар. Кассадан алып, әзерләп куярга куштылар. Балаларым, оныкларыма янау белән куркытканнар. 1988 елда акчамны санап, Яныбай Хамматов мине черегән байга чыгарган иде. Күрәсең, бу информация ясау булгандыр. «Ул бай! Аны талагыз!» – диде микән? Минем андый акчам юк, булса да өркеп бармас идем».

«Органнарга хәбәр итеп тә тормагыз, файдасы тимәс», – дигәннәр.

Әткәй соңыннан болай дип сөйләгән иде: «Дачадан кайттым. Иртәгә Мәскәүгә барасым бар. Дөресен әйтим, почта тартмасын ачканда, шөбһәләндем, ләкин бүген рэкетирлардан хат юк иде. Көн саен 90 мең сум акча сорап, хат калдыралар иде. Бүген юк. Чәйнек куйдым да 150 грамм салдым. Батыраеп киттем, курку да юкка чыкты. Фронтта чакта юкка гына бирмәгәннәр икән ул наркомныкын. Курку гел бетте, түшенкелеккә бирелү дә юкка чыкты. Чакырсыннар, әйдә, рэкетирлар! Тагы бер уртлыйм да барам бу талаучылар белән кара-каршы сөйләшергә дип уйладым. Ләкин бу хатлар мәкерле, усал уен булды, ахры. Кабат алардан хәбәр булмады».

Аның миңа бу турыда үзе дә сөйләгәне бар. Дус булып, аның кырыенда тыпырдап торучылар да, Мостай Кәрим заманы узды дип, үзләренчә тибеп китүне батырлыкка санаганнардыр. Мин шул вакытта әткәйгә:

– Нигә күңелегезгә якын аласыз, нигә шулай борчыласыз? Уйламагыз да алар турында, – дип, үземчә аны тынычландырырга тырыштым. Шунда әткәй:

– Әй, кызым! Менә кырмыска бәләкәй генә. Шул аягыңа үрмәли башласа, эчең поша бит... – дигән иде.

## Көндәлектән

19.07.90. «Кая карама, күз яше. Газеталар елый, радио елый, телевидение елый, шагыйрьләр елый – тормыштан зарланып елыйлар. Әмма бөтенесе дә бу яшәүнең сәбәбен узганнардан эзли, үткәннәргә яба.

Ә бит, асылда, бүгенгебез начар булган өчен елыйбыз, тик моны нигәдер танырга теләмибез. Янәсе, әүвәлге хәлләр безне шушы көнгә төшерде. Ә бит биш ел буенча эшсез, тәртипсез, әдәпсез дөнья көтүебез, еллар буе сүз сөйләвебез безне нәрсәгә китерде соң?

Ялган хәзер бигрәк алга килеп басты. Әнә, газеталар «Перестройка җиңде!» дип яза.

Җиңү нәрсә соң ул?

Көч сынашып, кемнедер, нәрсәнедер аска калдырып өскә чыгу. Нәрсәне җиңеп, кемнән өскә чыктык соң әле? Тәртипсезлекне, әдәпсезлекне, фәкыйрьлекне, җинаятьне җиңдекме? Коррупцияне, ил талауны, илдәге ызгыш-талашны җиңдекме?

Тормышны какшаттык, державаны таркаттык, садака сорап, читләргә кул сузабыз.

Шушыларны күргән, әйткән кешеләрне консерваторга, перестройка дошманына чыгаралар.

Нәрсә үзгәрде? Әүвәл заманда да начарны әйбәт дип бәһаләдек, әле дә шулай. Ул чакта, ичмасам, әйбәтнең килүенә, күзгә чалынуына ышанып кычкыра идек.

Хәзер нәрсәгә ышанырга?

«Литературная газета» мәкалә язуымны сорап, хат җибәргән. Баш тарттым. Аларга бит уйланулар, икеләнүләр кирәкми. Аларга фашлау, бүгенгене түгел, үткәнне фаш итү кирәк. Үләксә исеннән әле булса да туймыйлар».

## Константин Симонов киңәше

Әткәй Константин Симонов белән дус иде. Чит илләргә – Кипр, Сүрия, Төркиягә бергә булган сәяхәтләре аларны тагы да якынайткандыр. Бервакытны әткәйнең эш өстәлендә Симоновтан килгән хатны күрдем. Әткәй аны укыган, конверт ачык. Аның шундый дусларыннан килгән хатларны куя торган махсус урыны да бар иде. Кабинетны җыештыра идем, күз төште инде. Язучы хаты, җитмәсә, Симоновтан. Бу хатны да шул хатлар арасына куярга уйлаган идем, гафу итегез, кызыксынып киттем. Болай дип язган иде: «Мостай, синең яралы күкрәкләреңне күреп, шаккаткан идем... Сиңа бу сугыштан бик каты эләккән икән. Мин алай ук дип белмәгән идем... Син бит чын геройсың...» Сүзгә-сүз түгелдер, ләкин эчтәлек шуңа якын иде. Әткәй көндәлекләрендә Константин Симоновтан сабак алуы турында яза: «Бу хәл күптәннән булды. РСФСР Язучылар берлеге съездында чыгыш ясаганда, чыгышым матуррак чыксын дип, ниндидер мәкаль белән: «Халыкта шулай дип әйтәләр...» дип башладым. Тәнәфес вакытында Константин Михайлович минем чыгышымны мактады да болай диде: «Без синең белән иске дуслар, мин сине яратам, шуңа күрә турысын әйтәм – башка беркайчан да халыкның зирәк сүзләренә салынма. Син – шагыйрь, үзеңнең зирәклекне күрсәт. Шундый итеп әйт, халыкта аны «Мостай әйткән!» дисеннәр. Халык инде күптән әйткән ул сүзне, ә син аңа өстәп, бернинди яңалык та әйтмәдең». Симонов үзе беркайчан да әзер мәкаль, әйтемнәр кулланмый иде».

Әткәйнең канатлы сүзләре, фикерләре байтак кына. Ул афоризмнарны «Мостай әйткән» дигән исем астында бирегә дә кертергә уйладым.

**Мостай әйткән:** «...Народ, конечно, любит благородных, честных людей, но за них не заступается, поэтому палачи их убивают безнаказанно».

## Поши утравында

Әткәй язмаларында, ул кайда гына булмасын – иҗат йортындамы, хастаханәдәме – беренче чиратта, үзенең эше турында хисап яза. Иҗат йорты ярый әле, анда иҗат өчен булсын да, ди, ә бит хастаханәдә дәваланырга кирәк тә бит! Ләкин ул гына аз аңа. Мәскәүдә, Лосиный остров дигән бик матур җирдәге хастаханәдә кәгазьгә төшергән көндәлек язмалары белән таныштырыйм әле:

«22 көн инде Мәскәүдә «Поши утравы» дигән җирдә больницада ятам. Күп итеп тикшерделәр. Бүген эч-бавырны карадылар. Шикләре бар иде. Шикләр юкка чыкты. Өч атна эчендә 5 шигырь яздым, байтак дәва алдым.

Өч роман укып чыктым. Сенкевичның «Камо грядеши», Флоберның «Саламбо»сын, Альфред де Мюссеның «Исповедь сына века» әсәрен. Бу соңгы ике китап әллә ни тетрәнүләр китермәде. «Исповедь»ның төп идеясе безнең бүгенге көнебезгә аваздаш. Болардан тыш, Лена (тәрҗемәче Елена Николаевская – *Н.К.*) өчен 300 юл шигъри подстрочник ясадым. Монда килгәндә йончып килгән идем. Беренче көннәрдә уянам да: «Бүген дә яшәргә туры киләчәк», – дип пошына идем. Соңгы 15 көндә тышкы дөньяның нинди булуына карамастан, көннәрнең йончулыгына игътибар итмим, дөньяга өметем арта бара. Арыганчы йөрергә тырышам, төнен изрәп йоклап китәм. Иртән уянгач: «Тагы да яшисе әле...» – дип торам».

### Бәйрәм котлаулары

Әткәй үзе исән чакта минем аның турында кәгазьгә төшергән язмаларым юк дәрәҗәсендә. Язарга уйласам да, үземне тыя идем. Үземне үзем битәрли идем. Аны озак-озак итеп яшәтәсем килүнең бер сәбәбе иде ул. Имеш, әгәр дә аның турында истәлекләрне кәгазьгә төшерсәм, ул үлеп китәр кебек тоела. Бигрәк бала-чагача фикер йөрткәнмен инде. Шулай да архив битләрен актара торгач, кайбер язмалар табылды. Берсе 1993 елда язылган:

«Әткәй, танышлары, дуслары, хәтта туганнар ягыннан үзенә карата элеккечә ихтирам, игътибар булмаудан зарланып, шундый чагыштыру китергән иде. Лев Толстой инде олы яшендә, үз крестьяннарының аңар хөрмәтсез караулары турында зарланып, менә мондый истәлек язып калдырган: «Мужиклар исәнләшүен исәнләшәләр, ләкин хөрмәт йөзеннән бүрекләрен салмыйлар. Башларындагы бетләренә салкын тиюдән куркалар, күрәсең!» – дип сөйләгән иде әткәй, көлеп».

Илдәге үзгәрешләр аның җанына да, кәефенә дә, тормышка, кешеләргә карашына да йогынты ясамый калмады, әлбәттә. Аның безгә дә үпкәләгән вакытлары булган икән. Көндәлекләрендә ул болай дип язган: «Шул турыда уйладым әле. Кешеләр гомер бакый барлык игътибарларын, хәстәрләрен үзләреннән түбәнгә – балаларына юнәлтәләр. Бу табигыйдыр. Ыру саклау инстинкты. Бүген миңа бүтәнрәк фикер дә килде. Нигә шушындый хәстәрне ата-аналар исәбенә эшлибез? Мин начар ул да түгелмендер, әмма инәй (әнисе – *Н.К.*) турындагы хәстәрем кече туганнарыма караганда азрак төсле. Төсле генә түгел – азрак! Кемнең хокукы игътибарга зуррак соң? Балаларым, оныкларым әйбәтләр, әдәплеләр. Ә хатыным Рауза? Аңар игътибарымны биреп бетерәмме? Бу уйларым шуннан туды. Чирле инәем минем хәлне сорашып, Салисәдән ике тапкыр шалтыратты. Ә Мәскәүдәге балаларым мине бәйрәм белән котларга онытты».

Мәскәүдәге балалар – без. Бу – 90 елның 1 мае. Без әткәйне Беренче май белән котларга онытканбыз икән. Ул елларда Беренче май белән беркемне дә котламадык, ахры. Ул вакытта Мәскәүдә ничек җан асрау кайгысы иде. Кибетләрдә Нарзаннан башка берни дә юк. Универсамда берәр әйбер сатарга чыгарасы булсалар, кул сыярлык кына тишектән прилавкага ыргыталар иде. Чират чирү кебек! Буп-буш кибет! Ул вакытта нинди бәйрәм турында уйлау?! Беренче май да бәйрәм төсен югалткан иде инде. Әлбәттә, бәйрәм котлауларын, открыткаларны һәрвакыт мин яза

идем. Әткәй миңа үпкәләгән дип аңладым. Үпкәләү әткәйнең ул вакыттагы күңел халәте дә булгандыр. Башка елларны мин аның безгә үпкәләгәнен һич хәтерләмим. Чөнки булганы юк андый хәлнең. Ачуланса ачуланыр, ләкин һич тә үпкәләмәс иде ул. Аның өчен иң кадерле, иң зур бәйрәм – Җиңү көне иде. Ул бит аны үзе, сәламәтлеге хисабына, тормышы хисабына канын түгеп көрәшеп алган! Без ул хакта беркайчан да онытмыйбыз, онытырга хакыбыз да юк. Мәскәү белән Уфа арасында ике сәгать аерма да бар бит әле. Алар иртәрәк уяна. Кайсыбер елларда ул безнең котлауны да көтми, безне шаккатырып, хәтта уңайсыз хәлгә куеп, иртән-иртүк үзе шалтырата торган иде. «Беләм, котласыгызны да беләм! Минем өчен Җиңү көненең нинди бәйрәм икәнлеген дә беләсез! Ләкин үзем котларга булдым әле Җиңү бәйрәме белән, бу – минем бәйрәм. Туганнарны да, барыгызны да!» – дигәне бар иде әткәйнең. Чөнки ул аның заманы, аның шәхси бәйрәме булган. Ул заманда безнең аңа карата мөнәсәбәткә хөрмәтсез дип шикләнергә дә, үпкәләргә дә урын юк, ул аны яхшы белә. Ә инде 90 елдагы ул үпкә безнең аңа булган мөнәсәбәткә дә шикләнеп каравы дип аңлыйм.

Көндәлекләрендә әткәй хәтта Тимербулатка да үпкәләвен белдерә. Ул болай ди: «Тимербулатка юк-барга хәтерем калып йөрдем. Мыжык. (Ул үзе турында шулай ди. – *Н.К.*). Ачуланмаска вәгъдә иткән идем инде күптән. Үзем дә инде элегрәк язган шигыремдәге керпе кебек тырпаерга гына торам. Чынлап ачуланмыйм инде, үпкәлим генә. Картлыктан котыла алмаган кебек, юк-барга хәтер калудан да котылып булмыйдыр инде».

Менә ул шигырь:

«Онык – яшь арыслан. Бар куәте
Тимер тырнагында.
Атасы – йөк аты. Бар мөлкәте
Алтын тоягында.
Ә бабасы – керпе. Аның инде
Хәле аянычлы:
Тырпаерга торган энәләре –
Барлык таянычы».

Бу шигырь 1970 елда язылган. Әткәйгә ул вакытта нибары 51 яшь! Ләкин ул картлыкны да күрә белгән. Чөнки ул – шагыйрь. Шагыйрьләр – әүлия.

Бигрәк тә 90-91 һәм аннан соң килә торган әле байтак еллар – аның җанын әрнетеп, бу халәттән чыгарга чара табылмаган гаҗиз чор ул.

### Кем модада?

28.01.92. Әткәй Муса Гали белән Переделкинода. Таныш язучылар да бар икән. Шагыйрь Рафаэль Сафин да алар белән. Әткәй бу турыда үзе сөйләгән иде: «...Кичә Гыйлемдар (Рамазанов) белән Фәния (Чанышева) килде. Килгәч тә, безне чәйгә чакырдылар. (Рафаэль Сафин, Муса Гали, мин). Коньяк китергәннәр. Эчемлегеннән дә, күчтәнәчләреннән дә авыз иттек. Кирәй Мәргән әйтмешли, истигъмал иттек. Сәгать 12 тирәсе булгандыр, Рауль Мирхәйдәровны да чакырырга уйладык. Мин аңа шалтыраттым. «Йоклыйм!» – дип кырт кисте дә трубкасын куйды. Кара, ничек масаеп китте бу малай! Элекке очрашуларда минем аңа күп ярдәмем тиде. Ул

вакытта төнге дүрттә чакырсаң да, ыштанын кия-кия йөгерер иде. Ничәмә нәшриятка мин аның әсәрләрен тәкъдим итеп хатлар яздым. Күбесе минем үтенечемне үтәде. Ә хәзер ул андый эшләрне үзе хәл итә. Тиз оныталар. Уфада шушы араларда Әхияр Хәкимовның иҗат кичәсе булган икән. Аңа ярдәм иткән бик күп язучыларга рәхмәт укыган. Минем исемне телгә алмаган. (Перестройка башлангач, минем исемне әйтмәскә тырышалар.) Өтек! Аның өчен ниләр генә эшләмәдем мин! «Литературная газета»га туп-туры мәгънәсендә эшкә урнаштырдым, комиссия председателен үгетләп, күндереп, РСФСР премиясен алып бирдем. Минем иҗат буенча диссертация язып, кандидат булды. Әллә була яздымы? Әсәрләренә карата һәрвакыт фатихада булдым».

Ул сөйләшүдә әткәй сүзләренә мин дә өстәдем: «Аның «Куштирәк», «Думра чыңы», «Бәйге» һәм башка әсәрләрен Илгизнең рус теленә тәрҗемә иткәнен дә онытмыйк. Ул вакытта Илгизнең тәрҗемә итүен көтеп, татар, башкорт язучылары чиратта тора иде бит», – дидем.

Әткәй дәвам итте: «Ул бит аларның барысын да белә. Тик шуны да яхшы аңлый, исне тиз сизә. Мостай Кәрим хәзер модада түгел. Җитмәсә, «Мине Уфадан кудылар», – дип, кешеләрнең башын бутый икән. Ул бит Хәким Гыйләҗев белән ызгышып, үзе teләп китте. Кыскасы, җилнең кайсы яктан искәнен белеп тора. Афәрин, Әхияр! Шомбай! Юк, Шамбы!»

## Иҗат йортлары

Әткәйнең язарга дигән зур планнары булса, мәшәкатьле дөньяны калдырып, язучыларның иҗат йортына барып, иҗатка чума иде. Ул 40 елдан артык кыш айларында иҗат йортларына китеп, иң күренекле әсәрләрен язган. Аның яратып йөргән иҗат йортларының берсе – Малеевка, ул Мәскәүдән 250 чакрым чамасы. Икенчесе – Мәскәүгә якынрагы – данлыклы Переделкино.

Әткәйнең иҗаттан тыш, әзрәк тугарылып китәр өчен ике төрле яраткан шөгыле – хоббие бар иде. Берсе – бильярд, икенчесе – преферанс. Иҗат йортларында преферанс уйнагандырмы, белмим, аның уйнаучы дуслары Уфада күбрәк иде. Ә менә Малеевкада бильярдны уйный торган булган. Монда аның белән уйнарлык язучылар да байтак кына була.

Заманында бу иҗат йортында Антон Чехов та ял итеп, ул да бильярд уйнаган дип әйтәләр. Иң билгелесе шул: Чехов анда «Дом с мезонином» дигән хикәясен язган. Язучылар өчен Малеевка «догалы» урын булган, әлбәттә.

Малеевкада әткәй әле чаңгыда да йөри торган булган. Ә инде иң рәхәте – төшке аштан соң дуслары белән Малеевканың кардан чистартылган киң, тигез аллеяларыннан йөреп керү.

Бер елны әткәй иҗат йортында Сергей Островой дигән шагыйрь белән туры килә. Ул шагыйрьне күпчелек «Дрозды» дигән җыры аркылы белә. Татарча «Миләш чыпчыгы» дип тәрҗемә ителә. Ул шагыйрь күп вакыт хатыны белән килә икән. Малеевкада минем дә аларны күргәнем булды. Татьяна исемле ул ханым арфада уйный иде, Зур театр оркестрында солистка дип әйттеләр. Иҗат йортына да шул алагаем зур уен коралы арфа белән килеп, репетиция ясый, фойены яңгыратып уйный. Тагы шунысы да бар икән: ул ханым язучы Лев Толстой нәселеннән булып, үзен бик горур,

графинялар кебек тота иде. Әткәй бильярд уйнаганда, Сергей Островойга:

– Сережа! Синең хатының бик матур икән! – дип әйтеп куйган. Ә моңа каршы Сергей Островой бик җитди итеп:

– Ай Мостай! Син аны шәрә килеш күрсәң иде! – дип әйткән ди.

Әткәй Малеевкадан кайткач, бу турыда сөйләп, безне көлдергән иде.

## Юбилей

1992 елның гыйнвар ае. Мин 2 гыйнвардан 18ләренә кадәр Согуд Гарәбстанында гомрә хаҗында булдым. Бу ике ил арасында сәяси багланышлар башланып киткәнгә бер бүләк булды дип әйттеләр. Россиядән күп кеше бергә оештырылып барылган беренче, тарихи гомрә хаҗы булган ул безнең сәфәр. 129 кеше идек. Согуд Гарәбстаны короленең кунагы булдык. Мәккәне күрдек, Мәдинәне зиярәт кылдык. Гомумән, хаҗның барлык йоласын үтәдек.

Без ул көннәрдә Равил хәзрәт Гайнетдин җитәкчелегендә атнасына бер тапкыр эфирга чыга торган «Рухи мирас» дип аталган радиотапшыру башлап җибәргән идек. Мин «Карурманнан чыккан юлчылар» әсәрен яңа гына тәмамлап, «Казан утлары»на биргән идем. 1991 елда минем тәрҗемәдә төрек язучысы Азиз Несинның «Эт койрыгы» дигән китабы Татарстан китап нәшриятында дөнья күрде. Минем дә иҗатым юл алган еллар иде ул.

1992 елның 10 гыйнвары – Илгизнең туган көне. Юбилее. Илгизгә 50 яшь тулды. Юбилейны соңрак, мин хаждан кайткач үткәрдек. Арабызда әткәй дә бар иде. Уфадан Илгизнең сеңлесе Әлфия, аның ире Олег һәм уллары Тимербулат та килде. Тимербулат бу юбилейны, табынны видеога төшерде. Әткәй бу хакта үзенең көндәлекләрендә кыска гына язма калдырган:

«Кичә Илгизләрдә булдым. Бәйрәменә тик иске дусларын гына җыйган. Улыма сокланып утырдым. Бер үк вакытта аны нигәдер кызганам. Бик аз эчтем. Сәгать сигез тулыр алдыннан Олег (кияү) белән Булат (Тимербулат) мине Киев вокзалына кадәр озата килделәр дә поездга утыртмадылар, такси белән җибәрделәр. «Болай ышанычлырак булыр», – дип кырт кисте «дөнья күргән» Тимербулат. Ни тиклем генә эчем пошмасын, балаларым бар – таянычым бар. Бәлки, иң зур таянычтыр».

Әле һаман да аңлап бетерә алмыйм: ни өчен ул Илгизне «кызганам» дип язды икән? Ул очрашу искиткеч җанлы, күңелле бәйрәм булган иде бит. Үзенең җанын ашаган заман хәстәре хиссиятен Илгизгә дә күчереп караганмы? Әткәйнең бу сүзләрен аңламадым. Хәзер сорап булмый инде. Бәлки ул 50 яшенә җиткән улының иҗаты турында да уйлагандыр... Ул көнне улыбыз Нияз гына юк иде. Көньякта пионер лагерында иде. Нияз шәһәр Пионерлар йортындагы яшь корреспондентлар түгәрәгенә йөреп, шунда бик актив эшләп, хикәяләрен бастырып, дизайнер буларак үзләре чыгарган газетаны бизәү эшендә дә актив катнашканы өчен бушлай юллама белән бүләкләнгән иде.

## Без бит – авыл балалары

Үз гомеремдә Илгиздән зарланып, әткәйгә бер тапкыр сүз кузгаттым. Әле ул да киңәш сорап әйтелгән сүзләр иде. Ләкин әткәй кырт кисеп:

«Миңа минем улымны яманлама!» – диде. Шуннан соң инде мин телемне тешләп, әйтәсе килгән чакларда да дәшми кала идем. Йә булмаса мактыйм. Андый чакта әткәйнең кәефе була иде. Гаиләнең дәрәҗәсен төшерсәң, олыларның хөрмәте югала бит. Мин моны яхшы аңлый идем. Тик шулай да әйткәләгәнем булгандыр, күрәсең. Мин һәрвакыт Илгизнең озакка сузып эшләвеннән зарлана идем. Чөнки ул әткәйнең әсәрләрен тәрҗемә иткәндә дә шундый булды. Ул вакытта әткәй белән сүзләребез килеште. Әткәй генә түгел, башка авторлар да шалтыратып, миннән Илгизне ашыктыруымны үтенәләр иде. Андый чакта да әткәй барыбер улын якларлык сүзләр таба иде: «Шулай инде, ялкаулыгы бар инде. Ул бит, ни дисәң дә, язучы малае. Ә без синең белән – авыл балалары, эшкә күнеккән!» – дип аклый иде ул аны...

Тагын аның әле без өйләнешкән көннәрдә миңа әйткән сүзе бик каты уелып хәтердә калган. Ул миңа: «Ачуланышып, аерылып китеп, кабат кушылып йөрисе булма. Бер китәсең икән, гомерлеккә китәсеңне бел. Кабат кушылдым – юк! Киткәнче шул хакта уйла. Кире кайтасың килә икән, китеп йөрмә», – диде. Менә шулай. Кайчагында ирне акылга утыртыр өчен генә булса да, андый теләкләр башка килгәләде. Ләкин әткәйнең катгый киңәше ул адымнан саклап калды.

## Мостай Кәрим малае

Илгиз беркайчан да «мин – Мостай Кәрим малае» дип мактанып йөрмәде. Беркайчан да үзен әтисе малае дип танытмады, белгәннәр белгәндер, белмәгәннәр белмичә калгандыр. Шул уңайдан Илгиз бер кызыклы хәл сөйләгән иде. Ул Уфага кайткач (әле без өйләнешкәнче булган хәл), язучы Михаил Чванов белән ресторанга барганнар.

– Утырабыз, утырабыз, безнең янга килүче юк. Ә менә бездән ерак түгел бер өстәл янында официантлар мәш килеп кайнаша! Әле моны китерәләр, әле тегене куялар өстәлгә, йөгерәләр генә! Ниһаять, безгә дә чират җитте. Безнең янга килгән официанттан: «Кем ул анда, кемне шулай кунак итәләр?» – дип сорадык. Официант безгә пышылдап кына: «Мостай Кәрим малае килгән, шуны кунак итәбез, йөгертә генә безне». Без Миша белән кычкырып көлдек, – диде Илгиз.

– Ул түгел, мин ул Мостай Кәрим малае дип тә әйтмәдеңмени? – дидем мин.

– Юк, әйтмәдем. Безгә бик кызык тоелды официантларның йөгерешүе. Читтән карап тордык «Мостай Кәрим малаена», рәхәтләнсен, әйдә, дидек.

Монда бары тик лейтенант Шмидт балалары әтиләрен генә алыштырган, алар һәр чорда да бар, популярлык шулай итә дип кенә уйлыйсы кала.

Аның үзенең «әтисе малае» дигән популярлыктан файдаланганы булмаса да, аны куллanучылар күп булды.

...Бервакыт, 1987 еллар тирәсе булгандыр дип уйлыйм, мин улыбыз Ниязны Татарстанга авылга – әниләргә илтеп куйдым. Шунысын да әйтим: балалар, бигрәк тә Нияз, үсмер вакытларын җәйге каникулларда минем туган авылда үткәрде, шуңа күрә авыл тормышын да әйбәт белә, телне дә ару гына сукалый. Берничә көннән баланы авылда калдырып, Мәскәүгә кайттым. Кайтуга Илгиз:

– Минем җәйге туфлиләр бармы ул? – ди.

– Соң, авылга китәр алдыннан гына сиңа «Дом обуви»да эшләүче күршебез Хәсәнә ападан, өстәп түли-түли, Чехословакиядә эшләнгән менә дигән җәйге туфлиләр алып кайтып биргән идем. Кая соң алар? – дидем.

– Беләсеңме, син югында безгә Уфадан яхшы гына таныш бер язучы килгән иде. Аяк киемем бик кыса, берәр нәрсәң юкмы кияргә дигәч, бик җәлләдем дә биреп җибәрдем, – ди бу.

– Шәп иткәнсең, – дидем. – Хәзер менә сиңа каян алабыз инде? Табып булмы соң аны? Юк бит алар кибеттә.

– Ул үзенекен калдырып китте китүен, – дип, Илгиз, аяк киемнәре шкафыннан гәҗиткә бик пөхтәләп төргән нәрсә чыгарды. Мин бу «байлык»ны ачып карадым да:

– Бар, урамга чыгарып, чүп контейнерына ат бу нәрсәне! Бу башмаклар аңа иң кимендә 6-7 ел кыскандыр инде. Сиңа ярый торган нәрсәләр түгел, – дидем.

Шулай итеп, Мостай Кәрим малаенда тулып тора дип уйлаганнардыр инде. Нишлисең, Илгиз менә шундый иде, исемне акларга кирәк бит. Авыл күчтәнәчләрен күтәреп кереп киттем күршем Хәсәнә апага. Тагы берәр кием сандали булса да калмадымы икән!

## 1991 елның кыскача хәбәрләре

Әткәйнең көндәлекләренә күз салдым. 1991 елның 28 июлендә язган кыскача гына язма. Бу язмалардан өзекләр бирми кала алмыйм. Чөнки үзе төзегән, ул ил өчен көрәшкән, ул илнең һәрвакыт булачагына инанган карт коммунистның, язучының күз алдында аның партиясе, өмете, иле, хәтта дуслары юкка чыгып бара... Аңа нинди йөрәк чыдасын? Ул нәрсә уйларга, нәрсә эшләргә, кай тарафны тотарга тиеш?

Көндәлекләрдәге бу язмалар сугыш вакытындагы «Совинформ» хәбәрләрен хәтерләтә.

28.07.1991. «Бүгенге көндә Россиядә 45 партия хакимиятне җитәкләргә дәгъва итә. Ә хакимият футбол тубы кебек, бөтенесе өчен берәү генә. Илдә бар нәрсә дә җимерелә, инде болай булгач, борынгылар кебек мәгарәгә кереп, барысын да яңа баштан башларгадыр?! Кызганыч ки, юньле мәгарәсе дә юк бит аның! Рухи мәгарәдә яшәүчеләр пычратып бетергән аларны».

19.08.1991. «Радиодан хәбәр итәләр. Илдә гадәттән тыш хәл диләр... Тыңлыйм, котым оча... Чынлап та, илдәге хәл дәһшәтле! Һәм бу турыда ачыктан-ачык сөйлиләр! Бу бит коточкыч! Нәрсә булыр? Көне буе радио тыңладым. Ләкин юньләп берни дә аңламадым. Радионың да бер генә каналы эшли».

20.08.1991. «Хәлләр тагы да кискенләшә бара. Күп газеталар ябылган. Телевизордан Советлар йортын, баррикадаларны күрсәтәләр. Гаскәрләр тупланган. Кызым Әлфия Мәскәүдә. Аның өчен дә, Мәскәүдә яшәүче башка балаларым өчен дә борчылам» дип яза әткәй.

Ярый әле, ул көннәрдә әткәй үзе Мәскәүдә түгел иде. Үз күзләре белән күрсә, аның хәлен күз алдыма да китерә алмыйм.

## Үлемсезлек

Әткәй әле 1993 елда ук үлем турында әйткәли башлады.

«Мин карт имән кебек дөңгердәп авармын инде бер заман. Тик вакытында

китәргә кирәк. Артык яшәүнең мәгънәсе юк. Менә Сәйфи Кудаш – татар әдәбияты классигы. Ул 94 яшендә вафат булды. Тик аны озатырга Казаннан бер генә язучы да килмәде, оныттылар», – дигән иде ул.

Әткәйнең тууына 100 еллыкны Башкортстанда да, Мәскәүдә дә башка төбәкләрдә дә бәйрәм иттеләр. Мәскәү, Казан, Алма-Ата шәһәрләрендәге урамнарга Мостай Кәрим исеме бирелде. Уфа һава аланы Мостай Кәрим исемен йөртә. Хәтта аның исемендә теплоход та бар! Китапханәләрдә, мәктәпләрдә Мостай Кәримгә багышланган чаралар ел әйләнәсенә дәвам итте. Аның бу олы юбилее белән бәйле булган бик күп чараларны атарга булыр иде. Россиядәге күп кенә театрлар аның пьесаларын куеп, бу датаны билгеләүдә үз өлешләрен кертәләр. Аның әсәрләре нигезендә берничә нәфис фильм да төшерелде.

Хәзер инде мин бу гаиләдә 54 ел. Шуларның 35 елы әткәй дөньяда чакта узды. Быел тормыш иптәшем Илгизнең дә безне калдырып бакыйлыкка күчкәненә 5 ел булды. Илгиз әтисе Мостай Кәримнең барлык прозасын рус теленә тәрҗемә иткән югары дәрәҗәдәге профессиональ тәрҗемәче иде. Заманында әтисенең әсәрләре буенча берничә инсценировка ясады. Алар хәзер дә Башкортстанда театр сәхнәләрендә бара.

Яшәвенең соңгы елларында әткәй инде Мәскәүгә бик килми башлады. Ә менә җитмешенче, сиксәненче еллар Мостай Кәрим иҗатының күтәрелеш еллары булган дип әйтергә нигез бар. СССРның барлык театрларында дип әйтерлек аның әсәрләре куела, сайланма әсәрләре басыла, яңа китаплар чыга. Башкортча гына түгел, русча да, чит телләрдә дә нәшер ителә.

Мәскәүгә килгәч, безгә кермичә китми, бик еш очраша торган идек. Ул кунакханәдә йә булмаса язучыларның махсус йортында яши иде. Вакыты булганда, безгә кунакка килә. Кыш айларында Малеевка, Переделкинода аның әле генә язылган әсәрләрен дә, шигырьләрен дә иң беренче булып тыңлау бәхете безгә тия. Аның яңа шигырьләрен тыңлаганнан соң, нинди фикерләр әйткәнемне хәтерләмим дә. Фикерләрем булгандыр инде, булмаган түгелдер. Бәлки: «Әткәй, чәйне яңартыйммы?» – дип кенә сорый алганмындыр. Ничек кенә булмасын, ул безгә бик якын кеше иде. Тормышыбызның беренче көннәрендә үк әткәйнең: «Нәзифә безнең гаиләгә генә кермәде, күңел түрләребезгә дә кереп утырды», – дигән сүзләрен ишеткәч, бу гаиләдә үземне килен итеп кенә түгел, тулы хокуклы гаилә әгъзасы итеп тоя идем.

## «Нәзифә бифштекс кыздыра»

Әткәй җөмләдәге һәрбер сүзгә сак, кадерләп карый иде. Артык та, ким дә булмасын. Тәрҗемә әзер булганнан соң, алар Илгиз белән һәр сүзне, һәр җөмләне тикшереп чыга иде. Аларны җөмләнең язылышы гына түгел, яңгырашы да кызыксындыра. Кычкырып укып та карыйлар. Яңгыраш ничек? Русчасы ясалма түгелме? Тәрҗемә телнең яңгырашын биреп бетерәме? Тәрҗемәдә миллилек сакланамы? Бер сүз өчен дә озаклап бәхәсләшәләр иде. Бервакыт алар шулай эшләп утыра. Мин төшке аш әзерлим. Без икенче катта тора идек. Мин чүп түгәргә чыгып киттем. Ишекне ачуга, подъездан кемдер керде, ахры, артымнан ишегем шап итеп ябылып та калды. Үзем белән ачкычны алмаган идем. Керергә дип ишек төбенә

килдем дә кыңгырау төймәсенә басам, шакыйм – ачмыйлар! Аптырагач тибә башладым. Ишетмиләр! Бәхәсләшәләр, тәрҗемә тикшерәләр! Ишеккә типкән тавышны ишеткәч, әткәй: «Нәзифә ит тапый, бифштекс кыздырырга ниятли, ахры», – дип әйтә икән. Мин урамга чыгып, тәрәзәгә нәрсәдер атканнан соң гына тегеләрнең игътибарын җәлеп итә алдым. Аннан соң көлештек, әлбәттә! Бигрәк тә бифштекстан! Ул көнне котлет кыздырган идем. Әткәй аш-суымны яратып ашый иде. «Кеше хатыннары колбаса кискәнче, Нәзифәнең пилмәне пешеп чыга!» – ди торган иде.

## Әткәй бүләге

Шулай да бу язмамда әткәйнең үзе язып биргән кульязмасы турында тулырак әйтәсем килә. Каенатай үземә генә автографы белән әллә ни күп китап бүләк итмәде. Артык тыйнаклык күрсәткәнмендер, сорарга ояла идем. Безнең әткәй белән төшкән фотобыз да бер-ике генәдер. Автограф дигәннән, 1977 елда Казанда татарча басылган бердәнбер шигырьләр китабында, минем исемгә язылган шундый матур сүзләр бар иде. Ләкин бер танышыбыз китапны тотып карыйм гына дип алды да кире кайтармады. Әткәйнең татар телендә китаплары юк дип әйтергә була, кызганыч, шул шигырьләр китабыннан соң башкасы чыкканы да юк.

Шушы көннәрдә генә каенсеңлем әнкәйнең туган авылы, Башкортстанның Кушнаренко районындагы Бакай авылында шигърият кичәсендә булып кайтты. Ул миңа болай дип сөйләде:

– Әнкәй авылында халык шундый матур итеп татарча сөйләшә! Шигырь укыйлар, татарча җырлыйлар! Ә безнең хәтта бүләккә татарча китабыбыз да юк икән. Бу турыда уйларга кирәк, сораучылар күп, – дип, мине дә сөендерде.

Кечкенә китаплар сериясендә чыккан «Россиян мин» дигән китапны миңа бүләк итеп, әткәй болай дип язган иде: «Татар россиянкасына, минем киленемә». 1997 елда язылган бер шигырен, кулдан язып, татар телендә түбәндәге сүзләр белән бүләк итте: «Нәзифә өчен үзем күчердем, Әткәң Кәрим 7.02. 1997 ел». Әткәң Кәрим дигән сүзләре Мостай Кәрим дип языла торган кул тамгасы рәвештә куелган иде. Менә ул шигырь:

«Әтәч тавышлары тынды –
Сәгать ничәдә икән?
Без эчәчәк шәрабларны
Кемнәр эчәләр икән?

Җирдә давыл күтәрелде –
Сәгать ничәләр икән?
Без кичәчәк дәрьяларны
Кемнәр кичәләр икән?

Күктә йолдызлар болара –
Сәгать ничәләр икән?
Бу дөньядан икенчегә
Нигә күчәләр икән?»

Бу шигырьне укыганнан соң нигәдер бу шигырьгә җавап язасым килде. Юл саен сорау билгесе куелган шигырь, әлбәттә, җавап көтә сыман тоелды.

Әткәй шигыренә җавап яздым мин:

«Сәгать нәрсә, таң аткандыр –
Әтәчләр тынды инде.
Таң аттырып шәраб эчкән
Кичәләр калды инде.

Дәрьялар күптән кичелгән,
Давыллар тынганы юк.
Безнең өлеш – безгә төште,
Сәгатен белгәнем юк.

Бу дөньядан икенчегә
Күчәләр бүген, элек –
Анда сәгать сорамыйлар
Вакыт анда мәңгелек».

Ләкин үзем язган бу шигырьне әткәйгә күрсәтергә оялдым, күрсәтмәдем. Хәзер инде бу вакыйгаларга 27 ел вакыт узган. Алар истәлек булып калганнар. Әткәй үзе кул куйган кәгазь бите тә сакланган. Бераз саргайган, буяулары уңса да, укып була.

«Таң аттырып шәраб эчкән
Кичәләр калды инде...»

дигән юллар әткәй белән икәү бергә утырган кичәне искә төшерде. Бәлки ул шул турыда язгандыр?! Юкка гына миңа махсус җибәрер идемени? Бу фикер миңа әле генә – шушы кулъязманы искә алганда гына килде.

Язучыларның иҗат йортыннан кайткач – алар барысы да Мәскәү тирәсендә бит – әткәй гел безгә килә торган иде. Һәрвакыт! Проза язамы, пьесамы, алар янында һәрвакыт бер бәйләм шигырь була торган иде. Миңа ул шигырьләр бәйләме нигәдер үземнең әти урманнан бер арба печән алып кайтканда, бер бәйләм җиләкләр дә җыеп кайтуын исемә төшерә. Тәмле, сусыл, тәмам өлгереп җиткән урман җиләкләре. Әткәйнең дә шигырьләре шундый иде.... Алар күп түгел, энҗе бөртекләредәй санаулы гына, тик барысы да истә калырлык гали иҗат җимешләре иде.

Бервакытны шулай иҗат йортыннан кайткан әткәй соңлап кына шалтыратты. Иртәгә Уфага кайтып китәсе, күрешеп китим дип, сезгә кереп чыгарга уйладым әле ди. Ул һәрвакыттагыча «Москва» кунакханәсендә тукталган иде. Әткәй киләсе булса, табын тулып торырга тиешлеген инде беләсез, укучым.

Аның сәбәбе бар (әткәй дәресләренең тагы берсе). Әле генә өйләнешкән вакыт, әткәй безгә беренче тапкыр кунакка килде. Мин, Уфадан күреп кайтып, бишбармак пешергән идем. Өстәлдә тагыниләр булгандыр, әмма шунысы хәтердә: ризык әллә ни күп түгел иде. Әткәй табында ризыкның азлыгына, төрле-төрле булмавына ризасызлык белдергән. Үземә әйтмәде, Илгизгә әйткән. «Мин килгәндә, табыныгыз мул булсын!» – дигән. Шуннан бирле, әткәй киләсе булса, табын тулып тора иде. Соңгы елларда хәтта аның: «Сез безгә караганда да әйбәтрәк тукланасыз», – дигәнен ишеткәнем булды. «Әткәй, көн дә шулай булмый ул, сез килгәнгә генә!» – дигәч, күңеле булды. Ул үзе дә беркайчан да буш кул белән килмәде.

Шулай итеп, тагы әллә кайларга кереп киттем. Әйе, әткәй киләм дип шалтыратты. Мин, әлбәттә кунак көтмәгән идем. Ләкин запаста нәрсәдер булгандыр инде. Шунысы бик нык истә калган: суыткычта ясап куйган

пилмәннәрем бар, ниндидер бәйрәмнән калган башланмаган виски тора. Кызганыч, Илгиз өйдә юк, аның иҗат йортында чагы. Әткәй килүгә кухняга түгел, олы якка табын әзерләдем. Ул шулай ярата иде. Без аны беркайчан да кухня ягына утыртмадык. Ул киләсе булса, өстәл залга әзерләнә. Бу юлы да табын матур булды. Әткәй күчтәнәчләре дә куелды. Шулай итеп, ашап-эчеп дигәндәй, шигырьләр укып, әткәй белән соңгы хәбәрләрне сөйләшеп, байтак кына утырдык. Якташлардан иҗат йортында кемнәр булган, кемнәр белән аралашкан – әткәй аларын да сөйли иде. Таныш язучылардан кемнәр бар иде? Казаннан язучылар бар идеме? Аларын мин сорыйм. Менә бу югарыда әйтелгән «Таң әтәчләре кычкыра...» шигыре нәкъ шул без утырган кичә турында кебек тоелды миңа. Чөнки әткәй бу шигырьне юкка гына минем өчен махсус татарча язып, автограф белән җибәрмәгән бит! Әткәй белән рәхәтләнеп сөйләшеп, вакыт үткәнен сизмичә дә утырган, гомергә истәлеккә калган кичә булды ул... Әткәйне кунакханәгә озатырга кирәк бит инде. Вакыт соң. Такси чакырырга дип шалтыратам. Мәшгуль дә мәшгуль – телефонны алмыйлар. Заманы шундый иде шул. Кич белән такси кирәк булса, иртән шалтыратып куярга кирәк. Мин әйтәм: «Әткәй, әйдә, автобус тукталышына чыгабыз, анда машина тотып була. Бүген такси булмас, ахры», – дидем. Без аның белән тукталышка чыгып киттек. Вакыт соң, шигырьдәге кебек «таң атмаса да», төн урталары булгандыр. Бу февраль ае иде булса кирәк. Утыртып җибәрмичә күңел тынычланамыни?! Урамда кар эри, аяк астында су, пычрак. Мәскәүдә ел да шулай. Тукталышка кадәр дә байтак кына барасы бар. Юл өсте тайгак, бозлавык. Киттек бер-беребезгә тотынышып. Юлга чыгып, озак та тормадык, Ходай рәхмәте, бер машина килеп туктады! Әткәйне утыртырга дисәм, ул: «Юк, син утыр әле башта, бу пычракта, вакыт та соң, мин сине ялгыз җибәрмим, өйгә кадәр илтеп куям», – ди. Шулай итеп, ул мине өйгә чаклы машина белән озатты. Кайтып җиткәч, мин исән-имин кайтып җиттем дип шалтыратты да. Менә минем каенатай шундый джентльмен иде!

### Укырга кердем!

Без Илгиз белән өйләнешкәндә, минем югары белемем юк иде. Университетта белем алу кирәклеге минем генә түгел, Илгизнең дә хыялы иде. Ул башта ук: «Югары белем һичшиксез кирәк!» – дип әйтә килде. Кызыбызга бер яшь тулганда, мин университетка керергә әзерләнә башладым. Казан университетына керергә теләсәм дә, Уфага, Башкорт дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә керергә уйлаштык. Чөнки кызыбызга бер генә яшь иде бит! Бер яшьлек баланы авылга илтеп, минем әнигә калдырырга кызгандык. Әнине дә, баланы да. Янымда булсын дидек. Бала белән Уфага укырга керергә киттем. Әлбәттә, бала карау каенанай өлешенә төште. Мин аңа бик рәхмәтле. Елга ике тапкыр берәр айга кайта идем бала белән. Шунда әнкәйдән аш-су осталыгына да өйрәндем. Бик авыр вакытлар иде ул минем өчен. Алар өчен дә җиңел булмагандыр дип уйлыйм. Иртәнге якта имтиханнар, өйләдән соң көненә 8әр сәгать дәресләр. Бала бәләкәй. Каенанай чыдады инде. Өченче курста кызымны ике баласы булган сеңлемә кайтардым. Кешеләр бер яшьлек бала белән академик ял ала, ә мин укырга кердем! Шушы еллар эчендә

мин Илгизнең гаиләсенә, алар миңа иянәнде. Уфада укымасам, килен булуның ни икәнен белмичә калыр идем. Бергә көн итү миңа алар хакында байтак кына истәлекләр дә калдырган. Каенанай Илгизне бик ярата иде. Ул яратуның күпмедер өлеше миңа да тигәндер. Улың кемне яратса, киленең шул булыр. Каенанам моны яхшы аңлый иде.

Шунысын онытасым юк: каенанай ел саен май аенда минем туган көнгә каклаган каз җибәрә торган иде. «Менә бу казлар минем туган авылымда, Сәрмәсән елгасы суларын эчеп үскән казлар, сез дә авыз итегез әле!» дип яза иде ул хатында. Ул казны ничек турарга да әнкәй өйрәтте! Менә ул сәнгать! Ә инде Илгизнең туган көненә гыйнвар аенда ат ите, казылык килә торган иде. Әнкәй ул күчтәнәчләр янына озын итеп хат яза. Ничек пешерергә, ничек ашарга икәнлеген өйрәтә. Бер хатның ахырында «Хат кына булмады инде бу, инструкция булып чыкты!» дигән сүзләрен хәзер дә елмаеп искә алам. Хатлар һәрвакыттагыча татарча языла иде. Каенанамның архивымда сакланган бер хатын үзгәртми-нитми шушы урынга куям әле:

«Кадерле балакайлар! Сезне сагынып, сәлам җибәреп калам. Айгөлгә аерым сәлам, үзе кебек зурны.

Нәзифә! Илгизнең туган көненә әзрәк күчтәнәч җибәрәм. Гөмбә, билдәмә (казы), печенье (анысын әнкәй үзе пешерә иде. Искиткеч тәмле иде ул. – *Н.К.*) кыздырылган гөмбәне тик җылытырга гына кирәк, ул пешеп җиткән. Суганын аерым кыздырып өстә. (Консервировать итәр өчен суган салмыйлар.) Зур банкадагысы мариновать ителгән. Эчәге пироглары пешер. Эчәге бик свежий, тәмле булыр. Тик башта талдырырга кирәк. Сез талдырырга дисезме, парларга дисезме? Одним словом, бер 10 минут кайнатып алырга кирәк. Мин элекке елны җибәргәне кайнатып алынган иде. Илгизне туган көне белән алдан ук котлап куям. Сәламәтлек, бәхет телим икегезгә дә, өчегезгә дә. Илгизгә бүләк итеп, язлы-көзле киярга пальто заказать итәрбез диде эткәгез. Әлфия бүләкне үзе Мәскәүгә килгәч алып бирер. Барырга җыена. Шулай итеп, Илгизнең бүләк җыясы бар әле. Ярый, әлегә хушыгыз!

Айгөлне минем өчен үбегез. Әнкәгез. 2 январь 1972 ел».

Әнкәйнең тагы кечкенә бер хаты, ул аны күчтәнәч янына куйган. Ул күчтәнәч казылык булырга тиеш:

«Нәзифә! Бу – Ташкенттан килгән күчтәнәч. Пешереп ашарга кирәк. Ике сәгать кайнатырсың. Эткәңә дә авыз иттерер өчен ул сезгә барасы көнне пешерергә тырыш, яме? Өчегезне дә үбеп, әнкәгез».

Менә шулай, инструкцияме, түгелме – безне кайгырту. Рәхмәт, Әнкәй!

## Мәхәббәт формуласы

Шушы урында әнкәй турында сүз чыккач, аларның эткәй белән ничек танышуларын да язасым килде. Эткәйнең шигыре белән башлыйм әле:

«Күпме еллар инде йөртәмен  
Сине йөрәгемдә,  
Йөрәгемне каты чәнчү алды  
Капыл үткән төндә.  
Әллә авыр кайгың бармы синең?  
Әллә бармы шигең?  
Мин курыктым югалтам дип сине,  
Йөрәк куйса шиңеп».

Мостай Кәрим «Раузага» дип аталган бу шигырен 1956 елда язган. Күрәсең, аның күңелендә Раузасын югалту куркынычы үзен гел хәтерләтеп торган.

Хатыны Раузага багышланган шигырьләре күп түгел сыман. Ләкин ул ике кешене, ул гаиләне якыннан белүче гаилә әгъзасы буларак, аның барлык иҗаты Раузасы белән бәйләнгән дип әйтә алам. Сүземне раслап, аларның тормышындагы бик авыр бер вакыйганы искә аласым килә...

1964 елның матур җәе... Минем булачак каенанам белән каенатам Кавказ тауларына андагы танылган язучы, шагыйрь Алим Кешоковның 50 яшьлек юбилеенда кунак булалар. Ул бәйрәмнән соң Эльбруска баралар һәм аннан кайткан вакытта юл казасына очрыйлар. Ниндидер бер могҗиза белән генә тарлавыкка очмый калалар. Шофёр машинаны кискен борып, наратка бәрелә һәм машинаның алгы тәрәзәсеннән очып чыккан Рауза йөзе белән ташларга барып төшә. Каенатай җиңелчә генә яраланса, Раузасының башында ачык яра, тез сөякләре чәрдәкләнгән һәм ул аңсыз була... Тырнауз хастаханәсендә аңа операцияне Хәсәнби Каранашев исемле яшь хирург ясый. Операция уңышлы үтә. Мостайның Раузасы аякка баса. Таулар иле белән хушлашканда, Мостай Кәрим хирургка: «Сез минем хатынымны гына түгел, сез минем иҗатымны коткардыгыз!» – дип әйтә. Әгәр дә ул каза фаҗига белән беткән булса? Бу турыда уйлавы да куркыныч. Бу бит әле 1964 ел гына. Алда иҗат белән тулы 40 елдан артык гомер бар. Күпме әсәр язылган ул вакыйгадан соң? Димәк, Мостай Кәрим иҗатының һәр әсәре, шигырьләренең һәр юлы, тормышының бар уңышы мәхәббәтенең исән, янында булуына мәдхия, мәхәббәтнең гомерлек җимешләре дисәк, һич тә ялгыш булмас.

Мостай Кәрим бер истәлегендә: «Миннән еш кына «Нәрсә ул бәхет?» «Нәрсә ул мәхәббәт?» дип сорыйлар, – дип яза. – Мин бу сорауны артык гади, бик акыллы булмаган сорау дип атар идем. Чөнки бәхет белән мәхәббәт ул бармак эзләре кебек. Һәр кешедә үзенеке, кабатланмый. Кемгәдер бәхет өчен тулы кояш кирәк, ә кемдер бәләкәй генә нур чаткысы белән дә бәхетле».

Мин 22 яшемнән бирле бу гаиләдә, шуларның утыз биш елы әткәй белән әнкәй дип йөрткән кешеләрнең яктылыгында, аларның барлыгын тоеп яшәү рәхәтлегендә узды. Якыннарыбыз безнең арадан киткәч, их, менә моны сорыйсы калган икән дип үкенгән чакларыбыз күп була. Әле алар бакыйлыкка күчкәч тә, аларның юклыгына ышанмаган күңел киңәшәсе килгәндә дә, ниндидер шатлыклы хәбәр белән бүлешәсе килгәндә дә, аларга омтыла. Ләкин алар юк. Их дип үкенеп куясың. Минем язмамның геройлары – илле елдан артыкербөтен булып, бер-берсен аңлап, хөрмәт белән, чын ярату, мәхәббәт белән яшәгән кешеләр. Аларның очрашу, беренче күрешүләре турында язылган истәлекләр бар. Ул турыда әткәй бик тәфсилләп сөйләгән иде. Ә менә әнкәйнең аларның танышу тарихы турында сөйләвен бик хәтерләмим.

Кайбер әңгәмәләрдә сез инде ничә ел бергә яшисез, туйларыгыз ничек үтте дигән сорауларны укыганым бар. Ул сорауга каршы әткәй болай дигән иде: «Безнең бергә яшәүнең төгәл генә әйтерлек датасы да юк. Туйлар да булмады безнең. Ә менә танышу – анысы гаҗәеп бер тарих!»

Әткәй танышулары турында сөйләргә ярата иде. Һәрвакыт ниндидер яңа төсмерләр, яңа детальләр өстәлә. Язмыш дигән нәрсәнең барлыгын исбатлаган тарих аларның танышуы. Каенатам язмышка ышана торган кеше иде. Әле абыйсы Мортазаны өйләндергән вакытта ун яшьлек Мостафага Олы әнисе: «Сиңа да маңгаеңа язылганы насыйп булыр, тик кәләшең ерактан булыр, ахры, каш араларың бик киң. Берсе мәгърипкә, икенчесе мәшриккә караган», – дип әйткән була. Менә шушы «маңгаена язылган» дигән нәрсә аның күңеленә кереп утыра. Кем белә, бәлки аларны балачакта ишетеп, күңелгә уелган бу сүзләр, үз язмышына ишарәләгән билгеләрне таный белүе кавыштыргандыр да?

«...1938 елның май ахыры иде, – дип сөйли башлаган иде каенатай. – Шул көннәрдә әле басылып та чыкмаган поэмам өчен акча да түләделәр, базарда шуңа өр-яңа чалбар, аз гына киелгән туфлиләр сатып алдым. Өс-баш бөтен булгач, дәрт тә тик ятмый икән. Әнә шул иләс-миләс чакта сабакташ дустым Вафин Закир әйтеп салмасынмы: «Ничава гына егет күренәсең бит әле син хәзер. Шәрип авылында менә синең өчен генә туган бер кыз бар. Укытучы. Киттекме шуны күзләргә?» – диде. Исемен дә әйтте. Башта югалып калдым. Кыз-кыркын янында йөргәнем юк иде. Шулай да: «Киттек!» – дидем. Төш ауганда, без инде Шәриптә идек. Дустымның хатыны да безнең кайтуны чамалап торган, ахры, табын әзерләгән. Ләкин минем тамактан аш үтми, теге кыз белән танышасым килә. Алар – өч кыз, каршыдагы өйдә торалар икән. Өчесе дә – яшьләр: икесе – укытучы, берсе – фельдшер. Минем ике күзем тәрәзәдә...»

Ләкин алар бу юлы очраша алмый. Чөнки «аның өчен генә туган кыз», каникуллар башлану сәбәпле, Уфага апасына кунакка киткән.

Дустының хатыны башка бер кызны димли башлый. Монысы тегесеннән дә матуррак, син бит әле берсе белән дә таныш түгел, нинди аерма бар дип үгетләргә тотына. Ләкин «үзе өчен туган кыз» артыннан кайткан Мостай болай дип уйлый: «Булмагае тагы. Миңа калса, пар канатлы фәрештә булсын! Минем өчен генә тумагач... Болар бит ирле-хатынлы алдатып, мине отарга уйлыйлар, нык торырга кирәк. Үземнекен күрмәс әүвәл, ятка күз салу хыянәт түгелмени?» Кызның моны көтмичә китеп барганына әзрәк үпкә сыман бер хис тә барлыкка килә аның күңелендә.

Киткәндә, каенатай кызның Уфадагы адресын сорап ала. Ләкин ярый барырмын, табармын, ләкин үземнең шушы әрсезлегемне нәрсә дип аңлатырмын дип уйлый да адресны укып та тормый, кәгазьне ерткалап, җилгә очыра. Һәм бу хакта: «Менә шулай, бу язда мәхәббәт миннән эзен яздырды», – диде әткәй.

...1939 ел. Каенатайның беренче китабы дөнья күрә, эшкә урнаша, акча килә башлый. Студентның иң зур – тулай торактан фатирга күчү хыялы да тормышка аша. Алар «Отряд кузгалды» дип аталган беренче китапларын чыгарган Вәли Нәфыйков белән икәү бергә фатирга күченәләр. Ул фатир, Социалистическая белән Достоевский урамнары киселешендәге почмакта, 47 санлы ике катлы агач йортның икенче катында яшәүче Һәдия апа фатирындагы бер бүлмә була. Ул фатирга урамнан текә генә агач баскыч менә, ишек төбендә бавыннан тарткач чылтырый торган кыңгыравы да

була. Ә инде кем килгәнне беләсе килгән кеше өстәге тәрәзәдән карый да, аска төшеп тормый гына келәгә бәйләнгән бауны тартып, ишекне ача.

Беренче тапкыр килгәндә, аларга Һәдия апа, ишекне ачып, яши торган бүлмәләрен күрсәтә. Бүлмәдә зур өстәл, икесенә ике карават куелган була. Менә шунда йөри башлый инде барлык язучылар. Каенатай ул хакта: «Дусларым белән кайткач, Һәдия апа юкны бар итеп, барны күп итеп, табын әзерли торган иде», – дип искә ала. Минем бу урында Һәдия апа хакында да бер-ике сүз әйтәсем килә. Чөнки Һәдия апа белән мин дә таныш идем. Ул бик гадел, бераз кырыс, аш-суга оста апа иде. Гаиләдә аны Туган абыстай дип йөртәләр. Каенатайның фатирда тора башлаган вакытларын искә алып, миңа болай дип сөйләгәне булды: «Мостай көн дә бер язучыны ияртеп кайта иде. Барысы да ач-ялангач. Ул Рәшит Нигъмәтинең киеп йөри торган шинель итәкләре чәчәкләнеп, чукланып беткән булыр иде. Җитмәсә, үзендә туберкулёз. Мостай янына килеп, тамакларын туйдырып китәләр иде».

Менә мин темамның иң мөһим урынына да килеп җиттем шикелле. Ул хакта каенатай бик тәфсилле итеп искә ала: «Утыз беренче декабрь иде ул. Мин эштән чыктым, институтка бармадым. Ябалак-ябалак кар ява. Шуңа сокланып, хозурланып, өйгә кайтып киттем. Капкадан кергәч тә, көзен яфракларын коймый калдырган чия агачы тирәсендә талпышынып уйнаган кар бөртекләреннән аерыла алмый тордым. Башны күтәрми генә кыңгырауның бавын тарттым. Өстә ишек ачылып ябылды, ләкин келә күтәрелмәде.

– Сезгә кем кирәк иде? – диде миңа ят бер яңгыравык тавыш. Менә шушы тавыш кинәт кенә урады да алды. Мин дерт итеп, башымны югары күтәрдем. Тәрәзәдән каракучкыл йөз балкыды. Балкыды да сүрелде. Ярымкаушап, ярымшаярып:

– Сез кирәк, төшегез монда! – дип әйтеп салдым.

Келә һаман ачылмый.

– Сызгыра белсәгез, сызгырыгыз! Сызгырсагыз – төшәм! – диде дә кызыкай, матур борынын җыерып, елмаеп куйды.

Мин – гомергә сызгырырга өйрәнә алмаган кеше.

– Сызгыруын сызгырмам, тик гәүдәгезне күрсәм, менә шулай суырып алырмын! – дип, иреннәремне бөрештереп, һаваны суларга керештем.

Келә келт итте, мин баскычтан югарыга үрмәләдем. Ләкин нигәдер озак мендем. Йөрәгем ашкына иде бит, нигә шулай әкрен кыймылдадым икән?.. Әле һаман да аңламыйм...»

Фатир берничә бүлмәле. Ишек ачкан кыз башка бүлмәгә кереп киткән. Ә зур бүлмәдә каенатайның әтисе Сафа бабай белән бертуган энесе Ильяс авылга кайтып китәргә әзерләнәләр икән. Алар авылдан азык-төлек алып килгән булганнар.

Капчык авызын бәйләргә дип, Сафа бабай теге ишек ачкан кызны чакырып чыгара, кызның бик оста итеп сүс бау белән капчык авызын бәйләгәнен карап тора да:

– Афәрин, сылу кызыкай! Кулың эшкә килешеп тора икән! Миңа синең капчык авызын бәйләвең хаҗәт түгел, эшкә ничек тотынганыңны күрәсем килгән иде, – ди.

Авылныкылар авылга китә. Һәдия апа эштән кайтмаган әле. Өйдә икәү

генә калалар. Каенатай бу тылсымлы минутлар турында болай дип сөйли иде:

– Танышыйк әле. Минем исемем Рауза! – ди кыз, кулын сузып.

Мин аның кечкенә кулын учыма алдым.

– Рауза? Шәриптәнме?

– Ничек инде Шәриптәнме? – дип, ул кулын тартып алды.

– Сез Шәриптән! Сез ишек ачканда ук күңелем белән таныдым.

– Әйе, былтыр мин анда укыттым. Һәдия апа сөйләдеме?

– Ул сөйләмәде... үзем... Узган ел дустым Закир Вафин мине Шәрипкә сезнең белән таныштырырга алып кайткан иде. Сез Уфага китеп баргансыз. Мин ифрат боектым. Күрмәсәм дә, гашыйк булып киттем. Дөрес эшләгәнмен икән.

Хәзер инде шунысын да әйтергә була: Шәрип авылында очраша алмаган, Уфага апасына кунакка киткән кыз да, Мостай белән дусты торган фатир хуҗасы Һәдия ападагы кыз да Рауза булып чыга. Һәдия апа белән Раузаның әтисе Суфиян абый бертуган булалар. Менә язмыш шулай очраштыра аларны.

Шушы очрашудан соң, сугыш елларын санамаганда, алар гомер буе бергә. «Бу очрашуга без гаҗәпләнмәдек тә кебек, – дип сөйләгән иде каенатай. – Шәриптә аймыл булуыбызга торып-торып исебез китте. Инде байтак еллар узгач, әгәр дә без Уфада гына очрашкан булсак, Шәрип тарихы булмаса, бәлки безнең очрашулар исәнме-саумыдан ары китмәс иде дип уйлыйм. Чөнки ул вакытта Раузаның да күзе төшеп йөргән егете булган. Ә менә минем, Шәриптә миңа насыйбы булмагач, башкасы кирәк түгел дип, танышудан баш тартуым Раузага да тирән тәэсир иткәндер. Нәкъ илле ике ел без бергә, бу могҗиза түгелмени?»

Әнкәй бакыйлыкка күчкәч, әткәй тагы өч елга якын яшәде. Гаиләдә әнкәй һәрвакыт беренче урында тора иде. «Менә әнкәгез нәрсә әйтер? Менә әнкәгез генә килсен әле!» дип, безне «куркыта» да торган иде әле. Каләмнән төшкән әсәрләре иң башта Рауза кулында. Раузасы – беренче укучысы, беренче редакторы, беренче тәнкыйтьчесе дә! Ләкин әткәй сүзе кирәк вакытларда алда ул була торган иде. Алар – бер-берсенә хөрмәт, мәхәббәт, ышаныч белән яшәгән гаилә. Әнкәй беркайчан да гайбәт тыңламаган. Ирең тегеләй, ирең болай дип, гайбәт алып килүчеләрне, үзеңне бел дип, кире бора торган булган.

Аларның тормышы башланган ике катлы бу агач йорт турында болай гына язмадым. Анда язмышка ишарә ясаган байтак кына мизгелләр бар. Чөнки Уфадагы ул урам хәзер Мостай Кәрим исемен йөртә, хәзерге көндә ул урында күп катлы йорт торуга карамастан, йорт саны да 47 булып калган. Аннан ерак түгел әткәйгә – Мостай Кәримгә куелган бик мәһабәт һәйкәл бизи ул урамны. Шулай итеп, ул, мәхәббәт тулы тормышын кайда башласа, бүген дә шул урамда халкының да мәхәббәтен казанып басып тора.

### Татармы, башкортмы?

Без әткәй белән һәрвакытта да татарча сөйләштек. Еш бирелә торган «Мостай Кәрим татармы, әллә башкортмы?» дигән сорауга ул: «Минем ана телем – татар теле, рухи телем – башкорт теле. Шуңа күрәдер минем

өчен бу ике телнең икесе дә кадерле!» – дия иде. Ләкин күпләр аның бу аңлатуы белән генә канәгатьләнмичә, башкортка сатылган татар дип, күңелгә тия торган ярлыклар да тага. Ул әле һаман да бара. «Президиум шагыйре», «милләтен алыштырган» – гаиләсенә дә тагы әллә нинди усал сүзләр ишетергә туры килә. Бу гаиләдә килен генә булсам да, ул сүзләр минем йөрәгемә дә кадала. Әткәйнең әйткәне бар: «Шагыйрь тик үз илендә генә шагыйрь була ала. Ана телем – татар теле. Шуңа карап, мине сугыштан соң Казанга чакыручылар да булды. Әмма мин Казанга барып, татар шагыйре булуымны күз алдына да китерә алмадым, татар әдәбиятын, татар шагыйрьләрен бик яратсам да. Аяк астында туган туфрагың булмагач, ничек илһамланырга мөмкин? Барысыннан да болай, безнең киләшләр татарча сөйләшсәләр дә, башкортча уйлыйлар. Дөресрәге, башкортча уйлап, татарча сөйләшәләр. Чөнки тамырларыбыз, уй-фикерләребез башкорттан килә. Мин, мәсәлән, ике каннан – башкорт һәм татар канынннан яралганмын. Башкортча уйлап, башкортча язам. Килеп чыга диләр шигъриятне белгән кешеләр».

Шулай бервакыт Илгиз кәгазьләре арасыннан кош теледәй бер язма килеп чыкты. Әткәй кулы белән ни өчендер рус телендә язылган. Бәлки ул бу урында русча уйлагандыр. Бу шигырь – минем өчен табыш. Беренче тапкыр басыла.

«Я – поэт.
Поэт как ребенок, Он всегда ждёт.
Прошлое любит как память.
Настоящее как плоть.
Вот, всегда буду ждать...»

## Көндәлекләрдән

2.01.91. Өмет турында. «Бурый-бурый кар ява. Өмет турында уйланып утырам. Фәкыйрьләр, чирлеләр, хәсрәтлеләр өчен яхшылыкның килеренә өмет зуррак. Чөнки аларның өметтән башка таянычы юк. Менә хәзер безнең Ватаныбыз чирле, хәсрәтле, фәкыйрь. Аңа өмет бигрәк тә кирәк. Без – аның балалары ил өметен өзмик».

Бу сүзләрдән соң 23 ел вакыт узган... Үзгәрешләр бармы соң дип сорыйсы килә, тик сорар кеше юк. Җавап бирүче дә юк...

## Гаилә мәзәкләре

Каенатай сөйләгән иде.

Бервакыт Башкортстанның бер төркем язучылары Ырынбур якларына укучылар белән очрашуга барганнар. Чыгышлардан соң барысын да бер башкорт гаиләсенә кунакка дәшкәннәр. Ашлары бик тәмле булган. Берзаман өстәлгә тутырган тавык та чыгарганнар (Әткәй ул ризыкны яхшы белә, бәйрәмнәрдә әнкәй аны һәрвакыт пешерә иде. Үзем дә тавык тутырырга аннан өйрәндем. – *Н.К.*). Шунда әткәй:

– Бу бит татар халык ашы, башкортныкы түгел, кем пешерде моны? – дип сораган.

Хуҗабикә:

– Әй, киленебез татар безнең! Шундаен да оста инде, шундаен да әйбәт

инде, татар дип тә әйтмәссең! – дигән. Моны сөйләп, әткәй безне бик көлдергән иде.

Беренче тапкыр шушы көлкеле хәлне сөйләгәннән соң, әткәй миңа карады да: «Ә безнең килен татар булганы өчен яхшы!» – диде.

Милләт турында әйтү, бүлешү – андый нәрсәләр гаиләдә юк иде. Ә бу хәл инде – чын анекдот.

## Тагын бер мәзәк

Тагын бер булган хәл турында сөйлисем килә. Безнең гаиләдә, дуслар арасында ул фразеологик әйтемгә әйләнгән, әткәй әйтмешли – көлмәч!

Әткәйнең әле яңа гына беренче машинасын алып, машина йөртергә өйрәнгән чаклары икән. Уфада базар чатыннан борылуга әче итеп милиция сыбызгысы тавышы ишетелгән. Әткәй коелып төшкән. Нинди хата ясадым икән дип, тормозларны чинатып, педальга баскан. Караса, фуражкасын кырын салып, аклы-каралы таягын күн итегенә суга-суга, эленке-салынкы адымнар белән бер милиционер моның янына килеп баскан. Әткәй тәрәзә пыяласын төшереп, нәрсә әйтер микән дип, моңар текәлгән.

– Шамилләр Германиядә! – дигән милиционер. Моны ишетүгә, әткәй газга баскан да выжылдатып кузгалып та киткән.

Кем соң ул Шамилләр? Шамил абый – каенанамның сеңлесе Лилия апаның ире, хәрби кеше иде. Шамилләрнең Германиядә икәнлеген әткәйләр инде белеп оныткан. Шамил абый гаиләсе белән берничә ел Германиядә яшәде. Ә бу милиционер Шамил абыйның абыйсының малае булып чыккан. Әткәйне танып, хәбәр әйтә, имеш.

Мөһим булмаган, тозсыз нәрсәләрне олы хәбәр итеп сөйләүчеләргә карата без «Шамилләр Германиядә!» дип әйтә идек.

## Нәнәй

Әткәйнең 106 яшен тутырып вафат булган әнисе, Илгизнең әбисе – нәнәй Вазыйфа исемле иде. Вазыйфа дигәннән, минем әни белән бертуган Вазыйфа исемле апам бар иде. Илгизнең бертуган сеңлесе Әлфия, минем дә бертуган сеңлем Әлфия исемле. Илгизнең ике туган сеңлесе, ә минем тагы бертуган сеңлем – Алфира исемле. Минем бабайның әтисе Сафа исемле булган, әткәйнең әтисе дә Сафа исемле. Минем бабайның хәләл җефете – безнең әби Миннеямал исемле иде, әткәйнең Олы инәй дип йөртә торган Сафа бабайның беренче хатыны да Миннеямал исемле булган. Шулай итеп, безнең ике гаиләдә бер исемне йөртүчеләр ифрат күп. Моның үз фалы да бар икән. Язмышка бу исемнәренең дә йогынтысы булмый калмагандыр дип уйлап куям мин дә.

Нәнәй бик җор сүзле, шаярта белүне аңлаган карчык иде. 100 яше тулган көннәрдә: «Яшәргә дә ояла башладым инде», – дигән иде үзенә генә хас булган шаярту белән.

Без Илгиз белән өйләнешкән вакытта аңар туксаннан күпкә артык иде инде. Уфада узган туебызда да булды ул безнең. Олы яшьтә булса да, бәләкәй гәүдәле, җитез әби шәһәрдә үзе генә йөри ала иде. Зиһене әйбәт, шуның өстенә зирәк карчык иде. Без өйләнешкән елларны ул әткәйнең энесе Ильяс абыйлар

белән яшәде. Соңга таба аны Салават шәһәрендә яшәүче кызы Салисә апа үзенә алды. Әткәйләрдә дә еш була иде. Без анда чакта җәйләрен нәнәйнең дачада торганын хәтерлим. Инде 100 яшькә җиткән нәнәй күзлексез-нисез кызыбыз Айгөлгә авыл йоныннан бияләй бәйләп биргән иде.

Дачада чакта мунчада аны мин юындыра торган идем. Нәнәйнең чәче әткәйнеке кебек бөдрә. Нәнәй көлеп: «Мине шушы чәчем аркасында бәләкәй чакта ябалак дип үртиләр иде», – дип сөйләгәне бар. Чәчләре ябалак каурыйларына бик охшаган иде аның. Чәчләрен юып, тарап үрә идем, нәнәй шуңа бик күп рәхмәтләр әйтә-әйтә: «Иии, менә кем балаларыннан хөрмәт күрәм бит!» – ди. Юындырып бетергәннән соң ул бик каты итеп эссе салырга куша, аннан соң:

– Бар-бар, кызым, чыгып тор, сиңа читенгә килер, мин чабынам әле, – дип чыгарып җибәрә торган иде. Ләүкә түренә менеп утырып, ике кулына ике каен себеркесе тотып, көйләр чыгарып, озак итеп чабына иде нәнәй. Мунчадан бурлаттай кызарынып чыга. 100гә җиткән карчык дип тә әйтмәссең!

## Әткәй көндәлекләреннән

6.04.69. «Кич. Инәкәем минем кабинетта диванга урын түшәп ятты. Ниндидер дога укый. Мин Ленин томын актарам. Үземә кирәк нәрсәне эзлим. Бер бүлмәдә икәүбез. Инәкәем һәм мин. Менә дөнья нинди ул. Ул миңа комачауламас өчен пышылдап кына укый, ә мин аны уңайсыз хәлдә калдырмас өчен ишетмәмешкә салышам. Минем әнкәем бик әйбәт, мин дә аңа начар ул түгел».

## Нәнәй мәзәкләре

Нәнәй турында, аның белән булган кызыклы очракларны сөйләргә ярата иде Илгиз.

Бервакытны нәнәйләр күрше рус авылындагы бер рус кешесенә сыерларын сатканнар. Теге кеше арбага ат җигеп, сыерны алырга килгән. Тегеләй дә итеп карыйлар икән, болай да итеп карыйлар, сыер чыкмый гына икән ихатадан, иярми яңа хуҗасына. Шуннан нәнәй әйткән:

– Бозавын арбага сал да инде, коровасы артыннан иярер! – дигән.

Теге рус бернәрсә аңламый «чего, чего?» дип сорый икән.

Нәнәй сыер сатышырга иптәшкә чыккан күрше хатынга: «Кара инде бу урыска, үз телен үзе аңламый!» – дип әйткән, ди.

## Тагын бер мәзәк

Без дачада чак. Ул вакытта Нәнәй безнең белән байтак кына торды. Нинди генә йомышы булса да, беркайчан да кешедән ярдәм сорап тормый иде. Хәтта күзенә даруны да үзе сала. Аякларын сузып, идәнгә утыра, күзләренә дару салып, ике күзенә дә мамык куя иде. Беркөнне карыйм, нәнәй дачаның олы бүлмәсендә почмактан почмакка җил-җил атлап йөренә. Берәр нәрсә эзли дисәм инде... Шуннан:

– Нәнәй, нәрсә булды? Берәр нәрсә югалттыңмы әллә? – дип сорадым.

– Юк, балам, врачлар йөрергә куша. Физкультура ясыйм. Буыннар

катмасын дип тырышам. Ишегалдына чыксам, үләнгә абаланып егылырмын тагы. Бәласеннән башаяк! Менә физкультура өйдә генә, – диде ул, елмаеп.

## Тагын нәнәй турында

Үзгәртеп корулар вакытында Югары Шурада барган бәхәсләрне телевизордан күрсәтәләр иде. Нәнәй, русча аңламаса да, телевизор каршына килеп, келәм өстенә аякларын сузып, идәндә утырып карый иде ул тапшыруларны. Микрофон өчен талашыр дәрәҗәгә җиткән депутатларны күзәткән нәнәй бервакытны миңа:

– Кара әле, кызым, кара әле! Әнә теге шакмак кәчтүмлесе өченче тапкыр инде чиратсыз керә, гөнаһ шомлыгы! – диде.

Карасам, микрофон алдында Анатолий Собчак ярсый-ярсый үз платформасын яклап маташа иде.

## Әткәй язмаларыннан

Сәрән авылында бер карчык: «Ике ел буе Верховный Советны карый-карый телевизорым тузып бетте инде», – дигән.

Яман телле кешегә яки бик күп сөйләшкәнгә: «Телеңә тилчә чыккыры» диләр. Безнең депутатларның, гомумән, политикларның телләре нинди икән? Гел тилчә генәдер инде!

**Мостай әйткән:** «Әдәбият – милләтнең рухи дәүләте».

«Йолдызлар – янган йөрәкләрнең кузы, ә күктәге томан – аларның төтене».

## Әбди чалбары

Әткәй үзенең беренче гонорарына яңа чалбар алганын язган идем инде. Менә шул чалбарын киеп, әткәй Келәшкә кайткан. Нәнәй чалбарны бик җентекләп тикшергәннән соң:

– Менә әйбәт булган, улым, җылы тәнеңдә тузсын! – дигән.

– Борчылма, инәй, минем өстә тузмый кая барсын? Яңасын телә. Мин яшь, сау-таза! Була торсын диген.

– Әй улым! Сугыш дигән сүзләр йөри... Була гына күрмәсен инде берүк! Күптәннән сорыйсым килә. Сельсовет рәисе Әбди абыйга яңа постау чалбарны син премиягә биргәнсең диләр. Ничек булды ул?

Ә ул болай була: язу-сызуны начар белгән грамотасыз авыл советы рәисе колхозчыларны бүләкләү исемлеген хатасыз күчереп язарга дип, ул эшләрне яхшы белгән укучы Мостафага кушкан. Кемгә эшләпә, кемгә итек, кемгә чалбар. Исемлеккә үзен кертмәгән. Өе тулы бала-чагасы булган Әбди инде ничәмә ел ямау өстендә ямаулы иске чалбардан йөри икән. Кышларын ыштаны ап-ак булып, бәскә төренә, ди, малайларга чаклы көләләр икән үзеннән. Ә Мостафа аны кызгана торган булган. Һәм бүләкләү исемлегенә «авыл советы рәисе чалбар белән бүләкләнә» дип өстәп куйган. «Сельсовет рәисе дә кеше төсле постау чалбар кисен әле!» – дигән ул. Авылда Мостафаның ул «ялгыш»ын әле күп еллар яхшы сүз белән искә алганнар.

## Исемнең җисеме

Мостай Кәрим Казанда студентлар белән очрашканда, шагыйрь Роберт Миңнуллин, Башкортстанның халык шагыйрен тәкъдим итеп, аның исемендә ниләр ятканын әйтеп бирергә була:

– Мостай дигән исемдә «мост» – «күпер» сүзе ишетелә. Бу чынлап та шулай. Мостай Кәрим – безнең халыклар арасындагы күпер ул. Тагы ул исемдә «тай» дигән сүз дә бар. Димәк, ул тай кебек шигърият киңлекләрендә чаба гына! Әле тагы бу исемдә «оста» дигән сүз дә яңгырый. Яңгырап кына калмый, аның осталыгын да исбат итә.

Әткәй, үзенә генә хас булган хәйләкәр елмаюы белән Робертны тыңлап бетергәч, аның белән очрашырга килгән яшьләргә күз йөртеп, болай ди:

– Минем мулла кушкан исемем Мостафа. Гарәпчәдән ул сайланма, сайланып алынган дип тәрҗемә ителә. Олы инәем миңа бу хакта еш кына исемә төшереп тора иде – иң әйбәте булырга тырыш, синнән башкалар үрнәк алсыннар дия иде. Ә минем олы абыем Мортаза кебек буласым килә иде. Шигъриятне белә башлагач, Тукайны яраттым, аңар охшарга тырыштым. Ә менә сезгә, яшьләр, киңәшем шул – кемгә булса да охшарга тырышмагыз, үз юлыгызны эзләгез. Хыялланырга курыкмагыз! Хыяллар шигырь генә тудырмый, тормышны да мәгънәле итә.

Әткәй Роберт Миңнуллинны бик хөрмәт итә иде. Аның шаяртып язган икеюллыгын бирегә дә куям әле:

*Роберт Миңнуллинга*

Фамилияңне бозып маташма,
Ул килешә бары Гаташка.

## Әткәй көндәлекләреннән

20.07.91. «Литературная газета»ның 17 июль санында кайбер язучыларның СССР Язучылар берлеге урынына «Азат язучылар берлеге» оештырырга ниятләүләре хакында белдерү чыккан. Кем соң алар элекке берлектә азат булмаучылар? Миңа беркайчан да беркем дә басым ясамады, мин бары тик ярдәм генә тойдым Язучылар берлегеннән. Ә хәзер мине «Азат язучылар берлеге» дигән утарга япмакчы булалар.

«Литературная газета»да дусларым Рәсүл Гамзатов белән Михаил Дудин да СССР Язучылар берлегеннән баш тартканнар. Ә бит алар яшь чакларыннан бирле берлекнең ярдәмен тоеп яшәде. Елына 2-3 китап чыгаралар иде. Әле Дудинның, горурланып, үзен Язучылар берлегенә фронтның алгы сызыгында кабул иттеләр дип әйткәне бар. Шунда ук аңа язучылар билетын да тапшырганнар. Ә хәзер ул СССР Язучылар берлегенә каршы яза? Оят түгелме сиңа, минем иске дустым Михаил Александрович!

...Берни аңлый алмыйм. Нәрсә, алар барысы да акылдан язганнармы?»

## Ил башлыгы Уфада

2001 елның 10 июнендә В.В.Путинның Уфага килүе турында әткәй болай дип сөйләгән иде. «Кичә безгә Путин килде. Бик матур каршыладылар. Күңелне киткән нәрсә дә булды: үзе белән әллә мең тән сакчысы алып

килгән инде! Кая барма, шулар миңа әйтә тордылар: «Сюда нельзя. Вам не положено!»

«Акбүзат» ресторанына кереп барганда тотып туктаттылар. Нәкъ менә шушы ресторанга чакырган кәгаземне күрсәттем. Карамыйлар да. Берсе мыскыллап: «Вашу бумагу оставьте себе на память», – дигән була. Үзем түшемә Герой йолдызы да тагып алган булганмын. Минем илемә килеп, Мәскәү малайлары команда биреп тора. Аңлыйм, уяулык, саклык кирәк. Әмма мин – 82 яшьлек карт, күкрәгемдә Кызыл йолдыз. Шуны күреп торалар, миңа өстән аска карыйлар. Берсен төртеп җибәрдем дә ресторанга кердем дә киттем: «Иди, жалуйся на меня, зовут меня Мустай Карим. Номер паспорта: П АР 714082. Если арестовать надумаешь, принеси ордер на арест», – дидем. Килмәде. Кулга алмады.

Путин, күрәсең, Башкортстан турында шулайрак уйлый: һәр тәрәзәдән снайперлар мылтык төзәп тора. Аның шул тикле тән сакчылары белән килүе минем республикамның горурлыгына тиде.

Хәер, безнең бу заманда һәрбер тән җанга караганда кыйммәтрәк тора. Президентны саклау – шул эшләрнең берсе. Шушындый ук чиктән ашкан тырышлык белән теләсә нинди җинаятьче-мафиозины да саклыйлар. Тәннәрне саклыйлар, җаннарны таптыйлар».

Андый чакта әткәйнең хәтере калуы урынлы дип уйлыйм. Үзен танымасалар да, дәүләт биргән билгеләр күкрәгендә бит. Әткәйнең шушы сүзләреннән соң, аның белән булган бер шундый очраклы хәл искә төште.

Бер тапкыр шулай әткәй белән машинада дачадан кайтып киләбез. Ул: «Юл өсте, минем Киров райкомына кереп чыгасым бар, утырып тор машинада, хәзер чыгам», – диде. Аның «Волга» машинасы иде. Райком бинасы янына туктауга бер яшь кенә милиционер йөгереп килде дә:

– Машинагызны моннан алыгыз, монда куярга ярамый – диде. (Шул ук «вам не положено!») Бу милиционер әткәйне танымады дип уйлап куйдым. Җәй көне иде, әткәй күлмәкчән, ялан баш. Башкортстан кешесенә Мостай Кәримне танымау, минемчә, мөмкин түгел. Юк инде, теге өзми дә, куймый да, алып китегез моннан машинагызны, ди.

– Кемгә куярга ярый соң, миңа да ярамагач! – диде әткәй, аптырагач. Ул башта шаяртып нәрсәдер әйткән иде, күрәм, аның ачуы да килде.

– Монда хөкүмәт кешеләре генә куя ала! – диде милиционер.

– Менә мин хөкүмәт кешесе инде, алайса! – диде дә әткәй үзе белән исәнләшкән берәү белән райкомга кереп китте.

Теге милиционер аптырап карап калды. Бәлки аның беренче эш көне булгандыр. Райкомны артыгы белән сакларга тырышкандыр. Формасы да өр-яңа иде.

### Көндәлекләрдән

30.05.01. Әткәй авыр хәлдә дә җорлыгын югалтмады. Хәтта авырган вакытларында да.

«Больницага яттым. «Нинди чир белән яттың?» – дип сорыйлар. «Чирем юк, картлыкны озайтып маташам», – дим. Үзем чак-чак тын алам. Муса Гали, Ибраһим Абдуллин да монда. Хәлиткеч бросок алдыннан бергә

җыелышып, фронттагы шикелле көч туплап ятабыз. Аэропортта очкычка утыртыр алдыннан пассажирлар җыелган залны «накопитель» диләр. Без хәзер шул «накопитель»дә.

Бүген баскычтан менеп килгәндә, вахтёр хатын сораша:

– Нәрсә, Мостай абзый, хәл бетәмени?

Шуңа ифрат куандым. Бетә торган булса да, димәк, минем әле хәлем бар икән. Булмаса, беткәне күренмәс иде. Мәсәлән, акча булмаса, ул бетми бит».

### Юбилей

1994 елда әткәйнең 75 яшьлек юбилеен уздырдылар. Зур чараларда, юбилейларда барыбыз да һәрвакыттагыча әткәй белән әнкәй, туганнар янына Уфага җыелабыз. Юбилейның үз программасы бар. Опера һәм балет театрында бик зурлап котлыйлар, аннары банкет. Банкет 250 кеше сыя торган зур ресторанда уза. Банкетка туганнарның барысын да чакырырга тырышалар. Ул урыннарны билгеләү өйдә бер тамашага әверелә. Рәсми чара булганга күрә билетларның барысын да гаиләгә бирмиләр. Шуңа күрә аларның саны чамалы, җитми кала. Туганнар, дуслар арасында ризасызлар барлыкка килә. Билетлары булса, урыннары килешми. Урыннары булса, тагы бер-ике кирәк иде диләр. Тигезләргә тырышалар иде. Бик якыннарына әткәй чакыруны үз кулы белән яза. Шул ук вакытта рәсмилек тә саклана. Миңа язган бер чакыруда «Нәзифә ханым» дип укыгач сәерсенгән идем, әлбәттә. Карасам, кызыбыз – аның оныгы Айгөлнең чакыруында да «ханым». Үз кулы белән язса да, рәсмилекне саклаган. Бәйрәмнең икенче көнендә Мостай Кәримнең туган авылы Келәшкә алып баралар. Көннең нинди булуына карамастан, Чишмә районы башланган җирдә кунакларны ипи-тоз, казы-кымыз белән каршы алалар. Курай уйный, милли киемнәрдән яшьләр тантаналы итеп кунакларны каршы ала. Автобус, машиналарга төялгән кунаклар Мостай Кәримнең туган авылы Келәшкә юнәлә! Ә инде Келәш сынатмый! Мәктәп балалары данлыклы, яраткан якташының шигырьләрен укый. Утыртырга дип төбе-тамыры белән яшь агачлар да әзерләнеп куелган. Табын да мулдан! Барлык тантаналардан соң, халык «Кызлар тавы»на юнәлә, анда шундый учакка дигән утын да әзерләнгән. Бәйрәм район үзәге Чишмәнең мәдәният йортында искиткеч талантлы артистлар катнашында тантаналы очрашу белән тәмамлана. Беренче тапкыр Мостай Кәримнең 60 еллык юбилеенда келәшләр кунакларны авыл уртасында казылган, «Мостай Кәримнең илһам коесы» дип аталган коедан су уртлаттылар. «Мостай Кәрим илһамын татып карагыз!» – дип язылган иде кое капкачына. 70 еллыкта да, 75 еллыкта да, 80 еллыгында да кунаклар кое суын эчеп илһам алдылар, 85 еллыгында да! Без инде әткәйсез генә аның 100 еллыгында Келәшкә кайткач, бу коеның суын кунакларга тәкъдим итмәделәр. «Мостай абый бакыйлыкка күчкәч, коеның да суы бетте», – диделәр. Кое суы гына түгел, Мостай Кәрим үзе дә илһамландырган булгандыр ул суны, үзе киткәч, илһамлы суы да аңа ияргәндер. Шулай дип уйлап куйдым әле. Ышансагыз – ышаныгыз, ышанмасагыз – барып карагыз. Менә шундый могҗиза!

## Әткәйгә – 75 яшь

Әткәйнең бу юбилее турында аерым әйтәсем килә. Искиткеч бәйрәм булган иде ул. Без барыбыз да Уфага җыелыштык. Опера театрында халык шыгрым тулы. Башкортстан президенты да котлап сүз алды. Кунакларның да әткәй өчен иң тансыклары, халык өчен иң абруйлылары килгән иде. Әткәйнең бик күңеле булган иде ул вакытта. Чөнки аның бәйрәмендә Дагыстаннан Рәсүл Гамзатов белән хатыны Патимат, Казаннан Гариф Ахунов, Ренат Харис, Ринат Мөхәммәдиев һәм Хәйдәр Бигичев килгән иде. Гаиләдә барыбыз да Хәйдәр Бигичевның җырлавын яратканга, бигрәк тә Тимербулат аның «Керим әле урманнарга» җырын бик яратып тыңлаганга, әткәй аны чакырырга булды. Хәйдәр театрда да, банкетта да, икенче көнне өйдә дә җырлады. Күзләрдән яшь чыгарып, «Өченче көн тоташ кар ява» җыры да тетрәндергеч яңгырады. Әткәй белән әнкәй Хәйдәргә аерым рәхмәт әйттеләр. Әткәй шунда: «Хәйдәр Бигичевның җырын үз өемдә ишетер өчен генә дә 75 яшемне билгеләү акланыр иде», – дигән иде.

## Хәмдүнә

Җырчылар турында сүз чыккач, тагын бер җырчы белән бәйле хатирәне уртаклашыйм әле.

Очраклы хәлләр барысы да тәкъдирдә язылган диләр.

Байтак еллар элек, төгаен кайсы ел икәнлеген хәтерләмим дә, көннәрдән бер көнне Мәскәү гастрольләрен оештыру мәшәкате белән йөргән җырчы Хәмдүнә Тимергалиева һәм Мәскәүдә бергә укыган дустым, сүз остасы Зәйтүнә Яруллина безгә килеп керделәр. Мин бу кунакларга бик шат идем. Зәйтүнә белән дә байтактан күрешмәгән, Хәмдүнәне дә ерактан гына күреп, ишетеп кенә беләм, якыннан сөйләшеп утырган юк. Бәхетле кешенең кунагы бергә килә диләр. Хәтта әткәйнең бер язмасында «Бәхет ул кунакның чабата бавына ияреп килә» дигән сүзләре бар. Мин аңа ышанам, ул дөрес әйтә. Ләкин бу очрашуда кунакларга да тәтеде бәхет. Әткәйне көтә идек без ул көнне! Табыным әзер, шунысына да сөендем. Кунакларны сыйлар ризыкларым бар! Озак көттерми, әткәй дә килеп җитте. Очраклымы бу хәл, очраклы түгелме? Кем нәрсә дияр. Күрештеләр, таныштылар. Әткәй Зәйтүнәне белә иде инде. Зәйтүнә – безнең туйда минем яктан шаһит булган кеше. Әткәй белән таныш. Хәмдүнәне кем белмәсен! Табынга утырдык. Сүз барышында әткәй Хәмдүнәдән: «Башкортстанны сагынасыңмы?» – дип сорады. «И Мостай абый! Кем сагынмый яшәгән инде!» – диде Хәмдүнә. Әткәй акыллы хатыннарны ярата иде. Шундый матур сөйләшү китте. Хәмдүнә белән әткәйнең сөйләшер сүзләре бетми. Әткәй аны үз янына утырткан иде. Ул җырчының иҗаты белән дә кызыксынды, җырлатып та алды. Шуннан ул аның тормышы турында сораша башлады. Тору шартлары ничек, фатирың бармы дип сорады. Шунда Хәмдүнә зарланып та, ачынып та әйтмәде кебек, чөнки бик күңелле утырабыз бит, гадәти генә итеп, үзенчә – Хәмдүнәчә:

– Юк, Мостай абый, кая инде миңа! Тулай торакта торам. Бәлки берәр кайчан булыр әле дип уйлыйм... – диде.

Әткәй моңа гаҗәпләнеп карап кына куйды, каршы берәр нәрсә әйттеме – анысын хәтерләмим. Әйтмәгәндер, ләкин күңел түренә салып куйгандыр. Ул беркайчан да, бернәрсәне дә онытмый иде. Бигрәк үз-үзенә сүз биргәндә. Әмма ул вакытта Хәмдүнәгә бернәрсә дә вәгъдә итмәде. Итә дә алмый иде. Ул бит Татарстан кешесе түгел. Ләкин Казанга килгәч, шушы мәсьәлә белән Минтимер Шәймиевка кергән. Шәймиев әткәйнең үтенечен тыңлаган. Шулай итеп, әткәй кайгыртуы белән Хәмдүнә ике бүлмәле фатирга ия булды. Соңгы тапкыр Хәмдүнә белән 2020 елның август аенда булса кирәк, Бөтендөнья татар конгрессының 30 еллык юбилеенда күрештек. Ул мине кочаклап алды да:

– Нәзифә! Мостай абый мине фатирлы итте бит! Аңар рәхмәт белән яшим! Үзен чакырып, рәхмәт йөзеннән кунак та итә алмадым. Бер кил әле, шул очрашуларны искә төшереп утырыр идек, – диде. Очрашырбыз дип саубуллаштык. Язмаган булып чыкты... Шул очрашудан бер ай да вакыт үтмәде бугай... Хәмдүнәбез көтмәгәндә арабыздан китеп тә барды. Рухы шат булсын!

### Китапка исем эзлибез

Хәтерлим: Илгиз белән без дә Уфада идек. Төшке аштан соңдыр инде, барыбызның да зур залда җыелышкан булуыбыз истә калган. Шунда әткәй безгә: «Ничек дип атарга да белмим, менә әле яңа гына язылып беткән әсәремә исем табышыгыз әле!» – диде. «Озын-озак балачак» дип аталачак әсәренә исем эзләргә тотындык. Һәркем үз фикерен әйтә, ләкин берсе дә ошамый. Эзли торгач, әсәргә исемне әткәй үзе бирде дип әйтергә була, ләкин анда Илгизнең дә өлеше бар. Башта әткәй: «Күпер» дип атасак, ничек булыр? Балачактан олы чакка күпер, минемчә эчтәлеккә туры килә кебек», – диде. Ләкин әнкәйгә ул исем ошамады. Тагы эзләргә тотындык. Һәркем үз вариантын әйтте. Мин дә эзләүләрдә катнаштым. Шулчак тәрҗемәче Елена Николаевскаяның «Медленно седеющий младенец» дигән сүзләре исемә төште. Ләкин бит монда русча кирәк түгел. Башкортчасы ничек була соң моның? Күп төрле вариантларны кире какканнан соң, әткәй: «Әгәр дә «Озын балачак» дисәк, ничек булыр?» – дип сорады. Ә инде Илгиз: «Озын-озак балачак» дип атасак, яхшырак булыр сыман», – дигәч, барысы да аның белән килештеләр. Әткәйгә дә бу исем ошады. Бу әсәрне русчага Илгиз тәрҗемә итте. Шушы әсәр тәрҗемәсендә Илгизнең тәрҗемәче буларак осталыгы да күренде. Шуннан соң олы, классик язучыларыбыз да, әсәрләренә тәрҗемә ясарга дип, Илгизгә мөрәҗәгать итә башладылар.

Гомәр Бәширов, Нурихан Фәттахлар... Әмирхан Еники үзенең «Соңгы китап» әсәрен Илгиздән тәрҗемә итәргә сораган иде. Кайбер җирләрен кыскартып, карандаш белән битләрен билгеләгән ул китап әле һаман да бездә. Тик тәрҗемә ясарга насыйп булмаган. Үзгәртеп кору нәшриятларга да кагылды. Мәскәү нәшриятлары милли авторларны басмас булдылар. Илгиз Кәримов – татар язучыларыннан Гариф Ахунов, Рафаэль Төхфәтуллин, Марсель Галиев, Ринат Мөхәммәдиев әсәрләрен русчага тәрҗемә иткән тәрҗемәче. Алар үзгәртеп коруларга кадәр өлгереп калдылар.

Хәзер инде «Озын-озак балачак» пьеса буларак та билгеле, театрларда

куела. Әсәр язылгач та, Мәҗит Гафури исемендәге Башкорт дәүләт академия театрының баш режиссёры Рифкать Исрафилов әткәйгә бу әсәрне сәхнәләштерергә ниятләвен әйткән. Әткәй бу хакта спектакльнең премьерасыннан соң сөйләгән иде: «Рифкать миңа, әйдә, Мостай ага, эшлик әле шуны дигәч, мин авантюрист түгел, нинди спектакль ясап булсын аннан дигән идем. Ышанмадым. Кара әле, нинди матур спектакль килеп чыккан бит!» – дип, өйгә кайткач та, соклануын белдереп утырган иде.

## Кави

Әткәйнең беркайчан да акча салып йөртә торган портмонесы да, шуңа охшаган нәрсәләре дә булмады. Ул Илгиздән көлеп: «О-о, кара, моның портмонесы нинди шәп, чын тиредән эшләнгән, кая, акчасы бармы соң?» – дия иде, аның эченә күз төшереп. Бәлки акча күренмәгәчтер инде: «Өзелеп китсәгез, ялгап җибәрермен, сорагыз!» – дип әйткән чаклары да булды.

Әткәй акчасын болай гына кесәсендә йөртте. Бер ягында – кәгазь, икенчесендә – вак акчалар. Махсус түгел инде, шулай килеп чыга иде аның. Бәлки кесәсенең акчасыз йөргән чаклары да булгандыр. Киемен алыштыра бит кеше. Мин белгән чактан бирле әткәйнең кибеткә йөргәнен хәтерләмим. Йә, балалар алып кайта, йә булмаса әнкәй барып ала. Күбрәк әйбер кирәк булганда, машина белән баралар. Ләкин әткәй кибеткә ипи, сөт кебек әйберләргә йөрми.

Әткәй сөйләгән бер очракны искә аласым килә. Уфада беркатлырак, үзен шагыйрь дип йөрткән Кави исемле бер кеше бар иде. Минем аның үзен күргәнем булмады, ләкин телефоннан берничә тапкыр сөйләшергә туры килде. Мин Уфада чак. Телефон шалтырый, әткәйне сорыйлар. «Ул өйдә юк бит әле», – дим. «Ә син кем буласың?» – дип сорый телефондагы тавыш. «Мин – Нәзифә», – дим. «Ә-ә, Илгизнең хатынымыни? Беләм Илгизне, беләм! – ди бу. – Ул бит «Литературная Россия» дигән гәҗиттә эшли. Мин аңар шигырьләремне җибәргән идем. Положительный ответ та алдым. Әле хәзергә шигырьләрегезне баса алмыйбыз, язып торыгыз, басарбыз дип язган иде Илгиз. Мостай абый кайткач, Кави шалтыраткан иде дип әйтергә онытма!» – дип, трубканы куйган иде.

Без Кавиның «положительный ответ» дигән сүзен еш телгә ала идек.

Әткәй кайткач, Кави исемле шагыйрьнең шалтыратуын әйттем.

– Ә-ә, Кави! – диде әткәй, көлемсерәп. – Кызык кеше ул. Шигырьләр яза, әйбәт кенә оброзлар тудыра кайчагында. Күптәннән, 60 еллардан бирле минем тирәгә елышырга тырыша ул. Кави Башэнерго системасында электромонтёр булып эшләгән иде. Ул чакта мин РСФСРның Югары Советында президиум рәисенең беренче урынбасары идем. Нindидер властем бар вакыт. Үпкә авыруы белән авырган бу монтёрга бер бүлмәле фатир алырга ярдәм иттем. Кемнеңдер киңәше беләндер инде, миңа гариза язган иде. Соңыннан психик авыру буенча инвалидлыкка чыкты. Ару гына шигырьләр яза башлады. Бу миңа бик нык ияләнде. Чалбары яки ботинкасы тузса, туп-туры әйтә: «Чалбар кирәк иде... Ботинка кирәк иде... Алмаш күлмәк тузды», – ди. Кайсы вакытта Раузага әйтеп, кайчагында әйтми генә, аның гозерен үти килдем. Булганын бик пөхтә итеп киеп

йөри. Чалбар үтүкләнгән, галстук бәйләнгән, ботинкасы ялтырап тора. Бөеклек чире бар. Чире болай тыныч. Бөеклеген үзе генә белә, кешегә кычкырып йөрми.

Менә шул Кави урамда очраганда, акча бирми киткәнем юк минем. Кулымны кесәмә тыгам, бу чалбар кесәсендә акча бармы, юкмы дип уйлыйм. Кулларым акчага тигәч сөенәм. Әле аның да беркайчан да минем акчасыз чагыма туры килгәне булмады.

Бервакытны Кави өйгә килде. Бик сирәк килә ул өйгә үк. Димәк, бик мөһим эшләр белән йөри.

– Мостай абый, – ди, – сиңа ике йомышым бар. Беренчесе – акча кирәк иде безгә, икенчесе шигырьләр җыелды минем, китап итеп чыгарырга иде, синсез булмый икән.

– Кави, синең китабың бар бугай бит инде? Чыгардың бугай... – дигән булам. Шаяртам инде, беләм китабы юклыгын да, китап чыгачагы икеле икәнлеген дә беләм.

– Юк, Мостай агай. Менә чыгарырга иде. Син үзең мине шагыйрь диден бит.

– Кави! Минем авторитет бар инде ул бераз, шулай да барысын да булдырып чыга алмам. Менә бу ике йомышыңның кайсысы мөһимрәк, берсен бүген үк үтим!

– Алайса, акча инде! – диде Кави.

Кави турында әткәй сөйләгән тагы бер мәзәк искә төште. Әткәй әйтә, ара-тирә урамда бергә йөрибез, Ленин урамында танышлар да, таныш булмаганнар да исәнләшеп уза.

– Синең белән чыксаң, Кави, баш кагудан бушап булмый, – дим. «Бу якта шулай шул. Халык культурный. Мине таныйлар. Мин торган җирдә халык надан, тупас, күрмәмешкә салышып китәләр», – ди. Ул миңа шигырьләрен укый. Шигырьләре бик самими инде, бала шигырьләре кебек. Мин тыңлыйм, күңелен күрәм. Китап чыгарырлык шигырьләре дә бар иде. Нәшрият кешеләрен күндерә алмадым. Дәлил: «психик авыру». Күңелем боекса, уйларым сүрәнәеп киткән чакта Кавиның бер шигырен кабатлыйм. Ул аны «Ай тотылган төндә» фильмын карагач язган. Менә ул шигырь:

Ай тотылды – әй, көендек.
Ай котылды – әй, сөендек.
Мин дә шулай:
Бер карасаң, тотылган ай
Бер карасаң, котылган ай.

Әткәй бу хакта сөйләгәннән соң миңа:

– Беләсеңме, Кави белән аралашканнан соң мин күңелем белән чистарынып киткәндәй булам. Аның белән аралашканда, үземне күкләргә якынрак итеп тоям, Аллаһ бәндәсе инде ул Кави, – дигән иде.

Кавиның эш урыны да булмагандыр инде. Инвалид булгач дип уйлыйм. Белмим, әткәй нинди аргументлар китергәндер, кайларда сөйләшкәндер, Кавиның матди ягын юнәйтер өчен ул көченнән килгәннең барысын да эшләде дип уйлыйм. Әткәй Салават Юлаевның Агыйдел ярында, тау башында тора торган һәйкәлен саклаучы дигән штат берәмлеге булдырып, Кавига ай саен акча түләүне оештырган иде. Язучылар берлегеннәнме, нindидер башка оешмаданмы – анысын хәтерләмим, ләкин Кави, Салават

Юлаев һәйкәлен саклап, карап торучы буларак, ай саен хезмәт хакы алганын беләм.

Менә шундый иде ул минем каенатай.

## Фатих бабай

Тагы бер кызыклы кеше турында сөйлим әле. Минем аны беркайчан да күргәнем булмады, ул без өйләнешкәнгә кадәр вафат булган. Әткәй аны еш кына искә төшерә иде. Ул да булса, безнең нәнәйнең, ягъни әткәйнең әнисенең абыйсы Фатих бабай. Аның турында кызык хәлләрне күп сөйлиләр иде. Үзе бик зирәк кеше булган ул. Нәнәй кебек 106 яшькә җитмәсә дә, 96га кадәр яшәгән. Фатих бабай әткәйләргә килгәч, әлбәттә, аны «сыйламыйча» җибәрмәгәннәр. Вакыты шундый. Хәзер андый бабайлар хәмер тотмас иде. Фатих бабай шундый утырышлардан соң бияләен йә башка бер әйберен берәр җиргә кыстырып, «онытып» китә торган булган. Иртәгесен бик хафаланып, югалган бияләйне яки башкасын алырга килгәч, әлбәттә, баш төзәтеп җибәрәләр.

Әткәй бер хәлне сөйләгән иде.

«Фатих бабайны ишетеп беләсең инде. Ул – инәйнең абыйсы. Елына бер тапкыр Уфага килеп, бездә кунак булып китә торган иде.

Бер килгәнендә ашап-эчеп алгач, бу сүз кузгата:

– Без, Мостафа, әбиең белән кәҗә алырга булдык әле. Шул җәһәттән бер киңәш сорамакчы булам. Кәҗәнең ни, аның бәясе йөз тәңкә тирәсе хәзер. Син акыллы кеше, киңәш ит: шул йөз тәңкәне каян алыйм икән?

Үзе, башын бора төшеп, читкә карый. Мин аптыраган булып көрсенеп куйдым да:

– Мостай Кәримгә ымлап карасак, ничек булыр икән? – дидем.

– Шәп булыр! Иллә зирәк кешесең дә инде син, Мостай Кәрим!

Моны ни өчен искә алдым дисең? Хәзер миңа еш кына Фатих бабайча киңәш сорап киләләр. Акча сорамыйлар, фатир, университетта урын, малаена йә кызына эш һәм башкалар. Сорыйлар да: «Синең бер сүзең җитә!» – диләр.

Җитәр бер сүзең!

...Фатих бабайның бер кыланмышы бар иде. Өч рюмка эчкәнче, миңа Мостафа дип эндәшә, шуннан соң инде: «Сал тагы берне, Мостай Кәрим!» – дип, кулын болгый иде.

Ул чакта Фатих бабай күптән инде 80не узган иде дигән иде әткәй.

## Сумлап түлим

Барыбыз бергә җыелышкан чакта, бигрәк тә бала-чагалар күп булганда, әткәй кесәсеннән учын тутырып вак акчаларны чыгара торган иде дә:

– Йә, кайсыгыз әйтә ала, бу учта күпме акча бар, рублями плачу! – дип әйтә иде. – Аерма бер-ике тиен булганда гафу итәлә!

Әй, барыбыз да бер-беребезне бүлә-бүлә әйтәбез. Әткәй учын ялт кына итеп ачып күрсәтә дә тагы йомарлый. Әткәй саный да: «Юк, белмәдең!» – ди. Шулай байтак кына ярышабыз! Отучылар булгалады, әлбәттә. Юк, миңа андый чакта бәхет тәтеми, лотереяга бернәрсә дә ота алганым юк. Менә каенсеңлем Әлфия берсендә 179 сум откан иде. Мин санау комиссиясендә идем. Шунысын гына раслый алам: барысы да гадел булды.

## Бәхет запасы

Сөйләшеп утырганда, мин әткәйнең күңелен дә ишетә идем кебек. Күңелен бушатырга теләгән чагында заман борчуларын да, күңелендә саклаган шатлыкларын да сөйли иде. Ул сөйләгәндә, пафос та сизелми. Аны югары кимәлдәге сүзләрне чын күңеленнән әйткәненә ышанасың, ул бит – шагыйрь кеше. Аңар матур сөйләм хас.

«Уйладым да шундый фикергә килдем: минем бик зур бәхет запасы булган икән, бүгенге көнгә кадәр шул яшәткән мине, – диде әткәй беркөнне. – Иҗатым күп еллар миңа бәхет туплаган, һәр яңа юлның язылуына мин чиксез сөенә идем. Ярты гасырдан артык гомердә минем китапларым чыга килде, вакытында пьесаларым илнең дистәләрчә, йөзләрчә театрларында куелды. Алар минем бәхет казнасын бермә-бер арттырып килделәр. Монысы бер.

1945 елгы Җиңү бәхете. Ул – миңа бөтен гомерем өчен җибәрелгән бәхет. Чөнки аны тоймаган бер генә кешем дә булмады.

Тагы яраттым, яратылдым. Бәхетнең түбәсе шушы була торгандыр инде. Яңа ел белән котлап, кешеләр сиңа яңа бәхет телиләр. Минем ул булмаячак. Миңа иске, тугрыклы, сыналган бәхетем дә бик җиткән. Ул мине һәрвакыт җылыта. Мин аны карт солдат үзенең медальләр таккан иске гимнастёркасын саклаган кебек саклыйм.

Тагы шунысын әйтим: балачагымда әти-әнием, абыйларым, туганнарым мине беркайчан да рәнҗетмәделәр, түбәнсетмәделәр. Хәзер аңлыйм: бу бит бәхет булган! Балаларым, Аллага шөкер, авырлыклар китермәделәр. Соң, болар бәхет түгелмени?! Мин үземне бәхетле кеше дип саныйм. Менә бәхетле булганда үлеп китсәң иде ул», – диде әткәй, шаккатырып. Бәхетле булганда, кемнең үләсе килсен инде? Әткәйнең бу сүзләренә ышанасым килмәде. Бәхетең булгач яшә дә яшә әле, әткәй, без бит сине бик яратабыз дип кычкырасым килде. Тик дәшмәдем. Үз хәлен үзе белгәндер инде.

## «Үзгәртеп кору» нәрсә бирде?

Әткәй көндәлекләрендә кайчак рус телендә язган. Шул телдә уйлагандыр, күрәсең. Хөрмәтле укучылар, ул язмаларны сезгә дә укытасы килгәнгә, аларны татар теленә тәрҗемә иттем. Менә шул язмаларның берсе:

16.05.04. «Минем инде күп тапкырлар әйткәнем бар, нинди генә революция булмасын, ул кемнәндер бар нәрсәсен дә тартып ала, кемгәдер төяп бирә.

Бөек Октябрь революциясе минем халкыма барысын да бирде диярлек, бернәрсәне дә алмыйча дип тә әйтеп була.

«Үзгәртеп кору» халыкка нәрсәдер бирде, ләкин халыктан алганы күбрәк. Ә менә миннән барысын да алды. Ул миннән бөек дәүләтем СССРны тартып алды. Мин бөтен ил, бөтен кыйтга язучылары белән аралаша идем, күбесе минем дусларым иде. Барысын да «Үзгәртеп кору» тартып алды. Минем акчам да бар иде. Гомеремнең ахырына кадәр уртача тормыш итәргә җитәр дип уйлый идем. Аларны миннән «мадам Перестройка» талап алды. Ул «мадам» мине тулы мәгънәсендә бернәрсәсез калганчы чишендерде. Алмашка берни дә бирмәде. Мин шәп-шәрә калдым, ә ул үтә затлы киенде, әйтеп бетергесез баеды.

Мин горур, җиңелмичә, вәсвәсәләргә бирешмичә, алга атлыйм».

## «Перестройка бәете»

Җилләр кузы көйрәтте,
Еллар сүзне сөйләтте.
Көйрәтте дә, сөйләтте дә
Сәнәк итте көрәкне.

Кызыл катыш карабыз
Тамакларны ярабыз,
Кул кушырып тормыйбыз
Дөп-дөп күкрәк кагабыз.

Илебезне фаш иттек,
Койрыкларны баш иттек.
Акны манып карага,
Тоз сибәбез ярага.

Яңарттык бар чаманы
Җәен җиктек чананы.
Кышын җиктек арбаны,
Әммә эшләр бармады.

Кычкырсак бар көч-хәлгә:
– Әй, хәлвә, хәлвә, хәлвә!
Сөрәнләдек нахакка
Тәм кермәде тамакка.

Биш елга да түзмәде
Кыптыр куян тиресе,
Имеш, омтылдык алга,
Килеп чыкты киресе.

Әллә иблис котыртты,
Әллә Ходай «утыртты».

Ис-акылым калмады,
Бу бәетне язарга
Китәмен тел сатарга,
Китәмен җир сатарга,
Китәмен ил сатарга
Рыночный базарга.

1990 ел.

## Көндәлекләрдән бер шигырь

30.05.04.

Быел җәй коры. Күккә карыйм да
Явар әле, димен, явар әле.
Рухым сүнгән чакта сабыр итәм,
Янар әле, димен, янар әле.

Кара төннең карынында ак таң
Атар әле, димен, атар әле,
Мәңгелеккә киткән кешем берчак
Кайтыр әле, димен, кайтыр әле...

**Мостай әйткән:** «Әдәбият һәрвакытта да азатлык өчен көрәште. Хәзер азатлык бар, тик әдәбият кына юк. Чөнки көрәшерлек сәбәп калмады».

## Көндәлекләрдән

08.01.04.

Кавказ тауларында буран икән...
Карлар каплый дуслар каберләрен
Кайсын, Рәсүл! Ярты төннән бирле
Сезнең хакта сыктый хәтерләрем.

Берегез агай, икенчегез эне –
Мин һаман да сезнең уртадамын,
Арагызга сыенмакчы булып,
Вакыт-вакыт сезгә омтыламын.

Кавказ ерак хәзер, җитеп булмас –
Андый теләк аңга кермәсен дә,

Идел буендагы калкулыкта
Урыным бар ярым тирәсендә...
Ул үзенә мине чакыра,
Кар да явып тора чак кына...

**Мостай әйткән:** «Ил бәхете – тынычлыкта, туклыкта. Кеше бәхете – һәркемнең үзенеке. Аны башкалардан бурычка да, акчага да алып булмый. Туклык һәм тынычлык аның өчен бәхетнең бер өлеше генә».

## Көндәлекләрдән

27.10.03. «Тагы больницага килеп эләктем. Сул аягым шеште. Аның үзен генә җибәреп булмый бит инде, шуңа күрә уңын да алып килдем, сау булса да. Шаярткан булам тагы. Бөтен тәнем коелып төшеп бара. Моңарчы өч көн температурам 38 градус булды. Рухым да талпынып тормый.

Куанычым да бар.

84 яшемне бик матур итеп үткәрделәр. Президент Салават ордены тапшырды. Аны, тәмләп, телевизордан күрсәттеләр, радиодан сөйләделәр, газеталар язды. Рәхимовтан, Байдәүләтовтан шәхси телеграммалар килде. 19-21 октябрьдә бик күп халык килә-китә торды. Кала башлыклары, район башлыклары, министрлар өемне күреп, кулымны кысып чыктылар. «Чыктылар» дигәч тә инде, болай гына чыгып китмәделәр. Өч көн буе Әлфиянең табыны тулы булды. Кунаклары өзелмәде».

Бу урында шунысын да әйтәсем килә: әлбәттә, әткәй белән әнкәйне карау, тәрбияләү каенсеңлем Әлфия, аның ире Олег җилкәсенә төште. Без ерак. Якында булсак, без дә алар янында булыр идек. Мәскәүдә яшәсәк тә, шул заман казанында кайнадык. Балаларны күтәрергә, үзебезгә дә төшеп калмаска, җан асрарга кирәк иде. Мин эшләгән милли мәктәпләрнең фәнни-тикшеренү институты таралды. Эшсез калдым. Илгизгә дә эшкә урнашырга туры килде. Ул әле тәрҗемә эшләре белән күпмедер эшли ала иде. Ләкин милли язучыларның әсәрләренә нәшриятларда ихтыяҗ бетте. Илгиз дусты Ромен Гузаиров белән, «Арбат» дип аталган нәшриятны рәсми теркәп, китап чыгару, китап сату белән шөгыльләнә башладылар. Яңа эш миңа да кирәк иде. Көтмәгәндә, радиога чакырып, хәбәрче эше тәкъдим иттеләр, шул ук елны «Зыялылар Клубы» оештыру эшләрен башлап җибәрдек. Шулай итеп, минем бер түгел, ике эшем булды.

## Зыялылар Клубы

1992 елда Бөтендөнья татар конгрессы оешкан көннәрдә мин Мәскәүдән делегат идем, Гариф Ахуновның улы Рәшит миңа:

– Әйдә, Мәскәүдә татар зыялыларын җыябыз, барлыйбыз. Алар бит күп! – диде.

Һәм без «Зыялылар Клубы»н оештыру мәшәкате белән яши башладык. Бу – иҗтимагый оешма. Әле андый оешмалар турында кануннар чыкмаган. Уставлар да юк. Беренче чиратта, эшнең кануни ягын уйласак, икенче чиратта, кемнәр клуб әгъзалары булырга тиеш, бу Клубның максаты нидә дигән сорауларга җавап эзләдек. Гаилә дустыбыз, академик Роберт Нигъмәтуллинга шалтыратып, ниятләребез турында сөйләдем. Ул бу

башлангычны күтәреп алды! Шунысын да әйтергә кирәк: клубның булачак учредительләренең күбесе белән Конгресс вакытында Казанда танышкан идек. Димәк, алар инде Татарстанга билгеле шәхесләр! Уставлар язып, клубыбызга лаек кешеләрне эзли торгач, бер ел вакыт узып та китте. Безнең клуб уставының бер маддәсендә: «Клуб әгъзасы нинди кеше булырга тиеш?» дигән сорауга Роберт Нигъмәтуллин «Клуб әгъзасы яхшы кеше булырга тиеш!» дигән маддәне тәкъдим итте. Бу сүзләргә Клубны теркәгән вакытта Юстиция министрлыгында да каршы килмәделәр. Шулай итеп, 1993 елның августында Мәскәүнең татар зыялылары Клубы рәсми теркәлү алды. 10 кешедән торган учредительләр мине клубның директоры итеп билгеләде. Беренче профессия буенча училище дипломына язылган «Клуб мөдире» дигән сүзләр мине 25 елдан соң куып тотты. Ничек кенә булмасын, ул белемнәрнең бу эштә файдасы күп булды. Кемнәр иде соң ул учредительләр? Әлбәттә, беренче урында академик Роберт Нигъмәтуллин, Югары мәхкәмәдә баш судьяның урынбасары Ренат Смаков, Тышкы эшләр министрлыгыннан Фәрит Мөхәммәтшин (ул күп еллар Татарстанның РФдәге вәкаләтле вәкиле булып эшләде, чит илләрдә тулы вәкаләтле илче хезмәтен башкарды, хәзер инде Федерация шурасында), Россия телевидениесенең икенче каналында директор урынбасары булып эшләүче Рифат Сабитов (ул һаман шул эшендә), язучы, ул вакытта Татарстаннан депутат иде – Ринат Мөхәммәдиев, профессор, юрист, язучы Зөфәр Фәтхетдинов, кинорежиссёр Булат Мансуров, эшкуар Рәшит Ахунов, институт директоры (тумышы белән Мамадыш районыннан, безнең күрше авылдан), профессор Раиф Васылов һәм мин.

Бу Клубның Мәскәүдәге татар дөньясына керткән эшчәнлеге бихисап булды. Без татар зыялыларын барлап, аларны милләткә файдалы эшләргә җәлеп иттек. Ренат һәм Рәсим Акчуриннар, армия генералы Мәхмүт Гәрәев, врачлар, хирурглар, хәрбиләр, галимнәр, милләтебезнең горурлыгы булган кешеләр клуб әгъзалары булды. Алар үзләренең исемнәре, абруйлары белән Мәскәүдә күп төрле проблемаларны хәл иттеләр. Шуларның берсе: 1913 елдан бирле татарларныкы булып та, соңгы 50 елда Тышкы эшләр министрлыгы карамагында торган мәдәни үзәк – Асадуллаев йортын хуҗаларына – Мәскәү татарларына кайтару. Зыялылар Клубында Татарстан, Башкортстан республикаларыннан танылган шәхесләр – язучылар, артистлар, галимнәр, оешма вәкилләре белән дә очрашулар уздыра торган идек. Казаннан Язучылар берлеге, «Казан утлары» журналы, «Сөембикә» журналы редакциясе, Галиәсгар Камал театры, Казан консерваториясе һәм башка оешмалар белән очрашулар оештырылды. Клуб эшләгән 30 елда уздырылган чараларны санап бетерерлек тә түгел. Безнең Клубта Башкортстан көне дә уздырылды. Анда каенатам да катнашкан иде.

Мин 30 ел буена «Зыялылар Клубы»ның директоры вазифасын үтәдем.

## Хәтер калды

«Карт кешенең хәтере калырга гына тора бит ул, – диде әткәй берсендә. – Әле Санкт-Петербургның 300 еллыгына барырга делегация төзелгән. Миннән: «Бара аласыңмы?» дип, исем өчен дә сорамадылар. Барырлык

хәлем дә юк инде. Рәхмәт әйтеп баш тартыр идем. Ә бит миңа еш кына: «Син – республиканың горурлыгы, аның визиткасы», – диләр. Үзләре горурлыкны, визитканы өйдә калдырып, кунакка китәләр. Мин моны Президентның үзенә карата әйтмим, ул бит исемлек төземи. Исемлек төзүчеләр моны хәтерләргә тиеш дим». Әткәй елмаеп куйды да: «Мыжып алдым менә, тыныч булып калды», – диде.

Әткәй такмагы:

«Байның уе – керемдә,
Ярлыныкы – илендә.
Ачның күзе – икмәктә,
Тукның күзе – итәктә».

**Мостай әйткән:** «Аңламассың әдәм баласын, үземне әйтәм. Яшәү дә ялкыта башлады. Үләсе дә килми. Менә бер хикмәт».

«Ачуланышып ардым инде. Кабат тиргәшмәм. Үземә үзем батып, шундый тирәнгә кереп китәрмен, казып та чыгара алмассыз. Мин бит гомеремнең һәрбер ботагына чытырдап ябышмыйм, бары кәүсәсенә генә тотынып торам. Шуның өчен мине, өйдәме, өйдә түгелме, вак-төяк белән сынамагыз. Әгәр дә кәүсәнең какшавын сизәм икән, ботакларына ябышып маташмаячакмын. Торган җиремнән гөрселдәрмен дә авармын. Менә шулай».

«Гади хакыйкать: таза кеше чирдән курка, чирле кеше үлемнән курка».

Шагыйрьгә гомер бакый йә таш аталар, йә сөяк аталар».

## Әткәй сөйләгәннәрдән

«...Картлык сәер икән ул. Балачактагы хәлләр, кызыклар бик еш хәтергә төшә. Олыгайгач, әллә үзең дә дөньяны бала күзе бала күңеле белән кабул итәсең инде. Кеше картайган саен акыллылана, сабырлана, тормышның ыгы-зыгысына өстәнрәк, читтәнрәк карый диләр. Буш сүз икән ул. Киресенчә, һәр вак-төяккә бәйләнергә, үпкәләргә торасың. Ирнең иң акыллы, сабыр, төпле, ныклы, көчле ихтыярлы чагы – 35 белән 65 яшь арасыдыр. Чөнки бу чорда рухи хәзинәләр туплау аеруча аңлы, максатлы рәвештә дәвам итә. 65тән соң туплаган байлыкны туздыру башлана. Берәүләр аны тиз генә туздырып бетерә дә бөлеп кала. Икенчеләр саклык белән тотына һәм мөмкин булганча өстәп торырга да тырыша. Элек мине бөек шагыйрьләр, бөек романнар, бөек картиналар, бөек музыка, бөек фәлсәфи язмалар мавыктыра иде. Хәзер шушы даһи иҗат җимешләрен тудырган шәхесләр кызыксындыра. Кемнәр, нинди кешеләр алар? Пәйгамбәрләрме, әллә шайтаннармы? Әллә икесе бергә кушылган затлармы? Аларның игелекләрен дә, гөнаһларын да гадәти үлчәүләр белән генә үлчәп булмый. Аларның үз үлчәүләре бар, аларны шуның белән генә үлчәргә кирәк. «Бөек» дигән сүз ишетсәм, аңымда шундый сыннар пәйда була: Гомер, Конфуций, Данте, Гете, Рафаэль Санти, Фирдәүси, Пушкин, Бетховен, Чайковский һәм башка шундый шәхесләр. Ул үлчәүне Тукайга кулланырга икеләнәм.

Безгә бер кимчелек хас. Дөнья казанышларын азрак белсәк, үз

казанышларыбызның базары арта дип ризалашабыз. Үткән чорда башкорт әдәбияты дөньяга билгеле була башлаган иде. Әсәрләребезнең башка телләргә тәрҗемә итеп таралауы, чит укучыларга барып җитүе үзе бер югары бәһа иде. Хәзер ул үлчәү юк. Хәзер барысы да бертигез. Кайчак хәтер калып куя. «Агыйдел» журналының 70 еллыгын билгеләү уңаеннан мәкалә булды. 70 ел эчендә журналда басылган байтак романнар, повестьлар, драмалар мактап санала. Ә Ленин премиясенә лаек булган «Озын-озак балачак» белән «Ташлама утны, Прометей!» телгә дә алынмый. Сәер бит. Редакциянең бәһасенә лаек түгелмени алар? Чөнки бөтенебез дә бертигез. Шул тигезләр арасында кемнәрнеңдер онытылып калуы гаҗәп түгел».

## Тимербулат турында

Әткәй Тимербулатны аерып яратты. Чөнки ул әткәй янында үсте. Туганнан башлап. Кызының баласы да бит әле. Тимербулат үзе дә әткәйне бик ярата. Әткәй аның турында көндәлекләрендә бик күп яза. Булатның кечкенә чагында әйткән кызык сүзләреннән башлап, яхшы укуы, мәктәпне кызыл аттестатка тәмамлавы, университетны кызыл дипломга тәмамлавы – болар барысы да әткәйнең горурлыгы. Тимербулат, Америкага китеп, университетка кергәч, анда да бик яхшы билгеләренә укыды. Америкада калмады, илгә кайтты. Ничек яратмыйсың инде аны? Уфада узган юбилейларының берсендә әткәйнең Тимербулат турында ешрак сөйләвен ишеткән Рәсүл Гамзатов: (шаяртып, әлбәттә, ул барысын да белә иде): «Мостай, мин синең оныгың берәү генә, Тимербулат кына дип уйлый идем, тагы ике оныгың бар икән бит әле!» – диде. Әткәй җавабын озак көттермәде: «Әйе, бар шул, тик алар бит дөнья читендә, Мәскәүдә яшиләр, ә Тимербулат янымда», – диде.

Көндәлекләрендә Тимербулат турында язмалар күп. Мәсәлән: «Өч көннән Тимербулат китә. Мин инде сагышта... Тимербулатны озаттык. Мәскәүгә Әлфия белән китте. 28ендә Нью-Йоркка очачак. Егетнең күңеле тулып-тулып кала. Тик бирешми генә. Безне тынычландыра. «Нык булыгыз!» – ди. Бу баламны бигрәк яратам шул. Чыңгызханның да бик яраткан бер оныгы булган. Китәр алдыннан ул үтә игътибарлы, ягымлы булды. Болай да ягымлы, сөйкемле бит ул. Күзгә оныгымның егермесе тула».

25.12.94. «Тимербулат кайтты. Безне күрергә дәваханәгә килде. Тагы да үсә төшкән. Элеккечә ягымлы. Рауза әйтә: «Син анда кәләш алып, торып кала күрмә тагы, без сине Америкага бирер өчен үстермәдек», – ди. Больницадан кайтып, төшке ашны Әлфияләрдә ашадык. Барыбыз да шат. Шул ук вакытта эчемдә хәвеф. Раузаның тикшерүләре хакында нәтиҗә көтәбез, иртәгә ни әйтерләр? Менә шулай. Ни генә әйтмә, гомерләрнең очына чыгып киләбез. Күпме калуы мине борчымый. Беребездән икенчебез күпкә торып калмасак иде. Ул чакта «ничек яшәргә?» дигән сорау түгел, «нигә яшәргә?» дигән сорау алга килеп басачак».

Әнкәйнең тикшерү нәтиҗәләрендә борчылырга сәбәп юк дип әйткәннәр. Гаиләбез өчен зур сөенеч булды.

## Көндәлекләрдән

12.12.94. «Больницада ятам. Рауза белән бер бүлекчәдә. Палаталар гына аерым. 7 төрле диагноз куйдылар, кайсы чиремне генә чирләп бетерермен. Үлгәнче өлгереп булса ярый да... Моңа вакыт күп кирәк булачак».

**Мостай әйткән:** «Может быт я самый грустный весельчак?»

13.12.94. «Күңелгә таш ятты. Россия Чечняга гаскәр кертте. Нәрсә белән бетәр икән бу хәлләр?»

8.02.95. «Муса белән (Муса Гали) тагы Переделкиного килдек. Әүвәлгечә иҗади талпынулар, өметләр чамалы. Раузаны калдырып китүем дә мазамны алды. Быел Переделкино белән хушлашу елы булыр, ахры».

11.02.95. «Теге пьесага тотына алмый җәфаланам. Сугыш турында булырга тиеш. Идеям бар, ачык кына сюжетым юк. Барып чыкмас, ахры. «Гомер мизгелләре» дигән язмаларны дәвам итәргә тотынам. Анда хикәяләү азрак, уйланулар күбрәк булырга тиеш».

## Әмирхан Еники

Әткәй иҗат йортына барган чакта анда Татарстаннан да язучылар булмый калмый, алар аралашалар. Әткәй көндәлекләрендә ул очрашулар турында нинди дә булса язма калдыра. 1995 елның февралендә алар Әмирхан Еники белән бер вакытта туры килгәннәр. Әткәй аның турында болай дип сөйләгән иде:

«Әмирхан Еникине Казанга озаттык әле бүген. 86ны тутырып килсә дә, әле нык күренә. Ямансу булып калды. Китәр алдыннан кызык кына фикерләр әйтте. «Хәзер инде елларны түгел, айларны гына санап яшәргә кала. Үлемнән курыкмыйм. Яшәү теләге белән тормыштан бизү тойгысы типмә-тигез булып тәңгәлләште. Яшәсәм дә ярый, үлсәм дә ярый», – ди. Үзе ике тапкыр Мәскәүгә барып, җәйге костюм карап йөрде. Кыйбатсынып алмый кайтты. Өстендә бик әйбәт соры костюм, көзен Уфага килгәндә дә, өр-яңа кара-көрән костюм кигән иде. Димәк, әле битарафлык аның рухына иңмәгән. Бу бик әйбәт! Әмирхан абый әле егәрле, сәламәтлегенә дә зарланмый. Җаны арыгандыр, күрәсең. Шуңа күрә яшәсәм дә ярый, яшәмәсәм дә ярый, ди.

Мондый кәеф ара-тирә миңа да сугыла. Картны аңлыйм», – ди иде әткәй.

## Кем язып биргән?

Әле минем беренче хикәяләрем басылып чыкканда, «Яшь ленинчы» газетасындагы бер редактор:

– Минем каләм кергәч, хикәяләрең укырлык булды. Сиңа аларны Мостай Кәрим язып биргән бит инде! – диде.

Үзенчә мине түбәнсетергә теләгән бу кешегә:

– Мостай Кәрим булып, Мостай Кәримне дә төзәтеп язгач, син иң шәп редактор инде, – дидем. Ачу килү генә түгел, гарьләндем ул чакта. Әткәй язып бирү түгел, укып чыкканы да булмады. Әле басылганнан соң укыса да, рәхмәт әйтерсең. Шулай да бер тапкыр балалар өчен язылган китап чыккач, бер хикәя турында:

– Менә бу хикәядәге күрше хатыны артык. Аның кереп чыгып китүеннән

бернәрсә дә үзгәрми. Кирәк түгел ул бу хикәядә. Язмаң уңышлы булсын дисәң, персонажларны арттырма, – дип киңәш бирде.

Тагын бер тапкыр повестемны укыганнан соң, менә бу төше уңышлы булган дип мактап алган иде. Ләкин кабат мактап әйткән сүзләрен хәтерләмим. Хәтта повестем басылган «Казан утлары» журналын самолётка укырга алып та, шунда онытып калдырган булып чыкты. Уфага кайткач табып укыганнар. Анда да әткәйнең мактау сүзләрен хәтерләмим, әмма әнкәйнең: «Бик матур язгансың, рәхәтләнеп укыдым, тик кыска булды, тиз бетте», – дип әйткәненә бик сөендем.

Мәскәүдәге бер танышым миңа хикәяләрне Илгиз язып бирә дип уйлаган. Берсендә: «Кичә кич булган вакыйга турында бүген иртән радиодан тыңлагач кына, үзең язганга ышандым. Илгизнең алай тиз генә яза алмаганын беләм бит», – диде.

Минем турыда гына түгел, поездда Уфадан Мәскәүгә кайтканда, бер ханымның Мостай Кәрим үзе язмый икән, аңар язып бирүчеләр бар икән дигән сүзләрен ишеткәч, аңлашылды: шундый категория кешеләр бар икән ул. Ничек уйлап табалар икән шундый юк нәрсәләрне?!

***

Әткәй, үзенең көндәлекләрендә әллә кайчан булган вакыйгалар хакында бик тәфсилләп, барлык нечкәлекләр белән язуын, «хикмәт вакыйгаларның нинди булуында түгел, синең рухыңның, аңыңның, хәтерләү аппаратының ничек, нинди дулкынга көйләнүендә дип аңлата. «Алар кайбер нәрсәләрне гомерлеккә үзләштереп кала, кайберләрен үткәреп тә җибәрә. Шөкер, минем хәтерем 70 ел буе күргән яхшы әйберләрне, әйбәт кешеләрне, шатлыкларны тугры саклый. Рәнҗешләрем дә булгандыр, әммә алар хәтеремне борчымый», – дип яза ул.

Әткәйнең бу шигырен бик яратам.

## Өч тулпар

Татар Тукай, татар Такташ,
Татар Туфан. Тамаша!
Шушы затлар телемә килсә,
Җаным күкләргә аша.

Бу өч тулпар тартып килә
Татар рухы арбасын.
Сикереп төшмәс шул арбадан,
Татар кайда бармасын!

Пәйгамбәрен сатмас милләт
Әллә нинди хакларга,
...Әмма яман хәбәр-хәтер
Килә безнең якларга.

Чүп ыргыталар Тукайга,
Таш аталар Такташка,
Хөкем итәләр Туфанны
Иман саткан какбашлар.

Бу халыкның тамырына
Балта чабу түгелме?!
Шундый хәлләргә шаккатып,
Әрни башкорт күңеле.
Татар Тукай, Татар Такташ,
Татар Туфан. Тамаша!
Шушы затлар телемә килсә,
Җаным күкләргә аша!
1961 ел

## Көндәлекләрдән

22.03.92. «Бүген консилиум кебек нәрсә булды. Кайчан чыгарасыларын әле әйтмәделәр. Тик һаман тын кысыла. Күп йөреп булмый. Коридорга чыгам да тиз генә кереп утырам. Бу юлы сигнал нык кына булды.

Кичә Мәргән Мырзабаев килгән иде.

– Нәрсә болай реанимациягә эләктең? – ди.

– Оҗмахка чиратка языльп куярга дип барган идем, язмадылар. «Алдан язылу юк, чиратыңны көт, «живая очередь», – диделәр оҗмах вәкилләре. Ярый, ашыкмыйк әле. Хәзер тәмугка эләксәң дә, көтелмәгән хәл түгел. Анда халык отыры күп булачак. Ялгыз түгелсең. Кеше ни күрсә, шуны күрерсең. Хәтта мин шулай уйлыйм: анда ачык күңелле, хөр табигатьле, чая рухлы адәмнәр күбрәк җыелыр. Бәлки әле җырчылар да очрар».

7.11.93. «Октябрь бәйрәме. Әүвәлгечә түгел. Күңелдә бәйрәм юк. Әмма ниндидер яктылык, ерактан килгән җылылык бар. Борчылу, хәтер калу да юк түгел. Илгизләр бәйрәм белән котлап шалтыратты. Үзем Акназаровларга, Әсәдуллиннарга, Мусаларга шалтыраттым. Миңа башка берәү дә шалтыратмады. Бу мине онытудан түгел, кешеләр бу бөек бәйрәмне, үзләрен адәм иткән тарихны, чорны оныттылар. Үткәнне оныту яки аны мәсхәрәләү хәзер бер төрле дәрәҗәгә әйләнде. Уйлап карасаң, уелып китәрлек. Көйле генә барган дөньяның астын-өскә китереп ташладылар, моңа куанып, илне җимерүчеләр кул чаба, җитмәсә, безне дә чәбәкәй итәргә өндиләр. Твардовский талантсыз бер әсәрне мактаган тәнкыйть мәкаләсенең авторы турында болай диде: «Үзе бук чәйни, җитмәсә, нинди тәмле дип мактый».

Адәмнәр илдәге бу мәхшәргә күнегә, ияләшә башлады. Хайваннар – эт, ат яңа хуҗага тиз генә ияләшми, баш биреп бармый. Киек хайваннар аннан да үз холыклы. Ә кешеләр, татлы вәгазьләргә, татлы ялганнарга ышанып, теләсә кемгә иярә. Мәсәлән, затлы ерткыч юлбарыс начар, явыз күңелле кешеләргә бөтенләй буйсынмый, буйсынган булып маташса да, җаен табып котыла.

Радиодан моңлы милли җырыбыз ишетелде. Димәк, өметне өзәргә ярамый. Җырыбыз исән әле».

Көндәлекләр мине дә шул көннәргә алып кайта. Илнең, системаның алышынган вакыты гына түгел, кеше башындагы фикерләүнең, акыл юнәлешенең дә алышынган вакыты дип әйтер идем. Әткәй аны бик авыр кичерде. Беркайчан да килешеп бетмәде. Бу халәттән Конфуцийның сүзләре искә төшә. «Халык ул ак кәгазь, нинди иероглиф язасың, шул булачак». Әткәй шуны аңласа да, ул хакыйкать белән аның акылы килешә алмый иде.

**Мостай әйткән:** «Иң саф, иң хәйләсез һәм мәкерсез кешеләрне тизрәк пычраталар. Ул мескеннәр ак күлмәк кебек кер күтәрмиләр».

21.09.93 «Ун көннән артык Мәскәүдә булып кайттым. Булатны Америкага озату буенча мәшәкатьләр килеп чыкты. Самолётка билетлар алу, виза эшләү мәсьәләсе дә четерекле булды. Мәскәүдәге иске танышлар ярдәм итте. Унҗидесендә көндезге бердә очып китте. Әлфия, Олег, Нәзифә, мин озатып калдык. Беренче тапкыр шундый аерылышу бит, кыен булды. 19ында шалтыратты. Алар дүртәү киткән иде. Университет кешесе аларны Нью-Йоркта аэропортта каршылаган. Шул ук көнне Бриджпортка килгәннәр. Урнашканнар. Бүлмәсеннән риза, ашау әйбәт булганын әйтте. Күңел тынычлана төште».

Мәскәүдә алар барысы да бездә туктадылар. Бу мәшәкатьләр, әткәйнең борчылулары минем күз алдымда булды. Тимербулатны алар Уфадан гына озатып җибәргәннәр иде. Ләкин виза белән шундый хәлнең килеп чыгуы әткәйне ике сәгать эчендә Мәскәүгә килеп җитәргә мәҗбүр итте.

Бу юлы әткәй истәлекләрендә минем исемне дә телгә алган.

## Флюра апа

Әткәй әнкәй белән очраша башлаганда, аларның гаиләсе турында әле берни дә белми. Бары тик аның ятим бала булуын, фатир хуҗасы Һәдия апаны Раузаның әтисе белән бертуганы дип кенә белә. Беркавым вакыт үткәннән соң Рауза аңа әти-әнисенең репрессиягә эләгүен, Себердә вафат булганнарын сөйли. Тагын дүрт туганының балалар йортында яшәүләрен әйтә. (Әнкәйнең Завакуан исемле энесе балалар йортларында йөри торгач, хәбәрсез югала. Менә шул энесен искә алганда, әнкәй һәрвакыт ачынып, шул баланы жәлләп елый иде.) Репрессия корбаннары арасында аның тагын бер туганы – Тәлига апа гаиләсе дә була. Аларның бердәнбер кызы Флюра да балалар йортына җибәрелгән, Рауза өчен югалган, адресы да билгеле булмый.

– Их, шул баланы табарга иде, ничек кенә булса да ярдәм итәргә иде, – ди Рауза.

– Әйдә, эзлибез, детдомнарга хатлар язабыз, – ди Мостафа.

Эзли торгач, алар Флюраны табып, балалар йорты директорына хат язалар. Ул хатта яшь шагыйрь Мостай Кәрим һәм аның кәләше Рауза, балалар йортындагы Флюра Енгалычеваның туганнары булуын язып, якын арада аның янына килергә җыенуларын белдерәләр. Баланы яклауны үтенеп, сәлам әйтергә кушалар.

Флюра апа Енгалычева бу турыда үзе болай дип сөйләгән иде: «Шул көннән соң балалар йортында миңа мөнәсәбәт гел икенчеләнде! Мине кыйнаулар бетте. Шул көннән соң беркем дә кыерсытмый башлады. Димәк, минем якларлык кешеләрем бар. Димәк, мин бу дөньяда тома ятим түгел икәнмен!»

Әткәй бу хакта:

– Флюра безнең язмышның талисманы булды. Чөнки Рауза белән эшләгән яхшы эшләрнең беренчесе Флюрадан башланды, – дип сөйләгән иде.

Флюра Енгалычеваның язмышы гаҗәеп катлаулы, шул ук вакытта искиткеч. Ул бик әйбәт кеше иде. Без аның гаиләсе белән гомер буе элемтәдә булдык, хат алыштык. Мин Флюра апа турында язмыйча булдыра алмыйм, чөнки ул безнең өчен иң кадерле кешеләрнең берсенә әверелде. Безнең аның белән күңелләр туры килә иде. Мин килен булып, Илгизләр гаиләсенә кергән беренче еллардан башлап, Флюра апа белән аралашып яшәдек. Ул Кемерово өлкәсенең Тайга дигән шәһәрендә киемнәр тегүче бер фабрикада башта тегүче булып эшләгән, соңыннан производство бүлеге мөдире итеп билгеләнгән. Тегүче булып эшләгәндә, «Социалистик Хезмәт Герое» дигән исемгә тәкъдим ителгән, ләкин шул арада аны җитәкче итеп куйганнар. Ә инде ул исем гади эшчеләргә генә бирелә дигән сылтау белән бирми калдырганнар. Флюра апага ул вакытта Ленин ордены тапшырганнар. Флюра апа ел саен үзе эшләгән комбинатның продукциясен сатарга килешүләр төзер өчен ВДНХда уза торган ярминкәгә килә иде. Ул һәрвакыт бездә туктала, атна-ун көн бездә яши иде. Килгән саен төрле киемнәр тегеп алып килә, безне сөендереп бүләк итә торган иде. Иң мөһиме: иң интегеп яшәгән 90нчы елларда Флюра апа безгә бәрәңге, тозлаган гөмбә, җиләк кайнатмалары җибәреп торды. Мәскәү белән Кемерово арасында йөри торган поезд Флюра апалар яшәгән Тайга шәһәре аша уза иде. Ул поездда проводница булып аның танышы эшли. Ул хәбәр итә, без поездны каршылап, күчтәнәчләрне барып алабыз. Мин аңа гомер буе рәхмәтле, аның изгелекләрен кайтара алдыммы икән, белмим. Ел саен Яңа елга Флюра ападан ямь-яшел пихта агачы, аның янында эрбет чикләвеге, кедр күркәсе килә иде. Ничә еллар дәвамында безнең балалар өчен яңа ел шулар белән истә калган.

Флюра апаның бердәнбер кызы Светлана Томск университетының беренче курсында ук, Одессадан килгән бер студент егеткә кияүгә чыгып, бәби тапты. Бала Флюра апа һәм аның ире Юрий гаиләсендә тәрбияләнде. Кыз балага Лилия дип исем куштылар. Нигә боларын да тәфсилләп язам, чөнки аның сәбәбе бар. Кияү Игорь – Одессада яшәгән әнисе Рәхилнең бердәнбер улы иде. Ул, университетны тәмамлаганнан соң, Светлана белән аерылышып, әнисе янына кайтты да китте. Еллар узгач, Светлана яңадан кияүгә чыкты, тагын ике бала тапты. Лилия Флюра апада яши, аны әни дип йөртә. Шулай итеп, 90нчы еллар да килеп җитте. Шул вакытта Игорь әнисе Рахил белән Израильгә китәргә ниятлиләр. Ләкин Россиядән чыгып киткәч, Австриянең Вена шәһәрендә Израильгә дигән ниятләрен үзгәртәләр дә туп-туры Америкага юнәләләр. Игорь христиан дин әһелләре әзерли торган җиргә укырга кереп, аны тәмамлап чыкканнан соң, чиркәүдә эшли башлый, әнисе Рәхилне христиан монастырена яшәргә урнаштыра. Игорь кабат беркайчан өйләнмәскә ант итә. Русча әйткәндә, «обет безбрачия» кабул итә.

Менә шул вакытта ул кызы барлыгын исенә төшерә. Бәлки ул аны уеннан да чыгармагандыр. Шунысы кызык: Флюра апа Игорьга да, аның әнисенә дә бик әйбәт мөнәсәбәттә иде. Алар хәбәрләшеп тордылар. Америкадан хатлар килеп торды. Бала әбисе янында үсте, мәктәп тәмамлады, инглиз курсларында укыды. Лилиягә инде 17 яшьләр тирәсе иде. Флюра апаның кияве Игорь аерылган хатыны Светланадан: «Синең тагы ике балаң бар,

җибәр минем янга Лилияне. Мин аны укытып кеше итәрмен», – дип үтенә. Гаиләдә киңәшеп, моңа ризалашалар. Ләкин ул бит күрше авыл гына түгел. Илчелек – Мәскәүдә, Флюра апалар – Себердә! Игорь ни өчендер чакыруны илчелеккә җибәрә. Хәтта ул вакытта Американың дәүләт секретаре булган Бейкердан кул куйдыру бәхетенә ирешә. Һәм ул чакыруны илчелектән мин барып алырга тиеш булдым.

Күз алдына китерегез. 90нчы еллар. Ачы көз. Илчелек ябык. Аның каршына бары тик тартмалар куелган, Америкага бару теләкләрен белдергән кешеләр документларын шул тартмага салырга тиеш. Мәчетләрдәге садака тартмасына охшаган тартмалар иде алар. Ә бит миңа эчкә кереп белешергә кирәк! Кая ул керү! Якын килерлек түгел. Минем сүзгә генә ышанмадылар, Флюра апа оныгы белән Мәскәүгә килеп җитте. Ләкин алар да бу хәлләрне күреп, берни дә эшли алмады, Тайгага кайтып китәргә мәҗбүр булды. Америкадан Игорь шалтырата. Ул да ышанмый. «Бейкер үзе кул куйды бит!» – ди. Без чарасыз. Берничек тә селкетеп булмый торган таш ятты бу мәсьәләгә.

Көннәрдән бер көнне Илгиз Язучылар берлегендәге бер җыелышта бу маҗараларны тәрҗемәчеләр бүлегендә әгъза булып торучы, инглиз теленнән тәрҗемәче Татьяна Кузнецовага сөйли. Ул ханым үзенең Америка илчесе Джон Метлок белән дус булуын әйтә, аңа әйтеп карармын ди. Дәүләт секретаре кул куйган документ турында сүз баргач, Метлок үзе дә шакката. Шулай итеп, йөри торгач, Лилиягә визаны алып бирдек! Хәтта 5 декабрьдә Америкага оча торган самолётка билет та юнәттек.

Шул көннәрдә безне Илгиз белән Югославиянең бәйсезлек көне уңаеннан илчелеккә кунакка чакырдылар. Мин анда мәдәният бүлеген җитәкләүче ханым белән таныш идем, хәтта аның өчен Татарстанга экскурсия дә оештырганым булды. Бар иде заманалар! Югославия дә бербөтен иде. Америка белән дә дус иде! Хәзер инде андый ил дә юк. Ул көнне бәйрәмдә Америка илчесе Джон Метлок та бар иде. Мине аның белән таныштырдылар, һәм мин аңа Лилиягә виза алып бирүдәге ярдәме өчен рәхмәт әйтеп, сеңлебез Америкага бишенче декабрьдә очарга тиеш дидем. Ул миңа: «Мин дә шул самолётта Нью-Йоркка очарга планлаштырам», – диде. Русча әйбәт кенә сөйләшә иде.

Флюра апа оныгын озатырга Мәскәүгә килде. Бер яктан, сөенсә дә, йөрәге өзелгәндер инде аның. Чөнки ул нечкә күңелле, ятимлекне үз җилкәсендә татыган, бала җанлы, бик игелекле кеше иде. Ләкин әтисе, әбисе янына китә бит, балага алай уңайрак булыр дип тә уйлагандыр. Ә үзе сабырлыкка өйрәнгән кеше.

Бу маҗаралар әле моның белән генә бетмәде. Флюра апа Яңа елга Тайгадан, аерым-аерым төреп, поезд белән өч пихта агачы җибәрде. Берсе безгә, калган икесе тәрҗемәче ханым белән Америка илчесе Метлок өчен.

Лилияне озаттык. Ул православие динендәге яһүди әбисе янына монастырьга урнашты. Шунда яшәүче рус аристократ вәкилләре белән танышкан. Шуларның берсе патша генералы Врангельның туганы булып чыга. Алар белән аралаша торгач, Лилиянең үз-үзен тотышында аристократлык чалымнары барлыкка килә. Берничә елдан соң кунакка кайтты ул. Сөйләшүе искиткеч мөкаммәл, тәртибе сабыр. Аның нинди тәрбия алганлыгын без дә күрдек. Тайгада иркә онык булса, биредә инде

Европача тәрбия алган үсмер кыз иде. Лилия безгә монастырь каршындагы зиратта Енгалычевлар фамилиясе куелган каберләр булуы турында да сөйләде. Димәк, алар нәселе Америкага күптән китеп урнашкан. Чөнки Флюра апалар дворяннар нәселеннән. Аның тәртибе, үз-үзен тотышы, искиткеч илгәзәклеге юктан гына барлыкка килмәгәндер инде. Нәсел тамырлары нык булган. Яңа кануннар туган нигезен таркатып җилгә очырса да.

Лилия Америкада көллият тәмамлады. Һәм укыганда ук чәчәк кибетенә эшкә урнашты. Кеше ышанмаслык хәлләр! Чәчәк кибетенең хуҗасы – данлыклы Лев Николаевич Толстойның оныкчыгы Татьяна Толстая булып чыга! Татьянаның дүрт баласы була. Олы уллары Иван Лилиягә тәкъдим ясый, алар өйләнешәләр. Аларның хәзер инде үсеп беткән ике уллары бар. Берничә ел элек Толстойлар нәселе «Ясная поляна»да очрашу үткәргәндә, Лилия дә гаиләсе белән шушы очрашуга кайткан иде. Менә шундый язмыш. Флюра апа бу якты дөньяда юк инде. Аның вафаты алдыннан Илгиз, Тайгага барып, аның хәлен белеп кайтты. Ул Илгизне бик ярата иде. Без дә Флюра апаны бик яраттык. Рухы шат булсын. Ул әткәй белән әнкәйнең талисманы булып кына калмады, авыр вакытларда безнең дә ярдәмчебез булды. Мәңге хәер-дога аңа.

## Тарихыңны уйлап чыгарма

17.01.83. (русчадан тәрҗемә.) «Бездә ниндидер сәламәт булмаган күренеш күзәтелә. Һәрбер милләт үзен башкалардан борынгырак итеп исбатларга, имеш, аларның цивилизациясе борынгының да борыныгысына барып тоташа дип дәлилләргә тырыша. Үзе белән күбрәк горурлана, башкаларга караганда, үзенә күбрәк соклана. Мин әле шул вакытны (сугышка кадәр) хәтерлим: без күбрәк дусларны мактый идек, алар белән горурлана идек. Әлбәттә, һәр халык үзенең тарихын яхшы белергә, үзен өйрәнергә, шуны расларга тиеш. Ләкин «үзеңнең тарихыңны» уйлап табу – бу инде мескенлектән килә, бу халыкны түбәнсетү була. Бу теләнчелек белән тәңгәлләшә. Әби-бабайларда булмаганны «безнеке!» дияргә ярамый. Әгәр дә халык гасырлар дәвамында яшәгән икән, үзен раслар өчен аның булганы да җитәрлек.

Шуны әйтим дим, Гёте 1830 елның 14 мартында шуңа бәйле болайрак фикер йөрткән, ул Эккерман язмаларында калган. Бөек язучының тугры секретаре менә нәрсә дип яза: «Гомумән, – дип дәвам итте ул (Гёте) – бу милли күралмаучанлык белән сәер генә нәрсәләр килеп чыга. Ул мәдәниятнең түбән баскычта торганнарыннан бигрәк тә ярсулы, көчле ишетелә. Шул ук вакытта күрше халыкның бәхетен, кайгысын үзенеке кебек кабул итүчеләр баскычы да бар. Мәдәниятнең бу баскычы минем күңелемә якын, һәм мин ул баскычта алтмыш яшем тулганчыга кадәр күп еллар элек ныклы басып тордым».

*(Ахыры киләсе санда.)*

*Тәнзилә Салих кызы Дәүләтбирдина 1964 елның 3 августында Башкортстанның Бөрҗән районы Иске Монасыйп авылында туган. Башкорт дәүләт университетының филология факультетын тәмамлаган. Озак еллар мәдәният, журналистика өлкәсендә, Башкортстан Урман хуҗалыгы министрлыгында эшләгән. Хәзер Башкортстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары булып тора. Шагыйрә, драматург, публицист. Сигез китап авторы. Аның пьесалары буенча спектакльләр М.Гафури исемендәге Башкорт дәүләт академия театры, А.Мөбарәков исемендәге Сибай башкорт дәүләт театры, Салават башкорт драма театры сәхнәләрендә уйнала.*



Тәнзилә
Дәүләтбирдина

# ЭЧӘР СУЛАР ТАГЫН ТАРТА

## Уфама

Алтын йөгертелгән сарайлардан
Өстен бит ул Уфа минем өчен.
Ул бит өмет, хыял белән тулы
Асыл яшьлегемне сагыну төсе!

Һәр урамы, һәрбер йорты таныш –
Тамырландым инде монда күптән.
Бәйрәмнәре үтсә туйдай гөрләп,
Яуган төсле була бәхет күктән!

...Балкып торган урамнардан узам,
Юкәләрнең бал исләрен сулап.
Җылы сүзләремне әйтер өчен
Куймасамчы димен, Уфам, соңлап!

Һич күрмимен туган авылым белән
Мин кадерле Уфам аермасын –
Беркайчан да димен, беркайчан да
Мине язмыш синнән аермасын.

Ал-ял белмим, тынгы белмим әле,
Калам буйлап киләм, очам гына!
...Әмма теләгем шул – мәле җиткәч,
Авылым тавы алсын кочагына...

## Туган йортта

Әткәем юк үзенең бүлмәсендә,
Әнкәй утырмый түр башында.
Яңа хуҗаларның йөзе ачык,
Тик түр башы үзгә шул монда.

Ышанасы килми югалтуга.
Аңлап булмый шуны берничек.
Истән чыкмый әти-әни белән
Утырулар бергә чәй эчеп.

Алар моннан бары киткәндер күк
Вакытлыча гына кунакка.
Тик аларны инде кайтыгыз дип
Эзләп барып булмый ул якка.

## Вахтада

Без вахтада. Җырда әйтелгәнчә,
Чәчкенәбез җиткән үрмәгә.
Ял-бәйрәмсез кемнәр эшләмәгән,
Себер михнәтләрен күрмәгән.

Көнне төнгә ялгап һәркемебез
Дөнья көтәр өчен мал таба.
Таш бәгырьле Себер камчысыннан
Канга кушылып татлы бал тама.

Алданып шул балга, тешен кысып,
Җигелеп эшли монда байтагы.
Өйдәгеләр генә имин торсын,
Балаларның туйсын тамагы.

...Буранбайлар салган юллар буйлап
Бу башкортка күпме үтәсе.
Урау юлны язмыш насыйп иткәч,
Эләкми шул аның тәбәсе.

Өйдәгеләр генә имин торсын,
Бирешмәбез без дә Себердә.
Себердә мал тапкан ирләр барда,
Морҗаларда төтен җилфердәр.

Тик без шунда чакта йортыбызның
Сүрелмәсме серле учагы?
...Юлга чыгам. Эшсез итмәм диеп,
Йончысаң да, ашсыз итмәм диеп,
Янә җәя Себер кочагын.

## Юлга чыкканда

Эчәр сулар тагын тарта:
Туган яктан аерылам.
Минем юллар чорнала да,
Уңга, сулга каерыла.

Хәлем барда, юлда йөреп,
Табанны, дим, туздырыйм.
Берәүләрне урап үтеп,
Берәүләрдән уздырыйм!

Могҗизалар тулы дөнья
Көн саен ишек ача.
Күңелемнең түрләренә
Биләүсә-бишек аса.

Ә ул сабый – Өмет үзе.
Өметләнәм изгелеккә!
Яхшылыкны, иминлекне
Ихлас теләр мизгел җиткән.

...Минем юллар сырмалана,
Уңга, сулга каерыла.
Җан дусларым янда кала,
Ясалмалар – аерыла.

## Железноводскида

Бу тәрәздән һаман карый кебек
Мөлдерәгән шагыйрь күзләре.
Йорт шул көе, тормыш кына башка,
Кала, урам беткән үзгәреп.

Бу йорт эргәсеннән үткән чакта
Мең-мең уйлар башта чуалды.
Чуалды да, мәрҗән күк өзелеп,
Ташка төшеп китеп уалды...

Уалмаган уем калыкты да
Җирнең куенына уелды:
...Шагыйрь сизмәгән бит үләчәген,
Уен итеп күргән дуэльны!

Соңгы көндә ул сөйләгән диләр
Язылачак әсәр хакында.
Ә бит Әҗәл каравыллап йөргән
Шул тирәдә генә, якында!

Ни көткәнен без дә аңламыйча,
Ашкынабыз ярсып, ашыгып!
...Һәркемнең дә гомере капыл өзелә,
Һәркемнең дә үзенең Машугы*.

## Шопен

Авыр эшләр башкарганда
Ярдәм итә Шопен.
Канатланып китәмен дә
Уйлап куям: «Шәпмен!»

Пианистның бармаклары
Гүя чәчә очкын.
Илаһи бу музыкадан
Китәсең күк очып!
Бар дөньяны кочып!

Дәрт тә бирә, көч тә бирә
Шопен язган көйләр.
Шул көйләрдә язылалар
Йөрәктәге җөйләр.

## Мин агачтыр

Мин агачтыр – сынган ботагымның
Урынына үсә яңа ботак.
Гел яңарып торырмындыр шулай,
Язмыш балталары торса ботап.

Мин үлгәч тә ауган урынымда
Тамырларым бирер үсентеләр.
Шундый уйдан гел дәртләнеп китәм,
Үз-үземә һаман үсү теләп!

**Рафис КОРБАН** *тәрҗемәләре.*

*Машук – Биштау каласында Машук тавы итәгендә бөек шагыйрь М.Ю.Лермонтов 1841 елның 15 июлендә Н.С.Мартынов белән дуэльдә һәлак булган.



*Рузалия Шакирова 1994 елда Әгерҗе районының Салагыш авылында туа. Әнисе сыман ул да укытучы һөнәрен сайлый, әмма ул, әнисеннән аермалы буларак, ана телебезне һәм әдәбиятыбызны түгел, ә инглиз телен укыта. Язу мәсьәләсенә килгәндә, ул үзен балачактан ук тезмә жанрда да, чәчмәсендә дә сынап килә. «Авылда бит кая карама матурлык, кая карама илһам – чыда гына! Беренче шигыремне энемә багышлап яздым. Җиде яшь иде миңа ул вакытта. Уку дәверендә «Көмеш кыңгырау», «Яңарыш» газеталарында балачак шигырьләрем басылды. 2019 елдан инде «олыларча» яза башладым. Абстракт нәрсәләрдән логик фикерләр табарга, мәгънә эзләргә яратам. Минемчә, кеше җанында әллә никадәр хикәя, хәзинә, зирәклек яшеренгән. Шуларны ачарга омтылам. Язу – минем өчен җан терапиясе кебек ул. Шигырьләремә исем бирергә яратмыйм», – ди Рузалия.*

Рузалия
Шакирова

# АП-АК КӨННӘР БЕЛӘН ЯШИМ...

***

Һәр кешенең үз сукмагы кабатланмас,
Балачактан коры, кара картлыккача.
Эчемдәге бала шалтырата уенчыгын һаман –
Шалтыравык тавышыннан картлык кача.

Уен эзләп, җир читенә китәр иде сабый.
Аңа бар да матур, бар да яңа.
Күнегүнең ни икәнен аңлый алмый, һәр көн
Ач күзләрен текәп карый киң дәрьяга.

Нәрсә эзлисең син, котылыр юл әллә
Иң беренче хатирәңнән – караңгыдан?
Оныгының бетмәс шуклыгына шаккаткандай,
Читтән, өстән, олыларча шуңа карап торам.

Беркайчан да килә күрмә, уйнап,
Күнү дигән тешсез җанвар оясына якын.
Канатлы бул, саңаклы бул, яраш, ярыш,
Калам димә канәгатьлек яссысына ятып!

Өлкән булып уйнап кына йөри ул галстуклар,
Бутафорик ул пинжәкләр, җыерылган кашлар,
Әйтерсең лә онытылган шалтыравык,
Без җитдиләр шундый, «просто кошмар!»

Тавышына җыеп, үскән балаларның,
Җибәралмый шәрә артлы, шар күз чагын;
Күкрәгемдә, сыйдырмасны сыйдырырга
Ашкынучы шалтыравык суга чаңын.

***

Тамчы ялый табаннарны, җилләр үбә
Битләремнән. Син дәшәсең сөеп.
Нәрсә өчен бирә, нинди хакка гына
Дөнья миңа бу ләззәтне өеп-өеп?

Яңгыр юа безне – ике сөеклесен –
Болыт иңә тәннәребез аша эчкә.
Ә кешеләр шундый үзышанган, кыю,
Ә күперләр – алар шундый нечкә...

Шул күперләр аша күрешәләр алар,
Белмиләр дә могҗизаның кануннарын.
Давылларның очрак итеп очраштыру,
Очрак итеп кире тартып алуларын.

Ә күперләр – алар шундый нечкә...
Бер уйлаудан ишелеп төшәр кебек.
Басып торам шул күпернең аръягында:
Син карыйсың миңа көлеп, сөеп.

***

Мең көл булып, Феникс коштай кабат,
Белеп, чиста дәрткә дөрләп әйләнәсем,
«Ни булса да, шул булыр» дип, даулап
Бәйләнәсең, бәйләнәсең, бәйләнәсең...
Коткаручы тапкан мескен мосафирдай
Чишмәләрем каршысына тезләнәсең.
Сусавыңны баскач, кыргый табигатем җирләреннән,
Яшь нараттай шытып чыгып төзләнәсең.
Төзәләсең, төзеләсең, түзаласың – һич шигем юк:
Корылыкка, кырыслыкка, корычлыкка.
Ачуланма, яме,
Урманнарым капкын белән тулылыкка!
Корал тоткан уяу аучылар да,
Сакчылар да – катыргыдан бар да.
Пәрәвезләр, җәтмәләрем үрелгәннәр һич хәйләсез.
Димен: «Бар да бер өр, бер үр, бер күр генә син!»
Көләм эчтән: чөнки моны инде, күптән, әллә кайчан,
Миңа кадәр хәтта төшенгәнсең.
Офыгымда хәтәрләнеп, давыл булып, янә әйләнәсең.
Бәйләнәсең, бәйләнәсең, бәйләнәсең...

***

Сүндер инде шул экранны, ачу китергечне!
Бу бит җитдилекне онытыр чак. Чак-чак.
Мин сөенәм. Мин бәхетле килер көннәр өчен.
Алар сине очратачак һәм кочачак.
Калдырып тор авыр төшләреңне читкә таба!
Сыгылмалылыгың кабыз! Онытканбыз:
Аңлашырга безгә җитә бер юл кую, күрү, сулыш,
Тәмле сүзле, елмаюлы, балавызлы авыз.
«Киләчәкне юрама!» – дип сораганың истә. Өстә
Май аеның нуры эреп тама иде безнең башка.
Фаразымның хәерлесе чынга ашкандыр дип өметләнәм.
Хәвефлесе булгандыр дип галәмдәге
бездән башка «без»ләр белән.
Мин ышанам (шундый, шундый итеп!)
Гомеремнең иң яхшысын сайлавыма!
Кайчак исем китә – авыртуның түгел,
Мескен-бөек яратуның борчу капкан
Йөрәгемә сыймавына гына.

Ап-ак көннәр белән яшим. Ап-ак көннәр
Көтә мине аккошлардай ярда.
Экран сүнгән. Тәрәз артым – җәйгә чумган.
Тик ике сүз эчтә сулык-сулык килә:
«Мин са-гы-нам!»

***

«Ошатамын сине!» – дисең. Әй егеткәй,
Кызуланма, зинһар, үтенәм!
Кемне ошатканың
төшенгәнсең бик тиз,
Күңелеңә әллә ут кергән?

Ыбыр-чыбыр сүзгә вәсвәсләнү
Көтмә, айны башта махмырдан.
«Бетте, үтте, мин үзгәрдем!» – диеп
Авызың ачма аннан ахырдан.

Ярату ул юктан бар булалмый,
Бардан кире юкка чыгалмый.
Бер яратып янган йөрәкнең дә
Тагын
Гашыйк булган, иләсләнгән чагы,
Сирәк, әмма, «юк» дигәндә, ул да,
Дөнья булгач, бар да булгалый.

«Ошатамын!» – дисең.
Ә кафеда кем соң ошатмаслык?
Нинди комачау?
Рәхәт сазлыгыннан бер чыгуга
Бар хасиятең чыгып качачак.

Ашкудиең авызыңда, кулда – каһвә
(Әллә шунда бурсык сөтеннән).
Тартсаң, бер тарт, давай, папиросың,
Җан ачытсын өргән төтеннән!

Орчык кебек ап-ак кулларыңны
Йотып ала эшчән учларым.
Ширбәтләүләр түгел,
Шул куллардан зуррак
Кул эзләргә дучар булганым
Беләсеңме?
«Ошый» шырпысыннан
Кабызырмын дисең? Китсана!
Кара, күпме матур кызлар йөри,
Ә мин – кыргый, ачы дәрмана[1]!

Мәркәз уртасында «бизнес-ланч»та
Кем дә ошар тулган корсакка.
Хет авылга кайтып килик, әйдә,
Авыл әйтер кемне ошата
Синең күзләр.
Ук(ы)тучыны түгел,
Фырт киенгән, сөрмә сылаган.
Ул кыз ирек тоеп үскән, җирнең суын
Ятып эчкән, моңын сулаган.

Илһам, гүзәллеккә тиенгән ул,
Алдатмаска яшьтән күнеккән.
Яралган ул уҗым орлыгыннан,
Бәетләрдән, җырчы тавыклардан,
Комнан, лайдан, мәнсез күбектән...

Киң басудай чиксез аның җаны,
Тамырлары буйлап Иж ага,
Чәчләрендә – яңа чапкан печән,
Кыңгыраулар чыңлый үзара
Күзләрендә. Кулга өйрәтелгән
Җәнлек ясый аннан бу шәһәр.
«Ошатамын», «ашатамын» диеп
Тормаса ул шул тик, шул кадәр,
Нишләр иде микән сагынудан
Сандугачның җәйге җырларын?
Мужикларын, тешсез малайларын,
Сары бәбкәләрен, тальянын?..

Аның өчен матай, балчык исе
Шанель-манельләрдән болайрак.
Өзелгәнен көтеп яту түгел,
Шыштыр-пыштыр,
Ботак сыгып, бот сыдырып,
Үзе менеп алу кулайрак.

Качма, күргәч аны сырган ыштан,
Каткан толып кигән килештән!
«Килешми!» – дип торма, бер авылча
Йомры итеп, төкереп сүгенсә!

Батса әгәр авыл фәлсәфәсе, китсә,
Шәһәр мәрте, мәртәт тупаю,
«Бизнес ланч»та гына гәп корырлык
Сүз табылыр, егет, «зуб даю!»

[1] Әремнең бер төре.

## Сау бул, җәй!

Сәер, җылы бу яз. Урам кертми өйгә.
Зөбәрҗәт күк кавыштыра ай-кояшны.
Чәчәкләрдә генә ниндидер шом.
Ниндидер моң сыза – тоясыңмы?

Коясыңмы эчкерсезлек элеккечә?
Элек – кичә генә иде. Әрни һаман
Ул кич. Кулдан җәй өстери алга,
Ә мин без хушлашкан язда калам.

Анда әл(е) дә исә ваемсызлык җиле.
Анда ул шом – бары чәчәк чыңы гына.
Битараф «хуш!» әле әйтелмәгән, әле –
Үтермәгән,
ут өрмәгән яшәү чыбыгыма.

Соңгы киче язның. Суырылып, сулып,
Ятим чәчәк булып,
җилдә башым кагам.
Җылы язның шомлы тәрәзәсен ачып,
Син яшәгән җәйгә таба үрелеп багам.

Калам. Бер сораса, әйтегезче:
«Ул – хушлашкан язда һаман!»

***

Җәһәннәмнең уты өтсен иде!
Кайтсын иде кире ару, талу!
Үтенәмен: уйлап чыгарыгыз
Аннан көчле агу.

Агу бетте эчтә. Акмыйм.
Акмы, карамы соң бу тамаша?
«Аша!» – диләр. Мин тук.
Мин туктадым.

Када, зинһар, миңа бер ук!
Тагын! «Агулы»ны. Шашам –
Ашым булгач ризык түгел, агу!
Нигә миңа ялган койрык тагу?

Язмагандыр аннан зуррак шатлык,
Андый иңрәү табу.
Җәһәннәмнең уты суык миңа.
Һәм уңайлы – табут...

***

Яшьлек кебек тансык нәрсә бар соң? Сөйлә, белсәң!
Без икәүне очраштырыр сәбәп тагын бармы шундый?
Син исәнме? Димәк, җырым әле өзелмәгән.
Бу җәйне мин яшьлегемә багышлыймдыр.

Яшькелт-сары август белән култыклашып,
Тып-тын урам буйлап өйгә кайтып барышымдыр.
Безне тоташтырган күпер – август күге генә хәзер.
Бу җәйне мин безгә багышлыймдыр.
Бәлки, юкка, керфекләрем манып күз яшенә,

Алтын көннәремне сагышлыймдыр...
Көннәремне, төннәремне түгел,
Бик теләп тә, синнән кайтаралмас күңелемне,
Шул бер бичараны, кызганмыйча,
Мин җавапсыз һаман сиңа багышлыймдыр.

Бар да яхшы. Барысы да – хәерлегә бу дөньяда.
Шулай диләр. Ә мин сине яратам һәм...
Нәрсә тагын? Бары шулдыр.
Онытуым үзем эзләп тапкан хисне –
Күтәралмас гөнаһ булыр.

Мин гомеремне җиде ят та, шулвакытта
Үземнән дә яхшы белгән танышымны –
Кыйммәтле таш-табышымны
Күзем чытырдатып кысып! (Югалтмаска!)
Истә тоту хакына дип багышлыймдыр.



Равилә
Шәйдуллина – Мурат

# ЧӘЧКӘ ТАҖЛАРЫНДА КҮЗ ЯШЕ

ХИКӘЯ

«Әйдә инде, Казанга бергә машинада кайтабыз», – дип озак үгетләделәр. «Юк, дуслар, мин озын юлны машинада йөрергә яратмыйм, поезд белән кайтам», – дип каршы төштем. Яратам мин тимер юлда сәяхәт итүне! Тәгәрмәчләрнең чуен юл буйлап бер көйгә генә җайлап, ритм белән тукылдавы ничектер җанга үзенә күрә бер төрле рәхәтлек бирә. Тук-тук, тук-тук. Ниһаять, Пенза тимер юл вокзалында өч сәгатьләп көткәннән соң, Казанга кайтасы поезд моңсу гына кычкыртып килеп туктады. Аллага шөкер, инде юлдашларым җүнле кешеләр булсын да, исән-имин Казаныма кайтып җитәргә язсын.

Юлда барганда, күршең адәм рәтле кеше булса, беркемгә сөйләмәгән сереңне рәхәтләнеп бүлешәсең, чөнки ул кеше белән соңыннан беркайчан да очрашмаячагыңны беләсең. Ләкин...

Мин купега килеп кергәндә, кечкенә өстәл янында утырган нәфис гәүдәле яшь кенә хатын калтырана-калтырана елый иде. Кыяр-кыймас кына:

– Здравствуйте! – дип исәнләштем дә чемоданымны ипләп кенә ятагым астына урнаштырдым. Сәламемә җавап булмады. Минем өстәге сәндерәдә сугыштан дәваланырга кайтып баручы егет ыңгырашып ята. Анысының теш казналары җимерелеп беткән, авызы тулы тимер. Дүртенче юлдашым күренми. Поезд әле ярты сәгатьләп торачак икән.

Җүләр дә инде син, машина белән кайтып киткән булсаң соң дип, үземне үзем битәрләп, тәрәзәдән перронга карап, үтеп-сүтеп йөрүчеләрне күзәтәм. Барысы да каядыр ашыга. Кемнәрдер якыннарын озата, кемдер каршы ала. Елашалар, кочаклашалар. Әнә бер егет, нәрсәдер эзләп, арыбире чабып йөри. Бигрәк ябык инде. Өстенә кигән киеме карачкыга элгән кебек җилферди. Бу ябык адәм ничектер Тукайның Шүрәлесенә охшап

тора. Күпмедер вакыттан соң каршымда утырган хатын елап шешенеп беткән йөзен күтәреп:

– Гафу итегез, здравствуйте, – дип исәнләште. Күңелемнән, менә сиңа мә, өч көннән соң «Исәнме, кодагый» дигән уй үтте.

– Здравствуйте, – дип һәм башка бер сүз әйтмичә, уңайсызланып туктап калды. Купеда авыр тынлык урнашты. Тик сәндерәдәге егетнең сызып-сызып ыңгырашканы гына ишетелә иде.

– Вам плохо, чем я могу вам помочь? – дип, урынымнан кузгалдым. Может воды подать?

– Жуук, – дидеме, әйткән сүзен аңларлык түгел иде. Татар егете бугай. Нигәдер миңа шулай тоелды.

– Может какое-нибудь лекарство нужно? У меня есть.

– Жуук, – диде егет, ыңгырашып.

Йә, Аллакаем, бу егет минем оныкларым белән бер яшьтә бит. Безне рәхәт яшәтер өчен гомерен куркыныч астына куеп, кулына корал алып, явыз дошманга каршы яуга чыккан бит бу бала! Кемнеңдер газиз улы, кемнеңдер сөйгән яры! Яраланып, әти-әнисе янына кайтып бара. Егет башын күтәрде дә, нәрсәдер сорап, миңа мөрәҗәгать итте.

«Апа! Бирегез әле», – дигәндәй, ишарәләп, стаканлы суга салып куйган соломкага төртеп күрсәтте.

– Хәзер, хәзер, улым, – дип, өстәл өстендәге суны алып, егеткә суздым. Һәм аның йөзен күреп имәнеп киттем. Авыз тирәсен җөйләп-җөйләп теккәннәр, ә берничә җирдән антенна сыман тимерләр тырпаеп тора. «Раббым, бер Аллам! Бу егеткә сабырлык бир. Исән-имин сәламәтләнсен иде», – дип, Аллаһка ялварам.

– Улым! Әйдә, син аска төшеп ят, ә мин синең урынга күчәм. Сиңа шулай уңайлырак булыр.

– Жуук, – ди егет, суын соломка аша суырып. Авызы бөтенләй ачылмый икән. Ничек ашый икән соң бу бала? Үзәкләрем өзелеп, елаганымны күрмәсеннәр дип, тәрәзәгә таба борылам. Яңакларымны пешереп, күз яшьләре ага. Каһәр төшкән сугыш. Адәм балалары сугышмый тора алмыймы икәнни? Әле Бөек Ватан сугышы тәмамланганга да күпме генә вакыт үтте. Фронтовик әти сугыш турында сөйләргә яратмый иде. «Балалар, без күргәнне сезгә күрергә язмасын», – дип, сүзен тәмамлый иде. Инде менә безнең балалар, оныклар сугыш кырында харап була! Ил язмышы ирләр кулында шул.

Тиздән кузгалып китәчәгебезне хәбәр иттеләр. Дүртенче юлдашыбыз күренми, гәрчә урын-җире җәелгән булса да. Димәк, керергә тиеш. Поезд инде кузгалып китә дип торганда теге «Шүрәленең» тиз генә сикереп, вагонга менгәне күренде. Димәк, перронда чабулап йөрүче бу ябык адәм дә безнең купеда дип уйлап өлгермәдем, тирләп-пешеп, ябык йөзендә тир тамчылары җемелдәп тәгәрәшкән егет килеп керде. Көчкә сулыш алып, «Здравствуйте! – дип исәнләште дә гафу үтенгән сыман: – Еле успел», – дип куйды.

Каршымдагы ханым күзләрен тәрәзәгә төбәгән, ләкин күренеп тора, берни күрми. Әйтерсең йөрәгеннән ташып чыккан хәсрәт уты янып, суларга һава да калмаган. Тынлыктан арып, йөрәктәге җепләр чыңлап, зеңгелдәп өзелергә тора. Ичмасам, поезды да кузгалып китми, тәгәрмәчләрнең чуен юлга бәреп тукылдаган тавышыннан җанга азрак җиңеллек иңәр иде.

– Сезнең янга утырырга ярыймы? – дип, миңа мөрәҗәгать итте дүртенче юлдашыбыз. Кыяфәтенә караганда чувашмы, мари егетенәме охшаган иде ул.

– Рәхим итегез, – дип, тәрәзә янына таба елыша төштем. Күңелемнән тагын, машинада гына киткән булсаң, инде ярты юлны узган идек бит дип, үземне шелтәләп алдым. Кичә төн буе бер су заводының 110 еллык бәйрәмендә катнашып, тәмам арыган идем. Хуҗалар безне шундый зурлап кунак итте. Күңелгә матур хатирәләр төяп, Казанга кайтып барыш, үзем белән Әмирхан Еникинең сайланма әсәрләреннән бер томын алдым, исәбем классигыбызның җаннарны җылыта торган повесть-хикәяләрен күңелдә яңарту иде. Тик кая ул! Әйтерсең лә юлдашларымның йөрәгеннән актарылып чыккан җан әрнеше, хәсрәт, үзәкләрен өзгән авырту бергә укмашкан да, сулыш ала алмаслык һавага әйләнеп, өстемә ишелеп төшкән.

Поезд акрын гына тукылдап кузгалып китте. Аллага шөкер! Ниһаять, юлга чыктык. Тик ул хәсрәт, бәла, поездны да узып, алга чаба, күрәсең. Җанга тынычлык иңмәде.

– Апа! – ди теге «Шүрәле». – Таныш булыйк, минем исемем Иван, – дип, саф татар телендә миңа дәште.

– Сез татармыни? – дидем гаҗәпләнеп, исемемне әйттем.

– Юк, чуваш егете мин. Сугыштан кайтып киләм, – диде Иван, никтер авыр сулап.

Шунда йөрәгемне сызып, син дә инде бу егет турында Тукайның «Шүрәле»се кебек дип уйлап гөнаһка баттың. Ул бит синең кебек кунактан түгел, сугыштан кайтып килә.

«Үзең син, Шүрәле!» дидем, үземне-үзем битәрләп.

– Татарча әйбәт сөйләшәсең? Кайдан шулай матур итеп сөйләшергә өйрәндең?

– Врач мин, апа. Бер ел татар районында эшләдем. Аннан соң, безнең телләр охшаш бит, төрки телләр. Безнең Канашта татар телен бик күп кеше белә.

– Иван! Мин инде сине ярты сәгатьләп күзәттем. Перронда нидер эзләп, чабулап йөрисең. Берәр кеше белән очрашасың бар идеме?

– Юук! – дип сузды дүртенче юлдашым. – Минем инде бер ел буе гаиләмне күргәнем юк. Шундый сагындым үзләрен. Кызыма җиде, улыма биш яшь тулды. Үскәннәрдер инде, тәмам калкынганнардыр.

– Иван! Сугышка үзең теләп киттеңме?

– Әйе, илгә куркыныч янаганда, нинди җан белән түзеп ятмак кирәк, апа, әйтегез әле шуны? Мин инде Сүриядә дә булдым.

Җанымны, бар вөҗүдемне яндырып, «мондый халыкны җиңеп буламыни?» дигән уй үтте!

– Мин чыгып киткәндә, – дип, янә сүз башлады юлдашым, – хатыным күкрәгемә капланып: «Китмә, Иван, калдырма безне!» – дип елап калды. Ә балаларым, Нина белән Николай аякларыма сарылганнар да: «Папа, папочка, не оставляй нас!» – дип үксепме-үксиләр. Әни, йөрәген тотып, урынга ятып калды. Озатырга вокзалга да бара алмады. Хушлашканда, хатыныма әйттем: «Надя! Ышан миңа! Мин сиңа исән-сау әйләнеп кайтырга вәгъдә бирәм. Өйдә яратып көтәр кешең булганда, үләргә ярыймыни, җаным?! Бигрәк тә улым белән кызым көткәндә. Көт! Кайтырмын! Җиңү яулап һәм бер кочак чәчәкләр гөлләмәсе күтәреп, күкрәгемә орден-медальләр тагып кайтырмын» – дип, хатынымны, балаларымны кочагыма алып шашып-шашып үптем.

Апа, безне өйдә дә, мәктәптә дә Ватанны сакларга, якларга өйрәттеләр. Илеңә куркыныч килгәндә, ничек качып ятарга мөмкин? Әйтегез әле, яшәүмени ул? Андый кеше бер түгел, мең үлә бит ул.

Киткәндә эти дә: «Синең бит бабаң да 18 яшендә үк фронтка китеп, сугышның башыннан ахырына хәтле сугышып, Берлинны яулаган кеше!» – диде. Ничек инде мин бабама хыянәт итим! Кайтасыма ышандым мин, апа. Миңа ядрә дә тияргә тиеш түгел иде. Дрон да мине читләтеп үтте. Чөнки мин – алгы сызыкта, фронтта яраланучыларга беренче ярдәмне күрсәтүче доктор. Димәк, бу дөньяга мине Бог не просто так послал, – дип русчага күчте Иван. – Вәгъдәмне үтәдем, мин коткарган солдатлар хисапсыз, менә күрегез, – дип, өстенә элгән курткасының төймәләрен ычкындырды да, эчтән тагылган орден-медальләрен күрсәтте. Күкрәгенә тагылган медальләр чыңлап куйдылар. – Мактанып, бүләкләрен тагып кайтып килә димәсеннәр өчен, өстән куртка киеп куйдым. Ничектер уңайсыз...

– Син нәрсә, Иван, син нәрсә? – дидем, күземә яшьләр җыелып. Никтер минем бу егетне кочып аласым, аналарча: «Рәхмәт сиңа, улым, җаным», – дип, күзләреннән, битләреннән үбәсем килеп китте.

– Бу сугыш дигән афәт килеп чыккач, үзләренең мескен гомерләрен саклап, күпме тар җанлы ирләребез биштәрләрен асып, илдән чыгып качтылар. Кайтачаклар алар. Тынычлык иңгәч, кайтачаклар. Кайтып, тагын кайсыдыр бер җылы почмакка кереп оялаячаклар. Керемле урынга, тыныч урынга. Без әзерләгән тыныч урынга!

– Син, Иван, салып ат бу өстеңә элгән курткаңны. Күрсеннәр! Синең өчен горурлансыннар! Күкрәгеңне киереп, орден-медальләреңне чыңлатып кайт Канашыңа!

– Апа! Минем тик бер үкенечем калды. Надяга, хатыныма диюем, бер кочак чәчәк бәйләме күтәреп кайтам дип вәгъдә биргән идем. Беркайда да чәчкә сатмыйлар. Перронда чәчәк эзләп йөрдем мин, тик таба алмадым.

Ваняның күзләрендәге мөлдерәмә сагыш, менә-менә күз яшьләренә әйләнеп түгелер сыман.

– Иван, тиздән тагын тукталыш була. Поезд кырык минут торачак диделәр. Мин дә синең белән төшәм. Икебез ике яктан эзләрбез, табарбыз, Алла бирсә, табарбыз. Надяңа биргән вәгъдәңне үтәрсең.

– Рәхмәт, апа! Мин гаиләм янында ун көн булам да янә сугышка китәм. Мине анда дусларым, яралыларым көтә.

Менә поезд йөрешен акрынайтты да перронга якынлашты. Күрәм, елап, шешенеп беткән теге ханым да торып басты.

– Минем исемем Карина. Сезнең белән мин дә чәчәк эзләргә төшәм.

– Рәхмәт Сезгә!

Поезд туктады. Өчебез өч якка йөгердек. Мин инде перроннан чыгып китеп, зур кибетләр тирәсен дә әйләндем. Тик... Ник бер чәчкә сатучы булсын. Каршыма килгән кешеләрдән сорап карыйм. Юк, чәчәк сата торган кибетләр үзәктә генә диләр. Поезд кузгалырга биш минут кала, янып-пешеп вагон янына килеп җиттек.

– Бу егет тукталыш саен чабулап йөри иде. Инде өчәүләшеп чабышалар, – дип, безне сүгеп атты проводница. Купега кергәч, азрак хәл-әхвәл алдык та, әйдәгез, чәй эчеп алыйк дип, Кувакада әзерләп җибәрелгән күчтәнәчләрне өстәлгә тездем. Проводница стаканнарны челтәрләп эшләнгән подстаканникларга куеп чәй, каһвә кертте.

Ә өстәге татар егете, безнең ашаганны күрмәс өчен, купе стенасына карап, әйләнеп ятты.

– Улым, син нәрсә ашый аласың соң? – дип соравыма кулыма кечкенә генә кәгазь пакет тоттырды.

– Аңладым. Хәзер проводницадан савыт сорап алам да ризыгыңны әзерләп бирәм. Ашап-эчеп алгач, Иван үзенең сәндерәсенә менеп китте.

– Хәзер миңа югары күтәрелергә җиңел, – диде, елмаеп. – Ашказаным бик үк сау түгел минем. Фронтта җәрәхәте ачылды. Үзегез беләсез, анда ашау-эчү, консервалар һәм шуның ише миңа ашарга ярамый торган ризыклар. Егерме бер килога ябыктым. Бог даст, өйдә вылечусь, – дип, русча өстәп куйды.

Өстәге сәндерәдә ятучы татар егете дә тамагын туйдырды. Исеме Җәлил икән. Ыңгырашуыннан бераз туктап торды.

– Апа, рәхмәт! – дигән сүзен көчкә аңладым.

Каршымда утыручы чибәр ханымның, Каринаның исә үз хәсрәте.

– Әтием кичә Казанга, сеңлемне туган көне белән котларга киткән иде. Бүген иртән уянсалар, үлгән. Йөрәге туктаган. Аңа нибары 58 яшь иде. Аңлыйсызмы? Әни белән шундый матур итеп, рәхәтләнеп, зур фатирларында икесе яшәп яталар иде. Үткән ел әнине исерек шофёр таптатып үтерде. Бер зур хуҗа малае, наркоман. Сигез ай да үтмәде, әтием дә китеп барды. Уйламаганда, көтмәгәндә бит ул. Шифаханәгә дә барып карамаган сәламәт кеше. Бик авыр миңа, – дип, тагын үксеп елап җибәрде Карина.

– Елама, Карина, аның гомере шулай кыска булган. Адәм баласының бу

дөньяны ташлап китәчәге ана карынында ук язылып куела. Казанга барып вафат булмаган булса, бу хәл башка җирдә булыр иде. Аннан соң, алар әниең белән пар аккошлар кебек яшәгәннәр, ә аккош парын югалтса, озак яши алмый ул. Тынычландыра торган дару эчеп җибәр.

– Дару алмаган идем шул. Вакыт тыгыз булды. Онытылган.

– Хәзер, хәзер. Без өлкән кешеләрнең үзләре белән даруханә йөри! – дип, Каринага тынычландыра торган төймә сузам. Барысы да арып-талып, ял итеп алырга ятакларына аудылар.

Купедан чыгып, ап-ак пәрдәләр эленгән тәрәзә каршына бастым. Поезд урман эченнән бара. Нарат урманы. Гаскәр кебек тезелешеп йөзьяшәр агачлар безне озата баралар. Аллага шөкер. Тынычлык. Бомбалар да төшми, туплар да атмый. Ләгънәт төшкән беспилотниклар да җирнең җанын яралап шартламыйлар. Әйтерсең сугыш, кан-коешлар бездән бик еракта. Алар бу җиргә килмәс кебек. Килмәсен иде инде.

Безнең купеда баручы чуваш егете Ванялар, татар егете Җәлилләр булганда илебез тыныч яшәр. Балаларыбыз исән-сау булыр. Шулай булсын. Йа Раббым, үзең сакла! Солдатларыбыз әти-әниләре, сөйгән ярлары, балалары янына әйләнеп кайтсыннар иде.

Чаба поезд. Ашыга-ашыга тәгәрмәчләр тукылдый. Тук-тук, тук-тук. Кая шулай ашыгасың? Безнең әле чәчкәләр аласы бар. Ә син каядыр ашыгасың да ашыгасың....

Канашка җитәргә кырык минут вакыт калды. Нибары кырык минут. Ә Ваня хатыны Надяга бүләк итәсе чәчкәне таба алмады. Җан әрни. Егет купе диварына таба борылган да бер сүз дә дәшмичә ята. Надясына биргән вәгъдәсен үтәп, дошманны җиңеп, күкрәген орден-медальләр белән бизәп, иленә кайтып килә. Тик чәчкәләр генә юк.

Мин дә күңелем кителеп, купедан чыгып киттем дә проводница янына килеп:

– Зинһар өчен, әйтегез әле, Канашта поезд ничә минут торачак? – дип сорадым.

– Ярты сәгать. Тагын өчәүләшеп кая булса да чыгып чабасыгыз бармы?

– Әйе, чәчкәләр кирәк иде. Таба алмыйбыз.

– Эшегез беткән икән.

Башымнан яшен тизлегендә бер уй үтте. Доставка! Үзләре китереп бирә торган хезмәт бар бит! Тиз арада улыма-кызыма, кияү-киленемә, Казанга шалтыратам. Алмыйлар. Алыгыз инде, зинһар өчен, алыгыз. Миңа чәчкәләр кирәк. Юк, алмыйлар. Әллә поездда телефон тотмый микән? Йөрәк дөп-дөп тибә. Минем бит Ваняга булышасым килә, ә тәгәрмәчләр тукылдыйлар да тукылдыйлар, минем өчен бик кадерле булган минутларны саныйлар. Бер минут, ун минут. Кинәт мин өзелеп көткән телефон тавышы яңгырады. Киленем икән.

– Әни, исән генә кайтып киләсеңме? Сине Булат каршы алачак.

Исәнләшеп тә тормадым.

– Эльмира! Син хәзер үк чәчкәләргә заказ бир әле. Канашка, тагын 30 минуттан поезд килеп туктаячак. Поезд һәм вагон номерын хәбәр итәм.

Трубкада тынлык.

– Әни, берни аңламадым.

– Эльмира, кызым! Кайткач аңлатырмын. Кыйммәтле булсын чәчәкләр. Биш мең, ун мең, бәясеннән торма! Зинһар өчен тизрәк, тизрәк, бик кирәк.

– Әни, вакыт бик аз калды, җитешерменме икән?

– Ә син җитеш!

Ваняга бу турыда әйтеп тормадым. Әллә килеп җитә, әллә юк. Юкка өметләндермим егетне. Менә Канашка якынлашабыз. Тәгәрмәчләр акрынрак тукылдый. Тук-тук, тук-тук. Кайнарланып йөрәк тибә. Дөп-дөп-дөп. Телефон дәшми, җан әрни. Булыша алмадың... булыша алмадың... Ник бу уй алданрак башка килмәде? Ваняга әйберләрен җыярга булышабыз. Әнә Карина егеткә биштәрен кигезә. Өстәге сәндерәдән акрын гына Җәлил төште. Кочаклаштылар. Егет авызыннан «Кош, кош!» – дигән авазлар чыкты. Җәлил елый иде.

Поезд туктады. Ваняга сумкасын күтәрешеп төшмәкче булам. Ул тәрәзәдән үзләренекен танып: «Барысы да килгәннәр, әти-әни, Надюша һәм балалар», – дип сөенә.

Мин дә, Ваняның якыннарын күрергә теләп, тәрәзәгә күз салсам, бер кочак чәчкә күтәреп, озын аяклы бер егет җилләрне уздырып чаба!

– Ваня, тукта, төшми тор, – дип, перронга чыгам.

Китерүчедән чәчкәләрне алам. Кул куярга куша. Фамилиямне әйтәм. Вакыт юк.

Рәхмәт әйтеп, атылып вагонга кереп, чәчкәләрне егеткә сузам. Бер кочак чәчәкләр! Алар шул кадәрле күп һәм шундый матурлар. Чәчкә таҗлары янып тора. Ваня үз күзләренә үзе ышанмыйча:

– Это мне? – дип, мине чәчәкләрем белән бергә кочып ала һәм елый. Уңайсызланып, кеше күрмәсен дип, орден-медальләрен курткасы астына яшергән егет, беркемнән оялмыйча калтырана-калтырана елый. Чәчкә таҗларына чык тамчылары кебек батыр ир-егетнең күз яшьләре тама. Чәчкәләр дә аңа кушылып елый: әллә шушы мизгелдәге шатлыктан, әллә илгә килгән кайгыдан.

Вагоннан Ваняны Карина белән икәүләп озата төштек. Җәлил, купе тәрәзәсеннән карап, кул изәп калды. Ваня кулында бары тик гөлләмә генә иде. Әнә ул зифа буйлы хатыны, әти-әнисе кочагына атылды. Улы белән кызы тезләреннән кочтылар. Ир белән хатынның кочагында Ваня вәгъдә иткән орден-медальләр һәм гөлләмә уртасындагы зәңгәр кыңгыраулар тыйнак кына чыңлап куйдылар.

# ИНЕШЛӘРЕБЕЗ МУЛ СУЛЫ БУЛСЫН

## Башкортстандагы татар әдәбиятыннан бер сәхифә

Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе тарафыннан уздырылган (2023) татар телендәге әдәби әсәрләр конкурсында Башкортстанда яшәп иҗат итүче каләмдәшләребез дә актив катнашып, арадан өчесе төрле номинацияләрдә призлы урынны алучылар арасына керде. Мәкаләдә әлеге авторларның әсәрләренә күзәтү ясап, аларның поэтик эзләнүләрен, яшәеш мәсьәләләрен чагылдыру үзенчәлекләрен, һәрберсенә хас әдәби дөньяның бер читен ачу омтылышы ясала.

Бәйгенең «Роман» номинациясендә җиңеп чыккан Әлфис Гаязовны укучылар шагыйрь һәм драматург буларак белә. Уфада һәм Казанда «Казанчы каеннары» (1999), «Мин бәләкәй бит әле» (2014), «Бәхет догасы» (2018) шигырь җыентыклары басылып чыга. ТР Мәдәният министрлыгы һәм Театр әһелләре берлеге үткәргән «Яңа татар пьесасы» конкурсларында берничә тапкыр призлы урынны яулый.

Ә.Гаязовның «Кайсы яктан чыга соң бу кояш?» романында якындагы тарих – XX гасыр башында Пермь төбәгендәге өч мәчете, дүрт меңләп төрле милләт кешеләре яшәгән Казанлы авылында инкыйлаблар һәм Гражданнар сугышы чорында булган вакыйгалар сурәтләнә. Аерым кешеләр язмышына бәйле, аларга бу төбәк тарихына, Беренче бөтендөнья һәм Рус-япон сугышына бәйле хәлләр, еракларда килгән риваятьләр, хикәятләр, әкиятләр, халыкның шул чордагы көнкүреше, төрле йола-бәйрәмнәре, җыр-уеннары кушылып китә. Төп сюжет сызыгы Казанлыда туып үсеп, «Галия» мәдрәсәсендә белем алган Ильяс Муллаяров эш-гамәлләренә бәйле үстерелә. Беренче бөтендөнья сугышында яраланып, хәзер инде туган ягына поездда кайтканда, егет Казан мөселман социалистлар Комитеты әгъзасы Камил Якупов белән очраша һәм бу аның киләчәк тормышын тамырдан үзгәртеп ташлый. Алга таба укып белем алу нияте белән Казанга туктала һәм социалист-большевиклар белән аралашып, якынаеп китә. Сугыш вакытында дөньяга карашы җитди үзгәрешләр кичергән Ильяс, большевиклар идеясен яклау юлына баса һәм, партиягә кабул ителеп, үз төбәгенә марксистик идеяләрне таратуны оештыручы буларак җибәрелә.

Романда халыкның төрле катламнарының инкыйлабларга мөнәсәбәтен ачуга киң урын бирелә. Билгеле булганча, Беренче бөтендөнья сугышындагы унышсызлыклар, халыкның ачлыктан, социаль тигезсезлектән, җирсезлектән интегүе һ.б. сәбәпләргә бәйле Россиядә баш күтәрүләр, демонстрацияләр башлана. Шундый шартларда патша властьтан баш тарта, ил белән Вакытлы хөкүмәт идарә итә башлый. Әлеге хәбәрләр үзәктән ерактагы Пермь төбәгенә дә килеп җитә, анда да буталышлар башланып, власть булмаудан һәркем үзенчә файдалана. Ильяс Казанлы авылында сөргендә яшәгән социалист Я.Никонов ярдәме белән гади халыкны җир, ирек мәсьәләсе тирәсенә тупланырга өнди. Заман үзгәрешләрен тоемлап яшәүче Мөхәммәтҗан Фазылов һәм уллары исә меньшевикларны яклый, ахырда мал-мөлкәтне акчага әйләндерү фикеренә киләләр. Төбәкнең атаклы промышленнигы Матусов байлыгының бер өлешен чит илгә

чыгарса, икенчесен, тыныч заман киләсенә өмет итеп, су төбенә яшерә. Старшина Ибраһим Хаҗиев исә, илдәге башбаштаклыктан файдаланып, башкаларның байлыгын тартып алу фикеренә килә, шул юлда шактый эш-гамәл кылырга өлгерә. Урта хәлле крестьян Ризван әлеге шау-шулардан читтә калырга теләп, «миңа тимәгез, мин дә сезгә тимим» дигән караштa тора. Автор руханилар катламын да читләтеп үтми. Әхмәтгали хәзрәт икеләнеп калса да, халыкны сабырлыкка, иманны сакларга өнди. Ул дин әһелләрен бердәм булырга, килешенеп эшләргә чакыра, шулай да яңа властьны кабул итми, ак гвардиячеләргә кушыла. Сафа мулла халыкны көч кулланып, корал ярдәмендә тәртипкә китерү фикерендә тора. Төрле карашлар җитди бәхәсләргә китерсә дә, сайлау алдына куелгач, халык ике лагерьга бүленә, тартыш көчәя барып, аклар һәм кызыллар каршылыгына, партизаннар белән ак гвардия отрядлары сугышына үсә.

Чор вакыйгаларын үткәннәр белән бәйләп бару әсәрне укырга кызыклы итә, укучыга да бай мәгълүмат бирә. Пермь төбәге, Бөре өязенә төрле милләт кешеләре килеп урнашу, Казанлы мәдрәсәсендә Гали Чокрый кебек танылган мәгърифәтче әдип укуы, бу төбәктә шәркыять белгече Г.С.Саблуковның яшәве кебек тарихи мәгълүматларга татарларда таралу алган аждаһа турындагы легенда, Аккошлар тавы турындагы риваять, Зөһрә һәм Гали турындагы әкият, шулай ук өмә үткәрү күренешләре, кичке җыеннарда башкарыла торган җырлар, биюләр, такмак әйтешүләр килеп кушылу – барысы да төбәкнең тарихи-мәдәни тормышын күзалларга мөмкинлек бирә. Ә инде элекке старшина Гаязетдин белән лекарь булып эшләүче Прохорның Рус-япон сугышын үтеп кайтуы, Беренче бөтендөнья сугышына бәйле вакыйгалар, аларда Ильяс һәм Сафаның, шулай ук офицерлар сыйфатында Дедухиннарның, Салихның тартылуы, танылган социалист Г.Плехановның фикердәше, патша властена каршы чыккан өчен сөргендә яшәүче Я.К.Никонов язмышы һ.б. бу авылны бөтен ил тарихына бәйли.

Совет хөкүмәтенең Җир турында декреты чыгу, авылда мал-мөлкәтне яңадан бүлешүгә китерә. Шул шартларда авыл икегә бүленеп, үзара дошман отрядлар оештыру башлана. Романда Ильяс һәм Шакир оештырган партизаннар белән Хәмит, Степан кебек авыл байлары оештырган Дедухин җитәкчелегендәге отряд һәм аларга килеп кушылган штабс-капитан Салих Җиһаншинның акгвардиячеләре арасындагы сугыш вакыйгаларына шактый урын бирелә. Канлы бәрелеш партизаннар җиңүе белән тәмамлана, Ильяс хатынын һәм яңа туган баласын Сафа кулыннан тартып алуга ирешә. Шулай да әле сугыш-тартышның алга таба да дәвам итәчәге искәртелә.

Романдагы вакыйгаларны Ильяс Муллаяров образы бергә туплап тора. Мәдрәсә белеме алган егет Беренче бөтендөнья сугышы фронтларын кичеп чыга, авыр яраларыннан дәвалану озакка сузыла. Фронтта рус һәм немец армиясендәге солдатларның «туганлашу» күренеше, офицерларның кансызлыгы, большевик агитаторлар чыгышларын тыңлау һ.б. аның караш-фикерләрен үстерә. Акылы, белеме белән башкалардан аерылып торган Ильяс икеләнүсез гади халык мәнфәгатен яклауга килә, оста оештыручы булып таныла. Халык җыенында старшина итеп сайлануы да шуны күрсәтә. Партизаннар белән сугыш хәрәкәтләрендә катнашканда, хатынын урлаган Сафа мулланы эзәрлекләгәндә, Ильяс ныклык, салкын акыл, ихтыяр көче күрсәтә.

Әсәрдә промышленник Данила Матусов – уңышлы эшләнгән, үз йөзе белән аерылып торган образларның берсе. Автор аның тормышын, Кавказ якларыннан килүен, оста эшмәкәр булып танылуын шактый тулы ача. Күп телләр белүче бу кеше гадел булуы, һәр эшен алдан уйлап башкаруы, киләчәкне сиземләве белән аерылып тора. Шул ук вакытта аның борчулары, күңелендәге каршылыклар да психологик яссылыкта уңышлы бирелә. Ул яшь вакытта әти-әнисенә, туганнарына хыянәт итүен дә онытa алмый, шуңа да тынычлыгы юк, үзен бәхетсез хис итә. Зур байлыкка ия булса да, хатынын, кызларын югалта, ахыр чиктә ул корган дөнья җимерелә.

Әсәрдәге мулла Сафа образы яңа герой буларак кабул ителә. Дини белемгә ия булып,

үзен Алла юлында дип санаган бу бәндә бөтен каршылыкны көч белән хәл итү яклы. «Коралланырга кирәк, һәрбер бәләкәй генә ялгышлыкка да наган аша җәзасын бирергә кирәк» дип саный ул. Үзенең әхлаксыз эш-гамәлләрен дә Коръәннән алынган фикерләр белән дәлилләргә тырыша. Власть алышынган вакытта, үзенең отрядын оештырып, турыдан-туры талау белән шөгыльләнә башлый. Ә инде аның акгвардиячеләргә кушылып китүе, гаделлек эзләүче булмыйча, киресенчә, үз мәнфәгатен генә кайгыртып, башбаштаклык-анархияне яклавын күрсәтә.

Романдагы иң гыйбрәтле образларның берсе булып Ризван тора. Ул гаять уңган-булган, тырыш, максатчан кеше буларак ачыла. Үз тырышлыгы белән тормышын алып баручы Ризван һәрнәрсәне, һәркемне килештерү, тигезләү позициясендә торып эш итә. Ул төрле социаль катлау кешеләренә бердәй тигез мөнәсәбәттә. Берничә урында аның табигать белән тыгыз бәйләнештә булуы искәртелә, шуның белән автор аның күңеле сафлыгын, табигать белән уртак тел табып яшәвен ассызыклый. Җәмгыятьтә катаклизмнар вакытында, билгеле инде, Ризван корган идиллик дөнья саклана алмый. Вакыйгалар барышында яңа хакимияткә икмәк тапшыруда зур ярдәм итсә, чакыргач, качу мөмкинлеге булса да, аклар армиясенә кушылып китә. Кылычка кылыч килеп чәкәләшкәндә, урталыкта калып булмый шул. «Үз юлын эзләгән, беркемгә дә, беркайчан да буйсынмаган шәхес» ике арада калып, ике якка да ярарга теләве белән үзен-үзе һәлак итә.

Каршы як вәкилләре арасында штабс-капитан Салих Җиһаншин үзенчәлекле образ буларак ачыла. Татар авылында үсеп, патша армиясендә үзен табучы офицерлар күп булмый. Салих – шуларның бер вәкиле. Вакыйгаларда ул үзен булдыклы итеп күрсәтергә теләп тә максатына ирешә алмаган, шунлыктан бөтен дөньясына ачулы кеше итеп бирелә. Туган туфрагыннан аерылган бу бәндә иманын югалткан, үз авылында да әхлаксызлык, кансызлык үрнәге күрсәтеп йөри: партизан Мирон белән социалист Никоновны аттыра, Сәрияне көчли. Автор Салихның үз хәленә бәя бирә алуын да искәртә, кансызлана баруының сәбәпләре турында да уйлана ул, әмма таба гына алмый. Аның сәбәбе исә шактый өстә ята: патша армиясендә аз санлы милләт вәкиленә танылу, үсү өчен икеләтә көч түгәргә туры килгән. Шуның өстенә Салих һәрдаим үзенә түбәнсетеп карауларын сизеп яши. Күңелендәге ачуны ул әнә шулай көчсез кешеләрне җәберләп чыгара.

Романда яшь геройлар күп булып, аларның вакыйгаларга катнашуы мәхәббәт тарихлары белән үрелеп бара. Д.Матусовның кече кызы Маша белән авыл егете Миша арасындагы мәхәббәт тарихы саф хисләрнең тормыштагы социаль каршылыкларга бәрелеп юкка чыгуы кебек бирелә. Мишаның үткенлеге, башбирмәслеге, Машаның һәртөрле киртәне җимереп үтәргә әзер ташкын хисләре, матур сурәтләрдә ачылып, фаҗигалелеге белән тетрәндерә. Авыл бае Степан кызы Нина һәм Гәрәй яратышуы да беренче күренешләрдә үк каршылыгы, татар-рус мөнәсәбәтләренә килеп чыгуы белән игътибарны җәлеп итә. Гәрәйнең кызны яратуы, хис-кичерешләре байлыгы турында кат-кат әйтелсә дә, алар кыз белән мөнәсәбәттә, бәйләнештә ачылмый. Шулай да әлеге мәхәббәт тарихлары әсәргә романтик рух өсти, шәхси һәм социаль-иҗтимагый мәсьәләләрнең катлаулы йомгагын тудыра.

Романда җыр-музыка дөньясы да читтә калмый. Д.Матусов үзенең кызларына музыкаль белем бирүгә ирешә. Байның кече кызы Аннаның Ф.Шопен көйләрен уйнавы, шуңа бәйле музыканың, моңның сихри көче турында уйланулар әйбәт тәэсир калдыра. Ә инде халыкчан җыр-моңның татар халкының аерылмас юлдашы булуы әсәр дәвамында чагылыш таба. Фронттан кайткан Ильяс сөйгәне Сәлимәне көткәндә дә күңеле моң белән тула, автор аны гашыйк егетнең хисләре, белән уңышлы кушып бирә. Нәгыймә өендәге каз өмәсе вакытында башкарылган җырлар да халыкның күңел чишмәсе байлыгын ачуга хезмәт итә. Тау-урман арасына качкан партизаннар да җыр-моң аша күңелләренә тынычлык таба. Японнарга каршы сугышта катнашкан

Гаязетдиннең җыры турында автор болай яза: «Гаязетдин җырында аның башыннан үткән язмыш борылышлары да, булган шатлык-көенечләре дә, алдагы тормышка булган ышанычлары да – бар да бар иде...»

Романдагы вакыйгалар яңа җәмгыять өчен көрәшүчеләрнең җиңеп чыгуы белән тәмамлана. Автор хәл-күренешләргә бәя бирү юлыннан китми, ул аларны сәнгать алымнары белән сурәтли, ә калганы укучы өлеше. Әсәр Прологында булачак вакыйгаларга ишарә ителә. Беренче бөтендөнья сугышы һәм шуңа ялганып киткән Февраль, Октябрь инкыйлаблары, Гражданнар сугышы чын мәгънәсендә Россиягә афәт алып килә. Әлеге мәхшәр илдәге эчке сугышка китерә – халык, икегә бүленеп, канлы көрәшкә тартыла. Ике якка да бары кан-яшь, михнәт һәм күп бәла-каза китергән бу тартышны туктатырлык көч тә булмый. Җиһанны караңгылык баса, халык гасырлар дәвамында инанып килгән кыйбласын югалта: «Кайсы яктан чыга соң бу кояш?» Романдагы вакыйгаларда әлеге караңгылыкны үтеп чыгу, дөрес кыйбланы табу юллары эзләнә. Җиңеп чыгучылар ул юлны таптык дип ышанып, яңа тормыш төзи башлый. Эпилогта автор аны түбәндәге сурәт-символ аша чагылдыра: «Менә шул ертык болытлар арасыннан инде кояш та башта күренеп калгалады, аннан бөтенләй ачылып китте. Күк гөмбәзен ташлап узып киткән болытлар артында дөнья яктыга күмелде, кояш җылысы тамчыларны уятты, алар, боз сөңгеләре буйлап йөгереп төшеп, кышның соңгы көннәрен саный да башладылар.

Кояш һәрвакыттагыча үзенең гомер бакый йөргән юлында, тиешле урынында, үз ягында иде».

Шуның белән бергә, роман билгеле бер кимчелекләрдән дә азат түгел. Ул бик күләмле, бу исә күренешләрнең көпшәклегенә китерә. Әсәрнең эчтәлеккә, геройлар характерына яңалык бирми торган өлешләрен кыскарту сорала (мисал өчен, Ризванның гаиләсе белән күрше авылга яңа йортны карарга баруы бернинди яңалык алып килми; рекрутларны озату вакытындагы җырлар-такмакларның озынга китүе һ.б.). Язучының тел-стиле дә сораулар уята. Кытыршы җөмләләр, урынсыз кабатлаулар күп, сүз-сурәт балкышы җитми, кытыршы тел вакыйга-күренешләрне кабул итүне авырайта, кызыксынуны киметә.

Текстта ачыкланып бетмәгән фикерләр, күренешләр дә бар. Әйтик, Фазылов уллары Нигъмәтҗан белән Шаһимәрданның фирка әгъзалары каршында чыгыш ясаганда яңгыраган төрле саннар һәм фактларның кайдан алынуы ачыкланмый. Автор үзендәге мәгълүматны көчләп геройларыннан әйттерә дигән фикер туа. Икенче урында Гаязетдин болай ди: «Кырылышның нигезе хөррияттә түгел, милек бүлешүдә. Тик тиз генә аңлый алмабыз әле моны без! Кызганыч!» – ди. Ә үзе ничек аңлаган? Автор бу кешенең әлеге җитди фикергә ничек килүен аңлатмыйча гына көчләп үз сүзләрен әйттерә. Тагын бер мисал. Гәрәй Аннаның уйнавына бәя бирә: «Бармаклары сөяксездер аның, шул тиклем тиз дә, җитез дә уйный, шайтан». Болай дип әйтү өчен кызның уйнаганын якыннан карап торырга кирәк бит, ә егетнең бу йортка керә алуы яисә кергән булуы турында сүз юк.

Кайбер образларның эшләнешенә дә игътибар сорала. Бу, беренче чиратта, Ильяска карый. Төп образ буларак төрле яклап ачу омтылышы ясалса да, аның эш-гамәлләре гомуми планда бирелә, үзенчәлекле характеры белән аерылып торган көчле, олпат геройга үсми. Казанда аңа большевистик идеяләрне тарату, халык арасында эшләү бурычы йөкләнсә дә, эш-гамәлләрендә бу ачылмый. Асылда Ильяс вакыйгалар агышыннан, характер сыйфатларыннан түгел, бәлки автор теләге белән хәрәкәт итүче образ булып кала. Элекке старшина Ибраһимның корткычлык эшләренә байтак урын бирелсә дә, Матусовка дошманлыгы, эшләрен таркату сәбәбе ачылмый кала. Сафа образына бәйле психологик анализ да җитми. Әдәп-әхлак таратырга тиешле мулланың ачыктан-ачык җинаять юлына басу сәбәпләре, уй-фикерләре, теләкләре үзгәрү шартлары укучыга билгесез кала.

Әсәр исеме турында да уйланасы бар. Исемгә бөтен вакыйга-күренешләрне күз алдына бастырырлык итеп гомумиләштерү таләбе куела. Югарыда китерелгән өзектән күренгәнчә, «кояш (...) үз ягында иде». Димәк, «Кайсы яктан чыга соң бу кояш?» дигән атама әлеге бурычны үтәми. Татар өчен кояшның кайсы яктан чыгуыннан бигрәк, кыйбланың кайсы якта булуын белү мөһимрәк бит әле. Пролог белән Эпилог турында да уйланасы бар. Табигать күренеше шактый уңышлы бирелсә дә, ике каенның берсен яшен сугу, козгынның исе кимичә утыруы кебек детальләрнең вазифасы аңлашылып бетми. Китап булып басылып чыкканчы, язучы текстка билгеле бер үзгәрешләр кертер дигән теләктә калам.

Шулай да роман бар, ул укыла, соңгы вакытта татар әдәбиятында аз чагылыш тапкан тарихи вакыйгаларга мөрәҗәгать итүе белән җәлеп итә. Автор күп санлы геройларны, аларның эш-гамәлләрен, хәтердә калырлык хәл-күренешләр аша, тарих сәхифәләре буларак күз алдына бастыра. Реалистик сурәтлелеккә нигезләнгән вакыйгаларның романтик алымнар белән үрелеп баруы, гыйбрәтле әдәби детальләр, символик образ-сурәтләр белән баетылуы белән әсәр алдагы традицияләрне дәвам итүен күрсәтә.

***

Башкортстандагы татар шигъриятенең бер вәкиле булган Мөнир Вафин исеме әдәби җәмәгатьчелеккә яхшы таныш. Аның Уфа һәм Казан нәшриятларында басылып чыккан «Сүзләр чәчтем» (2001), «Дөнья – куласа» (2004), «Йөрәгем парәләре» (2007), «Тынлык моңы» (2011), «Мактанчык Гата» (2011), «Гомерем сәйләннәре» (2019) шигырь җыентыклары үз укучысын табып, тәнкыйтьтә югары бәя алды. Әдипнең «Уф-ф-ф» дип аталган шигырьләр шәлкеме конкурсның «Шигърият» номинациясендә икенче урынга лаек була. Ул тәкъдим иткән әсәрләрдә сөю-яратуның төрле төсмерләре, табигать сурәтләре, әрнү белән сугарылган гражданлык лирикасы, яшәеш кыйммәтләре, тормыш мәгънәсе турындагы уйлануларны үз эченә алган фәлсәфи үрнәкләр чагылыш тапкан. Тынгысыз авторның самимилек, борчылу, әрнү белән тулы уй-фикерләре, хис-кичерешләре укучыны җәлеп итә, үзеннән җибәрми.

Шагыйрь, көндәлек тормышта күргән-кичергәннәренә бәйле хисләрен шигъри формага салып, укучысы белән җитди сөйләшү алып бара. Традицияләргә таянган хәлдә, классиклар иҗатына да мөрәҗәгать итә. Шуңа да Тукай, Такташ, Туфан авазлары фикердә, сүз-сурәттә, образларда чагылып китә. Ул һәрнәрсәне йөрәге аша үткәреп яза, шуңа да әсәрләрен үзенең һәм халкының бүгенгесен үзгәртә алмауга бәйле үкенүле, ачынулы пафос иңләп үтә.

Бик күп язмышлар шикелле М.Вафинның лирик герое да авыл белән шәһәр арасында яши. Үткәненнән аерыла алмаган кебек, бүгенгесеннән дә китә алмый ул. Шуңа да бала чагын, әти-әниле йортны сагынып юана. Ул дәвер күңелен чистарта, пакьләндерә торган ак төсләре белән (әнисенең ак яулыгы, ап-ак чәче, ак кыш, ак көн һ.б.) күңелендә саклана. Балачагы калган авыл табигый матурлыкны, рухи байлыкны саклау урыны да бит (Карлар яву – күңел баю, / Тиң иде алар җырга»), хәзер инде шәһәрдә яуган кар аны күңелсез нәтиҗәләргә китерә: «Үзем дә үзгәрә барам / Шәһәр карлары кебек» («Бала чакта саф...»)

Аның милләт язмышы турында уйланулары илдәге, ике республикадагы сәяси күренешләр, милли мәсьәләдәге гаделсезлекләр, аяныч киләчәкне сиземләүдән гаҗиз калу буларак чагылыш таба. «Тукайга зарлану» шигырендә үз җирендә килмешәк хәлендә калдырылган лирик геройның әрнүле авазы йә халык шагыйренә хас усал тәнкыйть, йә сыкрану булып яңгырый:

Ата-бабам туган җирдә
Мин дә синдәй яралганмын.
Әмма ләкин үз җиремдә
Килмешәк дип аталамын.

Шигъри публицистика үрнәген тәшкил иткән шигырьләрендә автор милләттәшләрендәге битарафлыкка, күндәмлеккә борчыла. Узган җанисәп уңаеннан язылган «Мескенлек»тә хәзерге халәтебезне корбан сарыкларына тиңли, бүгенге белән, тән рәхәтенә омтылып кына яшәүнең ачы нәтиҗәләрен ачып сала:

Болай да бит безгә әйбәт, – диләр, –
Дөнья иркенлеген күр санә.
Иртәгесе көнне уйлыйсы юк,
Көтүчеләр юлны күрсәтә.

Шагыйрьнең «Атлыйм да борылам» дүртьюллыгы, М.Гафуриның борчылу хисләре белән тулы «Үзем һәм халкым» шигыренә аваздаш булып, аңа яңа гасырдан җавап буларак яңгырый. Классик шигырь өмет хисләре белән сугарылса, М.Вафин милләттәшләребезнең рухи йомшаклыгына, башкалар йогынтысына тиз бирелүенә, нәтиҗәдә ил буйлап сибелеп таркалуына, катнаш никахларга кереп, башка милләтләрнең санын арттыруына борчыла: «Тарала, карала, чит булып ярала... / Сүз көчсез. Гаҗиздән ни әйтим?..» Халыкның милли үзаңын уяту юлын автор җитди мәсьәләләр турында ачыктан-ачык сөйләшүдә, хакыйкатьне халыкка җиткерүдә күрә. «Ә телебез бер почмакта / Соңгы сулышында...» булган вакытта җитәкчеләребездән берсе әйткән «Без булдырабыз» шигаренең яраклашу һәм мактану төсмере алуын да билгеләп үтә («Тик хөррият сорар өчен, / Әлбәттә, котыбыз оча»).

Милли мәсьәләдәге югалтуларны җитәкчеләргә генә кайтарып калдыру һич тә дөрес булмас. Билгеле хакыйкать, җитәкче үз халкыннан узып беркая бара алмый. Шагыйрь үзе, әйләнәсе турында уйлана һәм, халык телендәге «илдә чыпчык үлми» дигән әйтемне метафора итеп кулланып, мондый фикергә килә:

Илдә чыпчык үлми диләр,
Шуңа яшибез әле.
Телләребез дә йолкынган,
Шуңа дәшмибез әле.

Кайчандыр бабаларның бөркет булган хәлен дә искәртеп үтә дә, аның кайтмаячагын, буш хыял белән яшәвебезне ачык әйтеп, сискәндереп җибәрә һәм үзиронияненң матур үрнәген бирә: «Чыпчык бөркеткә әйләнер / Чакларны көтеп ятам». Шигырь исеме дә милләтнең бүгенге яшәешенә төгәл бәя булып яңгырый – «ЧЫПЧЫКЛЫК».

М.Вафинның мәхәббәт шигырьләре яңача яңгырашы, хәтердә калырдай сурәтләр белән игътибарны җәлеп итә. Мәхәббәтне югалтуны атылган йолдыз белән чагыштыру мәңгелек аерылышу ачысын ача: «Шуннан башны салачакмын, / Кочагыңа атылып...» Чын сөю бар һәм ул мәңгелек дип саный шагыйрь һәм икенче дөньяда сөйгәне белән очрашуны өмет иткән гашыйк җан хисләрен гиперболик төсмерләрдә бирә:

Барлык уем синең хакта булыр,
Мин анда да зарыгып көтәрмен.
Бакыйлыкта җан сөйгәнем белән
Очрашулар өмет итәрмен.
(«Мин китмәмен якты дөньядан»)

Актив тормыш белән яшәүче шагыйрь яшәештәге социаль-әхлакый мәсьәләләрне дә читләтеп үтми. «Җәйдә калам» шигырендә гаять үтемле, тәэсирле итеп җәмгыятьтә әдәп-әхлак төшенчәләренең кыйммәте югалу, асылда «Абый, мин оялам» дип, оятсызлыкның чигенә җитү турында уйлана. Кешенең асылын билгеләгән тышкы һәм эчке матурлык мәсьәләсе дә җитди үзгәреш кичереп, әби-бабай яшәү рәвеше искелек дип бәяләнә башлады. Шул ук вакытта чит илләрдән үрнәк алу, төрле субкультураларга ияру күренешләре арту, төрлечә пропагандалану борчу уята. Шагыйрь фикеренчә, аларның күбесе тышкы матурлыкның сатылуы, шуның белән акча эшләү юлларын табу белән бәйле. «Шундый сылу» шигыре герое үзе мисалында укучыга гыйбрәт көзгесе куя:

Авызында сыра исе,
Иренендә тәмәке.
Тышкы ялтырауга кызыгып
Килеп каптым әднәке...

Сыкрану, сызлану пафосы иңләп үткән «Кайтты...» әсәре җан әрнүе булып яңгырый. Беркемгә кирәге булмаган сугышның иң кадерле кешеләрне алып китүенә рәнҗеш, аны башлаучыларга каргыш хисе булып калка:

Тәки кайтты. Кайгы, елаш
Салып халык бәгыренә.
Барча авыл чират торып
Балчык салды кабренә...

М.Вафинның фәлсәфи эчтәлекле шигырьләре яшәеш мәгънәсе турында уйлану белән сугарылган. Лирик герой, бүгенгесеннән торып, үткәненә мөрәҗәгать итә, картлык белән яшьлекне капма-каршылыкта бәяли. Табигатьтәге көз гомер көзе турындагы уйлануга алып килә: «Яшем – көздә, күңел – язда, / Ни кылыйм соң шул чакта?!» («Көзге шигырь») Кояш образына мөрәҗәгать итмәгән шагыйрь сирәк булып, аның күптөрле мәгънәләре ачыла. М.Вафин беркемне дә кабатламыйча, яңа сурәт тудыра: «Кояш та бит җылылыкка мохтаҗ». Мәңгелек энергия чыганагы җанландырыла да Кеше затының чикләнмәгән мөмкинлекләренә ишарә итә, шуның белән автор кешелеккә хезмәт итү идеясен калкытып куя:

Кояш та бит җылылыкка мохтаҗ,
Үз утымны аңа тамыздым.
Сүнеп барган күмер кисәгедәй,
Өрә-өрә аны кабыздым.

Бүгенге тынгысыз заманда, ул шигъриятнең бурычы итеп яхшылык, матурлык идеалларын яклау һәм саклауны билгели. Кешене Галәмнең уртасына куеп, яшәеш кыйммәтләре турында сүз алып барган Х.Туфан, С.Хәким, Р.Фәйзуллин, Р.Харис, Зөлфәт, М.Әгъләм һ.б. дәвам итеп, шагыйрь әлеге затка эндәшә: «Якты эшләр башкар, әй, Кешем!»

Шул рәвешле, татар поэзиясенең матур традицияләрен дәвам итеп, М.Вафин күңелендәге хис-кичереш байлыгы белән уртаклаша, яшәеш кыйммәтләрен чагылдыруның яңадан-яңа юлларын, алымнарын эзли. Аның шигърияте лиризм һәм фәлсәфилек синтезы булып тора, публицистик рух белән сугарылган әсәрләре кеше яшәеше һәм милләт язмышына барып тоташа. Нинди генә тема-мотивны алга чыгарып язса да, хис-кичереш халәте артында кеше заты турында уйлану, аның бүгенгесен һәм иртәгәсен яхшырак итү теләге калкып чыга.

***

Конкурсның «Балалар өчен хикәя» номинациясендә җиңеп чыккан Фатыйма Гыйльметдинованы укучылар «Казан утлары» журналында басылып чыккан хикәяләре аша белә. Уфа матбугатында аның шигырь-хикәяләре басылып килә, ул мәктәп укучылары өчен «Мәктәбем, укытучым» исемле җыентык та чыгара.

«Саташулы көннәр» хикәясендә вакыйга Зиннур исемле 4 сыйныф укучысы тарафыннан сөйләнә. Автор үзенчәлекле композиция төзи: беренче күренештә үк дәрескә соңга калучы малайның күңел халәте төгәл, ышандыра торган штрихлар аша бирелә һәм алга таба аның белән булган хәлләрнең сәбәпләре ачыла бара. Малайның өч көн инде үзе генә өйдә булуы, әтисенең озакка командировкага китүе, әнисенең ашыгыч рәвештә авылдагы картинәсе янына китеп баруы билгеле була. Анимация персонажы «Зин» белән төрле виртуаль уеннар белән мавыгучы Зиннур төне буе елап чыккан икән. Сәбәбе: ике хулиган акчасын һәм телефонын талап алган. Чынбарлыктагы

җитди каршылык малайга көчле тәэсир итә һәм ул, үзенең ялгызлыгын, уйлары белән уртаклашучы булмавын аңлап, бик борчыла. Автор Зиннурның уйлары белән бүгенгесен янәшә куеп, рухи дөньясын, шул исәптән кызыксынуларын, теләк-омтылышларын, әти-әнисенә, әбисенә мөнәсәбәтен тирәнрәк ача бара һәм шуларда аның әхлакый-психологик портреты тудырыла.

Зиннурны борчулы-куркулы халәттән чыгаручы – яңа партадашы Газинур. Беренче күрешүдән башлап үз булып киткән малай белән бик тиз уртак тел таба һәм моңа кадәр тыелып килгән җаны «бәйдән» ычкына. Иң мөһиме – ул үзенең табигый хәленә кайта һәм әлеге өч көндә булган хәлләргә бәя бирә башлый.

Мобилизациягә эләгеп, сугышка җибәрелгән физкультура укытучысы Фәрит абыйлары, әтисе тимер табутта кайтарылган классташы Артурның елавы, ике хулиганның үзен кыйнавы белән бәйле вакыйгаларны хәтерендә яңарта. Бала акылы белән ике «сугыш»ны янәшә куя: «Монда да «сугыш». Ил белән ил арасында да сугышлар шулай юктан да килеп чыга микән? Менә ул ике этрәккә ни җитми соң? Урам тармы?» Әлеге җитди, иҗтимагый яңгырашлы сорауга ул җавап таба алырлык яшьтә түгел әле. Әмма күңелендә үзгәреш башлана, үз-үзенә ышанычы арта бара. Газинурның янәшәдә булуы тагы да көч бирә.

Хикәянең тагын бер үзенчәлеге булып чынбарлык вакыйгаларының малайдагы саташулы халәт белән үрелеп баруы тора. Әтисен шундый сагына ки, дустының йөз чалымнарында аны күрә, хәтта аяк атлауларын да охшата. Боларга Газинурны өйләренә кунарга алып кайтуы, бергәләп ашарга әзерләүләре һ.б. кушылып китә. ...Һәм көтмәгәндә бу хәлләрнең төш булуы ачыклана. Алай гына да түгел, төш күрүе дә төш кенә икән...

Ниһаять, саташулы халәттән арынган Зиннур әнисенең телефоныннан мәгълүматлар укый башлый һәм, үзе әйткәнчә, «берничә яшькә олыгаеп киткәндәй булды». Хикәянең соңгы өлешендә аның белән булган хәлләр ачыклана төшә. Зиннур саташулы хәлендә булганда әтисе авыр яралардан үлем белән тартышып яткан икән. Малай, билгеле, икесенең дә бер төрле саташулы хәлдә булуларын аңлый да, аңлата да алмый. Әмма ул хәзер үзенең ир-егет булуын, якыннары өчен җаваплылыгын аңлауга килә: «Барысы да яхшы булыр, (...) тик сугыш кына туктасын...»

Шул рәвешле, хикәя үзенең психологизмы белән уңышлы. Автор 11 яшьлек малайның саташулы-уяулы халәтен күз алдына бастырып, аның рухи дөньясын ача. Үзе генә калу, кыйналу, яңа дус табу кебек күренешләрдә Зиннурның балалыктан чыгуы, көчек сораудан алып, әти-әнисе, картинәсе өчен җаваплы булуын тоюга кадәр үсүе сурәтләнә. Балалар өчен язылган хикәядә әхлакый, социаль, фәлсәфи башлангычлар үзара кушылып, гуманизм идеясе алга чыга. Шуның белән ул зурлар аудиториясенә дә йөз тота.

Ф.Гыйльметдинованың «Зумерлар һәм бумерлар» дип аталган скетчы «Кыска драма әсәрләре, скетчлар» номинациясендә өченче урынны яулап ала. Бу урында шуны да искәртеп үтик: балалар өчен заманча скетчлар иҗат итүчеләр күп түгел. Аңлашылганча, мондый әсәрләргә кыска һәм мәгънәле, бала психологиясен белеп язылган булу кебек таләпләр куела. Конкурста бу номинациягә шактый гына әсәрләр килсә дә, призлы урынга лаек дип бары Ф.Гыйльметдинова скетчы сайлап алынган.

Автор совет мәктәбендә бик популяр булган «тимурчылар» дигән хәрәкәтнең эчтәлеге хәзерге укучылар тарафыннан капма-каршы якка үзгәртелүен көлеп тасвирлый. Тимурчылык өлкәннәргә ярдәм итү, төрлечә булышуны алга куя, шуның белән ике буын вәкилләре аралашып, балаларда өлкәннәргә хөрмәт, шулай ук ярдәмчеллек, миһербанлылык кебек сыйфатлар тәрбияләүгә хезмәт итә. Хәзерге җәмгыятьтә исә укучы балалар аны үзләрен таныту, мактану, башкаларның игътибарын җәлеп итү максатында файдалана. Изге гамәл кылуның башкаларга күрсәтү өчен түгел, бәлки чын күңелдән башкарылганда гына үзен аклавын балаларга ата-аналар

да, укытучылар да аңлатмый икән. Автор бу хәлнең бөтен уку-укыту системасына үтеп керүен искәртеп, шактый усал чеметеп ала.

Мәктәп укучылары тормышыннан алынган күренешләрдә ике буын – зумерлар һәм бумерлар – арасында каршылык тудырыла. Бу төшенчәләрнең скетч исеменә чыгарылуы да уңышлы. Вакыйга барышында яшь буын вәкилләре кулланган төрле сленглар аларның үзләрен үк бәяләүгә хезмәт итә. Заман «зумерлары», ягъни сленг белән сөйләшкән булып, мода буенча гына киенә торган балалар өлкән буынны «бумерлар», ягъни чынбарлыктан артта калучылар дип атыйлар. Сәхнәдә күренгән дүрт укучы да роботлар кебек берүк сүзләрне кабатлыйлар, бер төрле эш-гамәл кылалар. Ул исә «тимурчылар» буларак ярдәм итү имитациясе ясауга, «хайп», ягъни ясалма шау-шу тудыруга кайтып кала.

Скетчның мөһим үзенчәлеге шунда: әби заман белән бергә атлаучы итеп сурәтләнә. Ул укучылар ялганын тиз тотып ала, алар уенын дәвам итеп, үзләрен фотога төшергән булып кылана. Алай гына да түгел, укучылар керәчәк башка әбиләрне дә кисәтергә өлгерә. Скетчта бу хәлләрнең нәтиҗәсе күрсәтелми, һәм ул кирәк тә түгел: әлеге укучылар, буш фотоаппарат белән кайтып, үзләре үк көлкегә калачагы һәркемгә аңлашыла.

Шулай да әлеге вакыйганың охшаш варианты «Ералаш»та урын алуы тәэсирлелекне киметә. Аннары тексттагы сленгларны тамашачыларның бер өлеше аңламаска мөмкин, ул вакытта эчтәлек тулысынча аңлашылмаячак. Әби дә аңлап бетерми бит, шуңа да ачыклык кертүче диалоглар өстәү сорала кебек. Гомумән, заманча, гыйбрәтле һәм әйбәт тел белән язылган, тәнкыйди эчтәлекле скетч тәкъдим ителә.

Шул рәвешле, әдәби әсәрләр конкурсы һәм җиңүче әсәрләрнең «Казан утлары» журналында басылып чыгуы Россия төбәкләрендә, шул исәптән Башкортстандагы татар әдәбиятының аерым үрнәкләре белән киң катлам укучыларны таныштыру мөмкинлеге бирә. Татар телендәге әдәбият – ул бербөтен. Инешләрдән мул сулы елга барлыкка килгән кебек, төрле төбәкләрдә иҗат ителгән әсәрләр дә аны баета, төрләндерә һәм әдәби сурәтләрдә чынбарлыкның төрле төсмерләрен укучыларга җиткерүгә хезмәт итә.

**Әлфәт ЗАКИРҖАНОВ,**
*филология фәннәре докторы,*
*ТР ФА Г.Ибраһимов исем. ТӘһСИның бүлек мөдире.*

# ИКЕ ДАҺИГА – БЕР РИВАЯТЬ

## Тукай – Дәрдемәнд

*«Шагыйрьләрнең язмышлары уртак –*
*бай булса да, гидай булса да».*
Газинур Морат

XX гасыр башы татар дөньясына, аның әдәбиятына фикер төрлелеге, бәхәс һәм иҗат иреге алып килде. Азатлык, хөррият җилләре һәм төрлечә карашлар сыешуы мәдәни үткәнебезне, хәзергебезне киңрәк җирлектә һәм яңача бәяләргә, элек тирәндәрәк яткан яисә олы сәясәт таләпләренә җавап бирми дип табылган хәзинәләрне, матурлыкларны яңача аңлатырга мөмкинлек бирде. Шул чорның шигърияте – сәяси-иҗтимагый үзгәрешләрне чагылдыруда, сүз-сурәт яңачалыгы, жанрлар төрлелеге җәһәтеннән гаҗәеп бер күренеш. Һәркайсы кабатланмас талант ияләре, милли җанлы Ш.Бабич, М.Гафури, С.Рәмиев, Н.Думави, С.Сүнчәләй, М.Укмасый, аеруча Тукай белән Дәрдемәнд теләсә кайсы әдәбиятны бизәрлек мирас калдырдылар.

Фәндә «җәдитчелек» дип аталган бу юнәлешне, ягъни татар шигъриятенең фәлсәфи-сәнгати үсеш юлларын ачыклауны, тәфсилләүне тормышның ачысын-төчесен яшьли татыган, татар җанлы, сурәтле фикерләү байлыгына ия, аеруча үзен иҗатында бәйсез тотуы белән бөтен мөселман дөньясын таң калдырган Тукай үз өстенә ала. Шагыйрь олы бер романга торырлык тормышын ике юллы бер мәснәвигә сыйдыра:

*«Азмы какканны вә сукканны күтәрдем мин ятим,*
*Аз-маз үстерде тик маңлаемнан сыйпап милләтем!»*
*(«Тәэссер»)*

Күз алдына китерегез: әле егерме яшен генә тутырган үсмер илнең сәяси-иҗтимагый халәтен чагылдырган «Хөррият хакында», «Иттифак хакында», «Дусларга бер сүз» (барысы да 1905 елда иҗат ителгәннәр) шигырьләрендә үз чорында барлыкка килгән мөмкинлекләрдән газиз милләтенә файдалы гамәлләрне эзли: «Мәдәният мәйданында урын алыйк», «Егла-тора алга таба атлыйк имди» дип яза «Дустларга бер сүз» шигырендә.

*Кая китте цензурлык,*
*Коллык, тарлык, ким хурлык.*
*(«Хөррият хакында»).*
*Файдаланыйк киңлектән,*
*Ваз кичик мин-минлектән.*
*(«Иттифак хакында»).*

Яшь шагыйрьнең киләчәккә өметләре, ышанычлары белән уртаклашасы килсә дә, без чынлыкта, «цензураны бетерү», «тиңлек» турында вәгъдә бирүләрнең хакимиятне кулга төшерү яисә саклау өчен сүздә генә икәнлеген тәгаен беләбез. Тукай шатлык, сөенеч хисләренең томышка ашмаячагын тиздән үзе дә аңлаячак. Аңындагы үзгәреш иҗатына да бик тиз үтеп керә.

Киләсе санәдә язылган сатирик рухлы «Сорыкортларга», «Государственная Думага», тормыш-көнитешкә багышланган «Көз», «Үз-үземә», «Мактанышу»

кебек шигырьләрендә реалистик һәм тәнкыйди башлангыч өстенлек итә. Тукайның зирәклеген, кыюлыгын янә бер кат искә төшерү артык булмас дип, күпләребезгә таныш юлларны кабатларга җөрьәт итәм:

*«Аристократ – сорыкортлар, калын корсак, кечек башлар,*
*Ашыйлар соң бирән булган кешеләр, ну, гаҗәп, ай-яй!»*
*(«Сорыкортларга»).*

Яшь шагыйрь үзләре турында гына кайгыртып яшәгән депутатларны да «тынычта» калдырмый.

*Ник безне кызганмадың соң,*
*Коллыктан коткармадың? –*
*Ах син, Дума, Дума, Дума,*
*Эшләгән эшең бума?*
*(«Государственная Думага»).*

Тукай сатира угын уңга-сулга кадау белән канәгатьләнеп утыра алмый. Ул туган халкының язмышы, киләчәге өчен борчылып, онтологик хисләренә бирелеп ала. «Татар бит мин үзем дә, чын татармын», «Татар бәхете өчен мин җан атармын» дип, «Үз-үземә» тезмәсендә күкрәгенә кагып алганнан соң, милләтенең җитешсезлекләрен күзләренә карап әйтергә хакым бар дигәндәй, күңелен бушата:

*«Татарларны мин җиңәм,*
*Минем кулымда җөгән;*
*Ник җикмәскә, татарлар*
*Җебегән бит, җебегән».*
*(«Мактанышу»).*

Тормыш-көнкүреш мәшәкатьләре белән беррәттән, Тукайны Казанда иҗтимагый-сәяси проблемалар да зар-интизар булып көтеп торганнар икән. Чишелеше кыен мәсьәләләрдән иң четереклесе милли, ягъни халык язмышына, киләчәгенә бәйлесе дә Тукайны борчымый калмый. Россия халыкларын йокыдан уяткан 1905 ел инкыйлабы тәэсирендә азатлык, үзбилгеләнү таләп иткән чыгышлардан куркып калган карагруһлар «Сезгә монда юк ирек, солтан җиренә китегез», – диләр. Әүвәл Тукай мондый тәкъдимне мантыйкка һәм күзаллавына таянып, кире кага. «Мондагы ун урнына ул җирдә унбиш шпион. Мондагы төследер анда һәм казаклар гаскәре» ди һәм гасырлар дәвамында яшәгән җирләрендә калырга тиешлекләренә кире каккысыз дәлилен китерә: «Иң бөек максат безем: хөр мәмләкәт – хөр Русия!»

Мәгълүм булганча, ил яшәешен нигездән үзгәрткән 1917 ел инкыйлабына кадәр татар халкының мәдәни, өлешчә икътисади мәнфәгатьләрен Казан белән Уфадан кала, Оренбург шәһәре һәм өлкәсе канәгатьләндереп килә. Аерым алганда, шәкертләргә төпле белем биргән, милли рухлы, Г.Исхакый мөгаллимлек итеп алган, бераз М.Җәлил белем эстәгән «Хөсәения» мәдрәсәсе бик күп булачак зыялыларыбызны укытып чыгара. Менә шул төбәкнең Җиргән исемле татар авылында сәүдәгәрләр гаиләсендә 1859 елның 23 ноябрендә киләчәктә «тылсымлы шигърият иясе» дип бәяләнәчәк һәм Дәрдемәнд тәхәллүсен алачак Закир Рәмиев дөньяга килә. Башлангыч белемне гаиләдә алып, күрше Моллакай авылы мәдрәсәсен тәмамлагач, укуын дәвам иттерү, чит телләргә өйрәнү нияте белән Төркиягә юл тота, шунда иҗатка тартыла. Төрек хикәяләрен татарчага тәрҗемә итүе, шигырьләр язуы мәгълүм. Көнчыгыш телләрен ныклап өйрәнгән, Аурупа лөгатьләреннән дә хәбәрдар Закир Рәмиев туган иленә белемле, әдәби-эстетик карашлары калыплашкан зыялы шәхес булып кайта.

Ул чорда язылган «Үткән көннәр» исемле шигыре Риза Фәхретдиннең 1903 елда чыккан «Әсма» хикәясендә урын ала.

*Әй, кая ул көн ки бездә –*
*Шәп торулар бар иде.*

*Һай гомерләр, үтте китте...*
*Кая китте ул заман!*
*(«Үткән көннәр»)*

Дәрдемәнднең халык язмышы, замандашының уй-хисләре турындагы җыйнак күләмле, тирән фәлсәфи мәгънәле, нечкә сиземле элитар поэзиясе белән укучы соңрак кына таныша алачак.

1905–1917 елларда Закир Рәмиев эшчәнлеген төрле, бигрәк тә мәгариф, мәдәният, уку-укыту юнәлешләрендә алып бара. Оренбургта үз исәбенә диярлек «Вакыт» газетасы, «Шура» журналы кебек алдынгы карашлы, милли җанлы татар зыялыларын туплаган матбугат чараларын нәшер итүдә, юнәлешләрен билгеләүдә даими катнаша[1].

1918 елда әлеге матбугат чараларын большевиклар яшәүдән туктатканчы, Дәрдемәнд шунда кырыклап шигырен бастырса да, аларны җыентык итеп чыгару турында уйламый. Җөмләдән, үзе исән чакта төрле нәшриятларда Тукайның утыз өч басмасын укучыга тәкъдим итәләр.

Бер-берсенең иҗатлары, фикер сөрешләре димим, хәтта фани дөньяда яшәүләре турында да имеш-мимештән башка (Тукай бер чыгышында «Вакыт» газетасын юк кына сәбәп белән «чеметеп» уза) хәбәрләре булмаган Тукай белән Дәрдемәндне туган милләтләренең язмышы, киләчәге турында борчылу хисе, шигъри фикер тирәнлеге, сәнгати осталык, һәр күренешкә үзләренчә, мөстәкыйль бәя бирү хасияте якынлаштырачак.

Татар шигъриятенең киләчәкле магистраль юлын реализм һәм халыкчанлык таләпләренә таянып үстергән Тукайны Дәрдемәнднең телебез биргән символларга, нечкә тоемлаулы романтик алымнарга өстенлек биргән шигърияте һәм башка сүз осталарыбызның эзләнү, ачышлары тулыландыра.

Шекспирны – Байрон, Пушкинны Лермонтов дәвам иттергән кебек, Тукай белән Дәрдемәнд, һәркайсы үзләре булып калып, киләчәккә бергә атлыйлар.

Шагыйрьләрне фанидагы гомерләре дәвамында озата килгән иң кыен мизгелләрдә таянычлары Аллаһның берлегенә һәм кодрәтенә ышаныч иде. Шул мәүзугъ мәгънәви вә шигъри җәһәттән иң камил әсәрләренең нигезенә ятты.

Тукай иҗаты сан, сыйфат дәрәҗәсе ягыннан бәяләгәндә, югары үренә күтәрелгән 1909 елда язылган «Таян Аллага», «Ана догасы» шигырьләренә хас илаһилык, Раббыбызда һәрдаим таяныч эзләү Дәрдемәнднең «Аллага тәвәккәл» әсәрендә табигый дәвамын таба. Тукайның «Ана догасы» иң каты күңелләрне дә иләсләндерерлек кичле талгынлыкны сурәтләү белән башлана:

*«Менә кич. Зур авыл өстендә чыкты нурлы ай калкып,*
*Көмешләнгән бөтен өйләр вә сахралар тора балкып».*

Шул ямьле сурәтле, иманлы «өй эчендә ястүеннән соңра», «бар җиһаннан күңле арчып» намазлыкта утырган, күзләреннән «тамчы-тамчы» яшь тамган карчыкның сүзләре китерелә:

*«Күтәргән кул догага, яд итә ул шунда үз угълын:*
*Ходаем, ди, бәхетле булсайде сөйгән, газиз улым!»*
*(«Ана догасы»)*

Әлеге шигырь баласына бәхет, игелек теләгән ананың рухи дөньясын ачу нияте белән язылган булса, «Таян Аллага» шигыре лирик затның балага изге теләкләрен иңдергән эчке сөйләм-монолог аша җиткерелә. «Әй бәһале, әй кадерле, әй гөнаһсыз яшь бала!», «Син фәрештә валчыгысың, йөзләрең ап-ак синең» дип, эчке сөйләмен дәвам иттерә. «Кыйл дога, ихлас белән тезлән дә кыйбла каршына» дигән киңәшен биргәннән соң, ул бала күңеленә бөтен гомеренә җитәрлек таяну ноктасын иңдерә: «Рәхмәте бик киң аның, һәрдам таян син Аллага!»

[1] Әдипләребез. Библиографик белешмә. – Казан. ТКН, 2009. Дәрдемәнд (1859–1921) – 470–472 б.

Диннең, намазның сихри көченә, тормышчанлыгына инанган Тукайның Лермонтовның «Молитва» шигыренә тәкълид «Тәэссер», «Өмид», «Бәйрәм бүген», «Бәйрәм вә сабыйлык вакыты» әсәрләрендә, аның сүзләре белән әйткәндә, «Гомернең иң читен, җайсыз бер минутында сәҗдәгә баш иеп, «Аллаһы хак! Аллаһы әкбәр!» дисәң, җаның рухи тынычлык табачак.

Дини гаиләдә туып-үскән, яшьлеге мөселман илендә үткән, диндар, изге күңелле Дәрдемәнднең ода жанры таләпләрендә иҗат ителгән «Аллага тәвәккәл» әсәренең лирик заты үзен тулысы белән Бөек көчкә тапшыра: «Абындым, таяндым», «Йөз ямау ямандым», «Атларга – печән, эткә – сөяк», «малга җим» булсам да, чигенмәдем, үкенмәдем һәм «дидем Аллага тәвәккәл!» Аллага мөрәҗәгать итеп язылган юлларда суфыйчылык фәлсәфәсенең нигезен тәшкил иткән Аллага платоник гашыйклык белән беррәттән, кодрәтенә ышануында милли, дини рәнҗетүләрне вакытлыча онытып торып, үзен тынычландыру юлын эзләве дә сизелеп тора:

*«Керләнде чалмам, уңды бүркем, шапкам кызарды,*
*Һәр төскә буяндым – дидем: Аллага тәвәккәл!»*
*(«Аллага тәвәккәл»)*

Дәрдемәнд Җир шары, Галәм, Кешелек мәнфәгатьләреннән алып, шәхеснең иң нечкә, үзе генә тоемлаган нәзберек хисләрен, кичерешләрен каләм очында уйнатуга сәләтле философ шагыйрь булып җитешә. Ул – яшәешнең асылы, җанның бәхеткә омтылышы, игелекнең, мәхәббәтнең үлемсезлеге турында хөкем йөртүгә сәләтле сүз остасы. Аның лирик каһарманының таянычы – Раббыбыз:

*«Гарибнең кайтырындан фал карасын,*
*Ходайдан кавышмаклык сорасын».*
*(«Әгәр барсаң, саба җил...»)*

Дөньяда һәм бигрәк тә туган илендә барлыкка килгән хикмәтләрнең асылын аңлап бетерә алмау тудырган чарасызлык нәтиҗәсендә Дәрдемәнд төшенкелеккә бирелеп ала:

*«Җитәр, җилкенмә, йолкынма, күңел, син,*
*Кияү булсаң да, ул туйга түгел син!.*
*Җиһан тормыш туен иткән чагында,*
*Синең урның – үлекләр аймагында».*
*(«Куанды ил...»)*

Моңаеп, дөнья мәшәкатьләренә кул селтәп утырган мизгелдә туган иленең җиләс җилләре, гаҗәеп, сирәк очраучы кешеләре бераз идеалист шагыйрьнең аңында борылыш ясыйлар:

*«Гариб бар өнендә җил-җиләснең –*
*Туган илләрдән искән җил димәссең».*
*(«Гариб моң бар»)*

Һәр олы шагыйрьнең иҗади куәсен, эстетик вә мәгънәви юнәлешен тәгаенләгән, сәләт күзәнәкләрен тасвири ачып җибәргән бер яки берничә әсәре була. Тукайда алар «Пар ат», «Китмибез», «Туган тел» булса, Дәрдемәндтә «Атам-анам йорты өчен...», «Каләмгә хитаб» һәм аның визит карточкасы «Кораб» дип саныйлар галимнәр һәм шигърият сөючеләр.

*«Атам-анам йорты өчен*
*Булса мең җаным фида,*
*Туган-үскән җирем өчен*
*Соң тамчы каным фида».*

Мондый ихлас юлларны кем генә хупламас икән! Яисә:

*«Шаулый диңгез...*
*Җил өрәдер...*
*Җилкәнен киргән Кораб».*

Тарту көченә ия тылсымлы юллар диңгезнең җилле-давыллы вакытында юлга чыгып, «ят ил карап...» барган кораб язмышына, теләсәң-теләмәсәң дә, битараф кала алмыйсың! Икенче алты юллыкта гадәти корабны «Ил корабы» алыштыра. Бергә-бер киңәйтелгән сурәтләү кыры укучыны милләт, халык язмышы турындагы киеренке уйлану – борчылулар даирәсенә алып чыга. «Җан сорап» тарткан упкында Россия халкы узган авыр сынауларны – 1905 ел инкыйлабын, 1917 санәдәге борылышны, шул еллардагы милли-мәгърифәти эзләнү-бәргәләнүләр кайнарлыгын тоясың! Уй-фикерләрен катлаулы образ-кодларга төреп бирү – Дәрдемәнднең сурәтле фикерләвенең үзенчәлекләреннән берсе.

«Кораб» – әйтеп бетерелмәгән серлелеге, сәнгатьчә камил эшләнеше, һәркемгә ул чорның вакыйга-хәлләренә үзе бәя бирүгә мөмкинлек калдыруы белән кыйммәтле, кадерле тезмә.

Аның тәүге «Әсәрләр» (кереш сүз авторы, 1930 елларда репрессия корбаны булган Ф.Кәрими) җыентыгы шагыйрьнең вафатыннан соң (1921), 1928 елда гына басылып чыга һәм рәсми ярлыкау тапмагач, популярлык казана алмый.

Дәрдемәнднең күренекле галим, профессор М.Гайнуллинның әтрафлы сүз башы белән нәшер ителгән (1959) «Сайланма әсәрләре», тиз арада лаеклы бәясен алып, әйләнешкә керә.

Рус телле укучыларны Дәрдемәнд иҗаты белән таныштыру юнәлешендә дә җитди адым ясала. «История татарской литературы нового времени» (Казань «Фикер», 2003) җыентыгында күренекле галим Н.Хисамовның Дәрдемәнд иҗатына багышланган фәнни мәкаләсе урнаштырыла (301–315 бб.).

Дәрдемәнд иҗатының татар дөньясында чын-чынлап танылуы, киң әйләнешкә керә баруы илдә мәгълүм күләмдә азатлык җилләре исеп, М.Җәлилнең «Моабит дәфтәрләре», Х.Туфанның сөргендә язылган шигырьләре басылып, киң таралыш алган еллардан башлана. Шул чорның әйдәп баручы өлкән буын шагыйрьләре Х.Туфан белән С.Хәким Дәрдемәнд иҗатының сәнгати яңачалыгын, яшәешебезгә үз шәхси карашын бирү сәләтен бәяләп, чыгышлар ясыйлар һәм аның наменә багышлауларын язып чыгалар: Х.Туфан «Җилкәнен киергән...», С.Хәким абруйлы каләмдәшенең нәзберек әдәби осталыгын җирдән алтын-көмеш эзләүгә тиңләп, «Йөз кат сынап...» шигырен язып чыга.

Вульгар социологизм элмәгеннән акрынлап котылып, өлкәннәрдән үрнәк алып, төрле елларда иҗатка килгән М.Әгъләм, Зөлфәт, Р.Харис, Р.Фәйзуллин, Л.Шагыйрьҗан, Н.Әхмәдиев, Р.Аймәт, Р.Җамал, Л.Лерон, Г.Морат, Р.Зәйдулла, Л.Шәех шигъри багышлаулары, чыгышлары белән Дәрдемәнднең танылуына, дөресрәге, китмәскә кайтуына җирлек-зәмин әзерләделәр.

Тукай белән Дәрдемәнднең мирасларында, әйдәп баручы жанр буларак, шәхес кичерешләрен, аның иң тирән уй-хисләрен чагылдыруда тиңдәше булмаган лирика жанры, аның дини, нисби фәлсәфи, көнкүрешкә, табигатькә, мәхәббәткә багышланган, шаян, фаҗигаи һәм башка төрләре үстереләләр. Аларның бер-берсенә таяну, үрнәк алу турында сүз куерту була алмаса да, Тукай белән Дәрдемәнднең иҗатларында тормыш-яшәешне, дөнья картинасын, адәм баласының күңелендә бөреләнгән шәхси хисләрен сурәтләүдә исемгә үк чыгарылган якынлык «фортунасы» яши. Уртак исемле «Нәсыйхәт», «Кыйтга», «Шагыйрь», «Шагыйрьгә», «Мөхәррир», «Мөхәрриргә» һ.б. тезмәләрендә шәхси башлангыч өстенлек итү сәбәпле, каһарманнары – шагыйрьләр үзләре.

Тукайның үз шәхесенә һәм күпләргә мөрәҗәгать итеп язылган «Нәсыйхәт»ендә «Теләнче капкаңа шакыса», «Каты сүзләр белән инсаниятен син таптама» ди һәм, аның сурәтле фикерләвенә хас булганча, киңәшенә ачыклык кертә. Бер яктан, ди автор, ул, бәхетсез, ачлар – һәммәсе Алланың коллары һәм, икенчедән, син бүген «байлык һәм шөһрәттә» коенсаң, иртәгә шайтаннан да ярлырак, хәерчерәк булу ихтималын онытма!

Иң төпле, кире каккысыз дәлилен иң соңыннан китерә: «Сизми калма ак сакаллы картның безне сынау өчен җибәрелгән «Хозыр Ильяслыгын».

Дәрдемәнд «Нәсыйхәт»енең эчтәлеге үзгәрәк булса да, үгет-киңәше, кем беләндер бәхәсе, әхлакый сөземтәсе, «эчке сюжет төзелеше» белән Тукай әсәренә аһәңдәш.

Шагыйрьләрнең нисби фәлсәфи-әхлакый гөманнары «Кыйтга» (өлеш, кисәк) парчаларында бөтенләй яңа сыйфатлары белән ачылып китәләр. Дәрдемәнднең «Тәмам булмаган бер әсәремнән» дигән аңлатма белән тәкъдим ителеп, гарәп-фарсы сүзләрен мул кулланган әхлакый рухлы «Кыйтга» парчасы автор тормыш юлына йомгак ясый, нәтиҗәсен чыгара дигәнрәк тәэсир калдыра.

Тукай да фани дөньядагы тормышының соңгы – 1913 елында язылган «Кыйтга» тезмәсендә гади халык мәнфәгатьләрен яклап, «залимнар, өстеннәр» белән көрәшеп, көчен кара көннәргә саклый алмаганы өчен үкенечен белдерә.

Дәрдемәнд шулай ук фәлсәфи дулкында фикер йөртеп, «гомерем бетеп, илтеп күмгәч», җанымнан, изге теләкләремнән торган сүзләрдән гөлләр шытып чыгачаклар дигән хыялын калкытып куя. Шагыйрьнең күпчелек әсәрләренә хас моң, үкенү, бәхилләшү сагышы экзистенциаль мотивны көчәйтеп, хис һәм фикер бердәмлегенә юл ача. Адашкан юлчыларны очратсаң, – «кальбемне вакла» да юлны яктырт! Юлчылар шул изгелегемне бәяләп дисеннәр: «бер заман бар булган ул да...» («Кыйтга»)

Дәрдемәнд шигырен теләк, өмет, ният белән тәмамласа, Тукай аның иҗатына, сүзенә ихтыяҗ арткан чорда, «дөньяны пакьли» алмаган килеш фани дөнья белән хушлашу мәҗбүриятен гаять авыр кичерә:

*Кайтмады үч, бетте көч, сынды кылыч – шул булды эш:*
*Керләнеп беттем үзем, дөньяны пакьли алмадым.*
*(«Кыйтга»)*

Тукай белән Дәрдемәнднең шигъри палитраларында туган табигать күңелләргә якын һәм газиз гүзәллегендә яши. Тукайның «Көз», «Чыршы», «Туган авыл», «Җир йокысы» шигырьләрендә күтәренке романтик күзәтүләр, еш кына кешеләргә хас сыйфатлар белән тулыландырыла. «Ай һәм Кояш» шигырендә күкнең ике мәңгелек бизәкләре – Кояш һәм Ай – «ике туган агай-эне» буларак тәкъдим ителсәләр, Җир шары да дикъкатьсез калмый: «Җир йоклый тыныч... Күреп тәмле төш» («Җир йокысы»).

Дәрдемәнд «Җәй үтте», «Кыеп күкнең йөзен», «Исәрме җил тугай буйлап» шигырьләрендә табигатьне яратып, моңын сизеп, иркәләп сурәтли.

Табигатьтәге хәрәкәтне, фасыллар алышынуны сурәтләүдә Тукай белән Дәрдемәнд һәркайсы, үзләре булып калган тәкъдирдә, якынаеп китәләр. «Җәй көнендә» (Тукай) «Көн кызды» (Дәрдемәнд) шигырьләре эссе, бөркү булса да, күңелгә якын тирәлек сынын тудыралар.

*«Каты эссе. Һава бөркү. Кыза дөнья, сабыр җитми.*
*Җил исми аз гына да, бер генә яфрак селкенми».*
*(«Җәй көнендә»)*

Тукайның «Кыза дөнья, сабыр җитми» дип зарлануын сизенгәндәй, Дәрдемәнд «Көн кызды! Кызды һава монарланып... Һава тымык, шалт итми! Кысылды тын», дип, Тукай белән килешә дә «күк йөзендә кара болыт» күреп алгач, «ягъмурны коеп» түктерә. «Бушанды күк», «күк ярылып шыгырдый», «шифалы ява коеп яз ягъмуры» метафоралары, ачыкламышлары табигать ахыр чиктә барысын да тигезли дигән нәтиҗәгә китерә.

Яңгыр көтеп әлсерәгән затны, «кыр» белән «дала»ны, вакытында яуган яңгырны, ягъни табигать тормышын шулай эзлекле, хәтердә калырлык итеп сурәтли алган шагыйрьләр дөнья харитасында да күп түгеллеген беләм.

Чынбарлыкны сурәтләүдә романтик-символик өслүбкә өстенлек биргән очракларда да Дәрдемәнд реалистик төгәллек ихтыяҗы турында онытмый. Еш кына табигать

күренеше кеше кичерешләре, мәхәббәт сагышы, юксыну белән үрелеп китә. «Исәрме җил тугай буйлап...» шуңа үрнәк-мисал:

*«Исәрме җил тугай буйлап,*
*Җырлармы кыз моңын сөйләп,*
*Көләрме шатланып, көйләп».*

Дәрдемәнднең «Кичә күр, иркәм...», «Әгәр барсаң...», «Тиң булырмы йолдыз тулган айга...» газәлләрендә табигать Әдәбият белемендә декадентлык поэтикасы йогынтысында туган дип бәяләнгән «Видагъ» (аерылышу)[2] табигать белән мәхәббәт «бердәмлеге»нең үрнәк газәле. Асылында ул «Нәзкәй бил»гә багышланган булса да, лирик зат әүвәл туган иле белән «таңгы җилгә» исәнлек тели:

*«Тәгәрәп – уйнап*
*Буй үскән*
*Туган илем, исән бул!*
*Йөгреп-йөгреп*
*Туктаган...*
*Яулык болгап*
*Сыктаган*
*Нәзкәй билем, исән бул!»*
*(«Видагъ»)*

Дәрдемәнд иҗатында мәхәббәт лирикасы дорфалыкны, тупаслыкны якын китерми торган нәзакәт оялчанлыгы белән үзенә җәлеп итә. Моңа ышану өчен алдарак искә алынган «Кичә күр, иркәм», «Әгәр барсаң...» һәм «Бүзләрем маналмадым», «Тиң булырмы йолдыз тулган айга», «Хикәяи гыйшык» һ.б. шигырьләре белән танышу лязим.

«Бүзләрем маналмадым» – XX гасыр башы татар шигърияте нең мәхәббәтне тарих, реаль тормыш белән бердәмлектә сурәтләгән уңышлы газәлләренең берсе. Сөямесөймиме икән дип, күңеленә юшкын булып утырган каршылыклы хисләрен шагыйрь тарихи аналогия ярдәмендә «фаҗига» дәрәҗәсенә күтәрә:

*«Янды Мәҗнүн, янды Фәрһад, –*
*Бер янып ат алдылар.*
*Мин гариб, мең янып та*
*Яндыга саналмадым...»*
*(«Бүзләрем маналмадым»)*

Өлкәннәр яшь җилкенчәкне «Әйттеләр, кем, бер бәхетсез Илгә гашыйксың, фәкыйрь. Лирик герой «Кемгә вәсләт, кемгә өмид» дип, милләт кызларына соклануда үзенә таяныч таба:

*«Сезне, милләт кызлары, аһ!*
*И өмид йолдызлары!*
*Таң-сәхәрләр эзләп-эзләп,*
*Бер күреп каналмадым».*
*(«Бүзләрем маналмадым»)*

Мәхәббәтнең йөгәнсез көче Мәҗнүн кебек мәхлукларны гына түгел, ә дөнья тоткасы – җиһанның зур бер кыйтгасын буйсындырып, үз кубызына биетеп яшәгән Сөләйман паша кебекләрне дә хатын-кыз чибәрлеге, назы эретеп төшерүен һәм бөекләрнең азгынлыгын Дәрдемәнд ун иҗекле бер юлда ачып бирә:

*«Сөләйманны җиңә Бәлкыйс аягы».*[3]

Форсаттан файдаланып, Дәрдемәнднең икешәр юллы мәснәвиләрендә яшәешкөнитешнең күп яклары сурәтле фикерләү үзәгенә алынуына дикъкатьне юнәлтәсе

---

[2] Әдәбият белеме. Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. – Казан, «Мәгариф», 2007, 44 бит.
[3] Б.Урманченың «Сөләйманны җиңә» исемле иллюстрациясе бар.

килә. Аларда ягымлы лиризм белән чәнечкеле сатира берсен-берсе тулыландырып киләләр:

*«Күңел һәр җирдә гөл эзли.*
*Къадәр һәр җирдә төкән төзли».*
*(«Күңел һәр җирдә»)*

Тукай 1907 елда язылган «Син булмасаң» шигыреннән алып, бәгырендә бөреләнеп, каләме безгә китереп җиткергән «Мәхәббәт», «Булмаса», «Бер рәсемгә», «Гашыйк», «Мәхәббәт шәрхе» һ.б. тәнкыйтьчеләребез, галимнәребез тәфсилле өйрәнгән шигырьләре мәхәббәт лирикасының югары казанышлары санала. Мәхәббәт – аның өчен иң кадерле хис һәм кыен мизгелләрдә таяну ноктасы:

*«И матур! Мин янмас идем – яндыручы булмасаң;*
*Таммас иде җиргә яшьләр, тамдыручы булмасаң».*
*(«Син булмасаң...»)*

Татар халык шагыйре Тукайны мәхәббәт җырчысы дип атау кемгәдер аның фикерләү, хисләнү офыгын тарайту, халык хәсрәте, туган илнең киләчәге, милләт язмышы һәм башка тематик юнәлешләр дә бар бит әле диебрәк уйлаучыларга җавапны аның үз сүзләре белән бирәм:

*«Юаныр идем бераз кояшка һәм айга карап,*
*Матурлыгың белән аларны каплаучы булмасаң!»*
*(«Син булмасаң...»)*

Туган теле халыкның иң кадерле байлыгы, өмете, киләчәге дигән фикерен Дәрдемәнд «Каләмгә хитаб», «Бүзләрем маналмадым», «Шагыйрьгә» кебек тезмәләрендә үстерә. Лирик героеның уйланулары шагыйрьнең эчке дөньясына тәңгәл, чөнки ул милләтенә кагылган һәр шәйне Тукай шикелле үк йөрәге аша уздыра. «Шагыйрьгә» тезмәсендә үзенә һәм каләмдәшләренә дә мондый киңәшен бирә:

*«Ал кошларга бакмакчы,*
*Газизем, булма такмакчы;*
*Матур гөлләргә бул былбыл,*
*Нәзакәт багына сакчы».*
*(«Шагыйрьгә»)*

«Телләр белү яхшы гамәлдер» дип хуплый һәм шунда ук туган телебезнең башка лөгатьләр йогынтысына бирелүен күзаллап, хәтта аның авыр киләчәгенә күрәзәчелек иткәндәй, «Катыштырма вәләкин телне телгә» дигән кисәтүенә кискен аңлатма бирә:

*«Тел уйнатмак наданлыктан, әсәрдер».*
*(«Кил, өйрән, и туган»...»)*

Тукай белән Дәрдемәнд берүк исемле «Шагыйрьгә» тезмәсендә каләм иясенең абруе югары дәрәҗәдә торырга тиешлекне искә төшерәләр. Тукай «шагыйрь» дигән сүз, еш кулланып, масаеп йөрү өчен бирелми дигән фикерен ассызыклый:

*«Сине күрсәтмәсен һич кем дә дип: «Бу*
*Менә шагыйрь, мөхәррир бу, әдип бу».*
*(«Шагыйрьгә»).*

Алдарак әйтелгәнчә, Дәрдемәнд халкыбызның тел хәзинәсен күз алмасыдай саклау өстенә, аны даими баетып, тулыландырып тору кирәклеген искәртә. Үзе җир астындагы алтын-көмеш эзләүче эшмәкәр кебек төрек, гарәп, фарсы телләреннән алынмаларны телебезнең сингармонизмына, авазлар яңгырашына, кафия таләпләренә буйсындырып, могҗизаи шигъри өслүб тудыра. Туган телебезне баетуның, халык сөйләменә якынайтуның янә бер чыганагын күрсәтә: «Урамнан һәм базардан чүпләмә сүзне, Алар бетмәс борын – барма еракка!» Сурәтле фикерләү тәкъдимен олы сәясәткә китереп бәйли:

*«Тупас та булса тел – илнең колагы,*
*Уеңны уйдырып сал шул колакка».*
*(«Урамнан һәм базардан...»)*

Тукай белән Дәрдемәнднең югары зәвыклы һәм намуслы шәхесләр булулары остазларына мөнәсәбәтләрендә дә ачык күренә. Көнчыгыш классиклары Сәгъди, Рудаки, Нәвои, үзебезнең канатлы гыйбарәләр остасы Акмулла, лирик Кандалыйларны, Байрон, Крылов, Г.Гейнеләрне зурлаган, Тукай иҗатына аеруча уңай йогынты ясаган, ике бөек шагыйрьне аерып куя:

*«Пушкин илә Лермонтовтан үрнәк алам,*
*Әкрен-әкрен югарыга үрләп барам».*
*(«Бер татар шагыйренең сүзләре»)*

Иҗади йогынтылар, остазлар, дәвамчылар турында сүз алып барганда, галимнәр Тукай белән Дәрдемәнднең мираслары төрле шигъри агымнар, эстетик зәвыклар бердәмлегендә туган мөстәкыйль күренешләр дип бәялиләр.

Дәрдемәнд остазларының исемнәрен төрләндерергә яратмаса да, галимнәр аның иҗатына суфи шагыйрьләрнең, шулай ук дөньяга карашы, сурәтле фикерләү үзенчәлеге калыплануда халык мифологиясенең йогынтысын аерып куялар. Ләйлә-Мәҗнүн мәхәббәтенә багышланган дастаннар, тарихи үткәнебезне үзәккә алган, татар фольклорының энҗесе «Идегәй» дастаны – аның  рухи дөньясына иң якыннары.

Кыпчак – болгар – татарлар даирәсендә киң таралган Ләйлә белән Мәҗнүн мәхәббәтен үзәккә алган дастан төрки-фарсы халыклары иҗатында үстерелә, Дәһләви, Физули, Җами кебек суфи шагыйрьләргә дә тынгы бирми. Халык иҗатының гаҗәеп бер мәхәббәт кыйссасын Дәрдемәнд тә әйләнеп үтә алмый һәм аны эпик оеткылы «Хикәяи гыйшык» балладасына өлге итеп ала.

Ике гашыйкның сокландыргыч мәхәббәтләренә көтмәгәндә кырау төшә. Мәҗнүн Тукайның «Бер рәсемгә» газәлендәге «Күрсә яңлыш бу матур кызның фәкать рәсемен генә, Шөбһәсез, селтәр кулын Мәҗнүн дә Ләйләсенә» җөмләсен укып тилергән диярсең! Мәҗнүн хыялы тудырган Ләйләгә гашыйк булып, җисми Ләйләсеннән баш тарта. Кыз, егетенең үзенә суынуының сәбәбен аңламыйча, саргаеп, фани дөнья белән хушлаша.

Үз бәхетенең кадерен белмәгән сәрхуш Мәҗнүн Ләйләнең үлеме һәм инде җиргә тапшырылуы хәбәрен ишеткәч, «фөрьяд орып», ягъни аһ-зар килеп, зыяраткә йөгерә. Шунда бер кабер кырында дер-дер калтыранып утырган малайны күреп, аның янына килеп, «Кайда кабре Ләйләнең?» дигән сөален бирә. Бала туры җавап бирмичә, мәгәр гашыйкларны аптырашта калдырырлык, уйга салырлык фикер әйтә: «Карап чык һәр каберне, Алып туфракны учка, «искә җирне», «нә җирдә» аның «исе бар, шунда аның кабре».

Дәрдемәнд халык дастанына яңа сюжет чишелеше биреп, мәхәббәтегезнең кадерен белеп, саклый алмасагыз, аумакай Мәҗнүн көненә калуыгыз ихтимал дип искәртә.

Дәрдемәнднең көтелмәгән, уйланмаган борылышларга осталыгын белгән тәкъдирдә дә, «Гөрләгән сулар башында...» тезмәсендә халык иҗаты җимеше – «Идегәй» дастаны белән «бәхәскә» керүен күз алдына да китерүе кыен иде. Әсәрнең исеменнән һәм «Йөрсә сыктап таң-сәхәрләр / Моң-сагышлардан хыял. / И туган илнең һавасы» юлларыннан чыгып, аны гадәти пейзаж лирикасы дип кабул итәсең һәм алдагы юлларда табигатебезнең илаһи бер күренешен сурәтләгән самими әсәр көтәсең!

Алдагы куплетта «Аһ, туган каумем газиз!» гыйбарәсе белән күңелләрне нурландырып, «Изге сөткә ни җитә» җөмләсе белән уйландырып алганнан соң килгән «Сөт калыр, Ватан китәр» гыйбарәсе белән автор, укучысын тәшвишкә сала. Дәрдемәнд әсәре «тукымасындагы» Ватан, сөт, мөкатдәс кан, моң, сагыш, туган ил һавасы кебек ачыкламыш төшенчәләр «Идегәй» дастанын искә төшерә. Халык иҗатында әүвәл

гадәти сөтне олылаганнан соң, «Сүзе татлы сөт калыр», «тел китсә» дигән борчылуны «Буында типкән кан калыр» җавабы киләчәккә күңелләрдә өмет чаткысы уята.

Сюжет өлгесен, атамаларының күпчелеген халык дастаныннан алган Дәрдемәнд үзе генә тирән мәгънәсен аңлаган, гади укучыны тетрәндереп җибәргән нәтиҗә ясый:

*«Сөт калыр, Ватан китәр!*
*Сөт калыр, Ватан китәр!»*

Дәрдемәнднең «Гөрләгән сулар башында...» тезмәсе шагыйрьләрне, зыялыларны уятып җибәрде. Берише чыгышларда яңгыраган («Мәдәни җомга», 2020, 4 сентябрь) кавем белән Ватанны капма-каршы куеп, беренчесен – мәңгелек, ә икенчесен вакытлы дип санауны күпчелек зур хата дип санадылар. Чөнки үз мөстәкыйль дәүләте булмаган кавем акрынлап телен, менталитетын югалта һәм буйсындырган милләткә чимал дәрәҗәсенә төшә.

Күпчелегебезне «сөт калыр, Ватан китәр» гыйбарәсе күпмәгънәлелеге белән борчуга салды. Мин Дәрдемәнднең Ватанны сөткә «алыштыруын» тирән уйланылган «уен» дигән фикергә килдем. «Сөт» бу очракта кайгы-хәсрәтсез, мул тормышта яшәү синонимы булып тора дип уйлыйм. Әгәр тамак турында гына уйлап, шундый яшәеш белән канәгатьләнеп, илнең, Ватанның язмышы, киләчәге турында уйламасак, «сөтебезне кочаклап, Ватансыз калырбыз» дип чаң суга шагыйрь дигән нәтиҗә сорап тора. Күңел Ватанны сөт «дәрәҗәсенә» төшерү яисә алыштыру белән ризалашмаса да, бәйлелектән котылган илләр сөткә генә булса да мохтаҗлык кичермиләрдер дигән «софизм» фәлсәфәсенә кереп китүдән, Дәрдемәнд әсәрләренә хас күп мәгънәлелек, полифонизм, сүз асты байлыгы хас дип, кыскасы, аның шигъри осталыгы турында уйлану белән канәгатьләнергә туры килде.

XX гасыр башының ике даһи шагыйре, камил инсаннары – Тукай белән Дәрдемәнд иҗатларына хас офык киңлеге, иҗади эзләнүләр төрлелеге, лирик жанрлар үсеше, көтелмәгән нокталарда уртак сурәтле фикерләү байлыгының чыганаклары турында күп уйлансам да, аларны тар кысаларга куып кертүнең мөмкин түгеллегенә инандым. Табигый талантларына нигез өлгене, илһам утын күңел-йөрәкләренә Ходаебыз иңдергән. Икесенең дә яшьлекләре Җаек-Урал, Ырынбур (Оренбург), Башкортстанның Мәләвез төбәгендә, татар, казакъ, башкорт, уйгур һ.б. төрки телле халыклар арасында узуы милли буыннарын, акыл шәрифләрен ныгыткан. Далалар киңлеге, тау-елгалар иркенлегендә халык иҗаты гәүһәрләре – мифлары, риваятьләре, җырлары, мәкаль-әйтемнәре күңелләренә үтеп керүе бәхәссез[4]. Яшьлеккә хас «ләззәтле дә соң яшерен газап, яшерен яну!» дип язачак соңрак Тукай «Мәхәббәт» газәлендә.

Мәкаләнең беренче битендә китерелгән Г.Моратның юраламасын да «аклаганнар» икән бөекләребез: Тукай 27 яшендә Клячкин хастаханәсендә газиз милләте белән хушлашса, Дәрдемәнд 1921 ачлык елында Орск шәһәрендә бакыйлыкка күчә.

Фани дөнья белән хушлашканчы Тукай – Дәрдемәнд бер-берсенә бәйсез рәвештә, зәркән осталарыдай, татар шигъриятенең, бигрәк тә лирикасының югары зәвыклы, тирән мәгънәле үрнәкләрен буыннарга ядкарь итеп калдыралар. Мирасларының төп эчтәлеген Кешенең җирдәге миссиясе турында уйлану – фаразлар тәшкил итә.


Тукай белән Дәрдемәнд – чылтырап аккан чишмә суыдай саф татар телендә язылган югары шигърият үрнәкләрен бүләк иткән Галәм шагыйрьләре.

**Тәлгат ГАЛИУЛЛИН**,
*Татарстанның халык язучысы, филология фәннәре докторы.*

[4] Мирсәй Гариф. «Җаек буенда Тукай эзләре. «Мәдәни Җомга», 2024, 9 август.

# ХОДАЙ БИРДЕ!

Остазым А.Гыйләҗевнең «Берәү» повестен бик яратып, шул ук вакытта хәлдән таеп, төрекчәгә тәрҗемә итеп бетергәннән соң ничек шатланганымны белсәгез иде... Ул биш ел ятты, рәхмәт яусын, Татарстан Язучылар берлегенең әдәби тәрҗемә бүлеге ярдәмендә быел Төркиянең абруйлы «Һәҗә» нәшриятында (2024, март ае) дөнья күрде. Мин остазымның яңа чыккан әлеге әсәре турында язарга алынмаслармы дип, Төркиядәге өч якын кешемә китапларны җибәрдем. Үзләренең бик теләп бу эшкә алынасы килә иде. Әмма һәммәсенең үз мәшәкате, көндәлек ыгы-зыгылары моңа комачау булып торды. Кат-кат әйтеп, яңадан аларны борчыйсым килмәде. Шулай да күңелем белән көтә идем... Түзмәдем, сентябрьнең алтысында алар арасында язасына нык өметләнгән, яза да башлаган дустыма шалтыратып, шул хакта әйттем. Чыннан да, аның тормышында төрле мәшәкатьләр килеп чыккан, язып бетерә алмаган. «Фатиһ дустым, ни кызганыч, син әйткән вакытка өлгертә алмыйм», – дип, түбәнчелек белән гафу үтенде. Мин аның хәленә кердем, нишлисең, һәр язманың үз язмышы бар бит. Шулай да мин гаҗиз калып: «Раббым Аллам, «Берәү» хакында бер язма булсачы!» – дип, Ходайдан сорый башладым. Шушы вакыт аралыгында әлеге өч дустымның берсеннән бер язма килерме икән? Юктыр, иң ышанычлысы да яза алмагач...




20 сентябрь килеп җитте. Изге җомга көнне иркенде вакытларында электрон почта адресыма бер хат килгәнен күрдем. Ачып карагач, күзләрем маңгаема сикерде! «Фатиһ бәй, исәнмесез, ничек хәлләрегез? Инде күптәннән «Окур» (Укучы) дип аталган китап журналында язам. Шушы айда А.Гыйләҗевнең «Берәү» повесте турында яздым. Шәп китап, тәрҗемәсе дә шәп. Котлыйм сезне! Алла бирсә, бу көчле әдипнең барлык әсәрләре сезнең каләмегез аша төрек теленә тәрҗемә ителәчәк. Ихтирам белән Мәһмәт Акиф Өзтүрк».

Әлеге юлларны укыгач, шатлыктан күңелем тулып: «И теләк-догаларны ишетүче чиксез мәрхәмәт иясе Раббым, Син бу гаҗиз бәндәңнең теләген кабул иттең! Колларыңа карата нинди шәфкатьле Син!» – дидем... Бу хәлгә остазымның хатыны Нәкыя апа әйтмешли, «Ходай бирде!» дими, ни дисең?

Шатлыгымны иң беренче итеп «Һәҗә» нәшриятына шалтыратып бүлештем. Ишетмәгәннәр, күрмәгәннәр икән әле язманы. Бу хәбәр аларга да сөенеч булды. «Берәү» повестен басып ялгышмаганнарына тагын бер кат сөенделәр. Икенче итеп, язмасын өлгертә алмаган әлеге дустыма шалтыраттым. Ул да бу хәбәргә ихластан сөенде һәм: «Кемгәдер кушмыйча, үзлегеннән, табигый рәвештә берәүнең язарга алынуы күпкә яхшырак булган!» – диде. Мәһмәт Акиф бәй журналда чыккан язмасының фотосын да төшереп җибәргән...

«Берәү» турында «заказ» бирмичә язылган әлеге язма бик кадерле һәм бик зур әһәмияткә ия дип уйлыйм. Аккан су юлын таба диюләре хак икән... Остазым А.Гыйләҗев милләттәшләрем күңеленә үтеп керү юлын тапкан һәм ул күңелләрдә чәчәк ата...

**Фатиһ КУТЛУ.**

# АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ ҺӘМ АНЫҢ «БЕРӘҮ» ПОВЕСТЕ ХАКЫНДА: «КЕМГӘ КАГЫЛМА, ТӨЗӘЛМӘГӘН ЙӨРӘК ЯРАСЫ»

Хәзерге заман татар әдәбиятының иң мөһим каләмнәренең берсе булган, СССР вакытында күп санлы әдәби бүләкләр иясе, язучы А.Гыйләҗев (1928–2002) әсәрләренең бүгенге көнгә кадәр берничәсенең генә төрек теленә тәрҗемә ителүе бу бөек язучының төрек укучысы тарафыннан танылуын кичектерде һәм һаман да кичектерә бирә. Төрекчә тәрҗемәдә чыккан «Өч аршын җир», «Җомга көн кич белән...», «Яра» повестьлары күптән инде сатуда юк. Төркиядәге бик күп укучының авторның әлеге китапларының берсен дә табып укый алмаганын шикләнмичә әйтә алам. Ә үткән айларда А.Гыйләҗевнең «Тәк» («Берәү») исемле әсәре «Һәҗә» нәшриятында дөнья күрде. Шунысы сөендерә: Гыйләҗевнең әсәрләрен бастыру эше зур нәшрияткә күчкән. Бу күренеш әдипнең булачак яңа тәрҗемә әсәрләре өчен күңелләрдә өмет уята.

Шунысы да хакыйкать: Гыйләҗев әсәрләрнең илебездә басылып чыгуы фәкать тәрҗемәче Фатиһ Кутлуның хезмәте генә. А.Гыйләҗевнең төрек телендәге барлык повестьлары, хикәя-язмалары Ф.Кутлу тәрҗемәсендә дөнья күргән. Аны үзен бу эшкә багышлаган дип әйтә алабыз. Ярый әле, мондый юлга баскан! Ник дигәндә, дөнья әдәбиятының гигант әдипләреннән бер дә калышмый торган бу бөек әдипне таныту – төрек әдәбиятына булган олы бүләк.

## Төрмә мәктәбендә

СССР да туган язучылар арасында төрмәгә юлы төшмәгән яки дәүләт-партиянең кысрыклавына дучар булмаган ничә әдип булды икән? Әнә А.Солженицынның язганнары, М.Горькийның күргәннәре, М.Булгаковның әсәрләренең язмышы барыбызга да мәгълүм. А.Гыйләҗев тә – шундыйларның берсе. Ф.Кутлуның кереш сүзендә әйтүенә караганда, А.Гыйләҗевнең гомеренең авыр елларын тасвирлаган автобиографик романы «Йәгез, бер дога!» әсәрендә шундый юллар бар: «Акылны төрмә кебек баета торган мәктәп юк». Автор «Берәү» исемле бай эчтәлекле повестен Сталин лагерьларында алты ел чамасы утырып чыкканнан соң яза. А.Гыйләҗевнең әлеге сүзләрен укыгач, әлбәттә, шундук исемә төрек язучысы Кәмал Таһир (1910–1973) һәм Достоевскийның төрмәдән чыкканнан соң язган әсәрләре төште. Дөрес, күпме язучының төрмәдән соң иҗат көче югары кимәлдә була. Әйе, төрмә ул язучының күңел тирәнлегендә яшерелгән гәүһәрләрне казып чыгара. Ә язучыдан нәрсәләрне алып киткәнен автор әсәрләрендәге юлларда эзлибез.

## «Өмет белән яшибез»

«Берәү» – Аяз Гыйләҗевнең моңа кадәр төрек теленә тәрҗемә ителгән әсәрләре арасында иң күләмлесе булуы белән беррәттән, сыйфаты ягыннан да бөек әсәр. Повесть баш каһарман Исхакның Күктау авылындагы әнисе Маһибәдәр апаның йорты яну белән башлана. Кечкенә Исхакның Күктау авылындагы тормышы – мәктәптә уку дәвере, Алманиянең Россиягә һөҗүм ясавы, сугыш еллары, сугыштан соңгы вакытлар, Исхак белән Саниянең мәхәббәте, Саниянең аянычлы язмышы, Исхакның шәһәр җирендә эшләве, туган авылы белән элемтәсенең өзелүе һәм аның сәбәпләре, ачлык, хәерчелек, нужалар... Болар барысы да повестьның төп темаларын һәм бүлекләрен тәшкил итә.

Повестьта ике төп тема турында сүз әйтә алабыз. Берсе – А.Гыйләҗев әсәрләренең күпчелегендә киң урын алган мәхәббәт һәм ул чор язучыларына тәэсир итми калмаган Икенче бөтендөнья сугышы. Әсәрдә колхоз тормышы,

дәүләтнең халыкка эзлекле басымы, хәерчелек, мәхәббәт үрелеп бирелә. Төп тема – мәхәббәт дип укыганда, кинәт сугышның дәһшәтле йөзе дә күрсәтелә. А.Гыйләҗев моны чагыштырмача йомшак рәвештә укучыга җиткерә. А.Солженицын яки Ч.Айтматовта сугышның рәхимсезлеге тагы да конкрет тасвирланганда, А.Гыйләҗевтә бу чама белән бирелә. Ләкин авторның тасвирлау сәләте укучыны сугышның барлык авырлыгы төшкән хәерче авылга илтеп ташлый. Шунысы да бар: игътибарсыз укучы А.Гыйләҗев СССРны, коммунистик режимны мактый дип уйларга мөмкин. Чынлыкта автор эзоп телендә режимны ул вакыт өчен мөмкин булган кадәр катгый итеп тәнкыйтьли. Автор турыдан-туры коммунистик идеяләрне түгел, ә тормышны һәм колхоз җитәкчелеген шундый итеп тасвирлый ки, укучы начар тормышта яшәүнең сәбәпчеләре кемнәр икәнлеген бик яхшы абайлый:

«Хезмәт көненә берәр йөз грамм арыш эләкмәсме дип өметләнгән идек, булмас, ахры... Чәчелгән җир аз, налоглар күп. Шайтан таягы үскән җир өчен дә чиста ашлык тапшырырга кирәк».

«Ничек яшисез соң?»

«Өмет белән, Хөсәен, өмет яшәтә!..»

А.Гыйләҗевнең гаиләсе һәм үзе партия һәм дәүләтнең аяусыз басымына дучар булганга күрә, аңа әсәрләрендә бу хәлне тасвирлау авыр булмаган дип әйтә алабыз. Чөнки аның бабасы Сәхабетдин, бертуганнары белән әтисе Гыйләҗетдин Төркиягә һиҗрәт кылганда, «Мин хәрби хезмәтемне Чечняда үтәдем. Чит җирдә яшәүнең нәрсә икәнен бик яхшы беләм», – дип, авылында кала һәм, 1930 елларда Сәхабетдин, Сталин режимы корбаны булып, Алабуга төрмәсендә юк ителә.

## Гел авылга кайту

Аның каһарманнары авылдан. Шәһәрдә яхшы гына тормыш итүенә карамастан, ниндидер бер сәбәп табып, мәсәлән, Исхак, Нурулла һәм Хөсәен кебек авылга кире кайталар. Авылга кайта һәм, ни кызганыч, татар халкына хак күрелгән рәвештә тагын дәүләт өчен, колхоз өчен үзен аямыйча эшли һәм, хезмәте бәяләнмичә, кадер-хөрмәт күрмичә, дөньядан китеп бара. «Менә Исхак институтны тәмамлар. Кулына диплом алыр! Диплом! Алыр да тагын шул ук радиосыз, электрсыз, караңгы Күктау авылына кайтып китәр. Тырнак төпләре канаганчы, чигә чәчләре бәсәргәнче, шайтан таяклары белән сугышыр. Икмәк үстерер. Аны Чаллыга илтеп тапшырыр...»

## Милли һәм уңышлы повесть

«Берәү» интернациональ әсәр түгел, ул – милли әсәр. Минемчә, аның уңышлы булуының бер сәбәбе дә миллилегендә. Аяз Гыйләҗев миллилектән мәхрүм, халыкара «кыйммәтләр» белән сугарылган, Аурупага йөз тоткан язучылар шикелле язмый. Әсәрне укыганда, кайчак уртак, гомуми темаларга юлыксак та, аның миллилеге безне Татарстанның Күктау авылына алып бара. А.Гыйләҗевнең иң уңышлы якларының берсе – ул әсәрләрендә телне, сүзләрне, фольклор элементларын куллану ягыннан башка язучылардан аерылып тора. Моңа Ф.Кутлуның җентекләп, түкми-чәчми генә тәрҗемә итәргә тырышуы да кушылгач, А.Гыйләҗевнең нинди зур язучы икәнлеген аңлыйсың.

Ч.Айтматовның нинди зур язучы икәнен танып, яратып укыйбыз икән, А.Гыйләҗевне дә шулай укырга кирәк. Әлбәттә, иң элек калган әсәрләренең тәрҗемә ителүе һәм тагы да яхшы агитация белән илебездә аларның күпләп сатылуы кирәк. Мин үзем Ч.Айтматов белән бер елда туган А.Гыйләҗевне аннан бер дә ким түгел дип уйлыйм. Берсе дөньякүләм билгеле бер язучы була торып, нигә А.Гыйләҗев артык беленми ул?

Язмамны төгәлләгәндә, шуны өстисем килә: А.Гыйләҗевнең шушы бер әсәренең илебездә беренче мәртәбә зур нәшриятта басылып чыгуы куандыра. Моның белән «Һәҗә» нәшриятын тәбрик итәргә кирәк.

**Мәһмәт Акиф ӨЗТҮРК.**
*Төркия.*
*Төрекчәдән Фатиһ Кутлу*
*тәрҗемәсе.*

# НАСЫЙРИ – РУС-ТАТАР МӘКТӘБЕ УКЫТУЧЫСЫ

1870 елда Россия хөкүмәте, Идел-Урал төбәгендә яшәүче мөселманнарга махсус уку йортлары ачып, дәүләт телен укытуны кертү турында карар кабул итә.

Каюм Насыйри Казан рухани консисториясенең атналык «Казан епархиясе буенча хәбәрләр»ендә *(1870, № 18)* басылган «Россиядә яшәүче инородецларны уку-укыту буенча күрелгән чараларның кагыйдәләре»н шатланып каршы ала. Мәгърифәтче соңрак үзе билгеләгәнчә, 1870 елның 26 мартында расланган «Кагыйдәләр»дә аны бер җөмлә илһамландыра – рус теленә өйрәтүне беренче мәлдә укучыларның туган телендә алып бару турында хәбәр була ул *(Насыйри К. «Казан халкына мөрәҗәгате»ннән // Насыйри К. Сайланма әсәрләр. Беренче том. – Казан, 1974. – Б.44)*.

1870 елгы «Кагыйдәләр»дә мөселманнар өчен башлангыч мәктәпнең ике варианты раслана: 1) казна хисабына эшләүче рус-татар башлангыч училищесы, анда дин гыйлеме аз укытыла, өстенлек рус теленә һәм математикага бирелә; укучыларның туган теле рус телен өйрәнгәндә кулланыла; 2) яңа ачылган мөселман дини уку йортларында рус класслары (рус теле һәм математика укытыла) ачу күздә тотыла, аның чыгымнарын мәхәллә кешеләре күтәрергә, 16 яшькәчә барча шәкертләр рус классына йөрергә тиеш була *(Материалы по истории Татарии второй половины XIX в. – М. ; Л., 1936. – Ч. 1. – С. 289-291)*.

Насыйри бу материалны, аерым алганда, хөкүмәт тарафыннан бушлай рус-татар мәктәпләре оештырылу турындагы өлешен «Балаларны урысча укыту тугрысында» дигән баш астында үзенең «Казан календаре»ның беренче басмасына кертә.

Казан уку-укыту округында мөселманнар өчен ачылачак яңа уку йортлары белән җитәкчелек итәргә татар, башкорт һәм кыргыз (казакъ) мәктәпләренең инспекторы вазифасы кертелүе һәм аңа күренекле тюрколог Василий Васильевич Радлов (1837–1918) билгеләнүе очраклы гына килеп чыга.

1871 елда тюрколог В.В.Радлов, яңа эш урыны эзләп, Барнаулдан Санкт-Петербургка кузгала. Юлда Казанда туктала һәм Н.И.Ильминскийның фатирында очраклы рәвештә Казан уку-укыту округының попечителе П.Д.Шестаков белән таныша, соңгысы исә аңа әле гамәлгә кермәгән вазифаны – мөселман мәктәпләре инспекторы булырга тәкъдим итә. Тюркологтан ризалык алгач, 1871 елның 10 мартында П.Д.Шестаков халык мәгарифе министры Д.А.Толстойдан шундый вазифа кертелүне сорап хат яза *(Саматова Ч.Х. Имперская власть и татарская школа во второй половине XIX – начале XX века. Казань, 2013. С.93)*. Башкалага килгәч, Радлов министр белән таныша, соңгысы Дәүләт Советына Казан уку-укыту округында татар, башкорт, казакъ мәктәпләре инспекторы дигән вазифаны гамәлгә кертүне сорап мөрәҗәгать итә. Радлов, гадәттән тыш кыюлык күрсәтеп, Дәүләт Советы рәисе аша инспектор штатын кертү мәсьәләсе буенча карарны чираттан тыш кабул иттерүгә ирешә һәм телләр укытуның яңа методикалары белән танышу өчен тарихи Ватанына – Германиягә юл тота *(Штернберг Л. Из жизни и деятельности Василия Васильевича Радлова (берлинский, алтайский и казанский периоды). СПб., 1910. С.XVII–XVIII.)*

В.В.Радлов, инспектор итеп билгеләнүгә, 1871 елның ноябрендә Казанга килә һәм Каюм Насыйрига татар-мөселманнар өчен казна мәктәбе оештырырга тәкъдим итә. Насыйри 1876 елда Радловны үзенең бәхетенә Аллаһ җибәргән кеше дип атый *(Насыйри К. Казан шәһәрендә мөселман балалары русча укый торган мәдрәсәнең ибтидасы // Насыйри К. Сайланма әсәрләр. Ике томда. Беренче том. Казан, 1874.*

*Б.49).* Насыйри В.В.Радловның Казанда һәм губернада ачылачак беренче рус-татар мәктәбенең мөдире һәм укытучысы булырга дигән тәкъдименә ризалыгын бирә.

Насыйри бу вакытта инде чит телле аудиториядә тел укыту методикасын камил дәрәҗәдә үзләштергән тәҗрибәле мөгаллим була. Шунысын да билгеләп үтү мөһим: 1871 елдан башлап, Насыйри үзенең фатирында берничә татар малаена рус телен дә укыта. Шулай итеп, мөгаллим Насыйри казна педагогы булып китә.

Шулай да Идел-Урал төбәге мөселманнары империя хакимиятенең яңа башлангычын сагаеп кабул итә. Татар бистәләрендә яшәүчеләрнең хәтта югары хакка да дәресләр үткәрү өчен бина бирергә теләмәүләре татарларга рус телен укыту проектының яңалыгы белән генә түгел, Насыйриның православие уку йортында эшләгән дигән репутациясе белән дә бәйле булгандыр дип уйларга кала. Дин кардәшләре бойкот игълан иткәннән соң, мөгаллим рус-татар мәктәбен Казанның Болак артында урнашкан, начар даны таралган Мокрый бистәсенә урнашырга мәҗбүр була.

Мәктәп кабак урнашкан бинаның икенче катында ачыла. Насыйри анда 6-10 татар малаена рус теленнән һәм математикадан дәресләр бирә, үзе күрше бүлмәдә яши. Авылда, мөэмин-мөселман гаиләсендә халык традицияләрен, гореф-гадәтләрен хөрмәт белән үтәп, ислам әхлагында тәрбияләнгән Насыйри ике катлы шушы йортта яшәгәндә күп маҗаралар шаһиты була: кабакка йөрүче исерекләрнең сугышуына, сүгенүенә, оятсыз җырларына түзәргә туры килә. «Бичара бу адәм дә чикте җәфаны: астында – төне буе җырлыйлар, сугышалар, күрше бүлмәләрдә – кайсы кәвешче, кайсы тегүче, кайсы скорняк. Ишегалдында уртадагы өйдә – сыра заводы. Ишек алды артындагы өйдә ... яки кызлар ханәсе. Чыкса – урамы кабахәт; керсә – күршесе кабахәт. Халык сүзен ишетсә, яман сүз ишетә», – дип искә ала ул тормышының төрле яклап катлаулы бу чорын *(Насыйри К. Казан шәһәрендә мөселман балалары русча укый торган мәдрәсәнең ибтидасы. Б. 50)*. Насыйри бу кыенлыкларга алга таба да түзәр иде әле, әмма ике айдан соң мәктәпкә йөрүче калмый: малайларның һәркайсын рус-татар мәктәбенә йөргән өчен мәдрәсәләрендә хәлфәләре яткырып суктыра торган булганнар *(Шунда ук).*

Инспекторга барып шикаять кылырга аның мөселманлыгы җибәрми. Мәктәпнең буш калганын кемдер Радловка ирештергәч, анысы, Насыйрига басым ясап, укуны яңадан оештырырга куша. Мөгаллим бу юлы  үзенең таныш-белешләренең, элекке шәкертенең улын, аерым шәкертләренең агай-энеләрен туплап, кабат 10-15 баланы укыта башлый *(Шунда ук. Б.50-51).*

Насыйри икенче тапкыр мәктәбен Захарьев (хәзерге Каюм Насыйри) урамында – Шиһабетдин Мәрҗани мулла булып торган беренче мәхәлләдә, 2 нче гильдия сәүдәгәре Шаһиәхмәт Салиховның (1825–1885) ике катлы агач йортында ача *(Исламов Р. Насыйри һәм аны өйрәнү // Каюм Насыйри: Әдәби-тарихи һәм документаль-биографик җыентык. Б.5)*. Рус-татар мәктәбе дип язылган такта кадаклагач, халык «чиркәү вывескасы» дип сүз чыгара, кайсыберләре полициягә барып, бу эшне туктатырга сорый. Яңа урында да укучылар җыю җиңел булмый. Кайсы баланы атасына яки агасына әйтеп, димләп яисә башка кеше аркылы әйттереп, чакырып 20-25 укучы туплый, озакламый аларга тагын 6 малай өстәлә. Янәшәдәге Ш.Мәрҗани мәдрәсәсенең кайбер шәкертләре дә бирегә йөри башлый *(Мөхәммәтхәнәфи Мозаффар. Габделкаюм Насыйри әфәнде хакында // Каюм Насыйри: Әдәби-тарихи һәм документаль-биографик җыентык. Б.491-492)*. Сыйныфта авторитетка ия өлкәнрәк яшьтәге бер фәкыйрь малай, аяк киеме булмау сәбәпле, дәресләрне ташлый, башкалар да аның үрнәгенә иярә. Насыйрига, башкаларны син ияртеп йөрт дип, малайга кәвеш алып бирергә туры килә. Яз көне җирләр кипкәч, әлеге малай лимон сата башлый: балалар кабат сабактан туктый.

Укытучы бу малайны, лимон сатып табыш иткән акчасына өстәп, көн дә ун тиенлек көмеш тәңкә биреп җибәрә-җибәрә, яллап йөртә. Югыйсә аңар ияреп килгән балалар да сабактан туктарлар дип курка. Ахыр чиктә, яхшы сүз белән, йомшаклык белән сыйпап-

сыйпап, рус-татар мәктәбенә утызлап малайны иялəндерүгә ирешә *(Насыйри К. Казан шәһәрендә мөселман балалары русча укый торган мәдрәсәнең ибтидасы. Б. 51-52).*

Бу чорда Насыйри ай саен 25 сум күләмендә жалованье алып тора. Әмма зарланмый: аның өчен торак бушлай була, кичләрен казна фатирында шәһәр мәдрәсәләрендә укучы берничә шәкерткә репетитор буларак дәресләр бирә.

1872 елның җәендә Насыйри шушы ук урамда өченче бинага күчә, ниһаять, биредә ул 35 малайны туплап, укыту процессын җайга сала *(Шунда ук. Б. 50).*

Алда әйтелгәнчә, 1870 елның 26 мартында чыккан «Россиядә яшәүче инородецларны уку-укыту буенча күрелгән чараларның кагыйдәләре»ндә яңа ачылган мәдрәсәләрдә рус класслары булдыру күздә тотыла, аларның чыгымнарын халык күтәрергә тиеш була. Ләкин бу вакытка инде Казанда мәчетләр янында мәдрәсәләр эшләп килә, яңалары ачылырга тормый. В.В.Радловның закон буенча мөселманнар хисабына рус класслары ачарга хокукы булмый. Мөселман дин әһелләре инспекторга рус классларын булдыруны файдалы, хәтта кирәк дип санауларын әйтәләр, әмма шул ук вакытта мәдрәсәдә рус теле укытучысына жалованье түләрлек акча булмавын, үзләренең бушка укытуларын, ә мәдрәсәдә яшәп укучы шәкертләрнең дәресләр өчен түләрлек матди мөмкинлекләре юклыгын ассызыклыйлар.

Инспектор исә дәүләтнең мәктәп сәясәтен гамәлгә ашыру юлларын эзли. Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: бу елларда В.В.Радлов карамагында әле укытучы кадрлары да булмый, ул рус теле укытучыларын отставкага чыккан хәрбиләр, студентлар һәм һөнәри эшчәнлеккә бәйле русча укый-яза белгән кешеләр арасыннан таба. Хөкүмәтнең мәгариф өлкәсендәге сәясәте кысаларында Симферопольдә (1872), Уфада (1872–1876) дүрт еллык татар укытучылар мәктәпләре оештырыла, алар булачак рус теле һәм математика укытучыларын әзерләргә тиеш була. 1876 елда Уфа татар укытучылар мәктәбен Оренбургка күчергәннән соң, В.В.Радлов тырышлыгы белән Казанда яңа мәктәп ачыла. Мондый шартларда Радловның Казанда берьюлы дүрт зур мәдрәсәдә рус класслары ачарга ниятләвен зур батырлык дип бәяләргә кирәк. Инспекторның бу башлангычыннан, асылда, Насыйрига беркадәр файда булмый түгел. Моңа кадәр мөселманнарның яңа тәртипләргә карата тискәре мөнәсәбәте һәм усал сүзләре бер Насыйрига төшсә, хәзер инде русча укуга каршы торучыларның бөтен ачуы, ким дигәндә, 5 кеше арасында «бүленә».

В.В.Радлов, дин әһелләренең рус класслары ачуга тискәре дипломатик җавабын алганнан соң, Казан шәһәр думасына мөрәҗәгать итә. Игътибарны «гласныйларның мөселман өлеше рус уку йортларына күп тапкырлар акчалата ярдәм күрсәтүенә һәм ел саен шәһәр управасының православие мәктәпләрен асрау өчен шактый суммада акча бирүенә» юнәлтеп, инспектор 1872 елның 28 апрелендә ачарга планлаштырылган 4 рус классы укытучыларына һәм дәреслекләр алырга акча бүлү турында үтенеч яза. Үтенече кире кагылгач, Казан уку-укыту округы попечителе аша шәһәр бюджетыннан мөселманнарны уку-укыту өчен кирәкле сумманы юллап алуга ирешә.

Мулла вазифасын башкарганда, дәүләт телен белү кирәклеген яхшы аңлаган шәкертләр атнага ике тапкыр өстәмә дәрес уку турындагы яңалыкны уңай кабул итә, шулай итеп, берьюлы 200 шәкерт рус телен укырга җәлеп ителә *(Медресе г.Казани XIX – нач. XX вв.: Сборник документов и материалов. Казань, 2007. С. 25-26).*

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: моңа кадәр мәдрәсәләрдә рус телен укыту тәҗрибәсе булмау сәбәпле, В.В.Радлов җитди хаталар да ясый, нәтиҗәдә мөгаллимнәр белән шәкертләр арасында аңлашылмаучылыклар килеп чыга.

Таякның авыр башы К.Насыйрига да төшә. 1873 ел башында аны Апанай мәчете каршындагы мәдрәсәгә рус теле укытырга җибәрәләр. Хикмәт шунда: 1872 елда «Күл буе» мәдрәсәсе каршында рус классын оештыруны планлаштырганда, В.В.Радлов Апанай мәчете мөәзине Мостафа Исәнбаевка рус теле укытучы итеп К.Насыйри билгеләүен әйтә. Шәкертләргә дә бу хакта хәбәр ителә. Әмма рус классын ачар алдыннан инспектор яңа укытучы таба һәм тәҗрибәле Насыйрины рус-татар

мәктәбеннән аеру дөрес булмас дигән карарга килә. Ул, телдән генә әйтеп, мәдрәсәгә Фәхри Мусинны җибәрә. Шәкертләр исә, Каюм Насыйрины көтәбез дип, яңа укытучыны мәдрәсәгә кертмиләр. Рус теле укытучысы Ф.Мусинның документы да юклыгын белеп, шәкертләр аны усал сүзләр белән куып ук чыгаралар. В.В.Радлов, бу турыда белеп алгач, шәкертләрне хөкүмәт карарына буйсынмауда гаепләп, мәдрәсәне ябу артыннан йөри башлый. Гаугалы эш Казан губернаторы Н.Я.Скарятинга барып җитә, ул каршылыкка килгән ике яктан да шәхсән үзе сорау ала. Скарятин мәдрәсәне яптырмаска дигән карар чыгара, өстәвенә В.В.Радловның анда елдан артык булмавы һәм бу мәсьәләне үзе хәл итәргә тырышмавы ачыклана. Губерна җитәкчесе 1873 елның 13 гыйнварында В.В.Радловка К.Насыйрины, башта ук килешенгәнчә, мәдрәсәгә укытырга җибәрергә кушып, каршылыкка нокта куя *(Шунда ук. Б.26-27)*.

Шулай итеп, Казан губернаторының «җиңел кулы»ннан Насыйри хакимиятнең мәхәллә руханилары белән каршылыгының үзәгенә килеп эләгә. Мәдрәсә мөдире Сәлахетдин Исхаков үзенең кул астындагы шәкертләргә рус телен өйрәнүнең язык булуын искәртеп тора.

Сәлахетдин мулла, шәкертләренә рус телен үзләштерергә комачаулык итү максатыннанмы, әллә, чыннан да, урын җитмәү сәбәплеме, рус теле дәресләрен фәкать гомуми бүлмәдә генә үткәрергә рөхсәт бирә. Яңа типтагы уку йортларына кертелгән рус мәгариф системасы класс бүлмәсенә кара такта, парталар куюны күздә тота, дәрес вакытында текстларны язарга кирәк була. Аларның булмавы укыту сыйфатына тискәре йогынты ясый. Русча укыту ысулы дәрес вакытында тынычлык таләп итә, традицион укыту исә дини текстларны кычкырып укуга яки ятлауга корылган, бу исә Насыйри белән шәкертләр арасында еш кына килешмәүчәнлек китереп чыгара торган була. Насыйри бу җәһәттән үзе турында өченче заттан болай дип яза: «...мәдрәсәдә укытырга бер дә рәвеш юк. Йөзләп малай шаулап тора. Анда ничек шөгыльләнергә кирәк. Бары мәдрәсәдә аерым бер дәресханә кирәк иде. Болай булганда, шәкертләрдән русча укырга мәел кылучы (алынучы) адәмнәр күбрәк булыр иде. Инде кемнең акылы җитә? Начальник булган адәмдә тәҗрибә булмак кирәк. Югары начальниклар мәдрәсәләрдә русча укытылсын дип хөкем ясаганнар. Алар мәдрәсә ни кыяфәттә икәнлеген килеп күргәннәре юк. Алар бәлки гөман кылганнардыр (уйлаганнардыр) гимназияләр шикелле дип. Әгәр белсәләр, икенче тарикъча бер тәдбир ясарлар иде. [...] Шулай итеп, бу мәдрәсәне вөҗүдкә чыгару хосусында бу адәм өч ел михнәт кичте» *(Насыйри К. Казан шәһәрендә мөселман балалары русча укый торган мәдрәсәнең ибтидасы. Б. 55-56).*

Радлов Насыйриның укыту нәтиҗәләреннән канәгать булмый. Мөгаллим бу җәһәттән «яше узган шәкертләр»не рус сүзләрен дөрес әйтергә өйрәтү аеруча кыен, сөйләшергә өйрәтү турында сүз дә була алмый дип яза. Насыйри фикеренчә, хәтта Уфа татар укытучылар мәктәбендә махсус рус телен генә укучылар да күп нәрсәгә тиз генә өйрәнә алмаган. Менә ни өчен мәдрәсә шәкертләренә бәләкәй балаларга караганда да рус телен өйрәтү авыррак дип нәтиҗә ясый *(Шунда ук. Б.54).* Бу юлларны Насыйри 1876 елда халык мәгарифе министры граф Д.А.Толстой үткәргән инспекциядән соң, беренче чыгарылыш укытучыларының рус телен начар белүе сәбәпле, Уфадагы татар укытучылар мәктәбе ябылгач яза *(Загидуллин И.К. Татарское национальное движение в 1860–1905 гг. Казань, 2014. С. 105)*

Биш-алты айдан соң шәкертләр дә, укытучылар да В.В.Радловка атнага ике тапкыр гына рус теле дәресләренең аз булуы турында җиткерәләр.

Әмма 1873 елның көзендә проблема кабат катлаулана. 15 сентябрьдә имам-хатыйп һәм мөдәррис Сәлахетдин Исхаков, мәдрәсәдә рус телен укытудан баш тартып, Радловка хат яза. Ул инспекторны шәригать кануннарын санламауда гаепли. Имам мәдрәсә бинасында рус теле һәм грамотасына өйрәтү иганәче куйган таләпләргә каршы килә, иганәче теләге буенча мәдрәсәдә бары тик дин сабаклары укытылырга тиеш дип яза. Шәригать буенча, «иганәченең шартларын бозу ярамый, гөнаһ эш»

икәнен ассызыклап, үзенең бу кануннарны бозган өчен Аллаһ җәзасыннан куркуы хакында хәбәр итә. Шул ук вакытта мәчет руханиларының һәм мәхәллә халкының сәяси лояльлеген һәм законнарга буйсынып яшәвен, гыйбадәт вакытында Россия патшасына, аның гаиләсенә иминлек теләп дога кылуларын да әйтергә онытмый. Сүзләренең хаклыгын дәлилләр өчен, ул Коръәннән һәм тагын ике абруйлы дини китаптан өзекләр дә китерә *(Материалы по истории Татарии второй половины XIX в. С. 312-313)*.

В.В.Радлов исә мөдәрриснең әлеге гаризасы дәүләт сәясәтенә каршы килә дип саный.

Сәлахетдин Исхаков Радловка атап язган икенче хатында Апанай мәдрәсәсенә җирне әтисе иганә итүен, һәм ул, мөселман дине әһеле буларак, үзенең сүзләренең хаклыгына ышанып гамәл кылуын, «әгәр дә моннан каза күрә икән, ул Аллаһ җибәргән барлык җәзаны да күтәрергә әзер» икәнлеген искәртә. Бу Казан мөдәррисләре арасында хөкүмәт карарына ачыктан-ачык каршы чыккан беренче очрак була.

Казанның мөселман җәмәгатьчелеге, тын да алмый, мулла белән инспектор арасындагы тартышны күзәтә. Исхаковның җиңүе Радловның мәдрәсәләрдә (бушлай) рус класслары ачу турындагы карарын кире кагу өчен башка мөдәррисләрнең дә кулларын чишәр иде, чөнки мәдрәсә биналарының барысы да мөселманнарның дини гыйлем алу ихтыяҗын канәгатьләндерү өчен дип, бай татарлар иганәсенә төзелгән була.

Мәсьәләне «дөрес хәл итү»нең мөһимлеген һәм принципиальлеген инспектор да аңлый. В.В.Радловның «җиңел кулы»ннан Казан уку-укыту округының попечителе П.Д.Шестаков хөкүмәткә С.Исхаковны, муллалыктан төшереп, мөселманнар яшәмәгән «әчке губерния»ләрнең берсенә сөрү тәкъдиме белән чыга *(Материалы по истории Татарии второй половины XIX в. С. 316-317)*. С.Исхаковның үлеп китүе бу карарны тормышка ашырырга мөмкинлек бирми.

Рус телен укытуның кирәклеге мәсьәләсендә Насыйри белән Радлов бер фикердә булалар. Бу – алар арасындагы мөнәсәбәтләрне аңлау һәм бәяләүдә төп нигез. Радловның Насыйри турында бик үк яхшы булмаган сүзләреннән шул гына билгеле: рус теле укытучысының казна жалованьесын вакытында килеп алмавы (берничә айдан соң гына) инспекторның ачуын китергән, инспектор бу гамәлне үзенең күрсәтмәсен үтәүгә битарафлык күрсәтү дип кабул иткән *(Рәхим Г. Насыйриның тәрҗемәи хәле. Б.64)*.

В.В.Радловтан 1874 елның 12 октябреннән рус теле дәресләрен арттыру өчен ел саен бирелә торган акчаны 560 сумга кадәр җиткерү турында мөрәҗәгатьне алгач, Казан шәһәр думасы үзенең мөселманнарны укыту өчен ел саен акча бүлеп бирү турындагы карарын юкка чыгара. В.В.Радлов, күп көч һәм зур тырышлыклар белән башлаган эшен ярты юлда калдырмас өчен, Халык мәгарифе министрлыгыннан укытучылар өчен 800 сум акча алуга ирешә. Бу акчалар мәдрәсә биналарында рус теле укытуны тәэмин итү мөмкинлеге бирә.

Рус классларында дәресләрне тикшерергә килгәч, инспектор мәдрәсәдә дәүләт телен укытуның нәтиҗәсез булуына үзе дә инана. Тырыша торгач, 1875 елның 9 июнендә ул Казан шәһәр думасыннан мәдрәсәләр каршында рус класслары өчен арендага махсус бүлмәләр алу өчен ел саен 500әр сум алуга ирешә. Һәм Радлов болай эшли: 1) 5нче җәмигъ мәчете мәдрәсәсе каршындагы рус классын Тихвин урамындагы татар малайлары өчен казна мәктәбендә ача, аңа Казан университеты студенты Шаһбазгәрәй Әхмәровны укытучы вазифаларын башкаручы итеп билгели; 2) 1нче җәмигъ мәчете каршындагы рус классын Захарьев урамында урнашкан бинада ача, анда укытучы итеп Мөхәммәтҗановны билгели; 3) өч мәдрәсә (Яшел мәчет, Завод мәчете һәм Апанай мәчете) шәкертләре өчен рус классын Иске Татар бистәсендәге Зур Мещан урамында бер бинада ача, анда укытучы вазифасын башкаручы итеп Ветеринария институты студенты Ибраһим Терегуловны билгели; 4) тагын өч мәдрәсә өчен рус классын Яңа Татар бистәсендә Кече Себер урамында ача, анда отставкага

чыккан унтер-офицер Гариф Газиевны билгели. Уку-укыту ведомствосы биргән 800 сум акчаны ул түбәндәгечә бүлә: Иске Татар һәм Яңа Татар бистәсендәге рус класслар укытучыларына 300әр сум һәм барлык классларга дәреслекләр алу өчен – 200 сум *(Медресе г.Казани XIX – нач. XX вв. С. 41-42).*

Шул рәвешле, В.В.Радлов баштагы планнарын үзгәртергә һәм рус классларының чыгымнарын өлешчә казна хисабына күчерергә мәҗбүр була, иң мөһиме – әлеге уку йортларының статусы рус класслары сыйфатында кала, алар, асылда, Иске һәм Яңа Татар бистәләрендәге урнашкан мәдрәсәләрдә укучыларга рус телен өйрәтергә тиеш була.

Тулаем алганда, үзен югары компетентлы педагог дип санаган Насыйриның үзенә күзәтчелек итүче чиновник В.В.Радловка карата мөнәсәбәте тигез генә булмый. Чит телле аудиторияләрдә укыту буенча зур тәҗрибәсе булган, дәреслекләр авторы Насыйри В.В.Радловның укыту процессын оештыруга куелган таләпләренә, укучылар белән аралашу рәвешенә, үз-үзен тотышына тәнкыйди күзлектән карый.

Кайчагында Радлов та, Насыйри да төрле катлаулы хәлләргә тара. Радлов дәрескә Халык мәгариф министрлыгының инспекторы формасын киеп килә торган була, шул сәбәпле балалар аны рус чиновнигы буларак кына кабул итә. (Ул заманда әниләр кечкенәдән балаларын: «Җылама, руска бирермен», – дип үстергәннәр) *(Насыйри К. Казан шәһәрендә мөселман балалары русча укый торган мәдрәсәнең ибтидасы. Б. 52).*

Насыйри үзенең хатирәләрендә Радловның училищеда үз-үзен тотышын болай сурәтли.

Беренче очрак. Рус-татар мәктәбенә килгәч, инспектор төрле әйберләргә күрсәтеп, балаларга шуның русчасын әйтергә куша. Укучылар алдан әзерләнмәгән була, яңа килгән укучылар, паникага бирелеп, куркып кала. Шулай ук инспектор балалар алдында укытучыдан аларның кайсы сословиегә караулары турында сорый: кем крестьян баласы, кем мещанныкы, кем сәүдәгәрнеке. Радлов авызыннан чыккан сүзләр арасыннан балалар «крестьян» дигәнен «крестить» дип аңлап калалар, икенче көнне бөтенләй мәктәпкә килмиләр.

Икенче очрак. Германиядән йөреп кайткан В.В.Радлов сентябрьдә мәктәпкә төрле рәсемнәр тотып килә. Аларны тактага элеп куя һәм алты ай үзе булмаганда укучыларның нәрсәгә өйрәнгәннәрен рәсемнәргә төртеп күрсәтә-күрсәтә тикшерә башлый. Юньле-рәтле җавап ала алмагач, балаларга кычкыра, Гамбургта шушы ысул белән укыталар дип сөйли. Насыйри яңа технологияләрне әкренләп кертергә кирәк дип җавап бирә. Бу хәлне белеп алган кайбер ата-аналар, балаларны сурәткә табынырга өйрәтләр икән дип, аларны мәктәптән ала. 1872 елның гыйнварына кадәр мәктәптә 5-6 укучы була, март-апрель айларында гына 32 бала җыела. Үзенең хатасын аңлап, Радлов кыш буе мәктәпкә килми *(Шунда ук. Б. 52, 53, 54).*

1872 елда рус-татар мәктәпләрендә В.В.Радловның «Белек. Балалар укыр өчен чыгарылган китап» («Белек. Книга, изданная для чтения детьми») дигән хрестоматиясен куллана башлыйлар, аның максаты рус-татар мәктәпләрендә укучыларны дөньяви белемнәр белән таныштыру һәм әхлакый тәрбия бирү була. Радловның уку китабы татар сөйләмә телендә язылган, 6 тематик бүлеккә бүленгән, анда табигать белеменнән, география, астрономия, зоология, тарих һәм башка фәннәрдән 162 гыйбрәтле хикәя һәм фәнни-популяр очерк тупланган була *(Закирова Л.Н. Василий Васильевич Радлов: казанский период деятельности: Монография. Казань, 2013. С. 190, 191)*. Дәреслек «Бисмилләһи әр-рахмән ир-рәхим» дип башлана һәм алга таба да анда Аллаһның барлыгы һәм берлеге турында языла *(Штернберг Л. Күрс. хезмәт. Б. XVI – XVII)*.

1874 елдан рус-татар мәктәпләрендә Радлов төзегән «Беренче уку китабы» дәреслеге кулланыла башлый.

Насыйри мөдирлек иткән мәктәпкә килгәндә, инспектор үз дәреслекләренең кулланылу дәрәҗәсен дә тикшерә торган була. Кайсыдыр бер килүендә Радлов, укучыларның дәфтәрләрен тикшергәндә, алар кулланган дәреслектән бер җөмләнең

сызылуын ачыклый. Сүз Насыйриның «Белек» яки «Беренче уку китабы»ндагы текстка үз төзәтүләрен кертүе турында барадыр дип уйлыйбыз.

Үзе төзегән дәреслектән сүзләрнең сызылуын Радлов авыр кабул итә һәм Насыйридан бу гамәленең сәбәбен аңлатуын таләп итә. Укытучы бу җөмләне сызарга мәҗбүр булуын әйтә, чөнки нәкъ шушы җөмлә аркасында берничә малай мәктәпне ташлады ди: ул җөмлә укучыларның әниләрендә нәфрәт уята икән. Шулай ук рус теленә тәрҗемә итеп белемнәрне ныгыту өчен үзенең «Кырык вәзир кыйссасын» тәкъдим итә, ул китапта халыкта шик уятырдай сүзләр юк дип ассызыклый *(Мөхәммәтхәнәфи Мозаффар. Габделкаюм Насыйри әфәнде хакында. Б. 492)*. Сөйләшүне югары тонда дәвам иттереп, В.В.Радлов алга таба Насыйрига китаптагы бер генә сүзне дә үзгәртмәскә куша. Насыйри инспекторның күрсәтмәләрен үтәүдән кискен баш тарта. Аның үзбелдеклеләнүенә ачуы килеп, В.В.Радлов аңа, кушканнарны үтәмәгән очракта, вазифасыннан китәргә боера. Үз дөреслегенә инанган Насыйри, бу текстны укыганчы, эшеннән китүне кулай күрәчәген әйтә. Шулай да, күпмедер вакыт узуга инспектор да, укытучы да кайтып төшә: Насыйри рус-татар мәктәбендә эшләвен дәвам итә *(Рәхим Г. Насыйриның тәрҗемәи хәленә гыйлавә. Б. 84)*.

1875 елда Насыйри Яңа Татар бистәсендәге рус-татар мәктәбенә күчерелә (гәрчә ул үзен элекке урынында калдыруын үтенә, чөнки аннан нәшрияткa йөрү, өйдә дәресләр алып бару уңайлы, иң мөһиме – укучылар аңа ияләшкән һәм, ул китсә, балалар мәктәпне ташлаячак дип борчыла) *(ТӘһСИнең Язма мирас үзәге, 11 ф., 1 тасв., 29 сакл. берәмлеге, 83 б., 83 битнең арты),* аның урынына Ибраһим Терегулов билгеләнә *(Рәхим Г. Насыйриның тәрҗемәи хәленә гыйлавә. Б.85).*

Бу вакытка Насыйри инде педагог буларак тәмам өлгереп җиткән, ул үзенең мәгърифәтчелек проекты булган «Казан календаре»н ел саен чыгара килә, дәреслекләр төзи. Шул сәбәпле, 1875 елны кече энесе Габделкавиның Зөя өязе земствосы управасына елына 800 сум хезмәт хакы белән эшкә кайтырга чакырган тәкъдименнән дә баш тарта *(Энесе Габделкави язган хатлар // Каюм Насыйри: Әдәби-тарихи һәм документаль-биографик җыентык. Б. 592)*.

Насыйриның Казан рухани семинариясендәге укучыларының берсе – Василий Владимирович Катаринский – 1875 елда яңа ачылган Оренбург уку-укыту округының татар, башкорт һәм казакъ мәктәпләре инспекторы итеп билгеләнә. В.В.Катаринский, Оренбургта рус-татар мәктәбе ачу өчен финанслар тапкач, 1876 елның 25 ноябрендә Насыйрины чакырып хат яза *(ТӘһСИнең Язма мирас үзәге, 11 ф., 1 тасв., 19 сакл. берәмлеге, 83 б., 25 б.)*.

Тик Насыйри Казанда кала. Бу вакытта ул үзе теләгән кыяфәттә рус-татар мәктәбен корган була инде. Ирешкән уңышларын ул түбәндәгечә тасвирлый: «...мәдрәсәнең сыйфаты гимназия классларыннан бер дә ким түгел. Һәммәсе Европа мәдрәсәләрендәгечә төзелде. Класс скамьялары һәйбәт, балалар шөгыль вакытында әдәп-инсаф белән утыралар, күргән кеше хәйран булырлык» *(Насыйри К. Казан шәһәрендә мөселман балалары русча укый торган мәдрәсәнең ибтидасы. Б. 57).*

Моңардан тыш, күрәсең, Насыйри үзенең мәгърифәтчелек эшчәнлеген университетлы Казан белән генә бәйләргә карар иткән була.

Инде әйтеп үтелгәнчә, рус-татар мәктәбендә ислам дине нигезләрен укыту өчен дә сәгатьләр каралган була. Үзе мөдирлек иткән рус-татар мәктәбендә бу сәгатьләрне К.Насыйри үзе укыткан. Ул, 1876 елның 3 июлендә Уфада Мәхкәмәи шәргыядә имтиханны уңышлы тапшырып, имам-хатыйп һәм мөдәррис дәрәҗәсе турында шаһадәтнамә ала *(БР МА. И-295 фонд, 4 тасв., 10554 сакдау берәмлеге, 2 б. – 3 битнең арты)*. Шул рәвешле дини дәрәҗәсе буенча үзен гаепләүче муллалар белән тигезләшә.

1876 елның 13 сентябрендә, В.В.Радлов тырышлыгы белән, Казанда тантаналы рәвештә Татар укытучылар мәктәбе ачыла, аның инспекторы итеп Мөхәммәтгали Мәхмүтов билгеләнә. Уку йортына әсбаплар кирәк була. Ярдәм күрсәтергә теләп, К.Насыйри Укытучылар мәктәбенә татар телендә язып ярымшарлар картасын һәм биш

кыйтга картасын бүләк итә. Карталар Санкт-Петербургта язуларсыз гына басылган була. «Казан татар мәктәбенең рус теле укытучысы» төзегән карталарның зур хезмәт икәнлеген һәм аларның Укытучылар мәктәбендә география укытуда файдалы булачагын билгеләп, Мәхмүтов 1877 елның 15 июлендә Казан уку-укыту округының попечителе П.Д.Шестаковка Насыйровка географик карталар бүләк иткәне өчен рәхмәт белдерүне сорап мөрәҗәгать итә *(Казанская татарская учительская школа 1876-1917 гг.: Сборник документов и материалов. Казань, 2005. С.24-25)*.

Насыйриның мәктәптән китүе В.В.Радлов белән рус телен укыту методикасы яки дәреслекне куллану буенча килеп чыккан каршылыкларга бәйле түгел, сәбәп башкада була. Насыйри эшләгән уку йортының бинасында черегән идән тактасы сынып, укытучы тирән чокырга егылып төшә. Шунда салкын су йотып, чактан гына тончыгып үлми кала. Аны күпмедер вакыттан соң гына күреп алып, аңсыз хәлдә табып алалар һәм медицина ярдәме күрсәтәләр. Ул аңына килә, әмма шок хәлендә була.

Каюмны олы абыйсы Габделхәй үзенә алып карый, дәвалый. Кайбер мәгълүматларга караганда, Насыйрида нерв горячкасы була. Ярты ел буена ул каты авырый, еш кына чынбарлыкны томый, саташа *(Рәхим Г. Насыйриның тәрҗемәи хәленә гыйлавә. Б. 84)*. Бу фаҗигале хәлдән соң Насыйри бик каты стресс кичерә, ул инде мәктәпкә укытырга кайтмый.

1871–1877 елларда рус теле һәм математика укытучысы булып эшләү аны дөньяви белемнәр тарату өчен Календарьларында Россиянең географиясе һәм тарихы буенча текстлар бастыруга этәрә *(Насыйри К. «Казан халкына мөрәҗәгате»ннән // Насыйри К. Сайланма әсәрләр. Ике томда. Беренче том. Казан, 1974. Б.44)*. 1873 елда – аның «Хисаплык» («Математика») дәреслеге, ә 1875 елда 72 битлек «Татарча-русча лөгать китабы» дөнья күрә.

Мөгаллимлек чорында Насыйри шәркый телләрдәге әсәрләрне туган телгә тәрҗемәләрдә әзерләүне дәвам итә. 1872 елда Насыйри госманлы теленнән ирекле тәрҗемә ясаган күренекле мөселман галиме, философ, юрист һәм табиб Әбүгалисина (980–1037) турындагы «Әбүгалисина» повестен нәшер итә (1881, 1889, 1894, 1898. 1900 елларда кабат бастырыла) *(Каюм Насыйриның басылып чыккан хезмәтләре // Насыйри К. Сайланма әсәрләр. Ике томда. Икенче том. Казан, 1975. Б. 294)*.

Шул рәвешле, К.Насыйри тарихка Казан губерниясендә малайлар өчен беренче, Казан уку-укыту округында икенче башлангыч рус-татар мәктәбенә нигез салучы булып кереп кала.

Насыйриның рус теле укытучысы буларак эшчәнлеген чагылдырган чыганаклар мәгърифәтченең сабыр, төрле тормыш сынауларын фәлсәфи бәяли торган, үзенең кылган гамәлләрендә нык иманлы, туган халкына файда китерү омтылышларында дин кардәшләре тарафыннан түбәнсетүләрне һәм гаделсезлекләрне башын югары тотып кичергән шәхес булуын раслый. «Мөгаллимлек дәвере»нә йомгак ясап, Насыйри үзенең эшчәнлеген «дөрес гамәл» дип бәяләгән, ул туган халкын мәгърифәтле итү миссиясенә инанган: «Моннан соңгылар, әлбәттә, файдаланырлар. Халык та күнегер, тыныч булыр, неприятно сүзләр ишетелмәс. Әмма һәрбер нәрсәне әүвәл башта ихтираг кылган, вөҗүдкә чыгарган (уйлап тапкан, эшкә ашырган) адәмнәр, халыкның тәгънәсеннән (тиргәвеннән) башка нәрсә хасил итмиләр. Нитәкки, Колумб вә һәм Гутенберг вә гайреләрнең кыйссалары мисалы мәшһүрдер (һәркемгә билгеле мисалдыр). Аларның хасиятен соңгы гасырдагы адәмнәр генә беләләр» *(Насыйри К. Казан шәһәрендә мөселман балалары русча укый торган мәдрәсәнең ибтидасы. Б. 57)*.

Нәкъ менә укытучы булып эшләгән чорда, схоластик укыту һәм традицион фикерләү белән көрәштә, шәкертләрне рус теленә һәм математикага өйрәткәндә, Насыйри тарафыннан алдагы гамәлләренең программасы эшләнгән, калган гомерен ул шуны тормышка ашыруга багышлаган.

**Илдус ЗАҺИДУЛЛИН,**
*тарих фәннәре докторы.*

# *Әдәби мизгелләр*

*18 сентябрьдә «Яңа исем» иҗат лабораториясе шәкертләре, аларның остазлары һәм язучылар Вахит Имамов, Ләбиб Лерон, Вакыйф Нуриев, Гәүһәр Хәсәнова, Рөстәм Галиуллин, шагыйрьләр Рифат Сәлах, Лилия Гыйбадуллина, проектның кураторы Гөлүсә Закирова Арча районына сәфәр кылды. Алар Әдәбият һәм сәнгать музеенда Гариф Ахунов, Гомәр Бәширов һ.б Арча төбәге язучыларының экспозицияләре белән танышты, Гөберчәктә Мөхәммәт Мәһдиев музеена кереп, әдипнең туган авылындагы каберен зиярәт кылып чыкты.*

*7 октябрьдә «Яңа исем» шәкертләре шулай ук остазлары Ләбиб Лерон, Рөстәм Галиуллин, Ландыш Әбүдәрова белән Яңа Татар зиратында булды. Аларга экскурсияне Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге Казан югары мөселман мәдрәсәсе ректоры Ильяс хәзрәт Җиһаншин үткәрде. Яңа Бистә зиратында татарның күренекле шәхесләре каберләрен караганнан соң, экскурсия мәдрәсәдә дәвам итте.*



*Арчаның Әдәбият һәм сәнгать музеенда. Сулдан уңга: Гәүһәр Хәсәнова, Мәрьям Ибраһимова, Азалия Сабитова, Лилия Гыйбадуллина, Рөстәм Галиуллин, музей мөдире Дамир Абдуллин, Вакыйф Нуриев, Рифат Сәлах, Алинә Хәбибуллина, Ихтыяр Кыямов, Зәбирә Габделхакова, Ләбиб Лерон, Гөлүсә Закирова.*



*Гариф Ахуновның эш өстәле.*




*Арчаның Әдәбият һәм сәнгать музее.*



*Гөберчәктә Мөхәммәт Мәһдиев музеенда. Сулдан уңга (басканнар): музей мөдире Халидә Габидуллина, Мәрьям Ибраһимова, Азалия Сабитова, Вакыйф Нуриев, Лилия Гыйбадуллина, Гәүһәр Хәсәнова, Рөстәм Галиуллин, Ихтыяр Кыямов, Рифат Сәлах; утырганнар: Ләбиб Лерон, Вахит Имамов.*

*Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге Казан югары мөселман мәдрәсәсе музеенда. Сулдан уңга: Ихтыяр Кыямов, Наил Кадыйров, Гөлүсә Закирова, Рөстәм Галиуллин, Фәрит Мифтахов, Ләйсән Низамова, Вахит Имамов.*







*Яңа Бистә зиратында Габдулла Тукай кабере янында. Сулдан уңга: Ландыш Әбүдәрова, Гөлинә Фәрхуллина, Мәрьям Ибраһимова, Ләйсән Низамова, Рөстәм Галиуллин, Ильяс Җиһаншин, Ләбиб Лерон, Ихтыяр Кыямов, Фәрит Мифтахов, Гөлүсә Закирова.*

*Вахит ИМАМОВ, Гөлүсә ЗАКИРОВА фотолары.*

*Шәрәф Мөдәрриснең тууына – 105 ел*

# ГОМЕРЕ КӨРӘШЛӘРДӘ ҮТКӘН



Быел ноябрь ае юбилейларга бай. Татарстан радиосында милләтебез олпатларының юбилейлары уңаеннан әзерләнгән тапшырулар ай дәвамында эфирга чыгып килә, һәм без эшебезне фронтовик шагыйрь Шәрәф Хасиятулла улы Мөдәрриснең (1919–1963) иҗатына багышланган махсус сәхифә белән башлап җибәрдек.

Журнал укучылар игътибарына исә без хәзер инде тарихи дип әйтелергә хаклы бер аудиоязма тәкъдим итәбез. Күренекле шагыйрь һәм журналист мәрхүм Әхмәт Рәшит 1990нчы еллар ахырында Шәрәф Мөдәррискә багышлап зур бер тапшыру әзерләгән иде. Монда шагыйрьнең шәхесе дә, иҗатының зурлыгы да бөтен тулылыгы белән ачыла. Тапшыруны Әхмәт ага болай дип башлап җибәрә:

«Шәрәф Мөдәррис куркып, партия түрәләре каршында калтырап яшәмәде, ул үзенчә хөкем йөртте, үз иманына тугры булып иҗат итте. Шуның аркасында байтак кына кыен да ашады. «Казан утлары» журналында Шәрәф абыйның хатыны Ләбибә ханым Ихсанова «Кемгә сөйлим серләремне?» дигән бик гыйбрәтле истәлек-повесть бастырды. Замана хакында ачы хакыйкать! Шәрәф абыйның шактый авыр тормышы да, иҗади эзләнүләре-бәргәләнүләре дә, әдәби чиновниклар белән компромиссыз көрәшкә ташланулары да шактый тулы бәян ителгән анда.

«Шагыйрь җәмгысе 44 елдан торган гомер юлын тоташ тынгысызлыкта, тоташ эзләнүдә үткәрде. Беренче китабы чыкканда, аңа 18 яшь кенә иде әле. Сугыш вакытында туплар гөрселдәве тынып торган араларда атаклы «Тупчы Ваһап» поэмасын иҗат итте. Тыныч тормышка кайткач, яңа дәрт белән эшкә кереште. Шигырьләр, җырлар, поэмалар... Шекспир сонетлары, Байрон, Бёрнс шигырьләре – болары турыдан-туры инглизчәдән. Немец телен исә ул фронт газетасында эшләгәндә өйрәнә башлаган иде. Монысы Һейне шигырьләрен тәрҗемә иткәндә ярап куйды. Шагыйрьнең итальян, испан, хәтта латин телләре белән мавыгуы, бөтендөнья тарихын һәм әдәбиятын яхшы белүе мәгълүм. Шуның өстенә газета-журналларда публицистик мәкаләләр, памфлетлар, фельетоннар, татар шигъриятендә иң беренчеләрдән булып яңа жанрда – сонетлар язарга алынуы, татар мохитендә шау-шу куптарган «Әбдүш Ялаяпов» повесте... Фронт юлларында чын ирләрчә чыныгу алган, фашист илбасарлары белән йөзгә-йөз очрашканда да куркып калмаган, ә нигә ниндидер партия чиновнигы алдында калтырап төшәргә тиеш әле ул?!»

Тапшыруда сез шулай ук танылган радио режиссёры мәрхүм Госман Әхмәтҗанның Шәрәф Мөдәррискә кагылышлы истәлекләрен, шагыйрьнең шигырьләренә язылган җырлар ишетерсез. Әлбәттә инде, биредә урын алган язмалар арасында иң кадерлесе – Шәрәф Мөдәрриснең үз тавышы. 1960нчы еллар башында ул үзенең фронт хатирәләрен магнитофон тасмасына яздырып калдырган булган.

Сугыш кырларында илебез азатлыгын, тыныч тормышта милләт мәнфәгатьләрен яклап көрәшкән батыр шагыйрьне хөрмәт белән искә алыйк.

*Тимергали Зиннуровның тууына – 75 ел*

# УЛ ЯЗМЫШЫН ТЕАТРГА БАГЫШЛАДЫ



Татарстанның халык артисты, заманында Кәрим Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театрында сәхнә тоткан актёрларның берсе Тимергали Зиннуровның (1949–2017) тууына – 75 ел.

2015 елда драматург Рәдиф Сәгъди белән без аның фатирында кунакта булган идек. Тимергали абый, катлаулы операциядән соң үз хәлен үзе генә белә торган бер халәттә булуына карамастан, ачык йөз белән каршы алды, үзен чын егетләрчә тотты, нәкъ элеккечә шаярып, уйнап-көлеп сөйләште. Театрга, сәнгатькә бәйле хатирәләре яңарды, сөенечләре, үкенечләре өскә калкып чыкты, хәтта Рәдиф белән гармун уйнап, җырлашып та алдылар. Гомеренең соңгы ноктасы якынлашуын сизенепме, ул безгә васыять итеп сөйләрлек фикерләрен, яшерен серләрен дә әйтте кебек. Кыскасы, безнең алда җаны-тәне белән театрга багышланган кешенең күңеле бөтен барлыгы белән ачылып китте. Һәм менә шул вакытта язып алынган әңгәмә хәзер сезнең игътибарга тәкъдим ителә.

Тимергали Зиннур улы Зиннуров 1949 елның 18 ноябрендә Лаеш районы Пәрәү авылында дөньяга килә. 1967 елдан – Казан дәүләт курчак театры актёры. Биредә ул шактый күп рольләр башкара, үзен курчакларга тавыш бирүче генә түгел, әсәрнең жанры таләп иткәнчә, аларның характерларын ачарга сәләтле актёр итеп күрсәтә. 1982 елда аны Кәрим Тинчурин исемендәге театрга эшкә чакыралар. Монда инде ул үзен чын сәнгать остасы итеп таныта. Сәхнә мөлаемлыгы, образның психологиясен тирәннән аңлавы, лирик, драматик, шулай ук комик рольләрне бертигез җиңеллек белән уйнавы аңа истә калырлык күп кенә матур образлар тудырырга мөмкинлек бирә. Шундыйлардан Аяз Гыйләҗевнең «Ефәк баулы былбыл кош» спектаклендә – Мияссәр, Туфан Миңнуллинның «Без бит авыл малае», «Алай түгел, болай ул», «Гармун» спектакльләрендә – Иршат, Гармунчы, Мәрди, Нәкый Исәнбәтнең «Хуҗа Насретдин»ында – Бики, Рәдиф Сәгъдинең «Сынган беләзег»ендә Зиннур роле һ.б. Театрда узган 30 елдан артык иҗат гомерендә әнә шундый берсеннән-берсе кызыклы дистәләгән образлар тудырды ул. Тамашачы аны үз итте, яратты.

Сез хәзер тыңлаячак тапшырудан бер генә җөмләне кәгазьгә күчерик. Әйткәнемчә, әңгәмә язылганда, Тимергали абый авыру иде һәм ул болай диде: «Артист сәхнәдән киттеме, сүрелә башлый, минем күп кешеләргә игътибар иткәнем бар. Мин дә авырып яттым менә. Хатыным Гөлфия әйтә, бүген театр фәлән авылда гастрольдә икән ди. Мин күз алдына китереп ятам, оһо, минәйтәм, болар барып җиттеләр, чәй эчәләр, грим салалар. Аннары тагын сәгатькә карап утырам, менә спектакль бетте, алкышлар. Кайтырга чыгалар... Менә шулай итеп санап үткәрдем гомерләрне...»

Театрга бирелгәнлек менә нинди була ул! Әйе, ул сәхнәгә ашкынды, хыялында йөрткән рольләре күп иде...

*Сәхифәне «Татарстан» радиосының шеф-мөхәррире* **Нәсим АКМАЛ** *алып бара.*

# 100 000 СУМ

## һәм башка бүләкләр

**Әлеге чараны оештыручы, кагыйдәләре, бүләкләр саны, уйнату вакыты һәм урыны буенча мәгълүматны tatmedia.ru сайтында белә аласыз.**

Акция 2024 елның 15 октябреннән 2025 елның 20 мартына кадәр уздырыла. Гаризалар 26.01.2025 кадәр кабул ителә. Реклама. Яшь чикләве 16+. Бүләкләр рәсемдәгедән аерылырга мөмкин.

ТАТ МЕДИА



# Ictimaği-mədəni tormışıbızdan
# Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

## КАЗАНДА БРИКС САММИТЫ

Башкалабыз Казан шәһәрендә XVI БРИКС саммиты булып узды. Ул 22 октябрьдә делегация башлыкларының очрашу тантанасы белән башланып китте. Икенче көнне БРИКС саммитының тар һәм киңәйтелгән форматтагы утырышлары узды. Чараның өченче көнендә XVI БРИКС саммитының «аутрич» / «БРИКС плюс» форматында пленар утырышлары булды. Россия Федерациясе Президенты Владимир Путин матбугат конференциясе үткәрде.

Казандагы БРИКС саммиты – соңгы вакытта уздырылган тышкы сәяси форумнарның иң зуры. Анда 35 дәүләт, 6 халыкара оешма катнашты, 20дән артык делегацияне лидерлар җитәкләде. Башкалабыз 20 меңгә якын кунакны кабул итте. Саммитның эшен 2 меңгә якын журналист яктыртты.

Кемнәр генә килмәде Казаныбызга: Кытай Рәисе Си Цзиньпин, Һиндстан Премьер-министры Нарендра Моди, Мисыр Президенты Абдел Фәттах әс-Сиси, Көньяк Африка Республикасы Президенты Матамела Сирил Рамафоса, Палестина Президенты Мәхмүд Аббас, Төркия Президенты Рәҗәп Тайип Эрдоган, Иран Президенты Масуд Пезешкиан, Эфиопия Премьер-министры Абий Әхмәт, Вьетнам Премьер-министры Фам Минь Тинь, БДБ илләре Президентлары һ.б. Шулай ук Берләшкән милләтләр оешмасы Генераль секретаре Антониу Гутерриш, Яңа үсеш банкы башлыгы Дилма Руссефф та Татарстан башкаласының кунаклары булдылар. Россия Федерациясе Президенты Владимир Путин алар һәм башка лидерлар белән ике яклы очрашулар үткәрде.

Саммитта оешманың барлык әгъзаларының мәнфәгатьләренә туры килә торган икътисади мәсьәләләр (сәүдә бәхәсләрен хәл итү өчен механизмнар, инвестиция, кыйммәтле металлар буенча платформалар, үзара исәп-хисап, ашлык биржасы, махсус икътисади зоналар арасында туры элемтә һ.б.) каралды. Киләчәктә БРИКС илләренең хезмәттәшлеген өч магистраль юнәлештә (сәясәт һәм иминлек, икътисад һәм финанс, мәдәни һәм гуманитар бәйләнешләр) киңәйтү һәм тирәнәйтү күздә тотыла.

БРИКС саммитында катнашучылар йомгаклау декларациясе кабул итте. В.Путин Казан декларациясенең уңай эчтәлекле, концептуаль документ булуын әйтте. Ул көннәрдә дөньяның карашы Казанга төбәлде. ТР Рәисе Рөстәм Миңнеханов билгеләп үткәнчә, мондый зур дәрәҗәдәге вакыйганы үткәрү республика өчен зур мәртәбә һәм җаваплылык иде.

## МОСТАЙ КӘРИМНЕ ИСКӘ АЛУ

Күренекле язучы, прозаик, шагыйрь, драматург Мостай Кәримнең тууына 105 ел тулу уңаеннан әдипнең Казандагы һәйкәле янында (Оренбург тракты белән Даурия урамнары кисешкән чатта, М.Кәрим скверында) искә алу чарасы узды. Анда Татарстан һәм Башкортстан Язучылар берлекләре рәисләре Ркаил Зәйдулла, Айгиз Баймөхәммәтов, Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллин, язучы Ринат Мөхәммәдиев, Татарстан Халыклар ассамблеясе Советы башкарма комитеты җитәкчесе Ренат Вәлиуллин, Татарстан Халыклар дуслыгы йорты директоры Тимур Кадыйров, Казандагы башкорт милли-мәдәни автономиясе рәисе урынбасары Тимур Йосыпов һ.б. чыгыш ясады.

## ЮБИЛЕЙ КҮРГӘЗМӘСЕ

«Сабантуй» журналына (элек «Яшь ленинчы» газетасы) – 100 ел. Шул уңайдан «ТАТМЕДИА» бинасының беренче катында басманың тарихына, анда эшләгән кешеләргә багышланган күргәзмә ачылды. Аны ачу тантанасында редакция коллективын, басманың ветераннарын, тәүге иҗат җимешләре шушы мәйданда дөнья күргән каләм ияләрен, килгән кунакларны Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе Айдар Сәлимгәрәев, «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте генераль директоры Шамил Садыйков, 1977–1986 елларда «Яшь ленинчы» газетасының баш мөхәррире булган язучы, журналист, җәмәгать эшлеклесе Роза Туфитуллова, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла, Татарстанның халык шагыйре Ренат Харис һ.б. котлады. Бәйрәмне филиал җитәкчесе, язучы Зиннур Хөснияр алып барды.

## КАЗАКЪ ШИГЪРИЯТЕ АНТОЛОГИЯСЕ

Татарстан Язучылар берлегенең «Язучы» нәшриятында «Хәзерге заман казакъ шигърияте антологиясе» басылып чыкты. Әлеге

китапка бүгенге көндә Казакъстан Республикасында киң танылу алган төрле буын казакъ шагыйрьләренең шигырьләре туплап бирелде

### ХӘЗЕРГЕ ЗАМАН АЗӘРБАЙҖАН ХИКӘЯЛӘРЕ АНТОЛОГИЯСЕ

Татарстан Язучылар берлегенең «Язучы» нәшриятында «Хәзерге заман азәрбайҗан хикәяләре антологиясе» басылып чыкты.

### Г.АФЗАЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ФЕСТИВАЛЬ

Татарстанның халык шагыйре Г.Афзал исемендәге республика иҗат фестивале уңаеннан Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла җитәкчелегендә язучылар делегациясе Актанышка кайтты. Кунаклар арасында Татарстанның халык язучылары Марсель Галиев, Камил Кәримов, Вахит Имамов, язучылар Мөхәммәт Мирза, Хәбир Ибраһимов, Алмаз Хәмзин, Гүзәл Әдһәм, журналист Рузилә Мөхәммәтова бар иде. Башта алар Г.Афзалның туган авылы Такталачыкка килде, әдипнең бюстына чәчәкләр салды. Актаныштагы 1нче мәктәптә укучылар белән очрашты. Әлфия Авзалова исемендәге мәдәният йортында фестивальнең йомгаклау тантанасы булды. Монда мәктәп укучылары арасында барган әдәби конкурска йомгак ясалды, 2011 елда Актаныш хакимияте тарафыннан гамәлгә куелган, татар әдәбиятының юмор-сатира өлкәсен үстерүгә зур өлеш керткән язучыларга бирелә торган Гамил Афзал премиясе  тапшырылды. Быел бу бүләккә язучы-сатирик, «Чаян» журналы мөхәррире, җырчы, композитор Алмаз Хәмзин лаек булды. Аңа премияне Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла белән Актаныш муниципаль районы башлыгы Ленар Зарипов тапшырды.

### ЮБИЛЕЙ ДӘВАМ ИТӘ

Татарстанның халык язучысы, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Вахит Имамовның 70 яшьлек юбилее Казандагы К.Тинчурин театрында уздырылган иде. Татарстан Язучылар берлегенең Чаллы бүлеген, «Мәйдан» журналын җитәкләгән, 32 ел буена монда милли мәнфәгатьләрне кайгыртып яшәгән шәхес юбилеена багышланган тантананың Чаллы шәһәрендә дәвам итүе дә бик табигый.

Бәйрәм Аяз Гыйләҗев исемендәге Татар дәүләт драма театрында уздырылды. Вахит Имамовны Чаллы шәһәре хакименең элекке урынбасарлары Фәйрүзә Мостафина, Рамил Хәлимов, бүгенге урынбасары Венер Харисов, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла, берлекнең Чаллы бүлеге җитәкчесе Факил Сафин, юбиляр белән бергә Казаннан һәм Мөслимнән килгән каләмдәшләре Татарстанның халык шагыйрьләре Рәдиф Гаташ, Газинур Морат, Татарстанның халык язучысы Фоат Садриев, язучылар Рафис Корбан, Мөҗәһит Әхмәтҗанов, «Безнең мирас», «Казан утлары» журналларының баш мөхәррирләре Ләбиб Лерон, Рөстәм Галиуллин, галимнәр Хатыйп Миңнегулов, Искәндәр Гыйләҗев, Актаныш районы башлыгы урынбасары Дилбәр Әнвәрова, әдип туган Иске Байсар авылының җирле үзидарә башлыгы Рәмис Сафин, Бөтендөнья татар конгрессының Түбән Камадагы бүлекчәсе рәисе Рөстәм Ганиев, Актаныш Якташлар җәмгыятенең Чаллы, Түбән Кама шәһәрләрендәге җитәкчеләре Фәнис Газетдинов, Фирдәвес Ханов һ.б. котлады. Равил Галиев, Гөлдания Хәйруллина, Илсөяр Зарипова, Нияз Һашимов, Илһам Хисмәтуллин, Чаллының «Болгар», Актанышның «Агыйдел» җыр һәм бию ансамбльләре, Чаллы драма театры артистлары җыр-моң, бию, нәфис сүз бүләк иттеләр.

### ОЧРАШУЛАР

Апас Үзәк китапханәсендә – Татарстанның халык язучысы Нәбирә Гыйматдинова, Әгерҗе районы Кадыбаш авылы мәдәният йортында – Татарстанның халык шагыйре Газинур Морат, язучы, драматург Хәбир Ибраһим, Түбән Кама шәһәренең Г.Тукай исемендәге һәм «Апуш» балалар үзәк китапханәләрендә шагыйрә, күп кенә популяр җырлар авторы Сания Әхмәтҗанова белән әдәби очрашулар узды.

2024 елның 18 октябрендә 73нче яшендә Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, философия фәннәре докторы, профессор, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе **Натан Моисеевич Солодухо** вафат булды.

Мәрхүмнең җәсәде Казандагы Арча кыры зиратында җирләнде.

2024 елның 21 октябрендә 73нче яшендә Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, журналист, рәссам, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, А.Алиш исемендәге әдәби премия лауреаты **Дания Заһретдин кызы Гайнетдинова** вафат булды.

Мәрхүмәнең җәсәде Теләче районы Олы Тиләҗе авылы зиратында җирләнде.

*Сәхифәне* **Вакыйф НУРИЕВ** *әзерләде.*

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*«Проза и поэзия»: роман З.ХУСНИЯРА «Аллюки», повесть Ф.НИЗАМОВОЙ «Вдохновение», повесть Н.КАРИМОВОЙ «Долгие-долгие судьбы»; стихи Р.ГАТАША, Р.ИСМАГИЛОВОЙ.*
*«Такташ FEST»: стихи Б.ИБРАГИМОВА, З.РАМАЗАНОВОЙ, Г.БАТТАЛОВОЙ, Г.АХМАДИЕВОЙ, И.ФАТИХОВА.*
*«Литература родственных народов»: стихи Т.ДАВЛЕТБИРДИНОЙ.*
*«Новые имена»: стихи Р.ШАКИРОВОЙ.*
*Литературный конкурс «Нравы отчего дома...»: рассказ Р.ШАЙДУЛЛИНОЙ-МУРАТ «Слёзы на лепестках».*
*Литературная критика: статья А.ЗАКИРЗЯНОВА, статья Т.ГАЛИУЛЛИНА к 165-летию Дэрдменда.*
*«Обзор книги»: статья Ф.КУТЛУ, статья А.УЗТУРКА к книге А.ГИЛЯЗОВА.*
*«Грот Абугалисины»: статья И.ЗАГИДУЛЛИНА, посвящённая 200-летию К.НАСЫРИ.*
*Фотоархив: Литературные мгновения.*
*«Бесценные голоса»: статья к 105-летию Ш.МУДАРРИСА и к 75-летию Т.ЗИННУРОВА. Рубрику ведёт Н.АКМАЛ.*
*Дневник общественно-культурной жизни.*
*На наших обложках: Театр Камала. Фото И.Абрамовой; ректор Казанского высшего мусульманского медресе имени 1000-летия принятия Ислама Ильяс Зиганшин.*

## IN THIS ISSUE:

*«Prose and poetry»: novel by Z.KHUSNIAR «Alluki», story by F.NIZAMOVA «Inspiration», story by N.KARIMOVA «Long, long destinies»; poems by R.GATASH, R.ISMAGILOVA.*
*«Taktash FEST»: poems by B.IBRAHIMOV, Z.RAMAZANOVA, G.BATTALOVA, G.AHMADIYEVA, I.FATIKHOV.*
*«Literature of related peoples»: poems by T.DAVLETBIRDINA.*
*«New names»: poems by R.SHAKIROVA.*
*Literary contest «Morals of the Father's House...» story by R.SHAYDULLINA-MURAT «Tears on flower petals».*
*Literary criticism: article by A.ZAKIRZYANOV, article by T.GALIULLIN on the 165th anniversary of Derdmend.*
*«Book Review»: article by F.KUTLU, article by A.UZTURK to the book by A.GILYAZOV.*
*«Grotto Abugalisina»: article by I.ZAGIDULLIN dedicated to the 200th anniversary of K.NASYRI.*
*Photo archive: literary moments.*
*«Priceless voices»: article confined to 105th anniversary of SH.MUDARRIS and 75th anniversary of T.ZINNUROV.*
*Rubric conducted by N.AKMAL.*
*Diary of social and cultural life.*
*On our covers: Kamal theatre. Photo by I.ABRAMOVA; Rector of Kazan Higher Muslim Madrasah named after the 1000th anniversary of the adoption of Islam ILYAS ZIGANSHIN.*

---

*Тышлыкның беренче битендә:* Камал театры. *И.АБРАМОВА фотосы.*

*Тышлыкның дүртенче битендә:* Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге Казан югары мөселман мәдрәсәсе җитәкчесе Ильяс Җиһаншин.